# Казан утлары

1

ЯНВАРЬ

1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

1
ЯНВАРЬ
1969

## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Ике кояш. Грузин халык җыры. Ленин рәсемен сатып алам. Донбасс кызлары җыры. Рәхмәт сиңа, Ленин. Рус халык такмаклары. Хачо. Әрмән халык җыры . . . . . . . . . . 3
С. РАФИКОВ. Халык зурлый . . . . . . . 6
Ф. ГАЛИМОВ. Ленин туган шәһәрдә . . . . . 12

ХИКӘЯ, ШИГЪРИ РОМАН, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР

Ә. ДАВЫДОВ. Йокысыз төннән соң. Роман-симфония . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Гомернең кырык сигез минуты. Хикәя . . . . . . . . . . . . . . . 39
Г. ЛАТЫЙП. Болыт — батыр; Минем нәсел. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 46
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Кеше — гаҗәп; Ни телисез! Мин төп Себер татарымын; Чибәр кызлар; Рас әйткәнсең; Бер ел үткән. Шигырьләр . . 48
И. АБДУЛЛИН. Якты күңел. Пьеса . . . . . . 50

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. ХӘБИБУЛЛИН. Унсигезенче яз. Повесть . . . 63
Г. СӘГЫЙРОВ. Ике кояш; Кыш көне дә ачып куям; Мең төрле буласың. Шигырьләр. Чишмә. Иртә. Рәсемнәр . . . . . . . . . . . . 117

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Үр менеп җиткәндә . . . . . . . . . . . 119

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. ХӘМИТОВ. Мировой Әмир. Очерк . . . . . 123

Г. КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Х. ХИСМӘТУЛЛИН. Заман белән бер эздән . . 135

Ф. КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

С. ХӘКИМ. Үлем турында уйлама . . . . . . 141

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Ү. БАЙЧУРА.** Әдәби телебез һәм яңа лингвистик ысуллар . . . . . 145

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

**Р. МОСТАФИН.** Тик бер өмет. Очерк . . . . . 152

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

**А. ФАЙНБЕРГ.** Шагыйрь күңелле рәссам . . . 161

ТӨРЛЕСЕННӘН

**М. ҺАДИ.** Псевдонимнар хакында берничә сүз . 168

СЕЗНЕҢ КИТАП КИШТӘГЕЗГӘ

**Г. ИДЕЛЛЕ.** Канатлар кая илтә! . . . . . 172
**Ф. МАКАЕВ.** Диңгез эзлим . . . . . 175
**В. НУРУЛЛИН.** Солдат хатлары . . . . . 176

ИСТӘЛЕКЛӘР

**М. МИРВӘЛИЕВА.** Шагыйрь белән очрашулар . 178
**С. РӘИМОВ.** Кечкенә генә бер истәлек . . . . 181

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Кырмыскалар туп уйный; Чәналар ла чәналар; Химчисткага бирәм, ди...; Җайдак; Шаян; Табышмак шигырь. Шигырьләр . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Г. РӘХИМ.** Таныш шагыйрьгә. Шигырь. . . . . 187
**Ш. ШӘРӘПОВ.** Энә. Мәсәл . . . . . 187
**Ә. СИНЕГУЛОВ.** Түбәтәй юуу. Шигырь . . . . . 187

Безнең календарь . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянен адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 15/XI-1968 ел. Басарга кул куелды 24/XII-1968 ел. ПФ 01509.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 17,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83446 экз
Заказ Д-1858. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.




# *ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

## *Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

### Ике кояш

*Грузин халык җыры*

Кояш, кояш, яшь койма син,
Нурлы булсын җир-ана.
Ильич синең дустың иде,
Алмаз кием бир аңа.

Күз яше — диңгез булырлык,
Аны бөтен ил түккән...
Кабатлама җир үксуен,
Елмаеп кара күктән.

Сезнең нурлы иканегез
Билгеле һәр кемгә дә.
Тик син көндез яктыртасың,
Ә ул балкый төнлә дә.

Кызу көндә дә йөрәккә
Үтми синең нурларың —
Яктырта тик кеше йөзен
Һәм кешенең юлларын.

Ленин яктысы — йөрәккә
Һәм күңелгә үтә ул,
Дусны дәвалый, дошманны
Көйдереп көл итә ул.

Дөньяга Ильич килгәнче
Нурлы идең син генә,
Безне беркем яратмады,
Җылы бирдең син генә.

Тәннәрне син җылытсаң да,
Күңелләр өши иде.
Бер телем икмәксез калып
Бихисап кеше үлде.

Сез булсагыз дөнья якты —
Икегез дә шундый сез.
Балкытасыз һәммә якны —
Икегез дә шундый сез.

Күктә син булмасаң, кеше
«Кояш юк!» — дип көенә.
Ә бүген чиксез зур кайгы
Җирде һәркем өенә.

Һәркемнең йөрәге җылый,
Башны иеп атлыйбыз:
«Безнең Ленинныбыз үлде —
Сүнде безнең яктыбыз...»

Мин ышанмыйм! Ленин алай
Беренче булып китмәс!
Ул үтеп кергән йөрәккә
Бүтән бер нур да үтмәс.

Син, кояш — җирнең җылысы,
Һәр тере чәчәк — син ул.
Ильичның нуры күңелдә,
Ә безнең күңел — кин ул.

Ул җәберне юк иткән һәм
Байларны буган кеше.
Ул җирдә кеше бәхетле
Булсынга туган кеше.

Сез ике кояш — сез безгә
Нур да, җыр да, әләм дә.
Сезнең үлемсез яктыны
Җиңәр көч юк галәмдә!

**Зәки Нури тәрҗемәсе**

## Ленин рәсемен сатып алам

*Донбасс кызлары җыры*

Ленин рәсемен сатып алам,
Пәрдәләр әләм рамга.
Ленин миңа тудырды таң,
Бәхетсез кыз балага.

Мин Ленин рәсемен алам да,
Алтынлыйм рамыбызны.
Ул мине чыгарды таңга,
Гади бер шахтер кызны.

Зур клубта Ленин сыны,
Якты тәрәзәләре.
Кызлар Советка сайланды,
Үсте дәрәҗәләре.

Җырла, шахтер кызый, җырла
Безнең бәхет турында.
Яшәү әйбәт хәзер монда
Әйбәтләнер тагын да.

## Рәхмәт сиңа, Ленин

*Рус халык такмаклары*

Рәхмәт инде сиңа, Ленин!
Рәхмәт инде йөз тапкыр!
Советлар власте өчен
Рәхмәт тагын бер тапкыр.

Ышан, Ильич, синең өндәү
Күңелләрдән югалмас,
Без — эшче халык кулыннан
Властьны бер кем алмас.

Җәен йөрүләре әйбәт,
Яшел кырлардан атлап,
Күмәк яшәүләре әйбәт,
Ленин васыятен саклап.

Без сугышны теләмибез,
Без бик шәп хәтерле бит:
Безнең иң беренче декрет —
Ленин кул куйган декрет.

## Хачо

*Әрмән халык җыры*

— Малай, Хачо,
Сәләмә Хачо!
Иске кабаңны [1] өстән салгансың,
Өр-яңа френч киеп алгансың.
Кем сиңа бирде?
Кем сиңа бирде?
— Кысып торучы сыным-билемне,
Бу френчны Ленин кидерде,
Ленин!

— Малай, Хачо,
Хәерче Хачо!
Тишек башмакны салып аткансың,
Бик шәп итекләр киеп алгансың,
Кем сиңа бирде?
Кем сиңа бирде?
— Озын куньчлы бу күн итекне,
Яңа итекне Ленин кидерде,
Ленин!

— Малай, Хачо,
Иптәш Хачо!
Элек сөйләшми идең түгелме?!
Хәзер бу оста, үткен телеңне
Кем сиңа бирде?
Кем сиңа бирде?
— Ялчы чагымда сөйләүдән качтым,
Үткен һәм оста телемне ачты
Ленин!

— Иптәш Хачо!
Профессор Хачо!
Син надан батрак идең әлгәре.—
Ой-ой-ой! мондый зур белемнәрне
Кем сиңа бирде?
Кем сиңа бирде?
— Мондый дәрәҗә һәм зур белемне
Минем күкләргә тик Ленин бирде,
Ленин!

**Нури Арсланов тәрҗемәләре**

[1] Каба — өс киеме.

## Сөббух Рафиков

# ХАЛЫК ЗУРЛЫЙ

## I

Ленинсыз яшәгән нихәтле еллар артта калды. Әгәр шул үткән гомер юлына бөтен балалык кичерешләрен, авыр уйлануларны искә төшереп әйләнеп карасам, күңелгә уелып куелгандай иң истә калган елларның берсе 1924 ел булыр. Салкын январь алып килгән авыр кайгы кемнәрнең генә җанын әрнетмәде икән ул чакта?!

Мин ул елларда туган авылым Нөркәйдә беренче баскыч мәктәптә укый идем. Урта урамда, хәлле, нык тормышлы кешеләрнең ихаталары белән янәшә салынган Шәех бай йортында иде безнең мәктәп. Таш өстенә салынган зур агач йортның биш матур бизәкле тәрәзәсе белән урам якка караган залында укый идек без. Күбесе оекчабатадан, өсләренә бишмәт, кайберләре сары тун кигән, киндер букчаларга китап, дәфтәрләрен салган малайлар һәм кызлар умарта оясыдай гөж килә идек. Ул вакытларда кайнар аш яки буфетның ни икәнен дә белгән юк. Кесәләрдә — куырылган борчак яисә берәр телем арыш ипие. Иртән киләбез, төш авышуга кычкыра-шаярыша өйләребезгә таралабыз. Безнең гамьсез көннәребез әкренләп үтә торалар.

Бер көнне укытучыбыз Харис Искәндәрев дәрескә гадәттәгедән соңгарак калып килде. Без аны мөгаллим абзый дип йөртәбез. Берәр күңелсезлек булса, аның битмаңгае кызара, тирән шадралары да рәтләп беленми торган иде. Ә бүген алай гына да түгел, мөгаллим абзыйның тере зәңгәр күзләре дә уйчан һәм моңсу, чырае артык җитди, буыннары йомшап калган кебек күренә. Ул, козырёклы колакчын бүреген салып өстәлгә таянды да, калтыраулы тавыш белән сөйли башлады:

— Балалар, авыр кайгылы хәбәр... Юлбашчыбыз Ленин үлгән. Бүген укулар булмый.— Ул безгә кыска-кыска җөмләләр белән Ленин турында сөйләде.

Укучы балалар, бүтән көннәрдәге кебек шаулашмыйча, ниндидер авыр адымнар белән, ашыкмыйча гына өйләренә таралдылар.

Өйдә утырасым килми. Мин киң такталардан җәелгән сәкегә менеп утырдым да үземнең «Татарча уку китаплары»н актарырга керештем. Юк кына бит, күңел бармый. Аннары мич астындагы кузналарымны барладым, кургашын коелган аткыларымны тотып-тотып карадым. Юк кына бит, кулдан төшеп китәләр, уйныйсы килми. Әни исә гел искәртеп тора: «Урамга чыгасы булма, анда — тәмуг салкыны, хут суыклары, Чыпчыклар очып барган җирләреннән егылып төшеп үләләр».

Барыбер түзеп булмый. Бер тәрәзәнең эчке өлгесе ватык. Мин, тыным белән өреп җылытып, тәрәзәдәге бозны эретәм дә, күзлек кадәр генә ачыклык ясап, урамга карыйм. Өйләре безгә тыкрык аша гына утырган күршебез алыптай гәүдәле кыргыз Габдрахман, тезгененнән җитәкләп, атын бәкедән су эчертеп кайтып килә. Әле быел гына ат алып, тернәкләнеп киткән бу кеше, гомумән шат күңелле, бигрәк тә атын сугарып кайтканда аның төсен елмаю матурлый һәм ул бөтен тыкрыкны тутырып атлый торган иде. Минем бу каравымда исә ул әллә ничек кенә бик ят шикелле тоелды. Абзыйның гәүдәсе кечерәеп калган сыман, чырае күләгәләнеп тора, хәтта аның колыннан чак кына калку булган еты да башын салган төсле күренде. Ул гына да түгел, миңа калса, ярым карга чумган өйләр, каралты-куралар да үзләренең элекке төсләрен җуйганнар төсле иде.

Минем һич кенә дә өйдә утырасым килми. Суык та куркытмый, эчтә ниндидер ут бар, теер бар. Өйдәгеләр — әни һәм апа — тын гына утыралар, ара-тирә торып йөриләр, сиртмәле кабык бишеккә энем йоклап ята. Үзенә сиздермәскә тырышып,

әнигә еш-еш күз салам, әйдән ничек тә булса чыгып таю ягын карыйм. Беләсе иде, хәзер клубта ниләр бар икән? Әйе, әни беркая да чыкмаска кушты. Ул мине январь суыклары белән куркытып та үзенең сүзен ныгытты бит. Гадәттә мин аны һәрвакыт тыңлый торган булсам да, бүген тыңлыйсы килми, күңел әллә нишли, йөрәк гел үз алдына дерелдәп тора. Шулай әйдә бераз арлы-бирле сугылып йөрдем дә мич башына мендем. Бу көннәрдә, салкыннарның зәһәр үзәгендә, мичебезгә саламнан тыш кизәк тә ягылгач, мич башында шактый җылы иде. Бүтән чакларда булса, анда мин, болай да җылыга рәтләп туймаган малай, морҗага кереп улаган җил тавышын тыңлап, сәгатьләр буе рәхәтләнеп ятар идем. Бүген өебезнең иң рәхәт, иң оҗмах саналган мич башы хәтле мич башында да озак ята алмадым. Аз гына уйланып яткан иттем дә оек-чабаталарымны шыпырт кына киендем, мич башыннан сак кына төштем һәм аралыктагы чөйгә эленгән киндер тышлы чуар бишмәтемне иңемә салып ишеккә атладым. Әнинең арттан: «И, ходаем, ирең чыгып китсә ишектән, син чыгып кит икән тишектән. Булса да булыр икән шундый тыңлаусыз, кайткач иеңне бирермен әле, әйдә, батырай»,— дигән орышу сүзләрен ишеттем.

Ул чакларда безнең авыл волость үзәге иде. Югары очтагы Волбашкарма йортына читләре кара тасма белән каймалган кызыл флаг эленгән. Волбашкарма каршындагы халык йортында да шундый ук флаг җилферди. Үзем кебек берничә малай белән халык йортына кердем. Түр як стенада пыяла рам эчендә Ленинның зур рәсеме тора. Аны да кара тасмалар белән урап алганнар. Халык йортына волость хезмәткәрләре, авыл кешеләре бер-бер артлы тула башладылар. Кергәне берсе бүреген сала, Ленин рәсеменә карый, тирән көрсенеп, юлбашчы төсе алдында үз кичерешләренә бирелә. Төн урталары якынлашып килгәндә генә халык йортыннан киттек.

Бүтән чакларда уеннаммы, мәктәптәнме аз гына кичегеп кайтсаң да пыр тузына торган әни, кисәтеп калган булса да, мине аз гына да орышмады. Күрәсең, ул минем кайда икәнлегемне кемнән дә булса ишеткәндер. Сораштыра башлады:

— Кеше күп иеме?

— Ифрат та күп ие.

Әнинең теле язылып китте. Ул, кучкардагы сукыр лампаның фитилен вакыт-вакыт калкытып, сөйләнә бирде:

— Әй, ходаем, дөньяны тотып торган шундый олы кеше дә үлеп киткәч инде, ниләр кылмак кирәк?

Мин аның бу сүзләренә берничек тә җавап кайтара алмадым. Бу халәтне сизенгән шикелле, әни әкрен-басынкы тавыш белән дәвам итте:

— Хатын-кызларга җир бирдерткән кеше, ярлы-юксылларның арка таянычы...

Берничә көннән соң мәктәп стенасына юлбашчы тормышына багышланган зур рәсем-плакат куелды. Дәрескә хәтле дә, тәнәфес араларында да безнең күзләребез гел шул плакатка текәлә торган булды. Менә Горкидагы тарихи бина... Менә караватка яткан авыру Ильич янында Надежда Константиновна Крупская утыра. Менә ул ярatып ял итә торган эскәмия. Менә бакчада Ленин балалар белән...

Бөек Ленин образы күңелләргә торган саен ныграк сеңә, йөрәкләрдә тирәнрәк тамыр җәя башлады. Без, авылның беренче пионерлары, Банат Салихҗаны җырга бик оста, бик килештереп, тигез ритм белән каккан барабан тавышына атлап, урамнардан җырлап үтәбез:

> Бабабыз Ильичның
> Юлыннан барабыз.
> Нык укып,
> Киләчәккә хәзерләнәбез.
> Һәр вакыт без хәзер,
> Алга омтылабыз;
> Хезмәт гаммәсен
> Коткару — лозунгыбыз!

Җыр тәрәзәләргә барып сугыла. Тәрәзә тәпләренә чүлмәкләргә утыртылган гөлләр исә тагын да сафрак, тагы да нурлырак һәм нәфисрәк балкыйлар сыман. Яшь ленинчыларның күкрәк киереп җырлаган ялкынлы сүзләренә бик күпләр куаналар,

чырайлары ялтырап ачыла һәм алар киләчәкнең матурлыгын тәсмерлиләр. Юк, барысы да алай түгел. Бай-бәтчәләргә ошамый безнең җырлар. Алар кашларын җыералар. Безнең тавышны ишетмәс өчен корьән сүрәләре укырга керешәләр.

## II

Ленин вафат булганнан соң, партия Үзәк Комитетының чираттан тыш пленумы Өндәмәсендә әйтелгән утлы сүзләр кешеләрнең күңелләренә һич онытылмаслык булып сеңеп калды:

— Ленин һәр намуслы эшченең йөрәгендә яши.

— Ленин һәр крестьян-ярлының йөрәгендә яши.

Берничә еллар үткәч, илебездә Ленин әйткәннәр яктылыгында культура революциясе башланды. Бөтен авыл парталар арасына утырды. Халыкның күзен томалап торган наданлык-караңгылык пәрдәләре алып ташлангач, Ленин исеме тагы да киңрәк таралды. Аның исеме халыкка тагын да якынайды. Халык арасында исеме бик еш телгә алынганга күрәдер инде, сабыйларның теле ачылганда ук гадәттә әйтә торган «әттә-әннә» сүзләре белән янәшә Ленин исеме йөри башлады.

Әйе, үзе мең авырлыклар, мең газаплар күрә-күрә, бөтен гомерен халык бәхете өчен биргән бөек һәм изге исем ана сөте белән үк безнең кешеләрнең аңына керә. Тормышта, гаиләдә очрый торган һәртөрле тискәре күренешләргә каршы да иң көчле һәм иң ышанычлы яктылык мисалы итеп аның исеме китерелә. Әйтик, бала сабагын укырга ялкаулана, начаррак билгеләре алып кайта икән: «Ленин бабагыз ялкау булмаска кушкан» яки «Ленин гел бишлегә укыган» — дигән сүзләрне бихисап күп тапкырлар ишеткәнем бар минем. Ул гынамы соң! Әйтик, бераү гаделсезлек турында шикаять яки дәгъва белән берәр җитәкче хезмәткәргә ничек тә булса мөрәҗәгать итеп, ул кеше әлеге йомышчы белән әйбәт сөйләшсә, мәсьәләне уңай якка хәл кылса: «Ленин кушканча эшли, дөрес кеше»,— дигән сүзләрне кайсыбыз гына ишетми. Ә, киресенчә, җитәкче кеше килүчене начар кабул итсә, мәсьәләне хәл кылмаса, болайрак әйтәләр андыйлар хакында: «Бу Ленин юлын тотмый. Көне үтсен өчен генә утыра, эш башыннан куып төшерәсе бар».

Җанлы Ленин образы беркайчан да халык теленнән төшми.

...Шулай бер җәйне, әле колхозлар оешканчы, безнең авыл агайларыннан бер төркем кеше янгын лапасы алдында сөйләшеп утыралар иде. Шул тирәдә урам чирәмлегендә ат-ат уйнап йөргән берничә малай да, аларның бик мавыгып һәм тәмле итеп сөйләшүләренә кызыгып, тыңлап тора башладык. Лапас кырыена куелган юан бүрәнә өстенә утырган бераз кысыграк күзле, чәндер чырайлы, кара мыеклы Шакир Мөхәммәтшин һәм озын гәүдәле, үзенең саргылт сакал-мыекларын бик пөхтәләп ыспай гына калдырып кырган, ак киез эшләпәле Шириаздан абзый Хәсәнов, тагы китереп югары очның Әгъләм абзый (аны Төпәй Әгъләме дип йөртәләр иде), бигрәк җаен китереп, килештереп сөйлиләр. Авылдагы байтак ярлы-ябагайлар кебек, кыш көннәрендә шахталарга барып эшләп кайта торган Шириаздан абзый үзе күргән яңалыкларны авылдашлары алдында ярып сала:

— Донбасста мин аның чын үзен күрдем.

— Ул ничек инде, ягъни мәсәлән,— дип түземсезләнеп, Әгъләм абзый агайның сүзен бүлдерде.

— Шулай, чын Ленин, тучмы-туч үзе, киң маңгайлы, өстендә кәчтүм, аягында өр-яңа ботинкалар...

— Ничек инде алай? Ул бит инде үлгән,— диде кайсыдыр.

— Ленин үләме соң, ул исән! — дип дәвам итте Шириаздан абзый: — Гранит ташка баскан, өстендә кара кәчтүм... Бер кулын алга сузган да юл күрсәтеп тора... Шул минем гел күз алдымда менәтерә.

Аның бу сүзләре кешеләрне гаҗәпләндерә калды булса кирәк, төрле сораулар ишетелде:

— Сурәтме?

— Юк,— диде Шириаздан абзый.

— Сынмы?

— Юк.

— Чуеннан койганмы?

— Юк.

— Соң нәрсә?

Агай, бераз тотлыгып торгач, бүленгән сүзен янә ялгап алып китте:

— Соң менә чын үзе инде. Бөтен кыяфәте үзе дим бит сезгә.

Моңарчы тын гына елмаеп утырган, дөньяны күп күргән кызыл партизан Шакир Мөхәммәтшин да сүзгә кушылды:

— Һәйкәл ул — памятник.— Юлбашчыга куйган һәйкәлне аның үзенең дә Уралда күреп кайтканы бар икән.

Агайлар гәпләшүләрдән тиз генә туктамадылар. Шакир Мөхәммәтшин Ленинның үндүртме, унбишме тел белүе турында каяндыр ишеткәнен әйтте. Тәпәй Әгъләме бу юлы да сораулы сүз кыстырмыйча түзә алмады:

— Татарча да беләме икән иптәш Ленин?

Кинәт кенә калкып чыккан бу сорауга шундук җавап табылмады. Шакир Мөхәммәтшин, бер мизгел уйланып торгандай итте дә, янә тел тибрәтте:

— Яшьтән үк татарлар арасында уралгач, аннан китереп Казанда укыгач, нишләп белмәсен, белгәндер, әлбәттә. Ул тикле башлы кеше, син тегә, кәк белмәс!

— Ай-яй, башлы дисәң дә башлы! Ниләр буласын алдан белгән,— дип тел какты Әгъләм.

— Ниләр эшләргә икәнен алдан күргән, әйтеп калдырган,— дип өстәде берсе.

Шириаздан абзый әле бер, әле икенче кешегә карашын йөртеп, бер үк вакытта үзенең кызыл эчле яңа резин кәвешенә дә ниндидер эчке канәгатьләнү белән карарга онытмыйча, Шакир әйткәннәргә куәт салды:

— Минем дә Ленин татарча ярыйсы әйбәт «сукалаган» дип ишеткәнем бар. Аның бит сакал-мыек йөртүе дә тучмы-туч татарныкы, безнең рәвеш.

Әгъләм абзый тагы да куертыбрак җибәрде:

— Сакал-мыегы гынамы соң! Ул үзе дә татар төсле бит. Минем Каташ-Карандагы баҗай гел Ленинның үзе инде менә! Кунакка да килгәне бар. Узган ел Сәйфулла җыенында икәү бергә ашка йөрдек.

— Синең исәбең бигрәк олыдан икән,— диде кайсыдыр.

Киң күңелле, җәйге зәңгәр күк кебек саф тойгылы агайлар күндәм генә көлешеп алдылар.

Партия сафларына керергә әзерләнеп йөргән Шакир Мөхәммәтшин сүзне түгәрәкләп куйды:

— Аңа урысы, татары юк. Аңа барлык халыклар да бер, һәммәсен дә тигез күргән ул безнең Ленин!

Бахәссез, авылдашымның бу сүзләре тулысынча хак. Ләкин бер татарлар гына түгел, башка милләт кешеләренең дә Ленинның бик күп сыйфатларын үзләренә охшатып юрауларын, аның тәсендә, фигыль-гадәтендә үзләренә иң якын охшашлык барлыгы белән горурлануларын бик күп мәртәбәләр ишеткәнебез бар безнең. Әйе, Ленин һәркайчан халык белән бергә!

## III

**Мин Казанда яшим,**
**Казанда!**
**Нужа белән кумыйм дөньяны.**
**Өй түремдә юкә чәчәкләре,**
**Торган җирем — Ленин урамы.**

**Үткән саен шушы урамнан мин**
**Сөенечем арта,**
**Шатланам.**
**Моннан, димен, яшь Ульянов үзе**
**Киләчәккә карап атлаган.**

Шагыйрь Галимҗан Латыйпның бу юллары күңелләрне узганнарга алып китә. Яшь Ленинның беренче сукмаклары ямьле Идел буйларында, безнең туган якларыбызда башланган. Үзенең туган җире кебек яраткан ул Казан тирәләрен. Кайчандыр Кокушкино урамнарында үзе яшендәге крестьян малайлары белән чүрәкәйле, кузналы уйнаган кечкенә Володя ат сакларга куна барып, учак янында әкиятләр тыңлаган. Халык-

ның моң-зарын ул бик иртә ишеткән, аларның авыр тормышларын иртә күргән һәм халыкка тирән мәхәббәт аның йөрәк түренә бик иртә салынган.

Казан. 1887 елның 4 декабре. Әнә шул көннән башлап унҗиде яшьлек Ульянов киләчәккә кыю карап атлаган. Беренче тапкыр кулга алыну. Сөрген. Тагы бала чактан ук таныш Кокушкино, таныш урамнар, таныш тыкрыклар, таныш өйләр, таныш читәннәр, арык ат җигеп, җир сукалаучы, авыр хезмәттән арка бөкреләре чыккан, ыштыр-чабаталы крестьяннар.

Ул хезмәтчел халык белән нык аралашып яши. Бөек Ленин беренче революцион чыныгуын безнең һәммәбезгә якын, һәммәбезгә кадерле Казан туфрагында ала. Совет Татарстаны кешеләре моның белән бик хаклы рәвештә горурланалар. Кокушкино авылы кешеләре Ленинны үзләренең авылдашлары дип саныйлар. Аларның 1922 елда Ленинга язган хатларында шундый җылы сүзләр бар: «...Совет властеның беренче чакыруы буенча, 1917 елның октябрендә без барлык алпавытларның, шул исәптән кулак Николай Фадеевның да киръәкләрен бирдек. 1918 елда барыбыз да бер кешедәй булып, Кызыл Армиягә киттек һәм Совет Россиясен аңа һөҗүм итүче дошманнардан, алпавытлардан, генераллардан һәм капиталистлардан саклап калдык. Сүзебезне тәмамлап, синнән сәләмәтлегеңне саклавыңны үтенәбез, чөнки син безнең бөтен Россиягә бердәнбер кеше. Мәктәп салгач, безгә кунакка килүеңне үтенәбез...» (И. Кондратьев. «Ленин Казанда»).

Йөрәктән чыккан гына йөрәккә җитә диган сүз бар. Халык, ил язмышын кайгыртып, чын йөрәктән чыккан Ленин сүзләре башкаларның йөрәгенә, күңелләренә барып тоташа. Яшь Совет дәүләте илебез җиренә беренче якты нурларын сибә башлаган авыр елларда аның татар әдәбияты белән, аерым алганда Габдулла Тукай иҗаты белән кызыксынуы нинди киң күңелле һәм игътибарлы икәнен күрсәтә. Бу безнең хәзерге заман язучыларына да тылсымлы бер көч, рух күтәренкелеге биреп тора.

Без даими рәвештә теге яки бу уңай белән Ленин әсәрләренә, ул калдырган бай мираска мөрәҗәгать итәбез. Ул көч чыганагыннан даими рәвештә үзебезгә фикер байлыгы алабыз. Шагыйрь Сибгат Хәким әйткәнчә, күңелебез бик еш кына Ленин белән киңәшә, Ленин белән сөйләшә. Чөнки бөек илебезнең, халкыбызның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге Ленин идеяләре белән бик тыгыз үрелгән, бик тыгыз бәйләнгән.

Ленин фикерләре халык мәкальләре, халык әйтемнәре булып, телдән-телгә күчәләр. Менә кайбер мисаллар:

— Эшче-крестьян — илнең төп таянычы.
— Кызыл Армияне күз карасы кебек сакла, ныгыт.
— Ашлык өчен көрәш — социализм өчен көрәш.
— Совет власте плюс электрлашу — коммунизм диган сүз.
— Дөрес куелган учет — социализм.
— Иң гадел закон — Совет законы.
— Халыктан узып эш итмә.
— Халыкның сүзенә һәркайчан колак сал.
— Киңәшеп, килешеп эшлә.
— һәр милләт, һәр халыкны тигез күр.
— Укырга, укырга һәм тагы бер кат укырга.
— Байлар, капиталистлар — сугыш чукмарлары.
— Кем эшләми — шул ашамый.

Безнең матбугатта һәм китапларда еш кына Ленин әсәрләреннән өзекләр алына. Еллар, вакытлар үтү белән алар да халык теленә күчеп яшиләр. Без үзара сөйләшкәндә яки җыелышларда төрле профессия кешеләре авызыннан: «Ленин болай диган, Ленин менә ничек әйткән», рәвешле сүз кыстыруларны гел очратып кына торабыз.

Җыеп кына әйткәндә, тормышыбызда Ленин иң якын киңәшчебез ул.

## IV

Халык үзенең иң нечкә тойгыларын, иң нечкә хисләрен җырга салып бирә. Җырларда туган як табигатенең матурлыгы, зифалыгы һәм, шуңарга үрелеп, лирик геройның кичерешләре гәүдәләнә. Бездә Ленинга багышланган җырлар да күп. Ул

җырларда Ленинга, партиягә тирән мәхәббәт, тирән ихтирам, кешеләрнең чын күңел нуры чагыла. Шуның белән бергә, ул җырларда илнең үсеш биографиясе, аның ышанычлы адымнар белән алга баруы да бик ачык тасвирләнә. Җырларның үзләренә сүз бирик:

Кызарып чыккан кояшның
Нуры төшә диңгезгә.
Хокук бирдең, ирек бирдең
Даһи Ленин син безгә.

Идел суы җем-җем итә,
Дулкыны кирта-кирта.
Ленин юлыннан партия
Коммунизмга илтә.

Даһи юлбашчы әйткәннәрнең тормышка аша баруын, ленинизм идеяләренең җир шарына киң таралуын, аның җиңелмәс куәткә ия булуын тасвирлаган күп җырлардан берничәсен искә төшерик:

Безнең клуб бакчасына
Кызыл гөлләр чәчкәннәр.
Берәм-берәм бар да килә
Даһи Ленин әйткәннәр.

Тыныч йокла, иптәш Ленин,
Һәрбер сүзең үтәлә,
Бөтен дөнья эшче халкы
Байрагыңны күтәрә.

Коммунистлар партиясенең какшамас көче — бердәмлектә, татулыкта, үзара киңәшкә кереп эшләүдә. Бу — безнең көннәрдә дә иң үзәк бурыч, иң зарури бурыч. Ленин сызган юлдан дистәләп илләр атлый хәзер. Ленин ул — киләчәккә маяк, аның алдында кара давыллар артка чигенә.

Күгәрченнәр җиргә төшә
Бергәләп гөрләшергә.
Ленин бабай эшчеләрне
Чакыра берләшергә.

Ак мамыктан ясый икән
Сандугачлар ояны.

Бөек Ленин сызган юлдан
Аппарабыз дөньяны.

Урман аша ярылып ята
Кара сусар эзләре.
Безнең өчен маяк булды
Ленин бабай сүзләре.

Ленин! Партия! Октябрь!
Шушы өч сүз, шушы өч таң — безнең өчен тормыш диңгезе, безнең өчен мәңге сүнми торган кояш! Безгә сыйнфый азатлыкны да, милли азатлыкны да шушы өч таң бирде. Безнең татар халкы бу турыда чын күңел кайнарлыгы белән менә ничек җырлый:

Бакчада таллар булмаса,
Сандугач кунмас иде.
Ленин бабай юл сызмаса,
Безгә көн булмас иде.

Кошлар кунган имәнгә,
Яфракларын игәнгә.

Рәхмәт Ленин бабабызга
Матур тормыш биргәнгә.

Биек тауның башларында
Ал чәчәк ата чия,
Җиңүләрдән җиңүләргә
Алып бара партия!

Моннан күп еллар элек, яшь егет Ленин Казан урамнарыннан киләчәккә караган һәм шуннан безнең бүгенге көннәрне күргән. Ул көннәр килде. Бөек кешенең тормыш юллары башланган Идел буйлары, Татарстан күптән инде чабатасын салды, агач сукаларын музейга тапшырды, сукыр лампаларны чүплеккә ташлады. Яңа тормыш, яңа сулыш! Бөтен җирдә машиналар, Ильич лампалары. Илебезнең уртак байлыгы, нефтьнең өчтән бере Татарстан җирендә чыгарыла. Алтын кырлар! Яңа төзелешләр!

Без яшәгән якларда Зәй ГРЭСы үзе генә дә элек бөтен Россия биргән егәрлектән күбрәк көч, күбрәк нур, күбрәк яктылык бирә. Мондый киң колачлы пәһлеваннар нихәтле бездә! Болар барысы да Ленин идеяләре, коммунистлар партиясе тудырган могҗизалар.

Ленин үйлары — безнең бүгенге тормышыбыз! Ленин безнең иҗат көчләрен канатландырып, йөрәкләребездә яши, мәңге яши!

**Фарук Галимов**

# ЛЕНИН ТУГАН ШӘҺӘРДӘ



Илебездә гүзәл шәһәрләр бик күп һәм алар тагы да ишәер. Ләкин Ульяновск шәһәре — планетабызда бердәнбер. Бу шәһәрдә, Идел яры буендагы кечкенә генә бер флигельдә, моннан 99 ел элек, кояшлы апрель көннәренең берсендә, пролетариатның даһи юлбашчысы, Коммунистлар партиясенә һәм Совет дәүләтенә нигез салучы Владимир Ильич Ленин дөньяга килде, шунда ул үзенең балалык елларын үткәрде.

В. И. Ленинның дөньяга карашы, характеры, иң элек, әти-әнисенең, туганнарының йогынтысы белән формалашты. Чын мәгънәсендә укымышлы семьяда үсә Володя. Аның әтисе Илья Николаевич 1831 елда Астрахань шәһәрендә тегүче семьясында туа. Бабасы крестьян була.

Илья Николаевич, Астрахань гимназиясен бик яхшы билгеләренә тәмамлагач, Казан университетында укый. 1859 елда, университет бетереп, математика фәннәре кандидаты дәрәҗәсе ала һәм Пенза дворяннар институтына физика-математика фәннәре буенча өлкән укытучы итеп җибәрелә.

Пензада ул үзе белән бергә эшләүче укытучының сеңелесе Мария Александровна Бланк белән таныша. 1863 елда алар өйләнешәләр һәм Нижний Новгород шәһәренә күчеп киләләр. Анда Илья Николаевич губерна гимназиясенең өлкән классларында укытучы булып урнаша.

Үзе халык арасыннан чыккан И. Н. Ульянов бөтен көчен һәм белемен мәгърифәт эшенә, халык арасында аң-белем тарату эшенә юнәлтә. 1869 елда, халык мәктәпләре инспекторы урыны булдырылгач, халыкка якынрак булу, мәгариф эшенең үсешенә ярдәм итү теләге белән, ул шул эшкә керә, хатыны һәм ике кечкенә баласын алып, кечкенә генә Сембер шәһәренә күчеп килә. Һәр яктан белемле, демократик фикерле, үз эшенә җаны-тәне белән бирелгән педагог Илья Николаевич, башта инспектор, соңрак Сембер губернасындагы халык мәктәпләре директоры булганы хәлендә, киң катлау крестьян массалары арасында чын-чынлап мәгърифәтче булып китә.

Сембер шәһәренә күчеп килгәч, И. Н. Ульянов семьясы, уңайлыклары булмаган квартирадан квартирага йөреп, шактый җәфалар күрә. Губерна властьлары крестьян балаларына аң-белем бирергә килгән рус интеллигенты семьясын урнаштыру турында уйлап та карамыйлар. Бары тик ун елга якын вакыт узганнан соң гына, 1878 елда, Илья Николаевич, хезмәт хакыннан өлешләп акча калдыра-калдыра, Московский урамыннан бер йорт сатып алуга ирешә. 1887 елга, ягъни Казанга күчеп киткәнчегә кадәрле, Ульяновлар семьясы шунда яши.

Күзгә пычракта булмасын, кышкы буранда булмасын, Илья Николаевич авылдан авылга йөреп яңа мәктәпләр ачтыра. Унҗиде ел эшчәнлеге дәвамында ул Сембер губернасындагы мәктәпләр санын 89 дан 434 кә җиткерә, ә ул мәктәпләрдә укучылар саны ике тапкырга арта.

Илья Николаевич классик әдәбиятны яхшы белә. Ул Казан университетында укыганда ук инде революцион демократларның — Белинскийның, Чернышевскийның, Добролюбовның һәм Герценның әсәрләрен бирелеп укый, «Современник», «Отечественные записки» журналларын даими күзәтеп бара.

Илья Николаевич балаларының тәрбиясе турында да даими кайгыртырга вакыт таба, аларны хезмәт сөючән, төгәллекле, аңлы дисциплиналы итеп тәрбияләүгә зур тырышлык куя. Балаларында ул югары идеалларга омтылыш уята. Балалары белән



*1870—75 елларда Ульяновлар яшәгән йорт.*

ул бик гади мөгамәләдә була, ял вакытларын алар белән уздыра, шахмат уйнарга ярата.

Ару-талуны белмәс эшчәнлек, эшкә җитди караш, ихтыяр көче, кешеләргә карата гаять тугры мөнәсәбәт — Владимир Ильич бу кешелек сыйфатларын әтисеннән мирас итеп ала. Ильичның әнисе — Мария Александровна Ульянова да (1835—1916) үзенең балаларына гаять уңай йогынты ясый.

Алдынгы карашлы врач кызы, өч яшендә үк әнисе үлеп ятим калган Мария Александровна, үзенең балалык һәм яшүсмер елларын Казаннан ерак түгел Кокушкино (хәзерге Ленино) авылында үткәрә. Әнисенең сеңелесе ярдәмендә ул өендә укып белем ала, өч чит ил теле: немец, француз һәм инглиз телләрен өйрәнә, ә соңрак, үзлегеннән әзерләнеп, халык мәктәпләре укытучысы дәрәҗәсе өчен имтихан тота.

Зур культуралы, олы җанлы, киң күңелле, гаять ягымлы, менә дигән музыкант һәм җырчы Мария Александровна эшсезлекнең, кәеф-сафа кылып йөрүнең, гайбәт сатуның чын дошманы була. Ул бу нәрсәне үзенең балаларында да тәрбияли.

Дөрес тәрбия бирү нәтиҗәсендә, Ульяновларның балалары яшьтән үк тормыш күренешләрен чынбарлыктагыча итеп аңларга, аларга дөрес бәя бирергә өйрәнәләр.

Илья Николаевичның табигать фәннәре белгече булуы яшь Ленинның дөньяга карашы үсешендә зур роль уйный. Аның бик еш үткәргән әңгәмәләре, ул тәкъдим иткән китаплар балаларында дөньяга материалистик караш тәрбияли.

Билгеле булганча, Илья Николаевич үзе чиркәүгә йөргән һәм дини гадәтләрне үтәгән. Ләкин ул балаларын Добролюбов методы белән тәрбияләгән, аларны аллага ышанырга мәҗбүр итмәгән. Бу турыда Мария Ильинична болай дип яза: «Илья Николаевич үзе динле кеше иде. Ләкин ул балаларга андый йогынты ясамады».

Бервакыт Илья Николаевич белән олы улы Александр арасында шундый бер сөйләшү була. «Син бүген төнге гыйбадәткә барасыңмы?» — дип сорый Илья Николаевич. «Юк!» — дип җавап кайтара Александр, кискен итеп. Бу сөйләшүдән соң андый сораулар инде бүтән кабатланмый.

Мария Александровнага килгәндә исә, ул балаларының дингә мөнәсәбәтенә бөтенләй диярлек игътибар итми. Бу турыда В. И. Ленинның энесе Дмитрий Ильичның истәлеге бик кызыклы. «Әниебез бәйрәм көннәрендә чиркәүгә йөрде, ләкин динле кеше түгел иде... Гомеренең соңгы елларында ул аллага бөтенләй ышанмый

башлады. Мин студент вакытта ул миңа попларның алдавы турында бик еш әйтә торган иде һәм чиркәүгә бөтенләй йөрмәс булды». Мария Ильинична да Мария Александровнаның дингә карата «әкият ул» дип әйтүен искә ала.

Владимир Ильич уналты яшендә вакытта атеистик әдәбият, аеруча Писарев әсәрләре йогынтысында, олы абыйсы Александр кебек үк, дин белән бөтенләй араны өзә. Бу түбәндәге вакыйгадан соң була:

Аның әтисе янына министрлыктан ниндидер зур чиновник килә. Илья Николаевич аңа балаларның чиркәүгә теләмичә генә йөрүләре турында сөйли. Чиновник, Володяга карап: «Суктырырга, суктырырга кирәк аларны!» — дигәч, яшүсмер, тирән ризасызлык белдереп, ишек алдына йөгереп чыга һәм муенына аскан тәрене өзеп ала да җиргә томыра.

Мөгаен, шуны истә тотыптыр, Владимир Ильич 1922 елда, РКП(б) членнарының бөтенроссия переписе вакытында, анкета тутырганда, «Аллага ышанмыйсың икән, кайчаннан бирле?» дигән сорауга «16 яшьтән бирле»,— дип җавап яза.

Владимир Ильич гимназия елларында Герцен, Белинский, Писарев, Добролюбов, Чернышевский әсәрләрен, «Современник», «Отечественные записки» журналларын мавыгып укый. Гимназиянең соңгы классларында социаль-экономик фәннәрне, аерым алганда, тарихны өйрәнергә омтылыш аңарда торган саен үсә бара. Шул ук вакытта ул тирә-юньдәге тормыш белән тирәнтен кызыксына. Иделгә чыккан вакытларында, грузчиклар, матрослар белән аларның тормыш хәлләре турында озаклап сөйләшеп утыра торган була. Әтисенең авыл турында, крестьяннарның хәле турында сөйләгәннәрен кызыксынып тыңлый.

Рус крестьяннарына караганда да авыррак шартларда яшәгән татар, чуваш, мордва халыкларына әтисенең карашы Владимир Ильичка зур йогынты ясый. Илья Николаевич көченнән килгән кадәр азчылык милләт халыклары арасында мәгърифәтне үстерергә тырыша, армый-талмый аларның балалары өчен мәктәпләр ачтыру артыннан йөри, милли укытучы кадрлар әзерләп чыгаруга зур игътибар юнәлтә, чуваш мәгърифәтчесе И. Я. Яковлев эшчәнлегенә һәрвакыт ярдәм күрсәтә.

Болар барысы да Владимир Ильичның изелгән милләтләргә теләктәшлек һәм ихтирам рухында тәрбияләнүенә зур йогынты ясый. Володяның Кокушкино авылында Бәһави исемле көтүче татар малае белән якын дусларча мөнәсәбәттә булуы билгеле. Алар бергәләп уйный торган булганнар, Володя Бәһавиның татарча җырлавын тыңларга яраткан.

Владимир Ильич, гимназиядә укыганда, чуваш егетенә латин һәм грек телләре буенча университетка имтиханга әзерләнергә ярдәм итә. Владимир Ильич милли изүгә һәм милли кимсетелүгә бик яшьтән үк нәфрәт белән карый.

Владимир Ильичның дөньяга карашы һәм характеры формалашуда абыйсы Александрның да роле гаять зур. Александр Ильич гаять эрудицияле кеше була. Бик тыйнак һәм хезмәт сөючән, зур ихтыяр көченә, кешеләргә карата олы ихтирам хисенә ия булганы хәлендә, ул һәр төрле хаксызлыкка утә нәфрәт белән карый.

Владимир Ильич, гимназиянең соңгы классларында укыганда, аның белән җәйге каникуллар вакытында гына очраша. Чөнки Александр Ильич, 1883 елдан алып, Петербург университетының табигать фәннәре факультетында укый. Семьяда алган тәрбия һәм шул вакыттагы тормыш шартлары аны да революцион көрәш юлына алып чыга. Патшага каршы һөҗүм оештыруда гаепләнеп, ул үлем җәзасына хөкем ителә.

Александрның җәзаланып үтерелүе Ульяновлар семьясына зур кайгы китерә. Әнисе, кечкенә энеләре һәм сеңелләре турында кайгырту хәзер Владимир Ильич өстенә төшә. Авыр кайгы көннәрендә ул югалып калмый. Менә шул чагында инде Володя Ульянов: «Юк, без мондый юл белән бармабыз. Ул юл белән барырга кирәкми»,— ди.

Абыйсының язмышы аның фикерләрен үткенләтә. Ул үзен алда авыр юлга әзерләү турында күп уйлана.

Бер-бер артлы килгән ике зур кайгы — 1886 елның гыйнварында Илья Николаевичның үлеп китүе һәм 1887 елның язында Александрның үлемгә хөкем ителүе Ульяновлар семьясының Сембер шәһәрендәге тормышын караңгылык пәрдәсе белән каплый.

Таныш-белешләре алардан читләшәләр. Соңыннан Владимир Ильич, бу көннәрне хәтерләп, Надежда Константиновна Крупскаяга Сембер обывательләренең мондый куркаклыгы үзенә бик начар тәэсир итүе турында сөйли. Надежда Константиновна язганча, яшүсмернең бу кичерешләре аңарда тирән эз калдыра, «җәмгыять»кә, либералларга карата нәфрәт тудыра. Ул либералларның төрле сафсата сатуларының җимешен бик яшьтән татый.

Александрның үлемгә хөкем ителүе турында хәбәр килгәч, гаять авыр рухи кичерешләргә карамастан, Владимир Ильич, үз-үзен кулга алып, өлгергәнлек аттестатына әзерләнүен дәвам итә, үз яшенә хас булмаган гаять тә зур ихтыяр көче күрсәтә һәм чыгарыш имтиханнарын бары тик бик яхшы билгеләренә генә тапшыра. Күптән түгел генә Сембер гимназиясе башлыкларына зур «җинаятьче» Александр Ульяновка алтын медаль һәм иң яхшы аттестация биреп чыгарганы өчен кисәтү булуга карамастан, гимназия советы Владимир Ильичка да алтын медаль бирергә карар чыгармыйча булдыра алмый. Володя Ульяновның белем дәрәҗәсе бүтән классташларына караганда шул кадәр өстен була, аңа укытучылар «гимназиянең горурлыгы» дип бәя бирәләр.

1887 елның июнендә, туган шәһәрен калдырып киткәндә, Володя Ульянов киләчәктә нәрсә эшләргә кирәген үзе өчен инде хәл иткән була. Ул үз алдына гомерен революция эшенә, хезмәт ияләрен гасырлар буена дәвам иткән коллыктан коткару өчен көрәшкә багышлау бурычын куя.

Шулай итеп 1887 елда Володя Ульянов, гимназияне бетереп, Казан университетының юридик факультетына керә һәм анда патша хөкүмәтенә каршы революцион көрәш юлына баса.

Владимир Ильич Ленин унҗиде ел яшәгән Сембер шәһәре хәзер Ульяновск исемен йөртә. Бу шәһәр үз исемен үзгәртеп кенә калмады, андагы «дворяннар оясы»ның да эзе бетте. Совет власте елларында ул зур индустриаль үзәккә әверелде. Әмма Ульяновск шәһәрендә һичнинди үзгәрешсез калган һәм бик күп еллар буена үзгәрмәячәк берничә йорт бар. Алар — В. И. Ленин тормышы белән бәйле биналар. Бу йортларны, аның белән бәйле урыннарны күрергә иксез-чиксез илебезнең төрле почмакларыннан экскурсияләр килеп тора. Анда чит ил делегацияләрен дә еш очратасың.

Менә Совет урамындагы ике катлы таш йорт. Аның тирә-ягы ямь-яшел бакчалар белән әйләндереп алынган. Бу йорт — Владимир Ильич укыган Сембер гимназиясе. Хәзер биредә — Ленин орденлы Ленин исемендәге беренче урта мәктәп. Бу мәктәпне илебез халкы гына түгел, дөньядагы барлык яшьләр һәм өлкәннәр дә беләләр. Хат ташучылар бу йортка көн саен бәйләмә-бәйләмә белән хатлар китерәләр. Мәктәпне карарга килүчеләр иртән дә, кичен дә өзелми.


Актлар залы белән янәшәдәге бүлмәдә — класс-музей. Андагы һәр нәрсә Володя Ульянов укыган замандагы кебек: өч урынлы парталар, укытучы дәрес бирә торган кафедра, кара такта. Ә беренче рәттә нәкъ тәрәзә турысындагы соңгы парта янына: «Монда 7 класс укучысы Владимир Ульянов утырган»,— дип язу кадакланган. Аерым бер бүлмәдә — Владимир Ильич укыган дәреслекләр, аның өлгергәнлек аттестаты һәм башка әйберләр. Шунда ук җир шарының төрле почмакларыннан бу мәктәпкә җибәрелгән бүләкләр...

Урам түбәнгә борыла. Урам буйлап барасың һәм дулкынланып уйланасың: «Нәкъ шушы урамнарда кайчандыр яшь Ильич йөргән».

Һәм менә ул яшәгән йорт. Анда һәрвакыт халык күп була. Ульяновск шәһәренә кем генә килмәсен, иң башлап ул В. И. Ленинның балачагы һәм гимназиядә укыган еллары шунда үткән йортны карарга ашыга.

Ульяновлар семьясы бу йортта ун ел яшәгән. Алар күчеп киткәч, ул берничә хуҗа кулында булган, вакытлар үтү белән шактый какшаган.

1923 елда бу йорт, национализацияләнеп, РКП(б)ның губерна комитеты карамагына бирелде һәм анда Революция музее ачылды. Владимир Ильич үлгәннән соң, шәһәр хезмәт ияләре аны В. И. Ленин һәйкәл-йорты итеп әверелдерү турында тәкъдим ясадылар. Советларның XIV губерна съезды бу тәкъдимне карады һәм йортны, Ульяновлар торгандагы хәлгә кайтарып, В. И. Ленин музее итү турында карар кабул итте.



*Беренче номерлы урта мәктәп. Биредә элек В. И. Ленин укыган.*

Реставрация эшендә Анна Ильинична, Мария Ильинична, Дмитрий Ильич Ульяновлар һәм бу семьяның якын дусты Вера Васильевна Кашкадамова актив катнаштылар. Шул ук вакытта Ульяновлар семьясында булган әйберләрне эзләү һәм җыю эшләре дә алып барылды.

1929 елның ноябрена йортны реставрацияләү эшләре тәмамланды һәм 6 ноябрьда, Бөек Октябрь социалистик революциясенең 12 еллыгы көнендә, шәһәр Советының драма театры бинасында төрле җәмәгатьчелек оешмалары катнашында үткәрелгән утырышында В. И. Ленинның музей-йорты рәсми рәвештә ачылды.

Мария Ильинична 1936 елда, музейны карарга килгәч, тәэсирләр кенәгәсенә болай дип язып калдырды: **«Туган якларда, күңелгә якын урыннарда, Владимир Ильичның балалык еллары узган һәм безнең бөтен семья яшәгән җирләрдә булу әйбәт тәэсир калдырды. Музей... бик матур оештырылган һәм күптән үткән истәлекләрне яңарта».**

Дмитрий Ильич, 1942 елның 2 июлендә музейны карап, түбәндәгеләрне яза:

**«Бик күптәнге, ләкин шул ук вакытта күңелгә чиксез якын көннәр күз алдына килә. Барлык нәрсә әниебезне, әтиебезне һәм Аны хәтерләтә. Кечкенә, җирән малай, һәрвакыт шат күңелле, һәрнәрсәдә гаять гадел һәм тәртипле Володя. Соңрак ул — бернигә карамый үз дигәнен булдыручан яшүсмер егет. Бик якын, кадерле образлар, һәм картайган күзләргә яшь килә, ләкин күңелгә шундый яхшы һәм рәхәт, бу йортны ташлап чыгып китәсе килми»...**

Музей ачылган беренче көннән башлап халык биредән өзелеп тормый. Баштарак Ульяновскида яшәүчеләр йөрделәр, аннары якын-тирә районнардан килеп карадылар, озак та үтмәде, бу музей турында хәбәр бөтен Советлар Союзына, барлык илләргә таралды. Музейны инде алты миллионнан артык кеше карады. Уннарча мең кеше үзләренең тәэсирләрен язып калдырдылар.

Калын-калын утыз дүрт том — төрле телләрдә шигырь һәм проза белән язылган тәэсирләр...

Ерак Мексикадан килгән негр, Канада эшчесе, Африка халыклары вәкилләре язган юллар, болгар, поляк, чех, француз, голландия һәм башка бик күп телләрдә язылган тәэсирләр!..

Себер колхозчысы, Донбасс шахтерлары, Ерак Көнчыгышта хезмәт итүче офицер, Казахстан республикасының хөкүмәт члены, Ленин һәм Дәүләт премияләре лау-

реатлары, Татарстан язучылары һәм артистлары, Ватан сугышы инвалидлары, пионерлар, мәктәп балалары — барысы, барысы да алар тирән дулкынлану хисләре белән бу йортның бусагасын атлап керәләр, барлык нәрсәсе иң кадерле кешене — бөек Ленинны, аның балачагын, яшьлек елларын хәтерләткән бүлмәләрне карап йөриләр...

В. И. Ленин музеен карау, андагы экспонатлар белән танышу һәркемдә гаять дулкынландыргыч, патриотик хисләр уята.

1930 елның июнендә музейны тырыш хезмәтләре өчен Ульяновскига путевка белән бүләкләнгән ударниклар карыйлар. **«Бөек Ленин күрсәткән юлдан барырга, социалистик тормыш төзергә, колхозларны ныгытырга ант итәбез»,**— дип язып калдырганнар алар. Авыл мәктәбе укытучысы үзенең хисләрен бер фраза белән генә белдергән: **«В. И. Ленин эшен ахырына кадәр җиткерербез!»** — дигән ул.



*В. И. Ленин музей-йортының урамнан күренеше.*

**«Берлин янындагы авыр сугыш вакытларында,**— дип язган сержант Хәкимов,— **минем күңелем һәрвакыт Ленин белән булды һәм, Ватан өчен сугышка кергәндә, мин куркуны белмәдем».**

Тәэсирләр кенәгәсендә Советлар Союзы Герое Зоя Космодемьянскаяның әнисе Л. Космодемьянская язган шундый юллар бар: **«Илебезнең бүгенге үсешенә нигез салган бөек кеше яшәгән бүлмәләрне карап йөргәндә, мин гаҗәп тирән дулкынлану хисләре кичердем. Минем кызымны,** Зоя Космодемьянскаяны, фашист палачларының **ерткычларча җәзалауларына бирешмәслек кыю һәм нык итеп, үлемгә батырларча барырлык итеп Ленин комсомолы тәрбияләде»...**

Утыз дүрт томлык мондый язмаларда кемнәрнең генә кулы юк, кемнәрнең генә хисе юк. Менә аларның кайберләре:

**«Кабатланмас бөек кеше, бөтен дөнья пролетариаты юлбашчысы һәм остазы В. И. Ленин яшәгән йортны күрдек.**

**Елга флоты халык комиссариаты һәм елгачылар профсоюзының Үзәк Комитеты карамагындагы «Пропагандист» агитпароходы коллективы В. И. Ленин семьясына кагылышлы барлык әйберләрне зур игътибар белән һәм күңел биреп карады. Кешелек дөньясы тарихын үзгәрткән, җир шарының алтыдан бер өлешендә социализмга нык нигез салган, калган алтыдан биш өлешендә эксплуататорларга каршы көрәш ялкынын кабызган кешенең туган һәм торган йорты** бездә **зур рухлану** хисләре **тудырды. Капиталистлар белән хәлиткеч көрәш көннәре инде ерак түгел.** Социализм, **һичшиксез,**

бу көрәштә җиңеп чыгачак. Бу йорттагы һәр нәрсә зур тәэсир калдыра һәм яңа тормыш, киләчәк өчен яңа көрәшләргә рухландыра...

Коллектив исеменнән агитпароход начальнигы —
А. Рагожин. 23/IX, 1934 ел».

«Бөек юлбашчы һәм остаз В. И. Ленин яшәгән һәм тәрбияләнгән йортны, тарихи урыннарны күрүебез белән без бик бәхетле. Владимир Ильич бүлмәсенең һәм йорттагы барлык әйберләрнең гадилеге дулкынландыра. Мондагы бөтен нәрсә бу семьяда китапны һәм хезмәтне бик зур хөрмәт иткәннәрен әйтеп тора.

Советлар Союзы Геройлары:
А. Ляпидевский,
И. Доронин,
М. Водопьянов,
Р. Эйдеман.
12 июль, 1934 ел».

«Мин Красноуральск (Блюхер исемендәге) пыяла заводы эшчесе семьясында 1905 елда туганмын. 1928 елга кадәр татарча да, русча да бер генә хәрефне дә белмәдем. Кызыл Армия сафына алынгач, татарча да, русча да укый-язарга өйрәттеләр. Армиядән кайткач, анда алган белемем рабфакка керергә мөмкинлек бирде. Рабфакның соңгы курсыннан Балашовтагы очучылар мәктәбенә киттем. Анда авиация белән эш итәргә өйрәндем. Хәзер мин авиация технигы һәм СССР пилоты дәрәҗәсенә ия.

Мин моның белән шуны әйтергә телим: укырга миңа В. И. Ленин мөмкинлек бирде, ул кешелек дөньясы тормышын хезмәт иясе массасы файдасына үзгәртте һәм шуның белән бөтен дөнья пролетариатына кешелек тормышын ничек итеп бәхетле итәргә кирәклеген күрсәтте...

Кәлимуллин. 25 август, 1935 ел».

«Волга-Волга» кинокартинасын төшергәндә, без, «Мосфильм» артистлары группасы, бөтен дөнья революциясенең бөек юлбашчысы, Коммунистлар партиясен тудыручы даһи Ленин яшәгән, укыган һәм җитлеккән йортны зур кызыксыну һәм дулкынлану белән карадык. Совет кинематографиясенең иҗат работниклары биредән үзләренең эшләре өчен күп материаллар алалар, һәм алар бу музейны булдыручыларга, анда эшләүчеләргә үзләренең эчкерсез рәхмәтләрен белдерәләр.

Коллектив исеменнән — атказанган
сәнгать эшлеклесе Гр. Александров,
И. Ильинский,
Л. Орлова һ. б. лар.
14 сентябрь, 1937 ел».

«Фашистларга каршы фронтка китәр алдыннан биредә булдык. Бу йорт безнең хәтердә мәңге сакланыр. Владимир Ильич турындагы уйлар бөтен дөньяда коммунизмның җиңүе өчен көрәштә нык торырга чакыра.

N че дивизия командиры Адашев Н. П.
29 июнь, 1941 ел».

«1942 елның 24 маенда безнең бөек Ленин яшәгән йортта булдым. Владимир Ильич яшәгән, кешеләр арасында иң олы кеше булып формалашкан бу бүлмәләрне авыруча дулкынлану хисләре белән карыйм.

К. Ворошилов».

«Ульяновскига килеп, кадерле Ильич йортын карарга мөмкинлек алган көнемне минем һич тә онытасым юк. Аның тормышын китаплардан укып мин элек тә белә идем. Монда күргәннәрем, шул белгәннәремә өстәмә булып, миндә бик зур, гыйбрәтле тәэсир калдырды.

Бу йорт — оештыручы йорты, хәзерге вакытта да халыкара пролетариатны якты киләчәк өчен көрәшкә өйрәтә торган йорт — бик озак заманнар, бөтен җир шарында аның тәгълиматы хакимлек иткәнгә кадәр, яшәргә тиеш.

Мин бу йорттан, әтием йортыннан чыгып киткәндәй, чыктым. Хәер, бөек Ильичны ничек итеп үзеңнең әтиең санамыйсың инде.

Тарихи истәлекләргә ихтирам белән —
Гадел Кутуй, татар язучысы.
20 декабрь, 1942 ел».

«Сәлам сиңа, бөек Ленин бишеге. Үткәннәрнең күпме хатирәләре монда...

Ульяновлар семьясының электәге дусты,
профессор А. Г. Русаков.
20 декабрь, 1942 ел».

«Казаннан Уфага кайтышлый, Ильичның музей-йортына кереп чыктым.

Юлбашчының туган җирендәге бу гади йортны саклаучы һәм аның өчен кирәк булганнарның барысын да эшләүче музей работникларына кайнар рәхмәт хисләремне белдерү өчен сүзләр таба алмыйм.

Бөек Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге — бай тормыш мәктәбе, һәрберебезнең иҗади хезмәте өчен мәңге кипми торган чишмә.

Г. Рамазанов, шагыйрь.
21 август, 1948 ел».

«Ленин туган йортны күрә алуым минем өчен зур бәхет. Ул безнең Голландия компартиясенең һәрвакыт дусты иде һәм аңа ярдәм итте. Бу, аерым алганда, Ленин әсәрләренең 35 томына кергән Вайнкоопка язган хаттан да күренә.

Давид Вайнкооп хатыны
(Амстердам).
23 июнь, 1951 ел».

«Совет Литвасы хезмәт ияләре якты бүгенге көнебез һәм коммунистик җәмгыять төзүдәге ышанычлы киләчәгебез өчен бөек Ленин тудырган партиягә үзләренең тирән рәхмәт хисләрен белдерәләр.

СССР Верховный Советы депутаты
К. Каванера,
13 август, 1951 ел».

«Владимир Ильич белән Казанда, Кокушкинода күп мәртәбәләр очрашу көннәренә инде алтмыш алты ел тулды. Мин Владимир Ильичны яшь егет — студент вакытында күрүем белән бәхетле. Шул вакытта ук инде ул кадрларны — профессиональ революционерларны — тәрбияли иде. Кокушкино авылына, елга буена, балыкка дигән булып, аның шәкертләре-иптәшләре (В. П. Викторов, Вольский, агалы-энеле Тихомировлар һәм Соловьевлар һ. б. лар) — киләчәктә революционер, ВКП(б) члены буласы кешеләр җыела торганнар иде...

Гомеремнең соңгы елларында Владимир Ильичның яшьлек елларын кабат искә төшерүем белән мин бәхетлемен.

К. П. Винокуров, Мәскәү шәһәре Киев
районы, 32 номерлы эшче-яшьләр урта
мәктәбе директоры. 14 июль, 1953 ел».

«Бөек Ленин төзегән Совет власте безгә бәхетле тормыш бирде. Бүген, В. И. Ленин туган көндә, ул яшьләреген үткәргән бу йортта мин, Совет власте булмаса кем булган булыр идем, дип кабат уйландым. Элек кимсетелгән халыкларга биргән бәхетле, шатлыклы тормыш өчен Владимир Ильичка рәхмәтем чиксез. В. И. Ленинның тууына 83 ел тулу көнендә аның туган җирендә кино төшерү эше тапшырылуына мин бик шат.

Кинооператор Гәрәй Әмиров,
Казан».

«Мин чуваш. Владимир Ильич һәм аның әтисе Илья Николаевичның чувашлар арасында наданлыкны бетерү өчен ничек тырышулары миңа яхшы таныш. Илья Николаевичның турыдан-туры ярдәмендә чуваш педагогы Яковлев чувашлар өчен беренче алфавит булдырган, чуваш педагогия училищесы оештырган...

**Владимир Ильич эше безнең йөрәкләрдә мәңге яшәр!**

Федя Матюшин, грузчик.
24 апрель, 1955 ел».

**«В. И. Ленин музееи карау бездә зур тәэсир калдырды, рухи баетты.**
**Ленинча эшлисе һәм яшисе иде.**
**Ераграк, югарырак һәм тизрәк очарга сүз бирәбез.**

Әрмәнстан очучылары.
27 октябрь, 1963 ел».

**«Үзенең тәэсир итү көче һәм тәрбияви әһәмияте белән бу музейдан да көчлерәк музейны күз алдына да китерү кыен. Кечкенәләрнең дә, зурларның да, партиясезләрнең дә, коммунистларның да — һәм совет кешеләренең һәм чит ил кешеләренең — бу кенәгәгә теркәлгән дулкынландыргыч хисләрен яхшы аңлыйм һәм аларны уртаклашам.**

Советлар Союзы маршалы
Ф. Голиков. 28. 05. 64 ел».

**«Ул безнең йөрәкләрдә яши, без аны һәр адым саен искә алабыз.**
**Без балаларыбызны Ленин кебек итеп тәрбияләргә тырышабыз.**

Манашировлар.
ДАССРның Дербент шәһәре. 16 июнь, 1964 ел».

**«Мин ташчы, Володя өендә булып, аның гадилеген күреп, күзләремә яшь килде.**

Смирнов. Ашхабад.
17 июнь, 1964 ел».

**«Бу мәһабәт бина миллионнарча кешеләребезне тәрбияләргә сәләтле.**

Советлар Союзы Герое,
гвардия авиация генерал-майоры
Жолудев. 27 декабрь, 1964 ел».

**«Дөньяның иң бөек кешеләреннән берсе булган безнең кадерле Владимир Ильич үзенең балалык һәм яшьлек елларын үткәргән бу йорттагы көнкүреш әйберләрен, аның рухи дөньясы белән бәйле нәрсәләрне караганнан соң, күңелдә туган дулкынлану хисләрен язар өчен сүзләр табу кыен. Бу йортны музейга әверелдергән кешеләрнең барысына да чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә.**

Бер төркем хәрбиләр исеменнән —
Советлар Союзы маршалы Баграмян.
16 март, 1963 ел».

**«Бөек Ленинның туган шәһәренә килгәч, мин аның музей-йортын карадым, үзенең тормышын бөтен кешелек дөньясына багышлаган бу кеше алдында тагын бер кабат башым идем.**

Мара Диомба, Гвинея республикасының
бәйсезлек ордены кавалеры, милли җыелыш
депутаты, «ЭР ГИНС» компаниясе директоры.
12 декабрь, 1963 ел».


Музейны карарга килгән кешеләр, төрле милләт вәкилләре, бик күп бүләкләр калдырып китәләр.

Узган елның декабрендә СССРның халык художнигы Н. Н. Жуков Ульяновскида булды. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга әзерлек көннәрендә ул «В. И. Ленинның тормышы, революцион эшчәнлеге» сериясенә кергән 150 дән артык әсәрен калдырып китте. Бу әсәрләр, юлбашчы тормышының менә дигән иллюстрациясе булу белән бергә, шәһәрнең культура тормышын баетуга танылган художник керткән зур өлеш тә.

Өч революциягә катнашкан, 1896 елдан партия члены Ф. Н. Петров музейга «Безнең йөрәкләр ялкыны» исемле шигырьләр җыентыгын һәм «Каторга утравында»

исемле китап бүләк итте. Аларда Федор Николаевичның һәм Шлиссельбург крепостенда утырган бүтән политик тоткыннарның шигырьләре, истәлекләре басылган.

Бүләкләр арасында — Н. Лакобның Ленин туган шәһәр турында абхаз телендәге лирик поэмасы, Ульяновскидагы В. И. Ленин музей-йортының керамикага төшерелгән сурәте (Рязань эшчесе В. Никифоров ясаган), Эстония ССРның Верховный Советы Президиумы председателеннән В. И. Ленинның эстон телендә чыккан әсәрләре бар.



*Ульяновск шәһәренең вокзал яны мәйданында В. И. Ульянов-Ленин һәйкәле.*

Ереванда яшәүчеләр В. И. Ленинның оста чигүчеләр эшләгән портретын, Пензадан — Ленин портреты төшерелгән хрусталь, ә Эстониядән Ленинның төсле янтарьдан эшләнгән сурәтен алып килгәннәр. Бирегә Ильич лампаларының 25 миллионынчы данәсен, Донбасс шахтеры каскасын, Полтава колхозчылары әзерләгән шикәр калачын, Украинадан — Ковпак җитәкчелегендә партизаннар хәрәкәте башланган урыннан — Путивльдән алынган туфрак салынган шкатулка һәм башка бик күп әйберләрне күрергә була. Алар барысы да — хезмәт кешеләренең бөек юлбашчыга мәхәббәтләренең, Ленин идеяләренә тугрылыклы булуларының символы.


Әлбәттә, иң күп бүләкләр — мәктәп укучыларыннан. Мәскәү пионерлары Петроградның Финляндия вокзалында В. И. Ленин басып речь сөйләгән броневикның макетын ясаганнар. Ә Якутия укучылары агачтан милли көнкүреш әйберләре ясап җибәргәннәр. Аларның барысын да санап бетерерлек түгел.

Чит иллардән дә бүләкләр килә. Франция коммунистлары В. И. Ленинның Парижда булуы турында фотодокументлар, Владимир Ильичның 1911 елның 6 январендә Париждан әнисенә язган хатын җибәргәннәр. Болгариядән, Гвинея республикасыннан, Патрис Лумумба исемендәге дуслык университетыннан килгән бүләкләр дә күп.

Еш кына музей витриналарына урнаштырып булмый торган бүләкләр килә. Мәскәүдән, Уралдан, Днепр елгасы буеннан зәңгәр чыршылар, каштаннар, яшь туйра, тал, кедр һәм шомырт үсентеләре алып килгәннәр. Музей территориясендә Краснодардан килгән 500 дән артык, Болгариядән килгән меңнән артык роза куаклары үсә.

Шәһәрдәге парк «Ульяновлар семьясы» исеме белән йөртелә. Бу парктагы үсемлекләр — әнә шундый бүләкләр...

Инде музейның үзе белән танышыйк. Ульяновлар бик гади яшәгәннәр. Йортта кечкенә-кечкенә ун бүлмә. Менә кунак бүлмәсе. Мебеле — гади, тәрәзәләрдә —



*Владимир Ильич бүлмәсе.*

полотно пәрдәләр. Кичләрен биредә Мария Александровна еш кына пианинода уйнаган, балаларына җырлар, романслар, опералардан арияләр җырлаган.

Илья Николаевич бүлмәсе дә башка бүлмәләрдән аерылып тормый: язу өстәле, күн тышлы диван, китап шкафы, кушетка һәм тагын бер кечкенә өстәл. Мондагы барлык нәрсә аның халык мәгарифе өлкәсендә армый-талмый эш алып барганлыгы турында сөйли. Стенада Сембер губернасы картасы эленеп тора. Аңа губернаның иң ерак авылларына барып йөрергә туры килгән. Язу өстәле өстендә аның документлары, халык мәгарифе буенча язган отчетлары ята. Шунда ук — аның яраткан китаплары һәм педагогик эшчәнлегенә 25 ел тулу уңае белән укытучылар бүләк иткән язу приборлары. Почмактагы кечкенә өстәл өстендә — «Современник», «Отечественные записки» журналлары.

Күршедә — Мария Александровна бүлмәсе. Аның бүлмәсе коридордан полотно пәрдә белән генә бүленгән. Биредә дә шулай ук бик гади: тимер кровать, бернинди бизәкләр төшерелмәгән борынгы комод, өстенә кул эшләре һәм китаплар куелган кечкенә өстәл.

Аннары — аш бүлмәсе. Бу зур өстәл тирәсенә утырып, балалар дәрес әзерләгәннәр. Ә Мария Александровна тегү тегкән. Шимбә көннәрендә ашханәдә «Субботник» дигән журналны кычкырып укыганнар. Журналны Александр редакцияләгән.

Тар гына баскыч буйлап өйнең өске катына — антресольгә менәсең. Анда балалар бүлмәләре булган. Мондагы барча әйберләр семьяда балаларның ничек яшәгәнен ачык итеп күз алдына бастыра. Александр Ильич бүлмәсендә китаплар бик күп. Алар үзе ясаган шүрлекләргә тезеп куелган. Дәреслекләр белән рәттән Тургенев, Толстой, Белинский әсәрләре, Дарвинның «Кешенең килеп чыгышы» китабы, Маркслның «Капитал»ы тора. Владимир Ильичның абыйсы гимназиядә укыганда ук химия белән мавыккан. Менделеевнең «Химия нигезләре» китабы, кечкенә шкаф эчендәге колбалар, пробиркалар һәм башка приборлар шул турыда сөйли.

Баскычтан менгәч тә почмакта — Владимир Ильич бүлмәсе. Өстәл өстендә — дәреслекләр. Дәреслекләр белән рәттән Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» романы, Некрасов шигырьләре ята. Стенага география картасы эленгән, аның белән рәттән — абыйсыннан күреп Володя үзе ясаган китап шүрлеге. Ул тыгыз итеп китаплар белән тутырылган.

Бүлмәдәге экспонатлар арасында Владимир Ульяновка бирелгән өлгергәнлек аттестаты, алтын медаль һәм гимназия директоры Керенский кул куйган характеристика да бар.

Музей карарга килүчеләр бүлмәдән бүлмәгә йөриләр, мондагы һәр нәрсәне хәтерләренә мәңгегә сеңдереп калдырырга тырышалар.

Өйгә терәлеп бакча үсә. Бакча хәзер дә Ульяновлар заманындагы кебек үк. Ишек алдында — хуҗалык биналары, кое.

Бакча аша чыгып, Владимир Ильич Ленинның Үзәк музее филиалына керәсең. Бу филиал 1941 елның 7 ноябрендә ачылган. Килгән кешеләр анда Владимир Ильичның тормышы һәм революцион эшчәнлеге турындагы материаллар белән танышалар. Ике катлы матур бинага урнашкан Үзәк музей филиалындагы унөч залга төрле рәсемнәр, макетлар, документлар куелган. Залдан залга йөрисең, синең күз алдыңа юлбашчының героик көрәш юлы ачык булып килеп баса.


Ә шәһәрдә тормыш кайный. Ул тормыш элеккеге Сембер тормышына һич охшаш түгел. Шәһәр дә инде элеккеге Сембер түгел, Ульяновск елдан-ел яңара, яшәрә.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте күренекле архитекторлар, художниклар алдына Владимир Ильич Ленинның туган шәһәре Ульяновскины юлбашчының исеменә лаеклы һәйкәл-шәһәр итү бурычын куйды.


КПСС Үзәк Комитеты, СССР һәм РСФСР Министрлар Советының 1964 һәм 1966 елларда кабул ителгән карарларында шәһәрдә киң колачлы төзелеш һәм реконструкция эшләре башкару планлаштырылган иде. В. И. Ленинның тууына йөз ел тулу көненә кадәр шәһәрдә миллион квадрат метрдан артык торак мәйдан, 25 мең укучыга мәктәп биналары, 12 мең балага мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, бик күп кибетләр, ашханәләр, больницалар, культура-көнкүреш бинапары салынырга тиешле. Болардан тыш, юлбашчының истәлеген мәңгеләштерү өчен, В. И. Ленин туган, үзенең балалык, яшүсмер елларын үткәргән урыннарда мәһабәт архитектура комплекслары калкып чыгачак. Владимир Ильич туган урында төзеләчәк мемориаль үзәк — зур политик һәм тәрбия эшләре, Ленинның революцион идеяләрен пропагандалау үзәге булачак.

Бу гаять зур бина — җәмәгатьчелек учреждениеләре комплексы. Аның күләме — 135 мең кубик метр. Анда В. И. Ленин Үзәк музееның Ульяновск филиалы, Октябрь залы, кино залы, лекция залы, 560 кеше сыйдырышлы политик мәгариф йорты, 1400 урынлы универсаль зал булачак. Универсаль залда җыелышлар үткәреләчәк, спектакльләр куелачак, кинофильмнар күрсәтеләчәк. Әгәр кирәк була икән, махсус механизмнар ярдәмендә урындыклар күтәрелеп, утырышлар залы зур танцы залына әвереләчәк. Мемориаль үзәкнең эчке ишек алдында Володя Ульянов белән бәйле йортлар мәңгегә элеккечә сакланачак.

Биналар ак мәрмәр һәм башка матур ташлар белән тышланачак. Ишек алдына күп кенә скульптура фигуралары куелачак. Мемориаль үзәктән кала икенче урында И. Н. Ульянов исемендәге педагогия институты булачак. Ул Мемориаль үзәк каршындагы мәйданның икенче ягына салына.



*В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көненә салынып бетәчәк мемориаль үзәк.*



*Мемориаль зонаның гомуми күренеше.*

Хәзерге Совет урамында да зур-зур биналар калкып чыга. Ленин орденлы Ленин исемендәге Беренче номерлы урта мәктәп бинасы реконструкцияләнәчәк. Озакламый шул ук урамда 23 катлы бина калкып чыгар, ул — 1000 урынлы гостиница.

Мемориаль зона территориясенә шулай ук пионерлар сарае, балалар китапханәсе, музыка училищесы, музыкаль комедия театры, көнкүреш йорты, сәүдә йорты һәм башка җәмәгать биналары салыначак.

Хәзер Ульяновск шәһәрендә комсомолның бөтен союз удар төзелеше бара.

Тимер юл беләнме, Идел буйлапмы, самолетта очыпмы — нинди генә юл белән килсәң дә, сине безнең шәһәрдә иң элек Владимир Ильич каршы ала: тимер юл станциясендә скульптор В. Е. Цегаль иҗат иткән монумент — Ленин-гимназистны сурәтләгән һәйкәл, Идел буендагы мәйданда юлбашчының мәһабәт фигурасы... Ул, җилкәсенә пальто элгән дә, әйтерсең, туган шәһәрендәге яңалыкларга сокланып карап тора...

Казан юлы белән килсәң дә, Куйбышевтан да, Мәскәү ягыннан да, Ульяновскида сине «Хуш киләсең Ленин туган шәһәргә!» дигән җылы сүзләр һәм шәһәребез кешеләренең ачык йөзе каршылар.

◇ II ◇

Әнвәр Давыдов

# ЙОКЫСЫЗ ТӨННӘН СОҢ[1]

РОМАН-СИМФОНИЯ

*Әнвәр Давыдовның яный яшәүче шагыйрь икәнен мин беләидем. Соңгы елларда ул каты авырды. Шигырьдә аның элекке темпы кими төшкән кебек тоелды. Аның турында син шулай уйлап йөрисең, ә ул яза, авыруына карамастан яза, ашыга, әйтеп калырга ашыга. Шагыйрь моңа хәтле, гомере буе уйлаганнарының бер йомгагын ясар өчен, гомумиләштерүнең югары бер формасын табар өчен тырышып яна. Әнвәр Давыдовның соңгы әсәре «Йокысыз төннән соң» дип атала. Бу — шигырь белән язылган роман. Шагыйрь аны Бөек Октябрьның 50 еллыгына һәм авыл хезмәт ияләренә багышлаган. Роман язылып беткән, үз кулы белән кучерелгән.*

*Соңгы әсәр. Аны аерым игътибар белән укыйсың. Давыдов кайчан да булса роман язарга тиеш иде. Ул поэмалар авторы. Поэмалары аның конфликтларының тормышчан, үткен, композицион яктан оста корылган булулары белән аерылып торалар иде. «Йокысыз төннән соң» романын мин шул поэмаларның синтезы дияр идем.*

*Империалистик сугыштан башлап, гражданнар сугышы аша коллективизация, Бөек Ватан сугышы еллары аша бүгенгегә кадәр үстерелгән крестьян Гайни образы бөтен каршылыклы характеры белән алга баса. Романда уннан артык образ. Шагыйрь аларны просто сурәтләү, тасвирлау белән чикләнми, чор, вакыйгаларга аның үз уйлары, үз кичерешләре, үз мөнәсәбәтләре оста үрелеп бара. «Бер күңелгә тыгызланып тулган чор» ди шагыйрь үз романы турында. Романы гына түгел, шагыйрьнең бөтен иҗаты йокысыз төннәрдән соң барлыкка килгән зур хезмәт.*

СИБГАТ ХӘКИМ.

Бер төнлеккәчә тыгызлатылган бер гомер.
Бер күңелгә тыгызланып тулган безнең чор.

## ПРОЛОГ

Мин һәр елның бер башыннан
Икенче башына,
Туган илнең бер башыннан
Икенче башына,
Бик күп йөрдем,
Туган авылымда,
Себердә, Азиянең җылы хавызларында,
Сугыш кырында,
Россиянең салкын кышларында
Бик күп нәше күрдем.
Балакайда —
мин аларның итәгендә йокладым.

[1] Журналыбызның 1 һәм 2 саннарында романнан фрагментлар бирелә.

Әнием...
Әниләр...
Просто миннән олылар...
Чәчләремнең
тузанлы чукларын
Берәмтекләп тарап,
сыйпап тордылар...

Аннары —
аларның балакайларе
минем итәгемдә йоклады.

Мин
йокыларын бүләм дип курыктым.
Селкенмәдем.
Сыйпадым нәниләрнең
ефәк чәчләре чукларын.

Юдым беренче яраларын.
Яраттым мин кешеләрне...

Алардан —
Минем бөтен уйлар,
бөтен хыяллар.

Аларга —
Минем бөтен уйлар,
бөтен хыяллар...

Кешеләрнең мөлаемлыгына тиң эзләп,
Мин йолдызларга карый идем...
Мәгънә эзләп
«азатлык», «дуслык» диган сүзгә
Мин туган ил буенча гиздем.

Әмма мин барын да
Кешеләрнең үзләреннән,
Аларның сүзләреннән,
Язган китапларыннан
белдем.

Һәм мин —
мин булдым.
Мин —
меңнәрчә куллар,
Йөзләрчә зирәк акыллар
продукты.

Тукта!
Мин нәрсә турында?
Ах, миңа бик күп с ˇләргә кирәк.

Кешеләргә —
кешеләр турында.
Шәһәрләргә —
шәһәрләр турында.

Башкаларга —
Үземнең туган яклар турында.

Илләргә —
    илләр турында.
Дөньяларга —
    дөньялар турында.

Миңа бик күп сөйләргә кирәк.
Миңа ашыгырга туры килә.
Ашыгам
Шуңа күрә менә
    роман урынына
Кагазь битенә
    шигырьләр ургыла.

Күпме яздым!
Әмма
Китапларымның әллә ничә мең дистә юлы
Әйтергә теләгәнемә
    пролог кына.

Пролог кына булса тагын бу юлы?
Укы, иптәш!
    Ярдәм ит!
        Сына!

* * *

Таңны каршы ала Гайни карт.
Ялгыз. Өенең басмачасында.
Сәякләре кебек, шыгырдап
Куя басмача тактасы да.

Кичтән бирле шулай. Гайни картның
Авыр адымымы, буыннарының
Сызлавымы аларны шыгырдатты?
Авырлыгымы башындагы бу уйларының?..

Кичтән...
    Кичтән!
        Кичтән...
Аңлатырлыкмы соң...
        Кичтән бирле
            киләр баштан кичкән.

Бетенесен!..
Башлыйн...
    Иске төшереп монысын...

Кичтән өч-дүрт машина
Улап керде урыс капкадан...
Оныгының адымы астында
Шыр-шыр килде
Басмачадагы иске такталар.

Ашыгыч сүзләр: «...Бабай... бүрәнә...
Пулат булыр... бар да кызыгыр...
Иң беренче бөтен тирәдә...
Әллә гомерең юкка уздымы?

Күрше йортын сатып алырбыз.
Бакча булыр... ял ит... той ил рәхмәтен...
Нигә болай чытыкландыгыз...
Күрергә тиеш бит без
дөнья рәхәтен!..

Бөтен кеше хәзер яңа өйдә,
Тик сез генә һаман кирегә.
Гайни өлгермәде бер сүз дә
Әйтергә.
Машиналар үтте йорт түренә.

Йорт түрендә караңгылыкта,
Ниндидер бер шомлы тау кебек,
Өелде бүрәнәләр.
Тынлыкта
уйлар китте, еллар сүтелеп...

Пулат... бакча... дөнья рәхәте...
Таныш уйлар...

Инде узылган...
Нича тапкыр нәфес бу тәләкне
Яндырган күңелдә...

Аннан... суынган...

* * *

Гайни бабай, йорт сал яңаны,
Үзеңчә сал, җиренә җиткезеп.
Оныкларың җыелыр янына!
Корымасын изге нигезең,—

Правление кыстый килде гел,
Гайни карт тик койды сөмсерен:
— Өем минем түзмәслек түгел...
Ә яшьләрнең белә кем серен?..

Кайсы эштә... Кайсы укуда...
Исән булса улым Исмәгыйль...
Урын булмас иде куркуга...
Булыр иде нигез исән әле.

Нигез...

Гайнинең бит йөрәк тамыры
Аның ташы араларында,
Анда күпме өмет, авырлык,
Шатлык, үкенү, әрну бары да.

Җил кагылды битенә.

Әйе, шундый җәй иде.
Урамда тездән үлән.
Яшь Гайни өй бетерә.
Күрергә халык килгән.

— Шыгырдап торган юкә!
— Ваграк бүрәнәсе...
— Мондый җорлык-тизлеккә
Безгәле үрәнәсе! [1]
Бит быел чыкты егет
Аерылып атасыннан,
Ә хәзер байлар кебек
Карый ихатасыннан.

Гайни нечкә мыегын
Сыпырып-сыпырып ала.
Зур урамдай төелып
Китә тар тыкрык аңа.

Зур салам бүрекләрен,
Таз кебек, маңгайга ук
Төшереп, күреп барын
Торалар өйләр. Явып
Коендыра кояшның
Нурлары бар дөньяны.
Кайный күңеле бу яшьнең
Кытыклый зур уй аны:

Ә, шулаймы? Туктагыз
Күрерсез тагын әле!
Булмамын ачык авыз.
Булыр бай чагым әле.

Өйләрегез өстенә
Ташпулат үсеп чыгар.
Гали бай исеменә
Булыр бу исем сыңар.

Турымнан узган чакта
Иячәк баш һәрберең...
...Иркәсенә караватта
Сөйләде кичен серен...

---

[1] «Өйрәнәсе»нең диалектта әйтелеше. Ә. Д.

Күзләре караңгыда
Ут кебек янганмыдыр,
Гөлзада җавабында
Каушады. Ялварды ул:

«Ник болай карый күзең?
Ник сиңа байлык кирәк?
Мин сиңа риза үзем
Гомергә тирес күрәп
Яшәргә! Тик язмасын
Яшерен шул уеңа
Бер көндәш булу миңа.
Мине ихлас назла син!»

Гайни терсәк таянып,
Гаҗәпләнеп, кузгала:
«Бу түбәнлек каян, син
Бит тәкәббер кыз бала!»
...Тәрәзәдән анда да
Ай сузылып кергән иде.
Нур төшереп Гөлзадага,
Сискәндерде Гайнине.
Чем кара зур күзләре
Дәртле дә, хәсрәтле дә,
Еш сулаган күкрәге,
Очлаеп әзрәк кенә
Калка ак күлмәгеннән.
Ул ала Гайни җанын
Моңача күрмәвеннән
Шундый зур бәхет барын...

* * *

Көннәр җиргә китмәскә килә...

...Сөйлиләр: кырык еллык дата, илле еллык...
Брест... Сталинград... Ашхабад...
Гайни өчен болар бер төргәк... Уралган нык.
Кайчак тормыш җиле, истәлекләр кылын
тарткалап,
Уята күңелдә йөз мең көннең берсен.
Кайчак бөтенесен берга айкалдыра.
Тукта: бүген әле ни өчен
Кузгалды болай, бер шатлык, бер кайгылар...
Күңел көймәсе Гайнинең
Чайкала ятып бер яктан икенче якка...
Менә дулкын күмде Исмәгыйлен.
Яшь Гайни үзе —
Ярман сугышында солдатта.

Чың-чың чыңлый кыңгырау
Аллы-гөлле дугада.
Ә күңелдә сыкрау.

Ут үрелә бугазга.
Ярманга сугыш ачкан
Патшабыз җәнапләре.
Бүртенәләр кояштан
Пристав яңаклары.

Исемлек укый писер.
— Ник исеме юк байларның?
— Аларда бит бар бүсер!
— Рәт бар барысын майларлык!

— Гайни, син ни карыйсың?
Синдә дә рәт юк түгел!
Борчыйлар җан ярасын
Гел тора әрнеп күңел.

Күпме хыяллар багълап,
Тирен түгеп тапканнан
Бер тиенне дә алдалап
Суыра алмас талпаннар!
«Гөлзада, тырыш, җаным,
Мин кайтканчы сакларга.
Табармын аннан җаен...»
— Утырыгыз атларга-а-а!

Калды хатын, малаең,
Калдылар елап, аһлап.
«Гайни бай» булалмадың,
Булдың син «Гайни солдат».
Чың-чың чыңлый кыңгырау
Аллы-гөлле дугада.
Ә күңелдә сыкрау,
Ут үрелә бугазга...

* * *

...Яшь балалы булса да
Буйлары сөлек кебек,—
Йортта чакта Гөлзада,
Гайни киталмый керөп,
Ала алмый ул күзен
Күкрәге калкуыннан,
Серле кара күзенең
Бик тыйнак чакыруыннан.
Әз генә калкып тора
Күлмәге — батисыннан
Түгәрәк кенә корсак,—
Мәҗүси алиһә сыман...

Гайнинең үлмәслеге
Шунда ич тып-тып тибә.
Гайни яшертен генә
Шуңа карап туктый дә,
Белә, утка, сәңгегә
Ул әзер шуның өчен...
...һәм күрмәскә мәңгегә
Хыялый байлык төсен...

Бер көн килеп керделәр
Әфисәрләр. Кайнага...
Гайнине җибәрделәр
Хәмер алып кайтмага.
Бер сәгать үткәнмедер —
Чувашлардан әйләнде...
Хатынына карады бер
Һәм телләре бәйләнде.

Сорамады. Дәшмәде
Һәм үксеп еламады.
Эчтә калды яшьләре.
Мәңге көйдереп аны.

Беренче кат шунда тик
Үкенде: ник алмады
Өндәгәндә большевик:
«Ал!» — диеп корал аны.

Бу эшәке өердән
Көл генә калыр иде...
Күзләре үк тилмергән
Гөлзада башын иде.

* * *

Аклардан туйды авыл,
Байраклар көткән ирек
Хәтта янып бетте ул
Самогон көйрәвендә.

Чыр-чу... Ха-ха... Гөрс... Ату...
Кайнага да гел шунда.
Дүртенче көнне иртән
Тора Гайни каршында.
Шешенгән, күзен кара
Кан баскан. Авызы кыйшык.
Сүгенү ташкынын, ахры,
Тыя, тешләрен кысып.

— Хәзер җик пар атыңны...
Большевиклар керәләр!
Калсаң... сине... хатыныңны
Таш коймага терәрләр.

— Мин кеше үтермәдем.
Мин кеше көчләмәдем.
Йорт-җиремне ташларга
диеп мин эшләмәдем.

— Ә шулаймы!
Гайнинең
Күзенә карый бердәнбер
Мәрхәмәтсез һәм тәпсез
Күзе белән револьвер.

Менә шулай соң тапкыр
Сулаганда йотлыгып
Үкенә Гайни тагын бер —
Ташлаганга мылтыгын.

Кинәт авыл башында
Кузгалды каты давыл.
Кайнаганы каушата,
Никтер калтырата ул.

Кай арада тезләнә —
Суктымы әллә яшен! —
«Кияү, коткар үлемнән,
Тиз генә мине яшер!»

Мылтыгы булса!.. Гайни
Яшьли чая баш иде,
Исерек баш кайнаганы
Һич аяп тормас иде.
Булмады... кызган чакта...
Басылды соңра күңел.
Ябылды имән капка.
Асылды йөрәккә гер.

Большевиклар авылда,
Авыл үз көе белән
Гөрли инде тагын да.
Җил белән өерелгән
Дулкыннар кебек, калка
Төрле башта җыеннар.
Икеләнү һәм каушау
Фәкать Гайни уенда.

Аның да кешеләр белән
Гөрләп йөрисе килә.
Яңа властьлар биргән
Җирне билисе килә.

Төптә — күңелне... исә
Тотып тора авыр шик.
Кайнага шәүләсеннән
Күләгәләнә ишек...

Базда ак кайнаганың
Ятканын кем соң белә?!
Авылның үз кайгысы,
Җыела да гөр килә.

Янган, изелгән, өзелгән
Гайни дә шунда йөри.
Бизгәндәй үз өеннән
Бөтен авылны урый.
Кеше белән гөр килә,
Көзне-язны чамалый...
...Тик кайттыса өенә
Хәсрәт аны сагалый.

Капка төбендә аны
Бәрешеп, иелеп, басып,
Шелтә көткән сыманмы,
Кара күзен зур ачып,
Көтеп тора Гөлзада,
Нидер ялварып, иңрәп...

Их, шул караш булмаса...
Җай табылыр иде мең рәт.

Өйдә идән астыннан
Вәли — карачкы чыга.
Гайнине сыный сыман —
Ике күзе кысыла.
— Юк, кияү! Саталмассың!
Муеныңда синең мин таш.
Мин ялгыз батаммы соң?
Батачак синең дә баш!

...Әмма нидәндер шүрли
Башладымы кайнага,
Бер көнне әйтеп бирде
Уе барын таймага:

— Мин юкка чыгам... пока...
Тик... китте дип куанма.
Яңа влачка ышанып
Яңа бәхет куарга...
Сак бул! — Кирәк вакытта
Хәбәр бирә торырмын!

Ялкын ыргып офыкка,
Куды морҗа корымын.

* * *

Аклардан тиз туйды авыл.
Кинәт урман ягында
Кузгала утлы давыл.
Большевиклар авылда.
Котылып калды авыл.
Кичә генә дөньяны
Тетрәткән бандитларың
Әллә кая югалды,
Кызыллар бай йортларын
Тикшерделәр. Отряд
Башында күрше Шәрип,
Абыстайга әзрәк
Йөргәндә иң шәп шәрик
Иде ул Гайни өчен.
Кара хәзер, нинди ул,
Беренче көнне үк кичен
Гайниләргә килде ул.
Эше белән. Шулай да
Гайни ачык каршы ала.
— Сый куйыйм!
— Башка җайда,
Гөлзада калтырана.

— Сорау бар сиңа, шарик.
— Соң?
— Вали сездә бездә бит.
— Юк!
— һе, тентик, иптәш Шәрип!
(Бу бер ашыгучысы.)
— Әмер итәм: отставить!
Агарган Гөлзадага
Да Шәрип карап ала.
Якында шул арада
Нидер нык шартлап ала.
Чалпарама ватыла
Тәрәзә. Өйдә төтен.
Отряд
тышка ашыга.
Урамын карый,
йортын.
Өйдә — Гайни, Гөлзада —
Аптырау, курку тулы.
Селкенә стенада
Гайнинең төлке туны.
Шуннан Вәли сүгенеп
Чыга. Маузеры тәти.
Өлгермәгән суынып.
Житмәсә әле үрти.
— Шүрләдең? Шәригең әле
Котылды, дога кылсын!
...Я ходай шундый мәлне
Тотылып буламы соң.
Вәлинең бугазына
Бата кул!
— Ая җаным.—
Кай арада базны да
Ачкан! Бу хатыннарның
Сөюе белән бергә
Йөри, ахры, хәйләсе:
Төшә Вәли дөмбердәп,
Ябыла идән. Әйтәсе
Сүз дә әле бугазда...
Яңадан керә Шәрип.
— Уф! Димәк, синең базда
Беркем ятмады, шәрик?
Ышанам. Бөтен якны
Айкадык... Кычытканны...
Әллә кая олакты.
Ярый... Барып чыкмады...
Ә син йомыш төштисә
Кил, онытма дуслыкны,
Ә без киттек. Эш — диста!..
Елмайды, көрешеп чыкты...

Юк, ул хәзер йөгерер иде Шәрип артыннан...
Ул мең мәртәбә барачак
әле килачәктә Шәрипкә —
Мең мәртәбә Шәрип аны
Чыгарачак әле
юлга һәр эштә...

Икәү. Гөлзада каткан.
Гүя ак таш багана.
Ә Гайни... Тагын сыкрый җан
Коралны ташлаганга.
Пуляны кайнагага
Батырып ләззәт белән,
Бөтен ил кайнаганда
Ул да бу отряд белән
Китәр иде... Шул чакта
Булмады... Әрни күңел.
Ябылды имән капка.
Асылды йөрәккә гер.

* * *

Аклар киткәч тә Шәрип
Авылда Сәвит булды.
Башта күктә яшәреп
Яшен болыты куерды.
Гайни үз-үзен кая
Куярга белмәгән чак.
Уйларны бер уңайга
Шәрип җибәрер очрап.
Бит сөрүдә, чәчүдә,
Ярлылыктан тырмашу,
Хәллеленкә ирешүдә —
Нык эшли Гайни башы.
Ярдәм ит Сәвиткә син.
Йөрмә бер якта гына.
Кирәктә бир киңәшең
Ярлысы, батрагына!

Совхоз һәм крәстиян
Арасын ныгыта Шәрип.
— Монда нем миңа терәк?
Син инде, Гайни, шәрик.
Совхоз орлыкмы бирә,
Машина кирәкме гел,
Ил Гайнине җибәрә...
Җиңеләя йөрәктә гер.
Карыйсың ярлы өе
Кояшны чагылдыра.
Гомерлек ялчы инде
Үзенә учак кора.
Авыл тормышны җайлый.
Йортлары җыйнаклана.
Ныклыкны сөйгән Гайни
Моны күреп шатлана.

* * *

...Ил сөйгән ил улы өчен
Ил кулы — табип кулы.
Гайни кызганмый көчен —
Кими йөрәк ялкыны,—
Шулай ук кереп китә
Җәмәгать кайгысына...

Совхоз һәр елны бирә
Уртасы, ярлысына
Тәҗрибәгә югары
Сортлы бодай. Орлыкка.
Җикче, Гайни, юрганны!
Баш иеп йөрмә юкка!
Үзеңә дә булыр... миңа...
Бар илдә җор куллылар —
Комитет исеменнән
Язу да тоттырдылар.

Совхоз: «Совет утлары».
Директор — Караулов.
Шул ук алпавыт утары.
Тик Гайни яңа авылның
Күрде тын-астан гына
Туып үсеп килүен.
Искелек астарына
Яңа чәпәлгән кием
Түгел бу: бар уйларны
Яңа эз ярган сыман.
Гайни бутап юлларны,
Бер читтә калган сыман.
Кеше белән кешенең
Мөгамәләсендәме,
Аңкытып бензин исен
Килгән Галәсендәме? —
Тик шунда шытты кебек
Гомерендә яңа дәвер.
Шул хис кермәсә килеп
Кире сызарга да ул
Әзер иде бер арада:
Совхоз канцеләренә
Баргач язу алырга
Алган нәрсәләренә,
Утыра, кем, диген, ә! —
Әлеге кайнагасы.
Ул Гайнине белми дә —
Шундый коры карашы!

Бөтен эшне бетереп,
Юлына чыккач кына,
Урманда чыкты килеп
Бер карачкы каршыга.
— Башны ашама, кияү,
Мин — башка кеше хәзер.
Элекке эш — юкны сөйләү —
Тик тырный эчне хәзер.
Эшлисем килә минем
Властька намус белән,
Харап итә күрмә син
Вакытсыз донос белән.
Озак тордылар алар
Гайни белән карашып.
Күңелдә төрле уйлар:
Бер күерә кара шик,
Бер күренә ялвару

Тулы күзләр карашы —
Гүя ишетеп барын
Тора күк Гөлзадасы.

Сүз дәшмәде Гайни, тик
Уйланып, китеп барды.
Калды, җанны әрнетеп,
Тагын
атмаган дары...
Кайткач та Гөлзадага
Ачылып карамады...
Тик күмер кебек һаман
Күзенең каралары
Көйрәттеләр күңелне,
Әллә ниләр уйлатып...
Көндез — илдә... ә төнне
Яткачтын өйгә кайтып,
Нидәндер калтыранган
Аның ябык тәнендә
Кагылып китсә, һаман
Иң түргә үпкәнендә
Кайткандай янып китә,
Онытылып елыша аңар.
Арада бар да бетә,
Бер булып кушыла алар.
...Була кайтыр шикелле
Яшьлек төне еректан...
Әмма уйлар-шикләрне
Уятып, туа ак таң...

◆ ◆ ◆

**Рафаил Төхфәтуллин**

# ГОМЕРНЕҢ КЫРЫК СИГЕЗ МИНУТЫ

хикәя



Әрәмәлек буйлап өч чаңгычы бара. Җәяүле буран юлчыларның битләренә кар сибеп үтә.

Чаңгычылар җиңел спорт киемнәреннән түгел. Иң алдан юл ярып барганы — урта яшьләргә якын, базык гәүдәле кеше — җылы бушлат кигән. Аның артыннан барган шактый өлкән яшьтәгесенең өстендә авыр кайры тун. Алар артыннан, чаңгыларын бик җиңел-җиңел атлатып, яшь кенә егет бара. Ул өр-яңа кыска сырмадан.

Сырмасы да яңа егетнең, түгәрәк йөзе дә мичтән яңа чыккан уңган күмәчтәй... Ул аякларын да көчкә генә тыеп бара бугай. Әгәр аякларына ирек куйса... чаңгылары кар өстенә тисә тияр, тимәсә юк иде аның. Шук колын кебек, үзеннән алда барган агайларны әллә кайларда калдырып алга җилдерер иде.

Ләкин алай итәргә ярамый.

Ул бүген өлкәннәр эзеннән юлга чыкты.

Бик көттереп, хәтта тиешлесеннән артыгын да көттереп килде бугай ана бу көн.

Сигезенчедә укыганда ук күңеленә беркетеп куйды Илсур: иртән торуга сумка асып мәктәп юлын таптап йөрүләрнең соңгы елы булыр бу, диде. Бик кирәк икән, кичләрен йөрер бу юлдан. Ә иртәләрен эшкә барыр. Юкса, ничек соң инде?.. Инвалид әтисе, слесарьлык коралларын асып, титаклый-титаклый ерак скважиналарны әйләнеп кайтканнан соң да кара төнгә кадәр струк-өтергеләрен кулыннан төшерми... Әнисе төзелештә ирләрдән уздырып таш күтәрә... Ә ул, колгадай гәүдәсен сузып, мәктәп юлында йөрсен, имеш. Килешәме инде шушы, я?.. Җитәр. Әти-әни җилкәсенә аннан башка да тагын дүрт җан кала. Берәр промыселгамы, төзелешкәме өйрәнчек-фәлән булып керергә дә үз ишиен үзе маңгай тире белән табарга вакыт аңа.

Бу нияте турында әтисенә дә, әнисенә дә ләм-мим сүз ачмады ачуын. Уку елы бетсен, эшкә керүне дә юллап-белешеп куйсын. Аннары гына мәсьәләне уртага салыр. Әтисе дә, әнисе дә каршы килеп маташмаслардыр. Әлбәттә, каршы килмәсләр... Куанырлар гына әле.

Шушы ният-хыялы аның күңелен җылытып тора, көннәрен мәгънәлерәк итә кебек иде.

Шушы ук ният-хыял белән янып, ул озак кына вакытлар бер нәрсәгә игътибар итмичә йөргән. Әтисе хәзерге заманда укымыйча калырга һич ярамавы турында нигә быел аеруча күп сөйли башлады соң әле? Илсурның көндәлегенә дә сеңелләренекенә караганда ешрак күз сала. Көндәлектә «өчле» күрсә, жентекләп төпченә башлый. Нигә алай? Тырышмыйсыңмы, әллә төшенеп бетмисеңме?

Еш кына күрсенеп куя:

— Их, юләр генә булдым укымыйча,— ди.— Сигезенчедә бер чирек укыгач ташладым бит. Тормышыбыз жиңелдән түгел иде. Бер әнигә дүрт бала... Әмма абый кат-кат әйтте. Укы, энем, сиңа гына терәлмәгән, диде. Юк бит... Юләр түгел диген... Укыган кордашлар инде минем әллә кемнәр булып бетте. Директор да инженер...

Әнисе бик житди генә әйтеп куя:

— Синдәге баш!.. Әллә инженердан кимме!

Әтисе, көлемсерәп, кулын селти. Әмма әнисенең сүзләрендә дөреслек бар кебек. Балаларының арифметикадан мәсьәләләрен чишә алмый утыруларын күрсә, әтисе кәгазь-карандаш ала да моны бик жиңел чишеп бирә. Аз гына буш вакыты булдымы, кулында китап, газета-журналлар була аның. Күршеләрдән, дус-иштән берәрсе кереп утырса, әтисенең авызыннан күзләрен ала алмыйлар. Ниләр генә сөйләми ул! Ерак планеталар, фән могжизалары, Вьетнамдагы хәлләр...

Бервакыт әтисе бик шатланып кайтты. Эшендә аның разрядын күтәргәннәр, моннан соң хезмәт хакы да артачак икән.

— Күптән вакыт иде инде,— диде әнисе. Гадәтенчә, шатлыгын берьюлы гына бушатып салмыйча, житди генә әйтте.

— Вакыт иде дә... Үзең беләсең ич...— диде әтисе шук елмаюын аз гына да сүрелдермәстән.

Әтисе белән әнисенең әнә шулай «үзең беләсең ич» дип нәрсәгәдер ишарә белән сөйләшүләрен Илсур әлегрәк тә ишеткәли иде. Сугыштан соңгы елларда әтисе авылда колхоз председателе булган. Шул чакта ул районнан килгән берәү белән бәхәскә кергән. Бәхәс һаман зурайган, тирәнәйгән. Ахыр чиктә алар авылдан күчеп киткәннәр. Әтисе нефтьтә эшли башлаган. Бер заман әлеге район кешесен дә бирегә күчергәннәр. Кем итеп диген — әтисенең начальнигы итеп. Тагын бәхәс, тагын ниндидер аңлашылмау... Нидән гыйбарәт ул бәхәс? Кем хаклы? Монысын Илсурның һаман да төшенеп житкәне юк. Бу турыда сорашырга Илсур бу юлы да уңайсызланды.

Әтисе шушы көнне ачыктан-ачык әйтте:

— Укы, улым, институт бетерми торып, укудан туктама. Унны бетергәч, бераз эшләп караганда да ярый. Анысын үзең карарсың. Ләкин институт турында да онытма. Фәннән башка бер шаг атлый алмыйсың безнең заманда. Шуны бел!

Илсур, эченнән генә көлемсерәп, тыңлап утырды. Уку елы гына бетсен, Илсурның да бу дөньяга үз карашы барын күрерсез әле...

Жәйгә чыккач, промыселга өйрәнчек булып керү турында юллап-сөйләшеп тә йөри башлады ул. Инде моның очына да чыгып килә иде шикелле... Әтисенең яралы аягы авыртып, көтмәгәндә больницага салдылар.

Баштарак: эш турында сүз ачарга сылтавы да чыкты,— дип уйлады Илсур. Әтисенә шуны әйтергә жыенгач кына, кинәт үз уеннан үзе куркып китте. Юк бит, нәкъ менә хәзер әйтергә ярамый бу турыда. Бик авыр кичерәчәк моны әтисе. Янәсе, дөнья куу хәзер олы малаена калып бара... Шулайрак килеп чыга ич.

Тугызны да укыды Илсур, унны да. Шуларга өстәп, унберенче класс та килеп чыкты әле. Туры килүен генә күр. Аннан элек тә урта мәктәптә ун класс булган, хәзер дә ун класска калды. Ә Илсурны унбер ел укыттылар.

Соңгы имтиханнарны биргәч, малайлар, кызлар, олы кайгыга батып, аһ орып йөри башладылар. Быел ВУЗларда конкурс коточкыч зур булачак, диләр. Безгә генә туры килде, уннар да, унберләр дә берьюлы аттестат алдылар, ВУЗга эләгү ышанычы икеләтә кими, диләр.

Сабакташларының мондый зарларын ишеткән саен, Илсурның авызы ирексездән колакларына таба җәелә дә китә иде. «Хәсрәтегезне уртаклаша алмыйм, егетләр, минем юлым инде күптән билгеләнгән — эшли башларга вакыт» дигәнне аңлата иде бу елмаю.

Әтисе дә улының ниятен хуплады. «Тик институт турында да онытa күрмә. Гаризаң гел кесәңдә йөрсен»,— диде. Аннары, маңгаен кинәт кенә бик тирән җыерчыкландырып, әйтте:

— Тагын менә, улым... Үзең ничек уйлыйсың?.. Кулыңда төпле генә һөнәр булмый торып эшли башлау... Теге, ничек әле... Элекке замандагы йомышчы малайлар кебек булмагае. Шундыйрак хәлдә йөрерлек булмасын дим. Ничек уйлыйсың?

Сөйләшә торгач, шунысы да мәгълүм булды: әтисе бу турыда күптән уйлаган, буровой кадрлар мәктәбендәге якташлары белән бу турыда сөйләшеп тә куйган икән инде. Тик мәктәпнең кайсы бүлегенә — бораулаучылар әзерли торганынамы, операторлар яки электриклар әзерли торганынамы — анысын, җаның тартуына карап, үзең сайлап аласың.

Әйтер сүзен әнә шулай маңгаен бик кинәт җыерчыкландырып, уйчан гына, салмак кына әйттеме — һич каршы килеп булмый аның әтисенә. Әллә ничек кенә шунда... ышанганыңны, килешкәнеңне сизми дә каласың.

Шулай итеп, яңадан күпмедер айларга парталар арасына кереп утырырга туры килде.

...Ниһаять, бүген ул юлга чыкты.

Әрәмәне үтеп, урман буеннан бара башладылар. Бирегә алай җәяүле буран уйнамый, тын, хәтта бөркү иде.

Илсур үзенең алдыннан барган кайры тунлының авыр-авыр сулавын сизеп алды. Аркасын, иңбашларын ак бәс сырган. Тирләгән, күрәсең.

Иң алдагы кара бушлатлының исә бирешергә аз гына да исәбе юк. Ашыкмый гына, һәр адымын «нәкъ шулай кирәк, бүтәнчә ярамый» дигәндәй, чаңгыларын гел бер көйгә тигез-сабыр шудырып баруын белә.

Кайры тунның гыжылдык сулышы ешайганнан-ешая. Кара бушлат та моны сизде бугай, адымнарын тыя төште. Чаңгыларын җай гына шудырып бара башладылар.

Ак бәс сырган кайры тунлы бу кеше — участок начальнигы Хәлил Гасан-задә. Баку ягыннан килеп, Татарстан нефтенең беренче скважиналарын эшләтешә башлаган карт оста.

Алдагы кара бушлатлысы — өлкән оператор Шәйхелислам. Гасан-задәнең беренче шәкертләреннән. Хәзер үзе промыселда бик абруйлы осталардан санала.

Иртән контора янында егетләр сөйләп торды: «Һәр яңа килгән операторга скважиналарны үзе күрсәтеп йөрмәсә, күзләренә йокы керми ул Гасан-задәнең. Менә күрерсең, сезгә дә иярер әле»,— диделәр. Шулай булды да.

Урман кырыен үтүгә, алда бик зур сиртмәсен акрын гына ия-бөгә утырган насосы, үлчәгеч ак шаны белән скважина күренде.

Гасан-задә инде хәл алып өлгерде булса кирәк, аланны яңгыратып кычкырып куйды:

— Һи-һи, Шәйхел! Бөтенләй йоклап киттең син. Айда, поживей!

Алар кызуладылар. Илсур чаңгы бауларын рәтләгән булып арттарак калды да буран уйнатып алар артыннан очты.

Кичә кич бүе әтисенең сөйләп сүзе бетмәде. Олы улының хезмәт юлына басу хөрмәтенә дип бер кызыл да алып кайткан иде. Әнисе төнге сменага китте. Сеңелләре йоклап беткәч, икәүдән-икәү генә утырдылар.

— Бик зур көнең, истәлекле көнең бу синең, улым. Бу хөрмәткә берне тотканда да гөнаһ булмас,— диде әтисе һәм улы белән тиз генә чәкәшеп, стаканын төбенә кадәр бушатып куйды.

Илсур үз стаканына иренен генә тидерде дә өстәлгә куйды.

Әтисе, моңа аз гына игътибар итмәстән, сөйли башлады. Үзенең бик яшьләй эшли башлавын, авылда колхоз төзелгән беренче язда басуга чыгуын, сукалап киткәч тә озын кара әремнәре тырпаеп калган ызаннардагы зур-зур кантарларны олырак малайлар белән ярыша-ярыша ватып йөрүен сөйли.

Илсур, өстәлдәге шешәнең матур этикеткасын караштыргалап, тыңлап утырды. Таныш шешә иде бу юкса. Алтын йөгерткәндәй матур итеп «777» дип язып куелган. Операторлыкка укыганда тоткаларга туры килде ул нәмәрсәне. Беренче стипендияне үк юдылар. Илсур да кушылды. Кушылмыйча ярамый иде. Юкса «элимент» булып, «тип» булып, хәтта «темнота!» булып каласың.

Илсур «элимент» та түгел, «тип» та түгел. Өйдән чыгуга, плащ якасын «заманча» итеп күтәреп куя ул, кепкасын бөгәрләп кесәсенә тыга да чәчләрен «заманча» чуалтыбрак җибәрә... Өйгә кайтып кергәндә, плащ якасы да, кепка да инде үз урыннарында була, кесәдәге «Трезор» пачкасы коридордагы электр счетчигы артында кала... «Стиляга чире аз гына да йокмаган» тәүфыйклы малай булып ишекне ача.

Бүген дә, матур этикеткалы бу шешә азрак күңелне кытыклап куйса да, һаман да шул ук «стиляга чире йокмаган» булып калуны артык күрде Илсур.

Әтисе хәзер үзенең армия истәлекләрен, сугыш истәлекләрен сөйләүгә күчте. Болары шактый кызык иде. Ә бер вакыйга Илсурны кинәт сискәндереп җибәрде.

...Моңарчы авылдан юньләп беркая да чыкмаган яшь кызылармеец Гәрәй Зәйнуллин армиядә беренче айларын шактый авыр кичерә. Армиянең кырыс тәртипләренә тиз генә иярләнә алмый ул, аннан да бигрәк, русча начар белүе бик теңкәгә тия. Шушылар егетнең туган авылын сагынуын көчәйткәннән-көчәйтә бара.

Ульяновск өлкәсеннән килгән Василий Демин дигән егет менә шундый көннәрдә Гәрәйне, «земляк» дип, бик якын итеп йөри башлый. Командир сөйләгәннәрне үзенчә итеп, аңлаешлырак итеп Гәрәйгә төшендерә, стройда «земляк» белән янәшә баса, тактик занятиеләрдә дә гел бергә булалар.

Беркөнне, Латвия урманында җәйге лагерьда вакытта, Гәрәй өчен һич көтелмәгән хәл була. Бөтен взвод аны, кызылармеец Гәрәй Зәйнуллинны, туган көне белән котлый, аңа открыткалар, кыр чәчәкләре бүләк итәләр.

Егет күз яшьләрен көчкә тыя. Мондый хөрмәтне, мондый игътибарны үз гомерендә беренче тапкыр кичерә әле ул. Татар авылларында туган көнне билгеләп үтү гадәте бөтенләй дә булмый ул чакта.

Күңеле шунда ук сизенә. Василий эше бу. Ул оештырган моны, рәхмәт яугыры. Кемнең кайчан туганын сөйләшкәннәре дә бар иде ич.

Бер таңны, әчке мул куанычы барлыгын тоеп, кинәт кенә уянып китә Гәрәй. Палаткада барысы да йоклыйлар. Подъемга кадәр әле шактый вакыт бар бугай.

Әлбәттә, куанычы зур. Бүген Василийга да унтугыз яшь тула. Подъем сигналы уйнауга, Гәрәй шул дустын иң беренче булып котлар. Бүләге дә бар. Берәүгә дә күрсәтмичә, иманнан бик матурлап тәмәке

савыты ясады. Капкачына пәке очы белән чокып ясаган рәсемне кәлмичә генә карап та булмый. Маймыл тәмәке тартып утыра. Күләргә дигәндә, Василийга бир инде...

Әнә ул, әле бернәрсә белмичә, янәшә йоклап ята. Сәгать таккан кулын одеалы өстенә куйган. Бөтен взводта бары Василийда гына андый сәгать. Чынаяк чокыры кадәр бар. Келт-келт иткәне бөтен палаткага ишетелә. Гәрәй шул чынаяк чокырына күз төшереп ала. Подъемга кадәр бер сәгатькә якын вакыт бар әле. Көтә башласаң, минутлары да шулай озак үтә инде аның.

Иртәнге тынлыкны бозып, һавада самолетлар очканы ишетелә. «Чынаяк чокыры» подъемга кадәр тагын кырык сигез минут калганлыгын күрсәтә.

Әйе, кырык сигез минут... Бу сан соңыннан Гәрәйнең хәтеренә гомерлеккә сеңеп кала... Кинәт таулар ишелгәндәй, җир ярылгандай коточкыч шартлау яңгырый. Шуннан башлап бөтен тирә-як тоташ шартлау, гөрселдәү, ут, төтен, гарасатка әверелә...

Гәрәй үзенең якын дустын туган көне белән котлый алмый кала. Василий Демин кара свастикалы афәтнең беренче бомбаларыннан һәлак була...

— Кырык сигез минут... Нибары кырык сигез минут йокысын кызгандым. Шунда... Уяткан гына булсамчы инде... Әйдә, улым, кайта алмаганнарның изге истәлегенә берне күтәрик әле,— диде әтисе.

Бу юлы Илсур да бераз чөмереп куйды.

Чөмермичә булдыра алмады. Аңа бит иртәгә нәкъ унтугыз яшь тула.

— Ну, егет, айда, действуй! — диде Гасан-задә. Бүреген салып, яулыгы белән кызыл маңгаен, юеш чал чәчләрен сөртә башлады.

Шәйхелислам нык итеп, мәңгегә береккәндәй итеп чаңгы таякларына таянып алды да маңгай астыннан гына Илсурга текәлде.

«Сынамакчы булалар,— дип уйлады Илсур.— Сынагыз, сына. Мәктәптә практик занятиеләрне «бишле»гә тапшырган егет бу, беләсегез килсә».

Ул ашыкмыйча гына, тыелып кына атлап, улчәгеч шан янына килде. Приборларны карады. Барысы да тәртипле. Шанга нефть тигез килә, катлам басымы нормаль.

Аннары задвижкаларны капшап-капшап үтте. Шан стенасына колагын куеп, нефть агышын тыңлап торды. Боларын ул өлкәнрәк операторлардан күреп алган иде һәм тегеләргә үзен күрсәтер өчен егеткә бу бик ярап куйды.

Инде хәзер әнә шул кечкенә будкадагы автоматларны тикшерергә, аннары, яшел кнопкага басып, автомат кыргычны төшереп-менгезергә, шулай итеп, нефть юлын парафиннан арчырга кирәк.

Будка ишеген көрт баскан иде. Тирә-ягына каранды, көрәк-мазар күренмәде. Озак эзләнеп маташырга ярамый иде — аны дүрт күз карап тора. Аяклары, куллары белән буран уйнатып, ишеккә юл арчырга кереште.

Шыгырдап ишек ачылды. Ишек ачылды... Илсур бусагада баскан килеш катып калды.

Нәрсә бу? Нигә болай?.. Биредә бернинди дә автомат приборлар юк, биредә әллә кай заманнардан калган кул чыгыры гына бар иде.

«Эшне бетергәнче, остазлардан бернәрсә дә сорамаска, хәтта алар-

га борылып та карамаска» дип, бая ук, үзен сынауларын сизгәч үк, күңеленә беркетеп куйган иде ул.

Борылып каравын үзе дә сизми калды.

Гасан-задә гамьсез генә тәмәке көйрәтә, ул Илсурны бөтенләй дә күрми, күзләрен кыса төшеп, урман ягына төбәлгән иде.

Шәйхелислам исә һаман да шулай чаңгы таякларына берекнәндәй басып тора, салынкырак кашлары астыннан аңа текәлгән коңгырт күзләрендә һаман да шул ук какшамас җитдилек.

Илсур эчкә үтте, тирән генә көрсенеп куйды да чыгырны әйләндерә башлады.

Укыганда сөйләгәннәр иде сөйләвен... Электр үткәрелмәгән ерак скважиналарда әле һаман да кул чыгыры кулланыла дигәннәр иде. Ләкин бит... Үнбер ел буе, аннары тагын ничәмә айлар буе шуның өчен, кул чыгыры әйләндерер өчен укып йөрдемени ул? Автомат җиһазларны, диспетчерлык системасын аеруча тырышып шуның өчен өйрәндемени? Сыныйм дигәч тә... Нигә болай мыскыл итәләр?..

Әйләнә чыгыр. Ямьсез итеп, үчекләгәндәй итеп чыелдый-шыгырдый әйләнә.

Әнисенең әйткәне бар иде. «Әтиеңә бәхет-уңыш дигән нәрсә гел аркасын күрсәтергә ярата»,— дигән иде. Инде менә бәхет-уңыш дигән ул нәрсәнең Илсурга да шулай аркасын күрсәтүе микәнни?.. Бу скважина бит моннан ары аның карамагында булачак, кайчан электр үткәрерләр дә кайчан автоматларга көйләрләр...

Әйләнә чыгыр. Шыгырдый, чыелдый... Үчекли.

Юкка гына үчекләми икән. Кулбашлары авырта башлады. Аркасы җылынды.

Егет, мона чын-чынлап үчекләнеп, чыгырны тагы да кызурак әйләндерә башлады. Кызу әйләнгәч, ул ачу китергеч шыгырдау-чыелдау да кимеде. Тагы да кызурак, тагы да...

Ике җылы тамчы арка буйлап бил каешына кадәр тәгәрәп төште. Тагы да кызурак, тагы да...

Дөрес, әнисе соңгы елларда әтисенең язмышыннан алай зарланмый башлады. Теге начальник кеше белән бәхәсләре хәл ителдеме, әллә ул кешене тагын башка урынга күчерделәр микән? Бәлки, бу турыда бик җентекләп сорашырга, әтисе белән ирләрчә сөйләшергә вакыт җиткәндер. Кем белә, Илсурның беренче хезмәт көне болай уңышсыз башлануда шул ук начальникның кулы уйнамый микән?.. Төбенә-нигезенә төшәргә кирәк моның. Йөрерсең аннары... бәхет-уңыш дигән нәрсә гел аркасын күрсәтә дип...

Кулбашлары гына түгел, бөтен беләге, хәтта бармак буыннары да авырта башлады. Маңгайдан агып төшкән тозлы тир күзләрне ачыттыра. Сынатмаска!.. Кызурак! Кыргыч менеп җитәргә инде күп та калмагандыр — катушкага чыбык шактый калын чорналды. Сулышны тирәнрәк, тигезрәк алырга кирәк... Күп калмады. Авырта бирсен беләге, ага бирсен тир... Күп калмады.

Ниһаять, менеп җитте кыргыч.

Илсур җиңе белән юеш маңгаен, кул аркасы белән күзләрен сөртте, бер якка кыйшайган бүреген төзәтте. Шунда гына күрде: Гасан-задә белән Шәйхелислам ишек катына ук килеп басканнар иде.

Гасан-задә, җиңен күтәрә төшеп, сәгатенә карады.

— Ну вот...— диде ул.— Кырык сигез минут. Кырык сигез минут эчендә беләсеңме кая кадәр төшеп менден син? Девон бабай янына кадәр үк. Вот как!

— Кырык сигез минут начар түгел ул,— диде Шәйхелислам какшамас җитдилеге белән.— Хәтерлим әле... Без сәгатьтән артык маташа идек.

Илсурның башы әйләнеп киткәндәй булды. Кырык сигез минут... Нинди сихри сан булды соң әле бу? Василий Демин, үзен унтугыз яшь тулуы белән котларга кырык сигез минут кала, фашист бомбасыннан һәлак була... Илсур унтугыз яше тулар алдыннан, шулай ук кырык сигез минут эчендә, Девон бабай янына кадәр үк төшеп менде... Ничек шулай туры килгән?

— Яшел егет булып төшеп киттең син девонга, инде менә, әйтергә була... Эһм... Әйтергә була, Его Величество рабочий класс чыгардыр кебек синнән. Ну, бир бишне!

Гасан-задә, аннары Шәйхелислам каты итеп егетнең кулын кыстылар. Шушы берсеннән-берсе кытыршырак куллар җылысы Илсурны кинәт айнытып җибәргәндәй булды.

Юк, гади туры килү генә түгел бу. Күрәсең, һәр буынның үзенең сыналу-чыныгу минутлары буладыр. Гасан-задәләр буынының да булгандыр андый минутлары. Василий Деминнар, Гәрәй Зәйнуллиннар, Шәйхелисламнар буыны андый сынауны бомбалар шартлавы астында кичкәннәр... Илсур да шундый сынау минутлары кичте түгелме бүген?..

«Девон бабай янына төшеп мендең»... Бу сүзләрдә дә зур бер мәгънә ята түгелме? Бик каты катламнар да үтәргә кирәк ул девонга кадәр, шактый йомшак, тиз алучан катламнар да үтәргә... Каты токым да бар җирдә, йомшак токым да... Тормышта да шулайдыр ул. Каты катламнар үтеп, каты токым булып үтәрме Илсур үз юлын, әллә йомшак катламнарга гына юлыгып, тиз алучан токым булып калырмы?

Дөрес, тиздән аңа да, бәлки, армия сафына басарга туры килер. Яше җитте. Ләкин инде еллар бөтенләй башка. Заманы бүтән. Ә каты катламнар, йомшак катламнар... һаман да бар ул!

Күрше скважинага яшь чаңгычы үзе генә китте. Карт оста белән яшьрәк оста, елмаешып, аның артыннан карап калдылар.

## Галимҗан Латыйп

### Болыт—батыр

Алтын-көмешкә биргесез
Байлык төяп,
Каян килеп чыктың әле,
Җиңел сөяк.

Ни арада җыеп алдың
Су парларын.
Мул күренә
Алып килгән
Олауларың.

Көткән идек,
Сагынган ла идек сине.
Төшләргә дә керә иде
Яңгыр җиле.

Кояш нурына манчылып,
Байлык ява,
Коеп ява,
Оеп ява.
Кислород парлары кебек
Җиңеләеп китә һава.

Ил-көннең хәстәрен күреп,
Дөбер-шатыр,
Дөбер-шатыр,
Йөкләреңне бушат, әйдә,
Болыт — батыр.

Сөенсеннәр
Әлсерәгән күгәрченнәр.
Шатланышып,
Гөлдер-гөлдер гөрләсеннәр.

Яшь бибиләр
Чупылдашып алсын әле.
Чәчәкләрдә салават күпере
Калсын әле.

Болыт — батыр,
Яудыр әйдә яңгырыңны,
Яудыр,
Яудыр.
Син яудырсаң,
Бар тереклек
Исән-саудыр.

Җир изге ул,
Тамчыларның кадерен белә.
Кырлар тулып
Алтын бөртек күтәрелә,
Күтәрелә,
Күтәрелә!

### Минем нәсел

Бабаларың кем дип сорасагыз,
Җир кешеләре булган, билгеле.
Типсә тимер өзгән,
Сукса ташны изгән,
Кирәк икән борган Иделне.

Яшәгән ул җиргә гашыйк булып,
Әсир булып җиргә яшәгән.
Кайгыларын җиңсә,
Шатлык килсә,
Төбе-тамыры белән яшәргән.

Канын биргән,
Хәтта жанын биргән,
Зарланмаган һич тә дөньядан.
Эчендәге тышта булган анын,
Беркемгә дә мәкер кормаган.

Кечеләрне бер дә кечерәйтмәгән,
Олыларны олы итә белгән.
Нинди генә йортка атласа да,
Сәлам биреп,
Аяк салып кергән.

Чукмар тотып,
Билгә кылыч тагып,
Чит җирләргә басып кермәгән.
Килсә дошман анын үз өстенә,
Мәйдан тоткан,
Курку белмәгән.

Наполеонын җиңгән,
Ике башлы
Албастысын алып ыргыткан.
Рейхстагка байрак кадаган да
Кайтыр якка таба юл тоткан.

Кимсетсәләр анын
Нәсел-ыруын,
Ул тау булып баскан,
Чикмәгән.
Җинаятьне,
Ялган һәм мәкерне,
Көчләүләрне гафу итмәгән.

Без килмешәк түгел бу дөньяга,
Үги бала түгел, беләмсез!
Нәсел-нәсәбәсез бер зат түгел,
Юлаучы да түгел, күрәмсез!

Без бу җирдә гөлләр үстерәбез,
Ихтирамга лаек халкыбыз.
Планетанын күпме гомере булса,
Шунын кадәр яшәү хакыбыз!

## Булат Сөләйманов

●

Кеше — гаҗәп. җирнең күкрәгенә басып,
Гашыйк булып, иңнәрендә зәңгәр күкне,
Айны, киек каз юлларын, йолдызларны —
Ничә гасыр йөрткән шушы авыр йөкне.

Егерменче гасыр, бөек минем гасыр.
Галәм көлми хәзер миннән күзләр кысып.
Җирнең тарту көчен җиңеп күккә мендем,
Йөрим йолдызларның күкрәгенә басып.

●

— Ни телисез?— дип сорадым мин гөлләрдән.
— Мәңге кояш көлеп торсын зәңгәр күктән!
— Җырлар отып алыр идек игеннәрдән, —
диде сабан тургайлары әллә каян.

— Ни телисең? — дип сорадым йөрәгемнән.
— Чиксез галәм киңлекләре чакыра мине!
— Тынычлык! — дип тавыш килде көнбатыштан,
Кырык биштә кайтмый калган солдатлардан.

●

Мин төп Себер татарымын чыгышым белән,
Гомер сөргән монда минем бабаларым.
Чал Иртышның үзе кебек борынгыдан
Яшәп килә монда Себер балалары.

Мин килмешәк түгел монда, туган җирем,
Гомерлеккә сине ташлап китә алмам.
Җирнең тарту көчен җиңдем, и Себерем,
Ләкин синең тарту көчең җиңә алмам.

1968

●

Чибәр кызлар назы кебек көньяк язы,
Ә шулай да сезне сагынып кабат кайтам.
Зәңгәр офык чатыр корган Себер күге,
Урманнарда муеллары чәчәк аткан.

Мин аларның кочагына кереп чумдым,
Мин бәхетле, чәчәк атты хыялларым.
Ә тегендә миңа никтер моңсу иде,
Син җитмәгән булган икән, туган ягым.

1968

●

Рас әйткәнсең гомерең юлда үтәр диеп,
Илләр гизәм дәрвиш кебек, күңелем ачык.
Минем гомерем гел юлларда үтсә үтсен,
Тик үтмәсен бер урында оя басып.

Бу дөньяда мин бер гади юлчы гына,
Юлда йөреп, юлда язам шигырьләрем.
Аларга да шуны телим, илләр гизеп,
Үзем кебек юлда гомер сөрүләрен.

1968

●

Бер ел үткән киткәнемә,
Әйләнеп кайттым бүген.
Сагынып иркә гөлемне,
Сагынып Себер күген.

Бер ел бит ул кеше өчен
Аз гына гомер түгел.
Ярсып-ярсып тибә йөрәк,
Талпына никтер күңел.

Урман эченнән үтешли
Бормалы юллар буйлап,
Хисләремне уртаклашып
Наратлар калды шаулап.

Җилләре дә йөгереп килеп
Битемнән үпкән була.
Юлың йомшак булсын дипме,
Ак карлар сипкән була.

Юл читендә куакларым
Ак гөлләр кемгә чиккән.
Каршыга килә авылым,
Ул әллә юлчы микән.

Бер ел үткән киткәнемә,
Әйләнеп кайттым бүген.
Саумы, минем туган авыл!
Исәнме, туган җирем!

◆ ◆ ◆

## Ибраһим Абдуллин

# ЯКТЫ КҮҢЕЛ

*Бер пәрдәле гыйбрәтле комедия*

**КАТНАШАЛАР:**

Нигъмәтулла — тракторчы. Гомеренең иң матур вакытын үткәрә — утыз бишләрдә. Күпләр аны, кыскартып, Нигъмәт дип йөртә, ә агач телләләр Нигъмәй генә диләр, тик олы яшьтәгеләр өчен, метрикада язылганча, Нигъмәтулла ул.

Әлфинур — аның хатыны. Савымчы. Газеталарда үзен еш кына мактап язалар, әмма кайнанасы бик үк мактап бетерми. Хәер, килен кайнанага бик сирәк ошый инде ул.

Гөлхаят — Нигъмәтулланың әнисе, Әлфинурның кайнанасы. Ашын ашаган, яшен яшәгән карчык, ләкин әле ул «семья ара» хәлләрдә дә күренекле генә роль уйный.

Бәдерхаят — Әлфинурның әнисе. Бик хуш күңелле карчык — аңа өстәлдә самовар җырлап торса, аяк астында оныклары шыбырдап йөрсә, ике дөнья бер кәнди.

Шәйбәк — ике йорт арасындагы читән аша сикереп кереп йөри торган күрше.

Мөбәшшир — кайдан һәм кем икәнлеге пьесаның азагына чаклы беленми.

Вакыйга безнең көннәрдә авылда бара.

Авыл башында, чылтырап аккан инеш буенда, алты почмаклы мәһабәт өй тора. Мондый йортлар хәзер һәр авылда гына түгел, һәр урамда да дистәләгән. Йортның нигезе таштан, түбәсе калай, дөнья ачыграк күренсен өчен, тәрәзәләре зур итеп, күп итеп эшләнгән. Тәрәзә яңаклары, челтәр пәрдә сымак, бик нәфис сырланып, иренми ясалган.

Берничә көн үтәр һәм бәхетле гаилә, чыр-чу килеп, шушы өйгә күченер, шаулап, тальян уйнап өй котлау үткәрерләр, тәрәзә төпләренә гөлләр куелыр, акшарлаган морҗадан, ефәк шлейф булып, күк төтен күккә күтәрелер. Кыскасы, яңа йортта яңа, матур тормыш башланыр, ә хәзергә... әле кемдер тәрәзә яңакларын буяп маташа, кемнәрдер түбә ябып яталар. Үтеп-сүтеп йөрүчеләр, бер генә минутка тукталып, башларын күтәреп, эшләпәләрен, кепкаларын арткарак этәреп, өйгә сокланып карап тора.

... — Ну шәп булып чыкты да бу Нигъмәй. Валлаһи газим, патша да мондый сарайда яшәмәгәндер.

... — Патша яшәвен яшәмәгәндер дә, әмма менә Нигъмәтулланың атасы Хәкимулланың төшенә дә кермәгәндер. Ындыр артына бура буратып кына куйган иде, сугыш чыкты. Сугыштан кайтып бурасын күчереп салыйм гына дип изаланып йөргәндә контузия аяктан екты да тәки шуннан мантый алмады мәрхүмең.

... — Әлеге дә баягы сугыш. Минем дә өч абыем, җизнәм ятып калды бит...

... — Нигъмәтулла кайтып килә түгелме соң?

... — Нигәдер танавын салындырган әле.

... — Әссәләмәгаләйкүм, Нигъмәтулла улым? Сихәтлекме?

Нигъмәт. Вәгаләйкүм, Зарифҗан агай.

... — Сәлам, Нигъмәй. Нигә балтаң суга төште әле болай? Мондый өй өлгертсәм — минем түбә күккә тияр иде хәзер.

Нигъмәт. Түбәне буярга буяу табалмый йөдәп беттем, Шәрәфи. Бармаган җирем, какмаган ишегем калмады. Кайчан барсы да магазинда булыр. Тартырга бармы? Әй, син ташладың бит әле.

... — Булыр әле заман, кайгырма. Яңа йорт салучылар ишәеп китте бит, буяу эшләп өлгертмиләрдер. Кара, өй котлаудан мине калдырма. (*Көлеп.*) Корьәнен дә үзем укырмын. Бәләкәй чакта картинәй аятелкөрси өйрәткән иде.

Зарифҗан карт. Аятелкөрсине өй котлаганда түгел, шайтаннар качырыр өчен укыйлар, Шәрифҗан, белмәсәң адәм көлдермә, белсәң диннән көлмә. Киттек әйдә.

Нигъмәт (*түбә ябучыларга күтәрелеп карый*). Агайлар, кайчан эшегез бетә?

Өй түбәсеннән тавыш. Кичкә булмаса да, иртәгә төшкә сыйпап куячакбыз.

Икенче тавыш. Яртың өстәлдә булсын, Нигъмәй туган.

Беренче тавыш. Бар белгәнең ярты булды инде.

Икенче тавыш. Шаярып кына әйттем лә инде, Галимҗан агай.

Беренче тавыш. Ә син эш вакытында аракы хакында шаярып та, уйнап та сөйләшмә. Нигъмәт, буявың, әлифең әзерме? Меңгән рәттән буяп та төшәр идек.

Нигъмәт. Әлиф юнәттем, ә менә буяу табалмыйм. Кермәгән ишегем-тишегем калмады...

Беренче тавыш. Бер дә булмаса, әлиф буяп төшәрбез. Яңгыр явып китсә, тутыгуы бар.

Нигъмәт (*уйланып*). Барометр яңгырга күрсәтеп тора шул әле... Кайдан буяу табарга инде? Икеләтә түләп булса да алыр идем...

Бу сүзләрне аның күршесе Шәйбәк ишетеп тора. Ул, карап торуга, гамьсез, пошмас җан.

Шәйбәк (*сызгыруыннан туктап*). Өй салуның ние бар, бурасы да чутласы...

Нигъмәт. Иң авыры чутлашуы-исәпләшүе шул аның, Шәйбәк күрше.

Шәйбәк. Ә шулай да күпмегә баса? Дөресен генә.

Нигъмәт. Кем бөртекләп исәпләгән әле аны. Түбәсе буялмаган, капка эшләнеп бетмәгән...

Шәйбәк. Ә шулай да? Примерны?

Нигъмәт. Өч меңгә тартыр.

Шәйбәк. Әллә-лә-лә-ләә... Яңа бер мең кушсаң, «Москвич» дигән сүз бит бу. Ә «ФИАТ» күпме торыр икән, ишеткәнең юкмы?

Нигъмәт. Кызыксынганым юк. Минем коляскалы мотоциклым бар, шул җиткән.

Шәйбәк. Юкка. Шәп машина булачак диләр. «ФИАТ» чыга башлау белән үземнең консерва банкасын — «Запорожец»ны очырам да «ФИАТ» алам. Семья да ишәйде...

Нигъмәт. Алырсың, алырсың, ә хәзер син миңа түбә буярга буяу табып бир.

Шәйбәк. Була ул. Ә нинди төскә буямакчы буласың? Кызылга буят. Яратам мин кызыл төсне.

Нигъмәт. Ә миңа яшел ошый.

Шәйбәк. Беләсеңме, күрше, син аның бер ягын яшелгә, икенчесен кызылга буят. Ә нигә көләсең? Хәзер бик модный мода ул. Минем Уфадагы бҗам квартирасының дүрт стенасын дүрт төскә буяткан.

Бер ягы яшел, икенчесе — кызыл, өченчесе — чия көрән, дүртенчесе — зәңгәр, идәне памидур, түшәме әфлисун төсендә. Бераз төшереп алгач, кайда идән, кайда түшәм икәнлекне бутый башлыйсың. Давай, син дә шулай буят әле, буяу табып бирәм. Ә нигә без модадан артта калырга тиешбез!..

Нигъмәт. Ә кайчан буяу табаласың, Шәйбәк?

Шәйбәк. Акчаң булса, хет бүген. Ничә кило кирәк?

Нигъмәт. Ике кат буяганда кырык кына китәр инде.

Шәйбәк. Икешәр сумнан, сиксән була.

Нигъмәт. Ә нигә ике сумнан? Магазинда бит...

Шәйбәк. Ә син тап магазиннан.

Нигъмәт. Кемдә ул?

Шәйбәк. Анысы минем эш.

Нигъмәт. Ихтимал...

Шәйбәк. Нәрсә — ихтимал?

Нигъмәт. Ихтимал...

Шәйбәк. Ихтимал, урлангандыр, дип әйтмәкче буласыңмы? Ә Шәйбәкне син кемгә саныйсың?

Нигъмәт. Шәп шоферга, игелекле күршегә саныйм.

Шәйбәк. Санагач?

Нигъмәт. Аңла, мин йортымның һәр казыгын, һәр кадагын хәләл акчама кактым.

Шәйбәк. Ә Шәйбәк күршең сине харамлашырга өйрәтәме? Хуш. Миңа әле буяу кирәкми. Минем түбәм шифр, кар да, яңгыр да нипачум.

Нигъмәт. Шәйбәк, кызмале...

Шәйбәк. Кызма дип, бәй, тартырга бармы? Син аңа кул сузасың, ә ул терсәгең бирә. Прәме кызык кеше син, Нигъмәй.

Нигъмәт. Урланган буяу булмасын дип шикләнәм мин, Шәйбәк дус.

Шәйбәк. Ә син Шәйбәкнең башы ике дип беләсеңме? Аның да биш баласы бар, ул да атлы казак түгел. Буйдак булганда да Шәйбәк кешенең энәсенә дә тимәде. Шәйбәкнең вөҗданы саф, биографиясе чиптиста. Анкета тутырам икән, «юк, юк, юк» дип язып тик барам. Вәт кем ул синең күршең беренче класслы шофер Шәйбәк Солтанморатович Шаһисолтанов.

Нигъмәт *(иплән кенә)*. Кайда, кемдә ул буяу?

Шәйбәк. Кайда икәнен беләм, кемдә икәнен төртеп кенә әйтәлмим. Чөнки мин үзем дә белмим. Стансада кода яши. Шуның танышы сата.

Нигъмәт. Алай булганда инде әллә... Тик ике сумга кыймммә бит әле... Минем ул чаклы акча да юк...

Шәйбәк. Әйттем мин сиңа шифр яп дип. Әнә минем түбәне яңгыр да, кар да алдыралмый бит. Ә сиңа кешедән уздырырга кирәк. Уздырасын килгән икән, әйдә уздыр. Ә мин тирмәнгә киттем. Балалар арыш икмәген сагынган. Вәт бит дөньялар. Без арыш икмәгенә дә тилмереп үстек, ә алар, бодай күмәченнән туеп, арыш икмәге сорый. Имеш, арыш икмәгенең витамины күп. Малайлар шул, көчле булып үсәргә телиләр. Ярый, гаепләмә, мин әйттем, син чиктең.

Нигъмәт. Шәйбәк күрше, әйдә, югәнлә машинаңны. Магаричын җәлләмәм.

Шәйбәк. Ә син Шәйбәк күршеңне магарич өчен йөри дип уйлыйсыңмы әллә? Алайса, хуш, мин тирмәнгә киттем.

Нигъмәт. Ярый инде, юк-барга да үпкәләп торма.

Шәйбәк. Үпкәләмим, ә дөресен сөйлим. Шәйбәк Солтанморатович Шаһисолтанов кеше күңелен күрер өчен яратылган ул. Миңа берәрсенә яхшылык эшләмәсәм, ашаганым аш, эчкәнем су түгел. Нәселебез белән шулай без. Ә син магарич дип хәтерне калдырасың.

Нигъмәт. Ярый инде, онытыйк. Безгә бит гомергә күрше булып яшәргә.

Шәйбәк. И яшәрбез дә. Күрше хакы — тәнре хакы, ди торган иде минем мәрхүм әтием. Үзе ач утырса утырды, әмма соңгы телем икмәген күршесенә кертеп бирде. Киттек.

Нигъмәт. Әлфинур, син өйдәме? Мин стансага буяу алырга киттем.

Кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә өйдән Нигъмәтнең хатыны Әлфинур чыга.

Әлфинур. Инде котылыр көнем бармы бу өйдән? Ярты картайдым.

Нигъмәт. Түзгән түз инде. Берәр атнадан шаулатып өй котлау үткәрербез дә...

Шәйбәк. Яңа өйләнешкән егет белән кыз шикелле гөрелдәшепсерләшеп кенә яшәрбез диген. Мәнә безнең яңа өйгә күчкәнгә дүртенче ел, бер-беребезгә авыр сулаганыбыз да юк.

Шул вакыт бернечә урыннан ямалган җиз комган тотып Гөлхаят карчык керә, бер як читкә китеп юына башлый.

Гөлхаят. Бисмилла ирахман ирахим... Чәнчелеп китсен, комганга салкын су салганмын икән...

Шәйбәк. Яңа өйнең тупсасын атлаганда бер-беребезгә сүз бирештек — искергән, алама гореф-гадәтләрне ишек артында калдырырга и беркайчан да кертмәскә.

Гөлхаят (*бу сүзләрне ишетеп*). Әстәгафирулла тәүбә, әллә корьән дә укытмадыгызмы, Шәйһибәк улым?

Шәйбәк. Укыттык, дөресрәге, бергәләшеп укыдык. Бер-ике рюмка төшереп алгач, «Синдә генә икән, синдә генә микән, күңелем» дип җырлап та җибәрдек. Мәнә ул безнең корьән, Гөлхаят инәй. Киттек, Нигъмәт дус. (*Нигъмәт белән Шәйбәк чыга.*)

Гөлхаят. Лә илаһа иллалла, лә илаһа иллалла, көфер сүз тыңлаган мин көфер. Хәзерге яшьләр өчен алла да юк, мулла да. Килен, комганга җылы су салып бирче, таһарәт алырга вакыт.

Әлфинур. Хәзер, кайнанам. (*Комганны алып, Әлфинур алачык ягына китә башлый.*)

Гөлхаят. Килен... киленне кайнана туфрагыннан яратылган диләр, киләле. Ишеттеңме, югары оч тыңкыш Әхмәдулланың өч баш сарыгын бер көнне бүре буып ташлаган, ди. Сигез баш каз бәбкәсен карчыга-тилгән чүпләп киткән, уналты чебешен ләтчә буып үтергән, ди. Ни өчен дисеңме? Алланы санга сукмаганы, йоланы онытканы өчен. Ялан тикле йорт салдырып керде, ә тавык суеп корьән укыта белмәде, юньсез. Акырышып-бакырышып көмешкә чөмерделәр дә шуның белән аллаһы әкбәр...

Әлфинурның энисе Бәдерхаят керә.

Бәдерхаят. Һи-ини... кодагый, тузга язмаганны сөйләп утырасың да инде. Тыңкыш Әхмәдулла хатыны Среднеазиягә кызы-кияве янына кунакка киткәч, үзе ике сарыгын сатып атна-ун көн буе умарталыкта эчеп, акчага кәрт уйнап ятты бит.

Гөлхаят. Ә ул ни өчен эчеп яткан дип беләсең, кодагый? Алладан җәяүләп качканы өчен. Рәсүлебез Мөхәммәт, минем өммәтемдәге бәндәләргә аракы түгел, партфейн да эчәргә харам, дигән. Оҗмахка кергәч, Кәүсәр чишмәсеннән туйганчы эчеп ятырлар, сүз әйтүче дә, акча сораучы да булмас, дигән.

Әлфинур (*комган белән су кертә*). Кайнанам, син теләсәң нишлә, әмма минем ризалыгым юк.

Гөлхаят. Куй, киленкәй, алай сөйләмә. Яңа өйдә корьән укытмасаң, почмакларына пәри оялый, йорт иясе чыгып кача, өйнең бәрәкәте китә, мал-туарга зыян килә ул.

Әлфинур. Кайнанам, ишетмәдеңмени? Шаһибәк күрше, яңа өйгә иске гореф-гадәтләрне алып керергә ярамый, диде бит. Без дә алып керәчәк түгелбез. *(Чыга.)*

Гөлхаят *(сикереп торып)*. Ә мин әйтәм: алып керәбез. Алласыз кеше — имансыз кеше ул. Ә имансыз кеше...

Бәдерхаят. Куй, кодагый, корьән укытам дип яшьләрне адәм мәсхәрәсенә калдырмыйк. Улың тирә-якка дан тоткан тракторчы, депутат, киленең активтан активка йөрүче орденлы савымчы.

Гөлхаят. Бәрәч, орденлы кешегә алла кирәкми микәнни? Әнә, күпер буе Тимеркәй заманында тракторчы гына түгел, дәһриләр башлыгы иде. Ике мәчетнең манарасын үз куллары белән аударды, ә хәзер, пенсиягә чыгып алгач, мәчет салдырырга кирәк дип тамга җыеп, мөфтигә барырга җыена, ди. Үкчәңә әҗәл килеп басса, алла исеңә төшә ул, нибуч.

Бәдерхаят. Һи-и, кодагый, суфый суган җыймас, җыйса кабыгын да куймас, дигәндәй, үзең дә быелтырлы-быелллы гына ураза тота башладың бит.

Гөлхаят. Корьәнне, кодагый...

Бәдерхаят. Һи-и кодагый, синең белән минем корьәнне ачып караганыбыз да юк бит, карасак та әлепне таяк дип тә белмибез. Анда өтер дә нокта, нокта да өтер. Булмаса, яшьләр эшенә кысылып, кәефләрен кырып йөремик. Хәзер алар дөньясы, күңелләренә ничек ошый, шулай яши бирсеннәр. Фәрит, Фәрит, урамга чыкма, машина килә. *(Чыга.)*

Гөлхаят. Алар дөньясы дип, без дә әле теге дөньяга китәргә җыенмыйбыз, иншалла. Авызым тулы теш, мунча керсәм, пар беткәнче чабынам... *(Комганнан су коеп, юына башлый.)* Әгузебиллаһи минашайтан разим... чәнчелеп китсен, эссе су салган бит бу игелексез. Килен, комганга салкын су өстә... Әллә күрше-мазар күрмәгәндә тәһарәт алмый гына укып ташлыйм микән?..

Бер көн үткән. Йорт түбәсен кызылга буятканнан соң, яңа йорт башына кызыл яулык бәйләгән яшь кызга охшап тора. Үтеп-сүтеп йөрүчеләр теләсәләр, теләмәсәләр дә, шул яңа, купшы йортка карап сокланалар.

... — Һа-ай, булдыклы булып чыкты бу Хәкимулла малае. Элек мондый йорт Афзалла байда да юк иде.

... — Элек, элек, нәрсә һаман элекке белән чагыштырасың, Зарифҗан агай. Элекке булган, черегән, беткән, тиленне әрәм итеп аны искә алырга да ярамый хәзер. Алга карарга кирәк.

... — Артка карап гыйбрәт ал, алга карап шөһрәт ал, дигәннәр борынгылар, Шәрифҗан улым.

... — Барыбер, артка түгел, алга карарга кирәк. Үткән — тарих өчен, киләчәк балаларыбыз өчен.

... — Нигъмәтулла кайтып килә түгелме соң?

... — Үзе. Авызы колагына җиткән. Сәлам, Нигъмәй! Я, кайчан өй котлатасың? Мин, сыерны сатып, пианино алып куйдым инде.

Нигъмәт. Алдагы атнага дип торам. Ишек алларын тазартып чыгарга кирәк. Бал да әчеп чыксын. Быел минем умарталар балны шәп бирә бит.

... — Кара, тамак аерма.

Нигъмәт. Табынның түрендә, аякчы булырсың, Шәриф.

... — Их, яратам өй котлау табыннарын...

Нигъмәт ялгыз кала, өенә сокланып карап тора.

**Нигъмәт.** Сәер кеше син, Шәрифҗан. Кем яңа өйне котлауны яратмасын инде... Кайчан бөтен авылда, бөтен авылларда да өйләр яңарып икән? Минеке сымак, таш нигезле, тимер түбәле, зур сигез тәрәзәле, пыяла террасалы, аерым кухнялы... ә без бит җиде-сигез җан өч тәрәзәле, тәбәнәк түшәмле тавык кетәклегендә чыр-чу килеп үстек. Җитмәсә, кышларын өйгә бозау, сарык бәрәннәре кертә торган идек...

*Нигъмәт янына хатыны Әлфинур килә.*

**Әлфинур.** Нәрсә авызыңны ерып торасың, Нигъмәт? Яңа өең бик каты ошыймы әллә?

**Нигъмәт.** Ә сиңа ошамыймыни, Әлфинуркаем?

**Әлфинур.** Исәнлек-саулык, бәхет-шатлык белән яшәргә язсын.

**Нигъмәт.** Яңа өйне котлап әллә...

**Әлфинур.** Нәрсә — әллә?

**Нигъмәт.** Янә бер малай мин әйтәм... Ул чагында ике кыз, ике малай булыр иде димен...

**Әлфинур.** Өчәүне кеше итсәң дә бик таманга килер әле, карткаем.

**Нигъмәт.** Ә нигә кеше итмәскә! Ата-аналарына ошасалар...

**Әлфинур.** Мактанма. Яратмаганым — мактанчык кеше.

**Нигъмәт.** Мактанмыйм, дөресен әйтәм. Аталары тирә-якка шөһрәт тоткан тракторчы, аналары — атаклы савымчы. Әйтергә яраса, дөньяның кендеге безгә бәйләнгән, Әлфинуркаем. Я, өй котларга нича кеше чакырабыз? Күңелеңнән исәпләп карадыңмы?

**Әлфинур.** Әниең... кайнанам, корьән укытырга кирәк, дип изаланып йөри бит әле, Нигъмәт.

**Нигъмәт** *(бөгелә-сыгыла көлә).* Корьән?.. Син нәрсә, акылың табаныңа төштеме әллә? «Сәнәк»кә эләгәсең киләме? *(Көлүеннән туктап.)* Ә син нәрсә дидең?

**Әлфинур.** Иске гореф-гадәтләрне яңа өйгә алып керәчәгебез юк, дидем.

**Нигъмәт.** Дөрес әйткәнсең.

**Әлфинур.** Әйтүен дөрес әйттем дә...

**Нигъмәт.** Тел төбендә калдырма, әйтеп бетер.

**Әлфинур.** Корьән укыттырмасалар, Сибайдагы кияүләремә китәм дә барам, дип сөйләнә икән.

**Нигъмәт.** Бар әйт әле үзенә. Чыксын. Политмассовый эш үткәрәм.

**Әлфинур.** Иплән кенә, йомшак кына итеп әйт инде, Нигъмәт, ату син бик кискен кеше.

**Нигъмәт.** Анысын үзем белермен.

*Әлфинур өйгә керә башлый да кире борыла.*

**Әлфинур.** Кыекны әйтәм, бигрәк матур, фермадан ук күзеннен явын алырлык булып күренеп-балкып тора. Шундый ачык кызыл буяуны кайдан таптыгыз?

**Нигъмәт.** Әллә, мин сатучының үзен күрмәдем. Шәйбәк барып йөрде.

**Әлфинур.** Кояшта тиз уңмаса инде. Үтә кызыл тиз уңар, диләр бит.

**Нигъмәт.** Әлифы шәп, натуральный, тиз уңмаска тиеш.

**Яшь малай тавышы.** Әлфинур апа, сине завферма фермага төшсен, ди.

**Әлфинур.** Әле генә фермадан кайттым ич. Нигә кирәк булдым икән?

**Яшь малай тавышы.** Анысын миңа әйтмәде. Әлфинур апаң как штык фермага төшеп җитсен, диде. Әллә «Мәфрүрә» бозаулап маташа, ди.

Әлфинур. «Мәфрурә»? Ветсанитар аны кысыр дип йөри иде бит. Кая, йөгерим әле. *(Әлфинур ашыгып чыгып китә.)*

Нигъмәт. Миңа да тимерлектән урап килергә кирәк...

Гөлхаят карчык күренә, кырыкмаса кырык урыннан ямалган җиз комганыннан су агызып, юына башлый.

Гөлхаят. Бисмилла ирахман ирахим... Чәнчелеп китсен, комганга тагын салкын су койганнар, йөзләре каралар. Әллә үч итеп салалар инде шул иманың качардай салкын суны... Килен!

Нигъмәт *(борылып, әнисен күреп)*. Әни, көн туа, син туасың, синең арттан сукрану-каргану туа. Ичмасам, яңа йортка күчкәч калдыр инде шул иске гадәтләреңне.

Гөлхаят. Менә Сибайга күчеп китсәм, берьюлы тынарсың әле. Бертуган әниеңне күпсенсәң, кайнанаң белән чәкелдәшеп яшәрсең.

Нигъмәт. Ә сиңа монда өй кысанмыни? Ике кодагыйга ялан кадәр булмә бирдем...

Гөлхаят. Бүлмә ялан кадәр булудамыни ул?

Нигъмәт. Ә сиңа тагы нәрсә җитми? Бала-чаганы кайнана, малтуарны үзебез карыйбыз. Синең бар белгәнең тисбе тарту да күргән төшләреңне сөйләп чәй эчү.

Гөлхаят. Шул йортка күчкәннән бирле төшем төш түгел, гел саташып, бастырылып чыгам. Бүген иртән, кәтү китәр алдыннан, шулай сул ягыма борылып яткан идем, төшемә әтиең мәрхүм керде. Күземә мөлдерәп караган да иреннәрен селкетеп тик тора. Хәер өмет итәдер инде, мәрхүмең. Корьән чыкканны...

Нигъмәт *(кызып)*. Әни!.. *(Кинәт басылып.)* Әни, аңла... Нинди заманда яшәгәнеңне аңла. Кем анасы икәнеңне аңла. Ә әтиебез кем иде? Герой-танкист...

Гөлхаят. Ярый, ярый, ярый... Акыллы сүзләреңне үзеңдә калдырып тор. Миңа юллык акча бир дә иртәгә таңнан ук Сибаема китәм дә барам.

Нигъмәт. Әни... бу бит кеше көлдерү, бу бит бездән көлү...

Гөлхаят. Ярый, ярый, ярый, мин киткәч көлүче дә, елаучы да булмас, тынычланып калырсың. *(Комганыннан су коя башлый.)* Әгузебисмиллараҳман рахим...

Нигъмәт. Әни, син мине тыңлап бетер әле...

Гөлхаят. Йомырка тавыкны өйрәтми. Әнә, бар, үз балаларыңны үгетлә.

Нигъмәт. Соң Әлфинурның әнисе корьәнен дә, намазын да уйлап та бирми. Көне буе оныклары белән, чебеш-бәбкә белән чыр-чу килеп тик йөри. Ә син...

Гөлхаят. Ярый, ярый, ярый, үз акылым үземә җиткән. Кодагый дәһри дип, мине дә дәһри ясарга тырышма, әлгазием билла, минем мәңге-бакый җәһәннәмдә янасым килми. Йөзем-хөрмә генә ашап оҗмахта яшисем килә минем.

Нигъмәт. Соң әле дә сандыгың тулы тәм-том да җиләк-җимеш бит инде...

Гөлхаят. Ярый, ярый, ярый, минем сандыгымны тикшермә, ана, бар, тракторыңа атлан да эшеңдә бул. Ә иртәгә мине стансага илтеп куй. Вәт. *(Өйгә кереп китә.)*

Нигъмәт. Их, әни, әти мәрхүм синең бу кыланышларыңны белсә, каберендә үрле-кырлы сикереп куяр иде... Шул саескан Мотыйгулла картның карчыгы боза аны. Таң белән чыгып китә дә олага бит... Хәзер нишләргә инде моның белән? Әллә Сибайга илтеп куяргамы? Анда да кызы белән киявенең тенкәсенә тиеп бетәчәк... Ә бит моннан ике-өч ел элек кенә «Хәтирә»гә биеп, «Кара тавык»ка җырлап йөргән бер гамьсез карчык иде. Ә хәзер бар белгәне оҗмах та җәһәннәм, алла да

мулла... Әлфинур сыерларыннан башканы, мин трактордан артыкны белмәдем шул. Ә бит аның балаларга да йогынтысы тия башлавы бар. Кичә кече улым бер бармагы белән учына «әлип-би-ти-си» дип төртеп утыра иде инде. Юк, болай ярамый, хатаны тизрәк төзәтергә кирәк. Тизрәк? Ә ничек төзәтергә соң аны?..

Шәйбәк керә. Өйгә карап сызгырып тора.

Шәйбәк. Нинди уйлар диңгезенә чумдың, күрше?

Нигъмәт. Һә-әй...

Шәйбәк. Яңа өйгә кайгы-хәсрәт белән керергә ярамый, күрше, ялт итеп торсын.

Нигъмәт. Әни карчык теңкәгә тия. Өй котлап корьән укытыйк, ди.

Шәйбәк. Ә бездә корьән укый белә торган кеше бармыни?

Нигъмәт. Анысы табылыр да ул...

Шәйбәк. Табылгач! Тотсын да укытсын.

Нигъмәт. Син уйнап сөйлисеңме, уйлапмы?

Шәйбәк. Әлбәттә, уйлап. Соң җитмештән узган карчыкка диннең зарары турында лекция укытып булмый бит инде. Укысаң да барыбер бер колагыннан керәчәк, икенчесеннән выжлап чыгып китәчәк.

Нигъмәт. Ә син үзеңнең нинди заманда яшәвеңне беләсеңме? Совет властеның илле еллыкларын бәйрәм иттек бит инде.

Шәйбәк. Шулай да аллага ышанучыларны орып-бәреп кенә үтереп булмый бит, күрше.

Нигъмәт. Анысы шулай...

Шәйбәк. Шулай булгач? Әйдә, үзенчә эшли бирсен. Ә син белмә дә, күрмә дә.

Нигъмәт. Ничек инде ул — белмә дә, күрмә дә? Үз йортында эшләнгән эшне дә белмәгәч...

Шәйбәк. Ә син тот та берәр көнгә командировкага кит. Я Уфага, я Сибайга. Запчасть юлларгамы, шайтан эзләргәме — сәбәбен табарсың. Ә карчыклар син юкта үз эшләрен эшләп алырлар. Бүре дә тук, сарык та исән.

Нигъмәт. Ә Әлфинур? Без бит икебез дә партиягә керергә җыенабыз.

Шәйбәк. Аны да үзең белән алып кит.

Нигъмәт. Юк, бармый. Бу күз буяу, вөҗданыңны алдау булачак.

Шәйбәк. Ул чагында инде әни карчыгыңны үгетлә. Тик, һай-ай, күндерә алырсың микән? Картлар алар бала-чагадан да тискәрерәк булалар. Ә түбә буявы шәп булып чыкты бит, ә? Ярый, мин гаражга барып киләм әле. Арьяк Сәмигулла агайга бүрәнә китерергә кушкан иделәр. Кайчан барырга икән? Ул да бит йорт бетерергә чамалый. *(Чыга.)*

Нигъмәт. Командировка алган бул да... Юк, юк, юл куя башласаң, алар башка менеп атланачаклар. Ату хәзер дингә каршы көрәшне бөтенләй оныттылар. Елга бер тапкыр я ураза алдыннан, я корбан бәйрәме җитәрәк районнан килеп бер лекция укып китәләр дә шуның белән вәссәләм. Ә монда карт-корыларың ел әйләнәсенә динне мактап, вәгазь укый йөри. Юк, болай ярамый, ярамый...

Бәдерхаят карчык керә.

Бәдерхаят. Тип-тип-тип-тип... Кара чебешем әллә кайда булды. Әллә тилгән типте инде, рәхмәт төшкере. Гел башкалардан аерылып йөри торган иде шул. Юкка гына, аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, дип әйтмәгәннәр борынгылар. Тип-тип-тип.

Гөлхаят керә.

Гөлхаят. Тилгән дә тибәр, бүре дә ашар... өйнең коты китәр, ашның тәме китәр диган изге китапта... Әнә югары оч тыңкыш Әхмәдулланың биш сарыгын бер төнне бүре буып киткән...

Нигъмәт. Җитәр! *(Чыгып китә.)*

Гөлхаят. Күрдеңме, кодагый? Монача әнисенә каты суламаган бала хәзер кайсылай җикереп кычкыра? Бөтенесе дә алла тәгаләне оныту галәмәте ул. Ахырызаман алдыннан ата улны, ана кызны белмәс, дип юкка язмаганнар иске китапта. Кодагый, әллә син дә минем белән өйлә намазы укып аласыңмы? Без хәзер синең белән бүген бар, иртәгә юк, бу дөнья белән мавыгып, теге дөньяны да онытырга ярамый. Без бу дөньяга кунакка гына килгәнбез...

Бәдерхаят. Әлләче, кодагый, кунакка килсәм дә, бик әйбәт кунак итәләр әле, бер дә генә китәсем килми. Яңа өйгә күчкәч, тыннарым иркенәеп, яшәреп киттем. Теге өйдә йоклый алмый, таң атканчы ызаланып чыга торган идем. Кичә бу өйдә башымны мендәргә төрттү белән оедым да киттем. Күземне ачсам, кояш чыгып килә иде. Ичмасам, бер төш күрсәм...

Гөлхаят. Ә мин төне буе саташып, бастырылып чыктым. Имеш, битемне сакал баскан икән, имеш...

Бәдерхаят. Куйчы, кодагый, тузга язмаганны сөйләмә. Әйдә, чәй яңарттым, кара-каршы утырып, яшьлекне искә төшереп, рәхәтләнеп тирләп-пешеп чәй эчик. *(Карлыккан тавыш белән җырлый.)*

> Грузинский чәй чәйнектә,
> Өстәлдә башкорт балы,
> Янында жаның сөйгәне,—
> Башка ни кирәк тагы?

Бу Сәйфи Кудаш дигәннәре би-ик чәй эчәргә ярата торган кешедер, ахры, рәхмәт төшкере.

Гөлхаят. Яшең җитмешне ашкач, шигырь-мигыр тыңлап, җыртакмак җырлап йөрергә оялыр идең, кодагый.

Бәдерхаят. Күңелең көр, тамагың тук булгач, йөзне үткәч тә җырлыйсың ул, кодагый. *(Чыга башлый.)*

Гөлхаят. Кодагый, каты сүз әйткән чакларым булган булса, нахакка рәнҗеткән булсам, зинһар, ярлыка инде, кенә куып, ачу тотып яшәмә.

Бәдерхаят. Бәй, бәй, бәй, кодагый, нишләп бәхилләшкәндәге сымак сөйләнәсең әле?

Гөлхаят. Бәхилләшәм шул, кодагый, китәм. Еракка. Дөнья читенә. *(Күңеле тула.)* Сибайга. Кызым белән киявем янына.

Бәдерхаят. Куй, куй, тузга язмаганны сөйләмә. Сине моннан бирәү дә кумый. Икебезгә бер бүлмә, бер самовар, өй тулы бала-чага, ишек алды тулы кош-корт... Урам аша чыксаң, чылтырап инеш агып ята, бакча артында гына умарталык... Мондый рәхәтлекне ташлап мин Сибайга түгел, Мәскәүнең үзенә дә китәчәк түгелмен.

Гөлхаят. Ярый ла синең монда кызың белән киявең...

Бәдерхаят. Һи-нии, кодагый, әйтерсең, алар сине рәнҗетеп яшиләр. Ни теләсәң, шуны ашыйсың, ни теләсәң, шуны киясең, көне буе урам кыдырып йөрисең... берсе бер, ичмасам, бер сүз әйтсә иде...

Гөлхаят. Аларның сүз әйтүләрендәмени, аналарының сүзләрен сүз итмәгәч. Яңа өйгә күчкәч авылдагы бөтен карт-корыны җыеп корьән укытырмын дип нәзер әйткән идем, ә алар... *(Күңеле тула).* Теләгәненне ашаудамыни ул, кодагый, ашаганың таш булып утыргач... *(Чыга.)*

Бәдерхаят. Әзрәк кош-корт карасаң, бала-чаганың күлмәкштанын юыштыргаласаң, әллә ашаганың аш булып та сеңәр иде дә бит, кодагый...

Әлфинур. Кысыр дигән сыерыбыз игез бозау бозаулады, әни. Икесе дә аналарына охшаш, коба...

Бәдерхаят. Кызым, юл куй, юл куй, усал килен дигән исемең чыкмасын.

Әлфинур. Ә усал килен булып минем нишләгәнем бар, әни?

Бәдерхаят. Укытсын әйдә шул корьәнен. Аннан бер җиребез дә кыйгаймас.

Әлфинур. Эш кыйгаюда, кителүдә түгел, әни, ә принципта.

Бәдерхаят. Нәрсәдә? Син минем белән кеше аңлый торган телдә сөйләш.

Әлфинур. Яхшы, без бүген яңа өй котлатып корьән укытырга рөхсәт итәрбез, иртәгә өйдә гает укырга, ә иртәдән соң мәчет салырга...

Бәдерхаят. Китәм ди бит.

Әлфинур. Китсен, тыймыйм.

Бәдерхаят. Ике тәкә башы бер казанга сыймаган шикелле, ике кодагый да бер йортка килешмәде, дип гайбәт сатарлар. Бер дә үз әнисен түгел, кайнанасын куып җибәрде, дип яман атыңны чыгарырлар... Мин синең өчен көяләнәм, кызыкаем.

Әлфинур. Юкка көяләнәсең, әни. Халык минем кемлегемне белә.

Бәдерхаят. Алай димә, кызыкаем, халыкның төрлесе бар. Берәүләр, гайбәт ишетсә, саруы кайный башлый, икенчеләр гайбәтне майлы аштан да артыграк күрә.

Әлфинур. Әни, мин гайбәттән курка торган кеше түгел. Үгетләмә, өркетмә. *(Өйгә керә.)*

Бәдерхаят. Гайбәттән дә куркырга кирәк ул, кызым. Курыкмасаң да сак булырга кирәк. Әнә Куян очы Сабирҗан кеше сүзенә карап кына бер гаепсез хатынын аерып җибәрде... Гайбәт тилебәрән орлыгы белән бер ул, кайсы чак бик акыллы кешеләрне дә акылга җиңеләйтеп куя... *(Капкадан чыгып китә.)* Тип-тип-тип.

Нигъмәт керә. Ачулы.

Нигъмәт. Шул пүчтәк нәрсәне өч көн маташтыра бит.

Әлфинур *(керәп)*. Ә минем «Мәфрүрә» ике бозау бозаулады, Нигъмәт. Ә ветсанитар аны кысыр дип йөргән иде.

Нигъмәт. Ә минем трактор һаман бәйдә тора. «Сельхозтехника»га барып килми булмый инде.

Әлфинур. Әллә, мин әйтәм, икәүләп барып киләбезме?

Нигъмәт. Ә анда сиңа нәрсә бар?

Әлфинур. Апамны күптән күргәнем юк. Үпкәләп ята торгандыр.

Нигъмәт. Син миннән нәрсәдер яшерәсең, Әлфинур.

Әлфинур. Минем усал килен исемен күтәрәсем килми, Нигъмәт.

Нигъмәт. Ә кем сине усал килен ди?

Әлфинур. Әниең... кайнанам.

Нигъмәт. Тукта, сиңа ни булды? Тиргәштегезме әллә?

Әлфинур. Юк.

Нигъмәт. Тиргәшмәгәч?

Әлфинур. Укытсын әйдә шул корьәнен. Колагыбыз тынып калыр. Ату ул кара сөрем булып йөри.

Нигъмәт. Танымыйм мин сине, карчыккаем.

Әлфинур. Ярый инде, карчыкның көнеле булсын. Юл куйыйк.

Нигъмәт. Юк, куймыйбыз, Әлфинуркаем. Без дингә, иске гореф-гадәткә түгел, ә алар безгә юл куйсыннар, юл бирсеннәр.

Әлфинур. Ул бит Сибайга китәм дип дулап йөри.

Нигъмәт. Китми, ә китәм дип куркыта гына. Ярый, соңга калсам, мине көтмә, кунып кайтырмын. Бар, паспортны гына чыгарып бир дә. Бер биш-ун сум акча да ал.

Әлфинур. Кибетләргә дә кереп чыккала әле, тәрәзә пәрдәләренә челтәр очрамасмы. *(Чыга.)*

Нигъмәт. Һай бу карчыкларны... Шәйбәк... Күрше, стансага барасың юкмы?

Тавыш. Бер сәгатьтән китәм. Әни карчыкны врачка күрсәтергә иде. Билен язалмый. Ә нигә? Йомышың бармы?

Нигъмәт. «Сельхозтехника»га керергә иде.

Тавыш. Киттек бергә. Минем дә анда йомыш бар.

Нигъмәт. Алайса доверенность яздырып алам да... Мин кәнсәләрдә булырмын.

Тавыш. Ярар, кереп алырмын.

Әлфинур *(өйдән чыгып)*. Егерме биш сум. Очраса, стенага берәр матур гына сурәт тә ал әле. Залга куярбыз.

Тавыш. Вакыт булса... Ярый, мин киттем. *(Чыга.)*

Өйдән Бәдерхаят чыга.

Бәдерхаят. Кызым, кодагый китәм дип пыр туза бит. Килен булып төшкән чакта кигән күлмәкләренә чаклы актарып ташлады.

Әлфинур. Соң мин аны нишләтим инде, әни. Нигъмәт якын да килми.

Бәдерхаят. Нигъмәтуллаң стансага китте бит. Куып кайтам, диде.

Әлфинур. Әгәр кумаса?

Бәдерхаят. Тот та фермаңа дежурга кит. Белүче дә, ишетүче дә булмас.

Әлфинур. Их, әни, син дә әллә нинди булып чыктың.

Бәдерхаят. Бер дә әллә нинди түгел, синең абруең өчен тырышам.

Әлфинур. Ярый, алайса, үз җаегызны үзегез карагыз. Мин бер нәрсә дә әйтмәдем дә, ишетмәдем дә. *(Чыга.)*

Бәдерхаят. Юкка көяләнмә, кызым. Усал әйтер — мин жиңдем, акыллы әйтер — юл куйдым. Кодагый, кодагый чык әле.

Өйдән төенчек тоткан Гөлхаят чыга.

Гөлхаят. Юлга акча бирмәсәләр, садакадан кергән акчам Сибайга түгел, Мәскәүгә барсаң да житәрлек әле.

Бәдерхаят. Куй төенчегеңне. Чакыр кунакларыңны, мин тиз-тиз генә аш-су әзерләп алырмын.

Гөлхаят. Рөхсәт бирделәрмени?

Бәдерхаят. Аулак алдык. Берсе бер якка, икенчесе икенче якка китте.

Гөлхаят. Собханалла, кемнәрне чакырырга икән соң? Кодагый, ишеткәнең юкмы, кем корьән укый белә икән?

Бәдерхаят. Кәҗә Үтәгол Сибайга күчеп китте, кылый Гамбәр былтыр вафат булды, ыы-әйе... Галимулланы зәхмәт сукты... Авылда башка корьән укучы да юк инде, кодагый.

Гөлхаят. Стансага былтыр яңа мулла килгән дип сөйлиләр иде, кирәк чагында, ичмасам, шул да килеп чыкмый. Ярый, син аш-суыңны карый тор, мин авылны әйләнеп кайтыйм әле. *(Чыга.)*

Бәдерхаят. Аш-су дип... ни мин... аларга ат казылыгыннан шулпа пешерәм дә чөгендерле катык куям. Чәй янына кодагыйның тәм-томы бардыр әле. Атакай, кара чебешем кайтты лабаса. Тип-тип-тип... рәхмәт төшкере, әйдә жим аша, ә мин синнән колак кактым дип пошынып йөри идем. Тип-тип-тип...

Төн килгән. Инде көтү кайткан, сыерлар савылып, ындыр артына куылган: әче, эссе тузан исе басылган һәм дөньяга илаһи кичке тынлык килгән. Тик сирәк-мирәк кенә

йокысыз кош чутылдап ала да адашкан каз бәбкәсе «бип-бип» дип кычкырып куя. Кинәт шул тынлыкны бозып, кемдер ямьсез, карлыккан тавыш белән «Суда, суда, суда йөзәләсеңме...» дип җырлап җибәрә. Бу тавыш Нигъмәтләр өеннән ишетелә. Капка төбендә Нигъмәт белән Шәйбәк күренә. Алар исерек, карлыккан тавышка колак салып, аптырап торалар.

Шәйбәк. Монда әллә син юкта өй котлау мәҗлесе үткәреп яталар инде, күрше?

Нигъмәт. Аңлашылмый. Кем шулай җиде төн уртасы үтеп киткәч, яшел тавыш белән мөнгерәп утырыр икән?

Шәйбәк. Әллә син юклыкны белеп берәрсе бичәкәең янына килде микән, ә?

Нигъмәт. Ай-һай, кеше хатыны янына килгән кеше шулай тамак ертып акырып утырыр микән...

Шәйбәк. Эчеп алгач, нигә килгәнен онытыр да...

Нигъмәт. Куй, тузга язмаганны сөйләмә. Минем хатын андый ирләрне себерке белән себереп чыгарачак.

Шәйбәк. Ә минеке ыклау белән кабыргаларын ук санар иде. Ярый, кайтып хатыным куенына чумыйм әле. Тыныч йокы.

Нигъмәт. Тыныч йокы.

Ул арада чылтырап тәрәзә пыяласы ватыла.

Тукта, тукта, бу ни хәл?.. *(Өйгә йөгереп кереп китә.)*

Шәйбәк. Чынлап та, аңлашылмый бит әле бу хәл... *(Тәмәке көйрәтә.)* Яңа өйнең тәрәзәсен ваткан кешенең башын ярырга кирәк ул... *(Җиңнәрен сызгана.)*

Ул арада өйдән Нигъмәт ярым исерек бер кешене якасыннан тотып алып чыга.

Нигъмәт. Син кем? Син нигә кеше өенә кереп гауга куптарасың?

Билгесез кеше *(аның исеме Мөбәшшир).* Как кем? Мин мулла.

Нигъмәт. Мулла? *(Көлә.)* Ә сине кем чакырды? Нигә?

Мөбәшшир. Как кем? Гөлхаят инәй чакырды, мин килдем. Куасыз икән, китәм.

Нигъмәт. Ашыкма. Әни, чык әле!

Мөбәшшир. Тс-сс... Бер шау-шу юк. Әҗерен бирегез дә...

Өйдән Гөлхаят карчык чыга.

Нигъмәт. Син нишләдең, әни?

Гөлхаят. Бохарадан мулла килгән дигәч, сез юкта корьән укытып алыйм дигән идем, улым, ә ул, юньсез, ашны бер-ике капты да көмешкә таптыра башлады... Хәердән килгән акчама бер чирек көмешкә алырга туры килде.

Нигъмәт. Әни, синең белән без соңыннан сөйләшербез, ә син, Бохара мулласы, хәзер үк табаныңны ялтырат, ату...

Мөбәшшир. Тс-сс, шау-шу юк. Әҗерен бирегез дә...

Нигъмәт. Нинди әҗер ул? Төш болдырдан, танавыңа кундырганчы.

Мөбәшшир. Тс-ссс, шау-шу юк. Гөлхаят инәй корьән чыккан өчен бер сарык бәрәне вәгъдә итте. Шуны бирсәгез дә...

Нигъмәт. Сарык бәрәне? Әни, бу дөресме?

Гөлхаят. Куй-куй, йөзең кара, мин сиңа сарык бәрәне дә, кәҗә тәкәсе дә вәгъдә итмәдем.

Мөбәшшир. Тс-ссс... Шау-шу юк. Шау-шудан сезгә генә зыян, ә миңа унбиш тәүлек утырып чыгу нипачум ул.

Гөлхаят. Соң син, йөзең кара, аятелкөрсине дә юньле-башлы белмисең бит.

Мөбәшшир. Как белмим? Мин настоящий корьән хафиз. Мәнә тыңлагыз. Аятел-тел... *(Төчкерә.)* Я. ярый, бәрән булмаса, бер биш

тавык та бата. Тик тс-ссс... Шау-шу кирәкми. *(Болдыр башына утыра да яшел тавыш белән кычкырып җырлап җибәрә.)*

Суда, суда, суда йөзәләсеңме,
Мин сине күрми түзәлəм,
Ә син түзәләсеңме?..

Читән кырында Шәйбәкнең башы күренә.

Шәйбәк. Тукта, тукта, бу бит Мөбәшшир.

Нигъмәт. Нинди Мөбәшшир?

Шәйбәк. Теге көнне миңа буяу саткан кеше. Кладовщик.

Мөбәшшир. Минем сезгә никакуй буяу сатканым юк. Мин Бохарадан килгән указлы мулла...

Нигъмәт. Мөбәшшир, Мөбәшшир... Без синең белән тракторчылар курсына бергә кергән идек түгелме соң? Син, староста булып, курсантлардан кирзовый итекләр сатып алыр өчен акча җыйдың да суга төшкән таш сыман юк булдың.

Мөбәшшир. Яла! Гайбәт! Мин бер төрле дә курста булмадым. Мин Бохарадан килгән указлы мулла. Мин...

Шәйбәк. Яхшы, күрсәт ул чагында указыңны...

Мөбәшшир. Хакыгыз юк. Мине мөфти генә тикшерә ала. Мине...

Нигъмәт. Яхшы. Иртәгә без мөфтигә шалтыратырбыз. Ә бүгенгә сиңа келәттә йоклап торырга туры килер.

Мөбәшшир. Хакыгыз юк. Мин... *(Селтәнә, дулый.)* Мин...

Шул вакыт урамнан участок милиционеры узып бара һәм ул, тавышны ишетеп, болар янына килә.

Милиционер. Гражданнар, җиде төн уртасында ул ниткән тавыш?

Шәйбәк. Менә жулик тоттык.

Мөбәшшир. Мин ж-жулик түгел, мин Бохара мулласы...

Милиционер. Анысын участокта тикшерербез, гражданин. Киттек.

Милиционер Мөбәшширне култыклап алып китә, ә тегенең «Мин ж-жулик түгел, мин Бохара мулласы» дигән сүзләре ишетелеп кала.

Нигъмәт. Их, әни, әни, яңа өйнең ямен җибәреп йөрисең шунда.

Гөлхаят *(күз яшьләре аша)*. Мин бит аны указлы мулла дип уйлаган идем, улым.

Нигъмәт. Минем өчен указлымы, дипломлымы — барыбер, алар барсы да халыкны алдаучылар, кеше .миен агулаучылар, яңа өйдә якты күңелле кешеләр яшәргә тиеш. Яңа өйдә яхшы эшләр генә эшләнергә тиеш.

Көр тавыш белән әтәч кычкырып җибәрә.

Әнә таң әтәчләре дә кычкыра башлады. Керәп ятыйк, иртәгә бәйрәм түгел.

Шәйбәк. Яңа өйдә матур төшләр күрергә язсын, күрше.

Нигъмәт. Өнәребез матур булса, төшләребез дә матур булыр, күрше.

Берьюлы берничә әтәч кычкыра.

Мөсәгыйть Хәбибуллин

# УНСИГЕЗЕНЧЕ ЯЗ

Повесть



*Мөсәгыйть Хәбибуллин 1927 елда Оренбург өлкәсе, Абдуллин районы, Габдрахман авылында туган. 1942 елда Магнитогорскига китеп, заводта токарь булып эшли башлый. 1951 елда Башкортстандагы Октябрьск шәһәренә кайта, бораулау конторасында мастер булып эшли. 1956 елда комсомол путевкасы белән авылга эшкә китә. 1960 елда Баулыга килеп, «Баулынефть» промыселлар идарәсендә шофер һәм механик булып эшли.*

*1966 елдан бирле Азнакайда яши, ул — район газетасының махсус хәбәрчесе.*

*Беренче хикәясе 1951 елда яшьләр җыентыгында басылып чыга.*

*Хәзерге көндә М. Хәбибуллин авыл кешеләре турында роман яза.*

## 1

Әти мине яратмады. Әниемнең әйткәне бар иде, мин тугач та ул бала табу йортына килмәгән. Тик икенче көнне иртән генә, лаякыл исерек килеш килеп, тәрәзә төбендә берничә папирос тарткан да китеп барган. Кыз, янәсе. Чынмы, ялганмы, ул хәтлесенә керешә алмыйм, әмма әниемнең бу сүзләрен мәңге онытасым юк. Чөнки белә-белүемнән бирле әти мине ичмасам бер генә тапкыр да алдына утыртып сөймәде. Күрәсең, әниемнең сүзләре дөрес булгандыр.

Мәскәүдә фестиваль көннәре иде. Әнием, беренче разрядлы гимнастка, аннан үз аягы белән кайтмады. Аның үле гәүдәсен гробка салып, самолет белән китерделәр. Телеграмма алу белән аэродромга бардык. Халык күп иде, иллешәр урынлы өч автобус килгән иде. Аэродромда мин еладым. Нигәдер күңелем әниемнең үлгәнлегенә ышанмый, нидер көтә, өмет итә иде. Әнием чәчәкләр арасында ята. Шуңа микән, ул исәндер, йокыга гына киткәндер кебек тоела. Менә хәзер башын күтәрер дә шомырт кара күзләрен тутырып миңа карар. «Кызым, Әнрүсә, исән-сау тордыгызмы?» — дияр кебек иде.

Зират еракта, шәһәр читендә үк. Әнине күмәргә мин дә бардым. Кызыл кирпечтән челтәрләп өйгән зират ихатасы киноларда күргән төрмә коймасын хәтерләтә. Күңелсез, монсу, күрү белән күңелне авыр тойгы баса. Ул көнне бездән кеше өзелмәде, эти күзләрен сөрткәләп йөрде. Машина артыннан халык ияреп барды, оркестр уйнады. Үзәк өзгеч матәм маршы колак төбендә яңгырап торды. Миңа еламаска, сабыр итәргә куштылар. Ләкин мин тыела алмадым.

Кабергә көрәкләрдән балчык коела башлагач, әниемнең инде мәңгегә җир астында калачагы зиһенемә барып җитте. Кабер өстенә капланып, үкереп-үкереп еладым. Хәтеремдә, кемдер мине юатырга, күтәреп алырга теләде, ләкин мин аларны тыңлаудан узган идем инде.

Кояш баеп, караңгы төшә башлагач кына зираттан чыктым. Тирәюнем тып-тын. Ахры, күрше хатыны Саҗидә апа да кайтып киткән. Каберләр өстенә утырткан чатлы-ботлы агачлар сагаеп, тынып калганнар; җәйге эссе кич булгангамы, һава житми, сулыш алуы авыр, бөркү. Хәзер инде мин еламыйм. Күкрәгемдә нидер кайнады-кайнады да чуер таш кебек катып калды.

Озак кайттым бугай. Шәһәр урамында утлар кабынды. Төтен бөркеп автобуслар узды. Мин җәяү генә кайттым. Зиһенем таркау, күңелемдә — таш. Шәһәр шау-гөр килә. Әйтерсең, минем әни үлмәгән, әйтерсең, бүгенге көн кайгылы көн түгел. Гомер, яшәеш, мәңгелек хәрәкәт.

Үзебезнең өйгә кайтып җиттем. Бакчага кереп, әни ял итәргә яраткан эскәмиягә утырдым. Монда да халык. Чуар кием, шпилька үкчәләр, челтәрле сандал, кулннән үргән чабаталар. Күпмедер утыргач, халык сирәгәя башлады, бакча бушап калды.

Кичке салкын һава битне сыйпап узды, утлар сүнде. Минем беркайчан да ут сүнгәнче бакчада утырганым юк иде. Курка идем. Ә бүген утырам да утырам. Төпсез зәңгәрсу һавада ипи кыерчыгы кадәр ай күренгәч кенә кайтырга чыктым. Урам караңгы, тар, әйтерсең мин бармыйм, урам миңа таба килә. Төрле төскә буялган өчәр, дүртәр, бишәр катлы йортлар бер-берсенә елышып, кысылып торалар. Менә безнең өй. Баскычларга баскан саен туктап, йөрәк кагуымны тоеп, икенче катка күтәреләм. Күз алдымда һаман әнием. Баскычлар шома, ялтырап тора. Баскычтан атлап йөргәнемне хәтерләмим. Зоопарктагы тиен кук, җан-фәрманга йөгереп кенә менә идем. Бүген баскыч сырларын саныйм: аяклар көч-хәл белән күтәрелә. Миемдә бер генә уй утыра: әни үлгән, әни юк. Ләкин күңел ышанмый, гүя әнием исәндер, гүя ул кухняда аш хәзерлидер, я булмаса келәм өстендә күнегүләр ясыйдыр кебек. Соңгы хыялым күңелемә ялган юаныч бирә. Ашыгып коридорга килеп керәм. Күземә беренче ташланган нәрсә — кухняда ут юк. Кунак бүлмәсенең киереп ишеген ачам. Бүлмә эче яп-якты, ул шундый якты, елый-елый шешенеп беткән күзләрне камаштыра. Диванда эти белән янәшә ниндидер чит хатын утыра. Алар бик кызу бәхәсләшәләр иде, мине күргәч, тынып калдылар. Әтинең соңгы сүзләрен генә ишетеп калырга өлгердем.

— Белдермәскә кирәк, аңлыйсыңмы, белдермәскә!..

Бу сүзләрне мин ишек төбендә үк ишеткән булсам да, уйланып тормадым, диванга күз сирпеп алдым да үз бүлмәмә кереп киттем. Ләкин тынычлана алмадым. Диванга утырган хатын минем әниемә охшаган иде... Гаҗәп хәл, охшашлык шулкадәр дә зур иде, мин баштарак, сагашам микән әллә, дип тә уйлап куйдым. Бәлки бу галлюцинация генә булгандыр, бәлки бу минутларда әниемне күз алдымнан җибәрә алмаганга, әниемне исән итеп күрү теләге гаять көчле булганга шулай күренгәндер, ни генә булмасын, охшашлык коточкыч зур иде, мин инде аны чыгып карарга да җыенып беткән идем, тик алдан-дан куркып кына тыелып калдым.

Миңа унҗиде яшь тулды. Әти һаман шулай булып яши бирә. Өйгә сирәк кайта. Хәтта кайчак атналап югалып йөри. Беренче мәлне мин бик борчылган идем, тора-бара, күнегеп киткәч, шаккатмый башладым. Ләкин көннәрдән бер көнне әти мине кочып маңгаемнан үпте. Бу көнне бик соң кайтты ул. Мин дәресләремне карап утыра идем. Ул аек иде. Керде дә өстәл янына килеп, минем башымны кочты. Озак, бик озак шулай торды ул. Ни уйлады икән ул бу минутта? Анысы миңа караңгы иде. Бәлки, мәрхүм әнкәйне хәтерләгәндер, ә бәлкем унҗидегә җитеп килгән кызын илаһи ата мәхәббәте белән бер тапкыр да кочып сөймәвенә үкенеп алгандыр... Мин кымшанмадым да. Миңа рәхәт иде. Әйе, кем әни кочагыннан мәхрүм, кем ана мәхәббәтеннән мәхрүм, ул, үз гомеренә бер йөрәк җылысын тоеп, сөйгән атаның вакытлыча яратуына да шат була икән! Бу минутта мин әтине барысы өчен дә кичердем, барысы өчен дә гафу иттем.

Гомумән, әти минем күп сөйләшми иде. Әни мәрхүмә исән чакта, көнозын бер авыз сүз әйтмәгән өчен, әтине орышканы әле булса хәтеремдә. Инде әни үлгәч, ул бөтенләй сөйләшмәс булды. Хәтта иң хаҗәт әйберен дә ымлап кына аңлата. Хәер, мин үзем дә әтине ярты сүзеннән, кечкенә генә хәрәкәтеннән, кашлары селкенеп китүдән үк аңлый башлаган идем инде. Ул әле дә дәшмәде. Башымны ике учына кысып, күзләремә тутырып бер карады да яшькә чыланган йөзен читкә борды. Бу минутта мин дә елый идем.

Күкрәк түреннән чыккан калтыравык тавыш белән ярым пышылдап:
— Кызым...— диде ул, бүтән берни дәшмәде. Шул сүзе белән үз бүлмәсенә керде, шул сүзе белән иртән эшенә китте. Шул булды минем унҗиде яшем тулып, әти белән йөрәк җылысы тоеп сөйләшүем. Әйе, нибарысы бер җылы сүз иде ул унҗиде елга.

Ләкин көннәрдән бер көнне әти үзгәрде. Көн тудымы, авыз эченнән шыңшып, нидер көйләп, сызгырып йөри башлады. Атнага бер пәке тимәгән, кара төк баскан яңакларын һәркөн ялтыратып кыра, көзге каршында озаклап галстук бәйли торган булды. Шимбә көнне ул мине, ике ярты, дүрт шампанский алып кайт дип, кибеткә җибәрде. Минем кебек кыз кешегә яхшы түгел бит, әти, дигәч, күз агын әйләндереп бер генә карады.

Кичен безгә кунаклар килде. Ничектер бөтенесе берьюлы, өерләре белән килеп керделәр. Өй эче шау-шу белән тулды. Әти миңа кунакларга күренергә кушмады. Мин үз бүлмәмә кереп бикләндем. Кемдер ишек шакыды — ачмадым. Кунаклар таралгач, өй эче тынып калды. Мин китап укып ята идем. Кинәт урнашып калган тынлыкка гасабиланып тәрәзә каршысына килеп бастым. Тышта — яз. Төн булуга карамастан, туңдырмаган, ахры, өй түбәләреннән тротуарга тып-тып тамчы тама. Карлы суны шаптыр-шоптыр ерып узган аяк тавышлары ишетелә. Күктә йөзгән язгы болытлар арасыннан тулган ай күренеп китә. Ай кайдыр тәгәри, оча, ләкин ай түгел, көчле җилдән болытлар агыла иде...

Соң яткангамы, кояш шактый күтәрелеп, караватыма төшкәч кенә уянып киттем. Мәктәпкә барырга соңга калганмын дип сискәнеп уйлавым булды, якшәмбе көн икәнлеге исемә төште. Бүтән йоклый алмадым, торып, залга чыктым. Бүлмәне кемдер бик пөхтә итеп җыештырып куйган иде.

Юынып, чәчем тарап, ваннадан чыгып килгәндә әни мәрхүмнең алъяпкычын бәйләгән берәү кухнядан чыкты. Тез буыннарым йомшап китте. Бу — үткән елда әти белән бергә булган хатын иде.

— Хәерле иртә,— диде ул һәм чибәр алсу йөзе белән көчәнеп елмайгандай итте.— Менә ничек үсеп җиткәнсең! — дип җилкәмнән килеп кочты. Шулай дигәндә аның тавышы ничектер калтырап китте. Мин

каушап калдым. Кай арада торгандыр, зәңгәр пижамын киеп, эти дә диванда утыра иде инде.
— Карасана,— диде чит хатын,— карасана син аның үсүен!
Эти дәшмәде — тәмәке кабызып маташа иде. Кулын пешерә башлаган шырпысын селкеп сүндерде дә:
— Күй,— диде.
— Унынчыда укыйсыңмы? — диде хатын, этинең кыланышына игътибар итмичә.
Мин баш кактым.
— Димәк, соңгы елың?..
Мин әйе дип тагын баш кактым. Ул яңадан сорашмады. Мин дә эндәшмәдем. Мөгаен, нәрсә булса да әйтергә кирәк булгандыр миңа. Аннары ул, берни дә булмаган кебек, кухняга чыкты.
Нәкъ шунда, кухняга борылганда гына мин аңа карадым. Юк, бу галлюцинация түгел, бу мине акылдан шаштырырлык охшашлык иде. Әйе, мин янә әнине күрдем. Бу — ул, аның шомырт кара күзләре, аның бәләкәй йомры ияге, алсу янып торган бит алмалары, хәтта борыны да, колагына таккан тамчы алкасы да, буй-гәүдәсе дә әниемнеке иде. Аптыравым ашып китеп, мин этигә күз сирпедем. Эти үрелеп, телевизорны кабызды.
— Таныш бул, Әнрүсә, әниең...
Ул моны ничектер иренен турсайтып, киная лэп әйтте кебек тоелды миңа.
Мин тәрәзәгә карап тора башладым. Миңа авыр, бик авыр булып китте. Юк, эти, юк, минем әниемне беркем дә алыштыра алмас. Чын әни бер генә була.
Мин чыга башладым.
— Сабыр ит,— диде эти, гөжләп торган стабилизаторның кызыл күзенә карап.
Минем эти кырыс йөзле. Бәгырьне телә торган елдам күзле. Чабак сырты сыман бөкре борынлы, җете кара күзле, киң маңгайлы. Бигрәк тә күзләре хәтәр аның. Бер текәлеп караса, коелып төшәм, бөтен тәнем буенча чемер-чемер салкын йөгерә.
— Әниең Мөнирә атлы. Ярат син аны. Сөйләш!..
— Ярый...— дидем мин, башымны иеп.

## 2

Көтеп алган җәй дә җитте. Озакламый имтиханнар башлана. Мин классташым Нажия белән, утырган тавык кебек, бүлмәдә сынаууга хәзерләнәм. Нажиянең йөзе матур, юнып ясаган кебек, төз борын, чынаяктай ак бит, ә тулы иреннәре күпереп тора. Ул семьяда бердәнбер бала, иркә. Затлы киенә. Классташ малайлардан футболист Фәнис Нажияне ярата бугай, кайчан карама, алар гел бергә булалар. Фәнис миңа да ошый. Моның өчен мин Нажиядән көнләшмим, юк. Нажия миннән күп матур, Фәнис юкка гына аның белән йөрми шул инде.
— Нажия,— дим мин, аңа туры карап,— имтиханнарны биргәч, бергә институтка керергә хыял тотасыңмы?
— Кем хыялланмый ул турыда. Унны бетерүченең институтка керү хыялы юк икән, үлгән җан ул, буш кеше.
— Ә минем артистка буласым килә.
— Артистка!
Нажия шаккатып миңа текәлде.
— Синме?!
— Мин.
— Җаны теләгән — җылан ите ашаган, әмма мин синнән артистка чыгачагына ышанмыйм.
— Нигә?

— Төсен-битен килмәгән — бер, иренең калын — ике...
— Булса соң...
— Ә-ә, беләсең килсә, артист кешенең ирене акчарлак канаты кебек була. Җәяләнеп тора. Менә минеке кебек. Шуна карамастан, мин анда элэгүемә ышанмыйм.
— Үз-үзенә ышанмыйсың?
— Әйе. Ә син ышанасыңмыни?
— Ышанам. Теләгем зур.
— Минем менә кияүгә чыгарга теләгем зур.
— Шаяртмачы, Нәҗия...

Президиумнан минем исем-фамилияне кычкырдылар.
— Сабитова Энрүсә.
Кемдер:
— Җырчыбыз, артисткабыз... дип өстәде.
Мәктәп директоры Ваһап абый кулымны кысты да миңа күн тышлы аттестат сузды.
Йөгереп урамга чыктым. Әче төтен бөркеп, тормозларын чыелдатып борын төбемдә үк «Волга» туктады. Кабина ишегендә шофер башы күренде.
— Җүләр, башсыз!..
Туктап та тормыйча, машина каршысыннан йөгереп уздым.
Шофер сүгенеп калды. Сүген, абый кеше, сүген. Мин — Энрүсә, бүген өлгергәнлек аттестаты алдым. Аттестат!..
Тротуар үргә менә. Миңа каршы кешеләр килә. Бик күп кешеләр. Урамның ике ягыннан юкә агачлары җилфер-җилфер итеп мине каршы ала, мин йөгерәм дә йөгерәм. Тизрәк өйгә кайтасым килә. Әти ни әйтер икән? Тәбрикләп нилэр әйтер?! Әни ни әйтер, әни!..
Мин үземдә ташып торган көч-куәт тоям. Миңа карты-яше, баласы-чагасы, уймак авызлы кызыл иреннәр, озын чәчле җилбәзәкләр юл бирәләр, мөгаен, алар минем аттестат алганымны беләләрдер.
Бүлмәгә сулышым кысылып кайтып кердем. Әти көзге каршында галстук бәйләп маташа, әни өстәл әзерли иде.
Бер сүз дә әйтмәстән, аттестатны әнигә суздым. Әни мине кочаклап, аркамнан сөйде, маңгаемнан үпте. Әти борын астыннан мыгырданып, ләм-мим бер сүз әйтмичә, өйдән чыгып китте.
Ләкин әни шат иде. Ул әтинең бу кыланышын күрми калдымы, әллә күрмәмешкә салыштымы, ул елмая, бөтен йөзе белән елмая, ә күзләре шатлык яше белән тулган иде.
Кичен ул минем исемемне язып торт пешерде. Миңа ак җирлеккә кара бүй төшкән паплин күлмәк бүләк итте.
Әти берсүз генә әйтте:
— Яхшы,— диде ул, алдындагы өчпочмакны ашап бетергәч. Мин аңламадым, әллә мине, әллә әни пешергән өчпочмакны мактады.
Кичке сәгать җидедә өчәүләп театрга киттек. Әти шактый калышып атлый, ә без алдан барабыз. Әни минем терсәктән кысып тоткан да колагыма:
— Әткәңнең кәефе юк. Пьеса язган иде, режиссер укыган да әтиеңне тетеп ташлаган, белсәң!..— дип пышылдый.
Шуннан соң ул әтигә әйләнеп карады.
— Белми ул пьесаны ничек репертуарга үткәрергә. Ничә ел театрда художник булып эшли, ә шуның рәтен-җаен белми.
— Әтиме пьеса язган? — дип сорадым мин сабырымны җыеп.
Ләкин «әни» әллә нигә эндәшмәде, күктәге беренче йолдызга карап атлый бирде. Ул үз дөньясына кереп чумды. Кем бу кеше, нигә ул минем мәрхүмә әнигә охшаган? Нигә аның миңа бер дә, ичмасам, бер

МӨСЭГЫЙТЬ ХӘБИБУЛЛИН ♦ УНСИГЕЗЕНЧЕ ЯЗ ♦

тапкыр да үзенең эч серләрен, үткән гомерен, уй-хыялларын сөйләгәне юк?

Кем бу?

Кем бу минем әни роленә керә алырлык хатын?

Без караган спектакльдә әни уйнамый икән. Ул мине беренче антрактта ук, кулымнан тотып, театр директоры янына алып керде.

Директор юка гәүдәле, бугаз төере йөреп торган озын нечкә муенлы шактый олы бер кеше иде.

Без керү белән ул урыныннан торды һәм яртылаш бөгелеп, ике куллап әни белән күреште.

— Рәхим итегез, Мөнирә ханым... Рәхим итеп утырыгыз. Мин үзем ялда идем, «Беренче мәхәббәт»кә рольләр сайлаганда өйдә булмадым, әйтер идем сезгә, Мөнирә ханым, үпкәм зур. Чын, чын... Нигә дип инде роль алмадыгыз?

— Авырдым, Хатыйп Харисович.

— Мөнирә ханым!..

— Хатыйп Харисович, зинһар өчен кәефемне бозмагыз әле! Дөресен генә әйткәндә, бу инде сер түгел, мине Казанга чакыралар. Аңлагыз мине, керегез минем хәлгә...

— Ярый, бигайбә,— директор юан аяклы өстәл артына кереп утырды.— Ярый, бигайбә, килештек, ди. Ни йомыш?

Мин әнинең йөзенә карадым. Бәлки, артистларның чын йөзләрен күрүе дә кыендыр, әмма бу минутта әнинең чырае моңсу иде.

Директор текәлеп бер мизгел әнигә карап торды да:

— Мин сезне һич тә аңламыйм, Мөнирә ханым. Бер китеп, бер кайтып... Картаеп киләбез бит инде без,— диде һәм кисәк кенә: — Бу кем? — дип сорады.

— Кызым,— диде әни.

— Кызың?! — диде директор, күзләрен зур ачып.

— Хатыйп Харисович!..

— Бетте, бетте. Мәйле. Я, ни йомыш?

— Әнрүсәнең артистка булырга теләге зур. Коллективка алсагыз иде. Үзем дә ярдәм итәр идем...

— Һы, һы,— директор торып йөренеп килде.— Һы, әйтик, алсам, алсак...

— Алсаң, рәхмәт укырмын, Хатыйп Харисович.

— Рәхмәттән спектакль чыгарып булса иде ул. Мин иң атаклы кеше булыр идем инде, Мөнирә ханым.

Бер мәлгә тынлык урнашты. Директор миңа текәлеп карап алды да учлап ияген тотты.

— Ярый, бигайбә. Гаризасын калдырсын... Иртәгә коллективка күренергә килсен.

## 3

Миңа ике сүз дә әйтми торган роль бирделәр. Ләкин шул рольне дә уйный алмадым. Әллә каушадым, әллә курыктым. Яныма әти-әни керде. Кара мыеклы режиссер ярдәмчесе Сибгат ага җилкәсен сикертеп:

— Теләми, теләсә булдыра ала,— диде.

Әти миңа акаеп карады да авыз эченнән генә мөңгерәп чыгып китте.

Мин үземне пиндидер упкынга очкан кебек хис иттем.

Бәрелә-сугыла ишеккә ташландым.

Гарьлектән кабарган йөрәгемне тыя алмыйча, караватыма капланып еладым. Дөньяга туган көнемне, туган сәгатемне каргадым. Аннары, арып-алҗып, йокыга киткәнмен.

Күзләрем ачып җибәрсәм — көн. Караватымда Мөнирә апа утыра. Аның йөзе сулган, күзләре эчкә баткан. Ул минем кулымны тотты.

— Әнрусә, кызым!..

— Борчымагыз мине... Мин барысын да беләм!

Мөнирә апаның күзләре түгәрәкләнде.

— Беләсең??

— Әйе, беләм, беләм!! — дип кычкырып җибәрдем мин, үз-үземне белештермичә.— Борчымагыз мине!.. Борчымагыз, ишетәсезме!!..

Ул акрын гына торды да, чак кына бөкрәя төшеп, артына әйләнеп тә карамыйча чыгып китте.

Ни өчен рәнҗеттем мин аны? Мин янә, бу юлы инде ачуым ташудан, елап җибәрдем.

— Китәм, Себергә китәм! Анда да яшиләр, эшлиләр! — дип үксү-үксү елыйдым. Аннары тагын йоклап киткәнмен. Мин уянганда, сәгать уникегә җитеп килә иде инде.

Булган хәлне күз алдыма китердем дә, тәвәккәл бер фикергә килеп, залга чыктым. Әйе, мин китәм, мин китәргә тиеш, бүген үк, хәзер үк. Шул чак өстәлдә ниндидер язу күрәм, тиз генә күз йөртеп чыгам. Язуны Мөнирә апа язган, аның язуы. Йөрәгем жу итеп китте.

«Әнрусә акыллым... Мин китәм... Кайгырма, мин сине барысы өчен дә гафу иттем, кичердем... Минем китүем очраклы хәл түгел. Кайчан да булса аңларсың дип уйлыйм. Хуш, үскәнем, балам, хуш!..»

Мин курка калдым. Чынмы бу, чынлап китүеме Мөнирә апаның? Әти кайда икән? Өйдәге әйберләрдән, стеналардан ярдәм эзләгән күк, бүлмәгә күз йөртеп чыгам. Тәрәзә төбендәге конвертка күзем төште. Каударланып кулыма алдым. Конверт тышына матур итеп әтигә адресланган сүзләр язылган.

«Галим, сиңа...»

Бер мизгел вакыт эчендә конвертны ачып укыйсым килеп китте. Әмма кулым болан сыеры сурәте төшкән конвертны ертырга дигәндә генә, бу уемнан кире кайттым. Ярамый болай, әти ни дияр? Ни хакың бар синең әтигә дигән хатны ачып укырга?! Хатны кире урынына куйдым һәм, күңелемнең тулуын тоеп, тахтага килеп аудым. Инде хәзер нишләргә? Мин, тик мин генә бит монда гаепле!.. Әти ни әйтер, син ни әйтерсең, әти!? Нигә, нигә мин аңа авыр сүзләр әйттем!.. Минем булдыксызлыгыма ул гаеплемени?! Юк бит, тагын йөз тапкыр, мең тапкыр юк!.. Әти, әти, бу ачудан, бу хәсрәттән син тагын эчә башларсың инде! Ник әйттем мин аңа, нигә әйттем, нигә?!.

Әйе, кеше күңеле — карурман. Кеше ул сер, ачылмаган йолдыз. Мәрхүмә әнием Дания, кайда син?!.. Нигә син мине калдырып киттең, нигә?! Кем кулына!.. Син, син исән булсаңмы! Син исән булсаңмы, әни бәгырем!.. Нинди бәхетле кеше булыр идем мин, әнекәем!..

Елап туйгачтын тәрәзә каршысына килеп бастым. Күзләрем урамда, ә күңелем әллә кайда. Бүлмәдә һава аз, һава җитми. Ниһаять, бернн аңламыйча, урамга карап катам. Башым фикерләүдән туктаган, гүя ул минеке түгел. Күзләр, тик күзләр генә күрәләр. Ә күзләр ни күрмәс алар. Әнә минем кебек үк бер кыз эштән кайта. Чалбар кигән, килешеп тора үзенә.

Кемдер ишек шакый. Ләкин мин урынымнан кузгалмыйм. Тораташтай басып торам. Кояш бүген зәһәр кылана. Тәрәзә аша тәнне кыздыра. Берннди хәрәкәт ясамыйча уйга чумам. Инде нишләргә миңа?

Урам тутырып эшчеләр эштән кайталар. Алар, бала-чага кебек, төрткәләшәләр, көлешәләр.

Ә нигә миңа да эшкә кермәскә? Нигә дип акыл илертеп торырга! Эш, хезмәт, тик хезмәт кенә коткара алачак мине. Шулай дия иде түгелме соң мәрхүмә Дания әнием!

Кич белән Нәҗия килде. Аның өстендә шакмаклы ситсы күлмәк, чәчен баш түбәсенә өеп төйнәгән. Аягында биек үкчәле ак «гвоздик». Көязләнә белә кеше!

— Син нәрсә, Әнрүсәкәем, кәефең юкмы әллә, кынан коелган чәчкә күк утырасың? — дип сузып алып китте бу.
— Утыр,— дидем мин, диванда үзем белән янәшә урын бирдем.— Эшкә керденме?
— Әле син кермәдеңмени?
— Юк әле.
— Һай, җүләр, нигә аны әллә кайчан әйтмәдең?
— Нигә?
— Нигә дип утырган була бит тагын. Мин менә беренче зарплатама күлмәк, туфли дә алырга өлгердем инде. Әти әйтә: «Кызым, акчаңны үз өс-башың карарга тот, без синең акчага мохтаҗ түгел».— ди. Ә син нәрсә, чынлап та сөмсерең коелып утырасың? Карасана син аны!..
— Җылыйсым килә, Нажия.
— Җылыйсың килә!.. Җүләр син. Бүген танцыга барабызмы? Акча ягы миннән.
— Танцыга!..
Мин риза булдым. Сәгать кичке биштә танцы мәйданы янына килермен дип сүз бирдем. Нажия ике җиңемнән тотып селкеп алды.
— Я инде, ташла инде шул турсаюыңны!

4

Танцы мәйданы чуп-чуар. Монда кем генә юк. Безнең кебек яшьҗилбәзәктән тотынып, кырыкны тутырып әле булса чын мәхәббәт, бәхет таба алмаган карт кызлар, маңгай өсләре ялтырап калган урта яшьтәге ирләр дә бар. Түр почмакта, купол астында тынлы оркестр. Нажия өстенә кара күлмәк кигән, аягында көндезге ак туфли. Ул минем «соры гына» өс-башыма, үкчәсез туфлиемә күз ташлады да кул селтәп:
— Нигә бераз ясанып килмәдең? — диде.
Кәефем кырылды. Борылып китә башладым. Нажия минем кулдан эләктереп алды.
— Менә җүләр, Әнрүсә, нишләвең бу, тагын турсайдыңмы?! Мин сиңа уйнап кына әйттем ич!..
Һава гөжли. Тынлы оркестрның музыка моңы мәйдан өстендә эленеп тора. Нажия мине мәйдан уртасына алып чыкты. Гаҗәеп, элек мин музыка тавышын ишетүгә баскан җиремдә бии башлый идем. Бүген исә музыка үзенең тылсымлы моңын миңа җиткерә алмады. Нидән булыр бу?
Түр почмактагы стена буе буш иде, без шунда таба киттек. Биючеләр юк. Мәйдан уртасы аша атлыйбыз. Безгә карап-карап калалар. Җиңенә кызыл бәйләгән берәү безне мәйдан уртасында туктатты.
— Чибәркәйләр, урам хәрәкәтләре кагыйдәсен бозасыз бит. Мәйданны кисеп чыгу катгый рәвештә тыела. Шуның өчен минем арттан иярүегезне үтенәм. Карышмагыз, җанҗал куптармагыз, соңы начар булуы бар. Кисәтеп куям.
Нажия тирә-ягына күз ташлап алды да егеткә нидер әйтмәкче булды. Аның болай да чибәр йөзе алсуланып китте.
— Сез, сез, үзегез дружинник, үзегез тәртип бозасыз!..— диде ул, хәтта борын яфраклары калтырап куйды.
— Гафу итегез,— диде егет,— хәзер музыка башлана, зинһар өчен җанҗалсыз гына иярсәгез иде. Юкса, танцыны туктатып торырга туры киләчәк.
Нажия теләр-теләмәс кенә егеткә иярде. Ул әле булса мине ычкындырмаган иде.
— Әйдә инде, мин бер үзем генә куркам.
— Ә мин үзем дә бара алам ич, җибәр мине!..
Ул да түгел, барабанчы барабанына сугып алды, без дә егет ча-

кырган почмакка килеп життек. Егетнең дусларыннан берсе минем алга килеп басты.

— Гафу итегез, ул бит шаярып кына. Бәлкем, минем белән биерсез?..

Мин иренемне бүлтәйтеп куйдым. Егет күрмәгәнгә салышты. Биергә әйдәде.

Нажияне мин күрә алмадым. Ул да, ахрысы, безне ияртеп килгән егет белән бии башлады. Егет минем билемә кулын салды.

— Мине әни иртән торгач та Вәсил ди. Ә сезне әниегез ни дип уята?

— Минем әнием юк.

— Шулаймыни?

Егет киң кара кашларын сикертеп, борынын жыергалап алды. Мин ихтыярсыз көлеп жибәрдем.

— Ә шулай да исемегез бардыр бит? Мин Гыйлажны сезне алдап алып килгән өчен орышырга теләгән идем дә, сезнең белән таныштырган өчен гафу итәрмен, ахрысы.

— Сезнең алда анык бер гаебе дә юк. Без гаепләргә тиеш аны.

— Нигә?

— Ә нигә дип, кулына кызыл бәйләгән дә кыланып йөри.

— Кулына түгел, беләгенә кызыл бәйләгән,— дип төзәтте мине егет,— ул бит дружинник, мәйданда тәртип саклау аның изге бурычы.

— Сезнеңчә, без тәртип боздыкмыни?

— Күрәсең, шулай килеп чыга.

Көмдер безгә бәрелеп китте. Егет Вәсилдән гафу үтенде. Вәсил карабрак йөртә башлады. Ул жиңел, йомшак итеп йөртә. Мин аның каты уч төбен тоям.

Менә музыка тынды. Егетем мине үзе алып киткән почмакка таба әйдәде. Ул нәзакәтле итеп минем терсәктән тоткан. Үзе бик аз гына алга чыгып, ыра-ера диярлек, миңа юл арчый. Мәйдан яшьләр белән шыгрым тулы. Кемнең булса аягын күрәм димә. Тик музыка тынып, егете-кызы үзләре кузгалган стена буйларына таралгач кына, мәйдан уртасы беразга арчыла, һәркем, безнең кебек, мәйдан аша үтәргә тели, аңа йөзләгән күз төбәлә. Ул үлчәнә, бизмәнгә салына, бәя ала. Хәтта кайберәүләр, бигрәк тә егетләрдән, тел шартлата, тамак кырып куя, я булмаса юри төчкереп жибәрә.

Егетем Вәсил мине без кузгалган урынга китереп житкергәндә, Нажия үзенең «милиционеры» белән кайнар бәхәс ачып жибәргән иде инде. Нажиянең үзгәрүенә мин бераз гажәпләнә калдым. Ул мине күрү белән:

— Әнрүсә, карасана Гыйлажны,— дип, кызыл тасма бәйләгән егетен миңа әләкли башлады,— без сезне күптән беләбез дигән була. Мәктәптән үк, ди. Без кечке мәктәптә укыдык, ә сез көндезгедә, ди. Чи ялган бит бу! Шулай бит! Без кичке мәктәптәге узган елгы малайларны биш бармак кебек беләбез.

— Бәлкем, шулайдыр,— диде Нажиянең Гыйлажы,— әмма безнең анда уку хак.

— Ә сез әле укыйсыз гынамыни? — диде Нажия юри үртәп,— без тагын сезне унны бетергәнсездер дип торабыз. Ярый инде, соңгарак калгансыз калуын да...

— Соң булса да уң булсын,— диде Вәсил, үпкәли башлаган иптәшен яклап.

— Анысы шулаен шулайдыр инде,— диде Нажия, үзен һаман да бик эре тотып.— Карагыз әле, Гыйлаж, мине үзегезгә шеф итеп алмыйсызмы? Минем быел институтка керергә исәп юк, эшкә кереп бер-ике ел эшләп карарга исәп.

— Нигә алмаска,— диде Гыйлаж.— Сез безне уку ягыннан шефка, ә без сезне эш ягыннан. Әйдәгез, безнең промыселга, кызлар.— Ул

Нажиянең колагына иелә төште.— Беләсегез килсә, безгә менә болай замерщиклар кирәк.— Гыйлаж кул сырты белән муенын сызып күрсәтте.

— Алсалар бит әле,— диде Вәсил, баскан урынында черлстонны биеп алды.

— Кыланып торма әле, Вәсил,— диде Нажия,— кеше эш турында сөйләшә...

— Пожалуйста, баш өсте...

Вәсил, күкрәгенә кулын куеп, йөзен төчеләтте.

— Һай, кыланчык та синең бу иптәшең,— диде Нажия Гыйлажга карап.

— Кирәк чакта егет була белергә кирәк.

— Ничек, ханым?

— Гыйлаж! — Нажия утә гажәпләнеп Гыйлажга карады.— Арестовать ит әле син бу кылтайчыкны...

— Йөрсен әле бераз, соңрак, танцы бетәрәк,— диде Гыйлаж, көлеп жибәрүдән чак кына тыелып.

— Наганың бармы соң синең?

— Юк шул.

— Соң, жанкисәгем, агачтан ясап булса да тагарлар инде аны. Юкса, нинди милиционер инде син! Әйт әле, жанкисәгем, ә?!

Нажиянең соңгы сүзләрен оркестр тавышы күмде.

Вәсил дер кубып Нажия каршысына килеп басты.

— Рөхсәт итегез...

Нажия бер миңа, бер Гыйлажга күз атты да бармак очлары белән генә итәгенә тотынды һәм мут елмаеп:

— Баш өсте,— диде.

Нажия белән Вәсил, бөтерелә-бөтерелә, биючеләр арасына кереп чумдылар. Гыйлаж беләгенә бәйләгән тасмасын кесәсенә алып тыкты да минем каршыга килеп басты.

— Бәлкем, Әнрүсә туташ каршы төшмәс.

— Нигә бу төчелек?

— Гафу итегез...

Гыйлаж да нәзакәтле итеп кулын билемә куйды, башын чак кына кыңгыр салып, әйләнә башлады. Мин аңа буйсындым. Гыйлаж миңа карамый. Аның такыр мангаена чәчләре төшкән. Кашлары коңгырт төстә. Күзләре зәп-зәңгәр. Зур гына чөенке борынлы. Кечкенә ияк очларында сары бала йоннары күренә.

-- Сез, Гыйлаж, нигә тасмагызны чиштегез?

— Соңыннан бәйлим мин аны, танцы беткәч.

Без кемгәдер бәрелдек. Гыйлаж баш иеп гафу үтенде.

— Нинди күнелле кич бүген! Беркайчан да болай булганы юк иде,— диде ул кинәт һәм үзенең сүзләреннән үзе үк уңайсызланып китте. Мин аны коткарырга ашыктым:

— Сез кайда эшлисез?

— Промыселда. Ә нигә? — Ул текәлеп миңа карады. Мин, аның туры каравыннан оялып, колакларыма кадәр кызардым.

— Болай, беләсем килә. Минем дә эшкә керергә исәп бар.

— Унны быел бетердегезме?

— Әйе.

— Нигә соң әлегә хәтле эшкә керми йөрдегез?

— Укырга керергә исәп иде дә...

— Соң?

— Быелга кермәскә булдым.

— Эшләүне жиңел дип беләсезме?

— Нигә алай дисез?

— Үзегез әйтмешли, болай. Мин шуңа гажәпләнәм: кайберәүләр, хезмәт романтикасына бирелеп, эшләүне күккә күтәрәләр, мактыйлар.

Нигә кирәге бар аның? Хезмәт беркем өчен дә жинел булмагандыр, булмас та. Ләкин хезмәтне ярату кирәк. Чөнки кеше хезмәтсез, хезмәт кешесез яши алмый. Яши алганда кеше исемен бирмәсләр иде аңа. Мин үзем шулай уйлыйм: кеше күрке — хезмәт. Хезмәт итә белмәгән кеше матур итеп ял да итә белми. Менә мин монда атнага ике-өч тапкыр киләм. Башкача вакытым юк. Китаплар укыйм, хыялланам. Хыял ул — эш, хезмәт. Кем хыяллана белми, аның өчен яшәү дә мәгънәсез.

— Сезне мин, Гыйлаж, сөйләтеп кенә торыр идем.

— Нигә кирәге бар аның?

— О, сөйли белү — зур бәхет ул.

Гыйлаж шаркылдап көлеп җибәрде. Ул арада музыка да тынды. Без ырып-ерып үз почмагыбызга үтә башладык. Гыйлаж алдан бара, ул минем кулдан кысып тоткан.

— Калмагыз,— ди ул, әйләнеп карый да елмая.

Нәҗияләр бездән соң килделәр. Вәсил аны сынар кулы белән биленнән кочып алган да колагына нидер сөйли. Нәҗия эче катып көлә.

— Ужас! — ди ул, авызын каплый, тирә-ягына карап ала.

Кемдер аңа:

— Чибәркәй, нигә шул кадәр көләсез, тәпиегезгә шайтан бастымы әллә? — ди.

Нәҗия тавыш килгән якка күз сирпә, ләкин әйтүчене күрми, тапмый, аннары янә пырхылдап көлеп җибәрә. Вәсил аңа таба иелгән дә колагына нидер такылдый.

Гыйлаж дустының бу төчелегенә түзмәде, ахрысы, Вәсилгә дәште:

— Вәсил!

Вәсил тәкәббер төстә башын күтәрде, бер адым безгә таба атлады да, күкрәгенә кулын куеп:

— Пардон, комсорг, онытып җибәрә яздым,— диде.

Соңгы танцы. Без вальс көенә, вальс моңына илереп бөтереләбез. Бар да, хәтта өстәге лампочкалар да әйләнәләр. Рәхәт. Җиңелчә баш әйләнә. Ләкин Гыйлаҗның көчле кулы мине нык тоткан. Мин күккә, лампочкаларга карыйм, ә Гыйлаҗ күзләрен миннән алмый.

— Әнрүсә, сез кайда торасыз?

— Күп белсәгез, тиз картаерсыз.

— Шулаймыни!

— Әйе...

Вальс тына. Яшьләр төркеме бердәнбер ишеккә агыла. Гыйлаж беләгенә тасмасын бәйли. Ул минем күзләремә туп-туры карап:

— Кешеләр таралганчы көтәсеңме мине, Әнрүсә? — ди.

Мин, башымны аска иеп, аяк очларыма карыйм. Ә аякларым идәнгә нидер сыза башлый.

— Нәҗия кайда соң?

— Аның өчен курыкмагыз, Вәсил аны өенә, кирәк булса әнкәсе кулына илтеп тапшырыр.

— Көтәрмен,— дим мин, күзләремне күтәреп карарга оялып.

Гыйлаҗ ишеккә таба китә.

Мәйданның тышкы ягында кемнәрдер кычкырышалар. Нindидер бер кыз дусларына эндәшә:

— Фирдәүсәү, Гөлүсәү, сез кайдау?..

Нәһаять, халык сирәгәя. Мәйдан тирәсе бушап кала. Җир астыннан килеп чыккандай, минем каршыма Гыйлаҗ килеп баса.

— Көчкә! — ди ул, авыр сулап.— Билләһи, бу дежур көнен әйтер идем. Ярый әле атнага бер генә. Юкса... Вәсил Нәҗияне озата китте. Әйдәгез, без дә...

Мин ишеккә таба атлыйм. Мәйданнан чыгу белән караңгылык эченә чумабыз. Әле генә гөлт итеп балкып торган утлар сүнә. Ә безнең әле шактый атлыйсы бар. Күккә баксаң — йолдызлар сибелгән. Биек йорт-

лар артыннан ай кыйпылчыгы килеп чыга. Ул тонык итеп кенә без атлаган урам белән ике арадагы скверны яктырта. Сквер кин түгел. Ике яклап каен, юкә агачлары утыртылган. Юкә агачларыннан килгән бал исе борынны кытыклый. Без сүзсез генә атлыйбыз. Гыйлаҗ кулына каен ботагы алган да шуны бөтерә, әйләндерә.

— Әнрүсә, сезнең төнге шәһәрне тыңлап караганыгыз бармы?

— Нигә булмасын. Төн төн инде ул.

— Юк,— дип каршы төшә мина Гыйлаҗ,— шәһәр төннәре берсеннән-берсе аерылалар.

— Төн төн инде ул, кояш байый, ай калка, калыкмаса, күк йөзе йолдызлар белән тула. Миңа менә бу якка,— дим мин, сквердан чыгып, урам аша өч катлы йортка таба атлыйм. Гыйлаҗ янәшә килә. Ул хәзер сөйләми, әйтерсең, авызына су капкан. Шәһәр инде «сүнә» башлаган — соры төскә кереп калган өйләрнең тәрәзәләрендә бөтенләй ут юк. Тик безнең квартирада гына ут яна. Әти залда утыра булса кирәк. Без ишек алдына керәбез. Гыйлаҗ миңа кулын суза.

— Ярый, хушыгыз, тыныч йокы сезгә.

— Рәхмәт, сезгә дә...

— Димәк, эшкә керергә исәп тотасыз?

— Шулайрак.

Гыйлаҗ кулына тоткан каен чыбыгын читкә ташлады. Беравык сүзсез торды. Кемнәрнеңдер кухня тәрәзәсеннән төшкән ут яктысында мин аның йөзенә, өс-башына күз ташлыйм. Костюмы яшел. Күк күлмәк. Якасы ачык. Түшендә кечкенә генә йолдыз. Аякларында очлы башлы кара туфли. Гыйлаҗ ут яктысына эләгүен һәм минем күзәтүемне күреп алды, ахры, якты төшкән җирдән караңгыга керде.

— Менә нәрсә, әйдә...

Мин уңайсызланып киттем.

— Хушыгыз, Гыйлаҗ...

— Хушыгыз, тыныч йокы сезгә...

Гыйлаҗ үрелеп минем кулны тотты. Аның кулы, бармак буыннары кытыршы, каты иде. Күрәсең, ул физик эштә эшли булса кирәк.

«Йомшак күңелле, каты куллы егет»,— дип уйлыйм мин үз алдыма.

Залга әти янына кереп тормадым. Коридор аша үз бүлмәмә үтим дигән идем, залдан әтинең карлыккан тавышы ишетелде:

— Әнрүсә, кереп чык әле!

Залда ут балкый. Түгәрәк өстәл артында, башын ике кулы белән кысып, әти утыра.

— Утыр әле.

Ул башын күтәрмичә, өстәлгә текәлгән килеш миңа карамый гына сөйләде. Тавышы тонык, дулкынлана.

— Әнрүсә, ни, кызым, әниең китте бит...

Мин капыл тораташтай катып калдым. Уем-зиһенем аша Мөнирә апаның буй-сыны, матур күз-йөзе үтте. «Улмы, улмы бездән китте?» — дип әйтәсем килде, әтине бөкрәя төшкән җилкәсеннән кочып, юатасым килде, әмма мин урынымнан да кузгала алмадым.

— Нигә?

— Казанга китте. Бөтенләйгә... Ул юк. Ишетәсеңме, ул юк, юк! Бүтәнгә китте ул...

Әти күзләремә күтәрелеп карады. Шунда гына мин аның шактый исерек икәнен аңлап алдым. Күзләре яшьле иде...

— Ишетәсеңме, ышанасыңмы? — диде ул, пышылдап,— әниең бездән китте. Бөтенләйгә. Тагын!..

Мин: нигә «тагын?» Нәрсә дигән сүз ул «тагын?» — дип уйладым.

Әти яшьле күзләрен бер секунд миңа текәп торды да, авыр башын өстәлгә салып, ниндидер ят тавыш белән:

— Бар, ят, бар, ят, ял ит,— диде.

«Төн төн инде ул»,— дим мин, үз сүзләремне янә кабатлап. Һәр төн бер-беренә охшап килергә мөмкинме? Юк, әлбәттә. Бер кеше дә шул ук төндә ике тапкыр йоклый алмый. Ә кеше өчен һәр төннең төрле кешегә төрле булуы, һәр кешенең үз язмышына, үз тормышына бәйле булуы хак түгелме?

Күкрәк түрендә нидер сыкрый, сызлый. Ләкин кем өчен, әни өченме? Мөнирә апа өченме? Янсә, әти өченме? Төшенә алмыйм. Бу хәл, Мөнирә апаның әтидән, бездән китүе мина ни өчендер аңлаешсыз, томанлы...

Елыйсы килә. Керфекләр дымлана. Мендәргә капланып ятам. Тулышкан күцел түремнән ташкын кузгала. Ул бер мәлгә күкрәк түрендә төер булып, буасы буылып тора да күзләремнән тышка бәреп чыга. Мин кем өчен, ни өчен елаганымны да белмичә, үксеп-үксеп, туйганчы, күңелем бушаганчы елыйм. Аннары ничектер бөтен буыннарымның бушап калуын тоеп, кыйнап ташлаган кешедәй, авыр йокыга талам.

5

Кадрлар бүлегендә мине чибәр генә бер апа каршы алды. Яшь булса да, шактый юан гәүдәле, тулы йөзле һәм шактый тупас телле хатын иде.

— Сезгә ни кирәк? — диде ул, өстәлгә куйган гаризама күз дә ташламыйча, йөземә текәлде.

Мин каушый калдым.

— Чибәр икәнсез. Нигә сезгә эш эзләп торырга, артист кына буласыгыз калган. Беләсезме артистлар ничек яши? Дөнья рәхәте аларга. Күнелең — буасыз чишмә. Гомерең — асылташ, гәрәбә. Нигә сезгә шушы чибәрлегегез белән нефть иснәп йөрергә?..

Дәшмәдем.

Ул, үрелеп, телефон трубкасын алды, сөйләшә башлагач, йөзе ягымлырак булып китте.

— Кара әле, Самат, Фатихка әйт әле, кереп чыксын әле монда... Я инде, кыланып маташкан булма... Кичен, жаныем, кичен. Бәй, шулай дими. Ирен дигәч тә ул бит, жанкисәгем, ногыт чикләвеге түгел, теләсә кемнән үптерергә... Җә инде, әйт инде, кереп чыксын. Әйтәм бит, хәжәт йомышым төште...

— Сабыр итегез,— диде ул, трубканы куеп,— хәзер ЭЛОУ начальнигының үзе белән сөйләшәбез. Ана бер лаборантка кирәк иде. Шушы көннәрдә алмаган булсалар...

Кабинетка күзгә ташланырлык озын буйлы, мәһабәт йөзле, карчыга борынлы берәү килеп керде. Ул минем якка күз ташлап алды да түргә узды, өстәл почмагына утырды.

— Карале, Фатих жаным, утырма әле шул өстәл читенә, американец түгелсендер бит!

— Бәйләнмә әле, Сальма. Кәефем юк, я, ни йомыш?

— Фатих! Жаным!..— Хатын аның колагына үрелде.— Бак әле син монда...

Хатын минем якка таба ымлады.

— Картинка бит, ә! Авыз суың корырлык,— дип пышылдады ул аның колагына.

Мин шулхәтле кызардым, шулхәтле оялдым, әгәр дә аяк астымда жир булса, һичшиксез, жир тишегенә кереп китәрдәй булдым. Йөземә бәреп чыккан ялкынның кызулыгын тоеп, борылдым да ишеккә ташландым.

Минем әле беркайчан да мондый житез кешене күргәнем юк иде, өстәл почмагында утырган Фатих дигәне, күгәрчен артыннан ташланган карчыга кук, ишек бавына тотынганда мине эләктереп алды.

— Сабыр итегез, исемегез ничек?
— Әнрүсә,— диде минем урынга Сальма.
— Сабыр, Әнрүсә. Зинһар өчен, безнең сөйләшүгә игътибар итә күрмәгез. Без бит шаярып кына. Сальма — минем туганай ул.
— Фатих! Житте! — диде Сальма.
— Нәрсә житте?
— Кеше белән кешечә сөйләш. Син башлаучы.
— Мин!
— Әйе.
Сальма өстәл тартмасыннан бер кап папирос чыгарды. Ашык-пошык шырпы эзли башлады.
— Зинһар өчен, тыңлагыз, аннары китәрсез,— диде Фатих дигәне, үтенеп. Ул һаман да минем беләкне кысып тоткан иде. Мин аның кулына кагылып алдым. Ул, исенә килеп, озын бармакларын беләгемнән ычкындырды да жиңелчә генә терсәгемә кагылды.
— Үтенәм, утырыгыз, әүвәл тыңлагыз. Соң, эшкә керергә килгәнсездер бит?
— Әйе.
— Шулай булгач.
Бүлмәгә папирос исе таралды. Өстәл артындагы Сальма авызын очлайтып тартып утыра иде.
— Я, килештекме? — диде ул, миннән бигрәк Фатихка мөрәжәгать итеп.— Аласызмы кызны лабораториягә?
— Утырыгыз әле, Әнрүсә. Шәп килеп чыкмады бит әле. Сальма, зинһар өчен тартмый тор әле!
— Тартмассың сезнең белән,— диде Сальма, борсаланып алды, тар юбкасын күтәрә төшеп, тез өстенә тезен куйды. Миңа аның юан йомры балтыры, шактый тапталган, сыдырылган ак туфля үкчәсе күренеп тора.
— Безгә лаборантка кирәкми, Сальма. Әгәр дә инде сез риза булсагыз,— ул минем якка карап, мөлаем итеп елмайды, бу хәлдә аның шактый зур колак яфраклары селкенеп куйдылар,— замерщица кирәк. Әүвәл, конечно, бер ай өйрәнчек булып йөрергә туры килер. Дөрес, ул кадәр баш ватарлык кыен эш түгел, әллә ни өйрәнәсе дә юк. Ләкин тәртибе шундый.
— Мин риза.
— Вот и хорошо. Сальма, бир әле гаризасын. Александр Иванович монда чакта кул куйдырып калыйк.
Ул ничек килеп керсә, шулай жилләнеп чыгып та китте.
Сальма папирос төпчеген савытка бастырып куйды да:
— Хезмәтендә уңышлар телим, чибәр кызый,— диде.— Шәп кеше ул үзе, Фатих Гафиятович. Мәгәр бер житешсез ягы бар: хатын-кызга карата буыны йомшак. Слабоватый. Ә эшне сөя. ЭЛОУны гел автоматка көйләмәкче. Барысы да аның тәкъдиме белән... Башы түгәрәк мәртәтнең...
Сальма авызын шундый итеп турсайтты, хәтта миңа: «Мин аны, мәртәтне, шуның өчен генә сөям дә», дигән кебек тоелды.

Эшкә керүемне әти хуп күрде дип әйтә алмыйм. Ул ничектер миңа төбәлеп карады да канәгатьсезлеген белдерде, иренен бүлтәйтте. Аннары башын беравык чайкап торгач, кул селтәп чыгып китте.
ЭЛОУ. Нефтьне электр ярдәмендә сусызландыру, тозсызландыру жайланмасы. Ул кадәресен, гәрчә нефтьне күп күргән булсам да, хәтта промысел вышкаларына менеп, тирә-юньгә таң калып карап торганым булса да, белми идем әле. Соң, бер уйлаганда, нефть нефть инде ул, аны судан арындырып торуның нигә кирәге бар? Мәктәптән үк беләм:

нефть судан җиңелрәк. Ә тоз тоз инде ул. Нефтьтә тоз булыр дип кем уйлаган. Булса соң! Барыбер чан төбенә утырачак бит ул. Ләкин алай түгел икән. Тоз белән су нефтьнең җан дуслары булсалар да, кан дошманнары икән. Минем хезмәтем шул булды: эшкә киләм дә, колбалар алып, янәшә тезелеп торган икешәр катлы өй биеклек, түбәләре танцы мәйданы киңлек чаннар түбәсенә менеп, пробага нефть алып төшәм. Нефтьнең чандагы тигезлеген, түгелү чамасын үлчим, кыскасы, шул минем хезмәтем: нефтьнең пробасын алу.

Бер уйлаганда оекбаш бәйләү минем өчен авыррак кебек. Юк икән шул. Ифрат та катлаулы, җаваплы эш икән ул замерщица булу. Тотынган эшеңне җиңел итеп күрсәтүне әни мәрхүм яратмый иде. Нинди җиңел эшнең дә син күрә алмаган кыен ягы була, ди торган иде. Синең өчен җип-җиңел тоелган эшкә игътибар белән, күңел биреп тотынсаң, башлаган эшеңнең авыр икәнен шундук күрерсең. Эшне җиренә җиткереп эшләү ул — үз-үзеңне таләпчән булырга өйрәтү.

Әни, синең бу сүзләреңне мине идән юарга өйрәткәндә үк күңелемдә калдырган идем. Рәхмәт, әнием, сиңа...

Тирә-юньгә нур сибеп, кояш чыга. Башта ул Урал таулары артыннан үрелеп карый: гүя көмеш чаннарны, урман-болыннарны, елга-күлләрне, күккә үрелгән вышкаларны күреп таң кала; шушы күренешкә гаҗәп булып торгач, йомык күзләрен ачып җибәрә дә, нур чәчеп, дөньядагы бар нәрсәгә җан өрә.

Мин арыш басуы аша узган тар сукмактан ашыкмый гына ЭЛОУга таба атлыйм. ЭЛОУны болай читкә салу кемгә кирәк булды икән? Ул шактый чокырлы урынга урнашкан, ә тирә-ягында куе карурман. ЭЛОУ ихатасына терәлеп торган арыш басуы ничектер шәһәр белән авылны якынлаштыра кебек. Үзем биеклеге булып үскән игеннәр арасыннан атлавы рәхәт тә, күңелле дә. Яңа мыек җибәрә башлаган башаклар әкрен искән җилгә баш иеп серләшәләр, сөйләшәләр, гүя үзләре белән янәшә генә гөҗләп, гүләп утырган чаннарга, нефть куган моторларга сәлам бирәләр.

Капка төбендә мине Нажия каршы алды. Ул тар кара чалбар кигән. Башына җете кара төскә ал роза төшкән, кай ягы беләндер чегән хатыннарының шәлъяулыгын хәтерләткән яулык бәйләгән.

— Әнрүсә, җаным,— диде ул, мине күрү белән боргалана-боргалана миңа таба килә башлады,— кичә комсомол җыелышы булды бит. Ник килмәдең?

— Әйтүче булмаганга...

— Комсомол җыелышына чакырып килмиләр.

Нажиянең ачуы чыкты.

— Белдерүне дә күрмәдем,— дидем мин, акланырга теләп.

— Белдерү тактасын үткәндә күзең күтәреп карарга кирәк, җанкисәгем. Беләсең килсә, сиңа шелтә бирмәкче булдылар.

— Мин, чынлап та, белмәдем,— дидем мин, каушап калып.

— Шаярма,— диде Нажия, имән бармагын күтәреп, башын кырын салып, мәгънәле итеп елмайды,— шаярма, Әнрүсә җанкисәгем. Әйт әле, кинода булырга каян таптың вакыт? Ә! Шулай диген... Сөйгән егетеңә отказать итә алмадым диген...

— Минем бер егет белән дә кинода булганым юк.

— Тик тор, тутый кош! Зинһар өчен тик тора күр!

— Нажия!

Мин, кабарган ачуымны кая куярга белмичә, китә башладым. Нажия, минем каршыма төшеп, биленә таянды.

— Әйт әле, Басил белән булдыңмы?

— Кайчан, кайда?

— Сина ул билет алдымы, әллә син аның үзен чакырдыңмы?

— Нажия!

— Юк, юк. Тукта, әйт әле син миңа шуны. Васил җыелыштан соң кинога китте. Син чакыручымы аны?

Мин, чынлап та, кинода булган идем. Васил белән. Ләкин мин кинога Васил чакырып бармадым. Мин килгәндә билетлар беткән иде инде. Каршыма Васил килеп чыкты. Кулында ике билет. Артык билетым бар, диде. Әйдә керәбез, диде. Мин риза булдым. Васил кино буе минем кулымнан тотарга теләде. Чыгып китәм дип куркыттым. Әлбәттә, Нажиянең белмәве әйбәтрәк иде дә бит. Ни хәл итәсең, ул инде барысын да ишеткән. Күрәсең, Васил үзе сөйләгәндер. Нишләргә соң? Дөресен сөйләп бирергәме, әллә яшерергәме?

— Дәшмисең? — диде Нажия, ачуы чыгып.— Ярый, хуш...

Һәм ул борылды да иңбашларын уйнаткалап китеп барды.

Әле генә сөенеч-шатлык белән тулы күңелем әллә нишләп китте, эчем поша башлады. Сменамны Фәйрүзә ападан кабул итеп алдым да чаннарга таба киттем. Иң олы чанның баскычы буйлап менгәндә башым әйләнгәнен тоеп, беравык тукталып, йөрәгемнең шашынып тибүен тыңлап тордым. Шәп килеп чыкмады бит әле бу.

Пробалар алып, нефтьнең биеклеген үлчәп төштем. Тагы башым әйләнгәнен тойдым. Нәкъ шул чак каршыма Гыйлаҗ килеп чыкты.

— Исәнме, Әнрүсә!

— Саумысыз...

Мин китә башлагач, Гыйлаҗ мине туктатып:

— Ашыкма,— диде.

— Сезгә ни кирәк миннән?

— Сүзем бар.

Гыйлаҗ — ЭЛОУ цехының комсоргы. Әлбәттә, ул минем ни өчен комсомол җыелышында булмавым белән кызыксынырга тиеш. Ләкин нигә хәзер сорый ул?

— Әнрүсә,— диде Гыйлаҗ, чаннарга күз ташлап,— мин сиңа ышана идем. Сине җыелышта комсомол прожекторына сайларга исәпләгән идек.

— Нигә мине, беткәнмени тәҗрибәле кеше? Аннары, гомумән, нигә дип бәйләнәсез әле сез миңа? Килмәгән, килмәгән, димәк, сәбәбе булган.

Шулай дип китеп бардым. Гыйлаҗ баскан урынында катып калды.

Смена азагында минем янга мастер Гали абый килде.

— Әнрүсә, кызым, түбән төшеп задвижкаларны карап кил әле. Васил, шайтан, кайтып китәргә дә өлгергән. Пульттан күрсәтми,— диде ул, үтенеп.

Чаннардан нефтьне үз агымы белән җибәрә торган задвижкаларны тикшереп, карап чыктым. Дүртенче чанның задвижкасы ябык, күрәсең, автомат ача алмаган. Чанның ташып китүе бар. Мин дүртенче чан янына йөгердем. Өске капкачтан кара тасма кук нефть агып ята. Мин задвижканы ача белмим. Аяк астында вак таш. Аркылы-торкылы сузылган торбаларны әле сикереп, әле астан үтеп, пульт баскычына йөгердем. Мастер Гали абый анда иде.

— Гали абый, дүртенче чан ташый!

— Поступлениене яп,— диде ул, пульт каршында утыручы Гыйлаҗга. Гыйлаҗ миңа әйләнеп карамыйча гына ниндидер төймәгә басты. Кызыл, яшел кечкенә лампочкалар белән тулган щит гөҗләп куйды. Аннары дүртенче чан рәсеме төшкән турыда кызыл лампочка кабынды.

— Ачып кара,— диде Гали ага Гыйлаҗга.

Гыйлаҗ бер туктаусыз диярлек задвижканы ачу төймәсенә басты.

— Эшләми, алмый,— диде ул.— Барып карарга кирәк. Васил кайда?

— Ярый, мин аны үзем җибәрермен,— диде мастер һәм чыгып китте.
— Утырыгыз,— диде Гыйлаж, каршы яктагы агач диванга күрсәтеп.
— Рәхмәт,— дидем мин, борылып чыгып та киттем.
«Ни дип бәйләнәләр әле алар миңа? — дип уйладым, проходнойга таба атлый-атлый.— Җыелышка килмәгән өченме? Васил белән кинода булган өченме? Соң бит, Әнрүсә килмәгәннән җыелыш булмыйча калмаган. Әйтмәделәр ич. Белдерүне күрмәдем».
Проходнойны үткәндә мине цех начальнигы Фатих Гафиятович туктатты.
— Миңа кереп чык әле, Әнрүсә.
Мин кечкенә бүлмәдә, цех начальнигының кабинетында, диванда утырам.
Фатих Гафиятович, гадәтенчә, өстәл почмагында.
— Әнрүсә,— диде ул, карчыга борынын тартып куеп,— эшләр ничек бара?
— Ярыйсы болай, өйрәнәм, рәхмәт.
Фатих Гафиятович, урыныннан торып, ишекле-түрле йөренә башлады. Ул иягеи учлап тоткан да ни турындадыр уйлый иде.
— Кичә бездә бик зур үзгәреш булды бит әле, Әнрүсә. Гыйлаж тәкъдиме белән сине диспетчер итеп күчерергә булдык.
— Сез көләсез, Фатих абый.
— Көләм!
Ул туктады да сәерсенеп миңа карап торды.
— Ярый,— диде ул, тиз генә өстәл артына кереп утырды. Ярый. Димәк, теләмисез?
— Мин нибарысы бер ай эшлим монда.
— Бер ай аз гомер түгел. Аннары, сине бит бүген үк пульт артына утыртырга җыенучы да юк. Идарә каршында курс ачыла, шунда йөрерсең. Әлбәттә, эштән соң. Өч айлык, аннары...
— Өч айлык!
— Син нәрсә, әллә пульт артында утыруны курчак уйнау дип беләсеңме? Соң, шулай булгач... димәк, риза?
— Уйлап карармын.
— Ярый, иртәгә кереп әйтерсең. Әгәр син риза булмасаң, бүтән кандидатура эзләп карарбыз. Сөйләштекме?.. Вәгъдәме?
— Сөйләштек.
— Сөйләшкәч, булды.

## 6

Соңгы көннәрдә эти белән бергә утырып ашарга да туры килми башлады. Эти кичләрен өйдә булмый, ә мин көнозын эштә. Бүген ял көне. Эти иртә таңнан торган да, буйлы пижамын киеп, диванда утыра. Бер ноктага карап уйга чумган.
— Әнрүсә,— диде ул, миңа карамыйча гына,— тамак ялгарга берәр нәрсә әмәлләсәң иде.
Мин кухняга чыгып бәрәңге әрчим, чәй куям һәм, эти янына кереп, итебез юк, дим.
Эти укып утырган газетасын читкә куя да ашыкмый гына киенә. Киенеп беткәч, мин аңа сумка тоттырам.
Күңелсез, эч поша. Нигә булыр икән бу? Мин урам як тәрәзә буенда басып торам. Каршыда — ашханә. Анын ишеге бүген ябылмый диярлек. Эш көннәрендә мин дә, эти дә гел шул ашханәдә ашый идек. Бүген нигәдер этинең өй ашы ашыйсы килеп киткән.
Кояш кыздыра. Эссе. Су керәсе, рәхәтләнеп комда кызынып ятасы иде. Урамнан Васил үтеп бара. Миңа ул безнең тәрәзәгә күз ташлады.

Мине күрдә дә күл болгады. Мин елмайдым һәм әйдә безгә кер дип аңа кул изәдем. Ул беравык туктап торды да безнең йортка таба йөгерде. Бераздан коридорда аның аяк тавышын ишеттем. Нигәдер йөрәгем катырак тибә башлады. Үзем дә сизмәстән, ишеккә таба киттем.

Ишек шакыйлар.

— Керегез!

Аркылы зәңгәр буй төшкән, ачык якалы, кыска җиңле күлмәк кигән Васил килеп керде.

— Хәерле иртә, туташ!

— Мин сиңа нинди туташ булыйм ди?

— Я, ярар ла,— ул кулын селкеп куйды,— бәйләнергә генә торма әле. Су коенырга барасыңмы? Соңгы автобус унда китә.

— Барасы иде. Ләкин мин ашамаган бит әле.

— Буфет була анда.

Василнең йөзе шундый ачык, шундый ышанычлы, гади күренде, мин йөгереп үз бүлмәмә кердем. Тиз генә коену костюмы кидем дә, җиңел җәйге күлмәгемне элеп, башыма әниемнең киң читле эшләпәсен чәпәп, Васил каршына килеп бастым.

— Булдың да!.. Йөгердек, автобус китеп барыр.

— Тукта.

— Йөгереп кухняга кердем, газны сүндердем.

— Әйдә!

Икешәр баскыч аша сикерә-сикерә, ашыгып урамга чыктык. Карасам, сумка тотып әти кайта.

— Әнрүсә, син кая барасың?

— Су коенырга.

— Тамагыңа ашадыңмы хет?

— Анда ашармын әле.

Әти яныннан йөгереп үтеп киттек. Әтинең күзенә чалынып калган йөзе елмая, әчке бер куаныч, шатлык белән елмая сыман тоелды. Белмим, бәлки, ул минем кинәт үсеп китүемә, әни кебек сылу булуыма куангандыр.

Васил чиратны ыра-ера кассага таба китте. Мин, бакча рәшәткәсенә таянып, аны көтеп торам. Бакчада бер миләш шундый таралып үскән, шундый нәфис, шундый матур итеп каенга сарылган, гүя ул каеннан башка үсә алмас, кояш күрә алмас кебек.

Күлмәгенең ике сәдәфен өздереп, ике билет тотып, Васил килеп җитте.

— Фу-у, мәхшәр! Көчкә!.. Күрәсеңме, чак кына чишендермәделәр. Булавкаң юкмы?

— Юк бит...

Автобуска утырабыз. Мин тәрәзәдән карап барам. Күк йөзе чиста, аяз һәм шундый саф, ихтыярсыз күңелем күтәрелеп китә.

— Һава бүген бөтен болытка ультиматум куйган. Сыңар болытка да рөхсәт итмәгән. Димәк, көн нәкъ су коена торган. Ә нигә син, Әнрүсә, теге атнада төшмәдең? Шул хәтле халык күп булды. Ык буена болыт төшкән диярсең. Берәү батты да бугай. Мин үзем күрмәдем, Гыйлаҗ күргән. Ул чыгарышкан.

— Әллә үлгән?

— Юк, пиво дип белеп, Ык суын эчкән.

— Шаяртмасана...

— Билләһи менә...

Автобус кузгалып китте. Васил минем колагыма пышылдап:

— Синең ашыйсың килә инде, әйеме? — диде.

— Курыкма, сине тотып ашамам. Ул дәрәҗәгә җитмәдем әле.

Васил, күзләрен зурайтып, бер мәл карап торды да шаркылдап көлеп җибәрде.

— Үтердең бит, Әнрусә, билләһи менә... Один — нуль...

— Нигә, әллә котың алындымы?

Минем күңелем шат иде бүген, ни сөйләсәм дә урынлы иде.

Автобус төчкерә-төчкерә түбән төшә башлады. Мин тагын күккә карадым. Алгы яктан кояшны каплап кара болыт килә. Ул хәтта көнне дә караңгылаткан кебек тоела иде. Тик борынны ярып кергән ачы ис кенә моның болыт түгел, нефть калдыкларын яндырганнан күтәрелгән төтен икәнен аңлата иде. Ул, чокыр буеннан бөтерелә-бөтерелә, айкала-айкала, күккә күтәрелә, үзенең афәт күренеше белән күңелгә әллә нинди куркыныч шом сала иде. Тәрәзәгә карап торган Васил, нидер исенә төшеп, әйтеп куйды:

— Шушы төтен өчен миңа эләгә язды.

— Нинди төтен өчен?

— Әнә бит — яна. Бер уйлаганда коточкыч. Үткән елны ЭЛОУдан чыккан нефть калдыкларына ут төрттеләр. Пожарниклар үзләре дә шунда иде. Тирә-юнь күренмәс булды. Теге шулкадәр кызды, домна миче кебек, улап яна башлады. Ерак та түгел, скважинада труба үткән иде. Яна-яна шул җылынып шартламасынмы! Җиде шәһәрдән җитмеш машина килде. Су сипкән саен котырыбрак яна. Унбишләп бульдозер җир белән күммәкче булдылар. Халык җыелды — сабан туе диярсен. Кулларында көрәк тә чиләк...

— Шуннан?

— Шуннан шул: мең бәла белән сүндерделәр, дөресрәге, сүндердек.

...Елга тугае җылы яклардагы Кара диңгез буен хәтерләтә. Кая карама — палатка да буфет. Башта без буфетка кереп, кайнар котлет капкаладык, күбекләнеп торган газлы су эчтек.

Су коенучыларның чыр-чуы яр буйларын яңгыратып, Нарыш тауларына җитә кебек. Кем генә юк монда! Васил бик оста йөзә икән. Ул шамбы балыгыдай шома, кояшта янып, ялтырап торган тыгыз тәнле. Елганы дүрт-биш тапкыр йөзеп чыкты. Безнең Ык шундый ул: диңгез кебек сине өстә тотарга теләми. Йөзә белмәгән кеше, кургаш кебек, су төбенә төшеп китә. Мин үзем бик оста йөзүчеләрдән булмасам да, ирләрчә нык йөзәм, озак итеп су төбендә торам. Мине моңа мәрхүм әнием өйрәткән иде. Әле булса хәтеремдә. Бер тапкыр шулай су коенырга төштек. Әти белән әни, су коена-коена, куышып уйнарга тотындылар. Әни суга чумды, аның артыннан әти. Миңа ул секундлар бер гомер булып тоелды. Әни дә, әти дә юк. Мин елый башладым. Бераздан әтинең башы күренде. Ул пофылдап сулу алды да тирә-ягына каранды. Әнине күрмәгәч, миңа: «Әнием тагын чумдымы?» — дип кычкырды. «Юк»,— дидем. Әти тагын чумды, тагы чыкты, Әни юк та юк. Шуннан соң ул бар көченә, бар тавышына кычкырып җибәрде. Су астындагы әни моны, бәлки, ишетмәгәндер дә. Ләкин ул шул минутта дияр лек су астыннан калкып чыкты. Ул чакта мин яр башын бер итеп үкереп елый идем инде. Алар чыктылар да, берни булмаган кебек, мине юатырга тотындылар. Әти генә әнине шелтәләп: «Баланы куркыттың, юньсез, шул гомер торалармыни?» — дигән булды.

... Яр башында әкәм-төкәм, бака кабырчыклары белән аралашкан вак кына күксел ком. Мин кайнар комны алам да бала йоннарым кабарып торган тәнемә коям. Рәхәт! Васил йөзтүбән яткан, бармак араларыннан «тегермән тарттыра».

— Әнрусә,— ди ул, миңа күтәрелеп карамыйча гына,— ничек, эшең ошыймы?

— Белмим, Васил. Иялəндем инде. Мин хәзер эшләми тора алмам кебек.

Мөсәгыйть Хәбибуллин ◆ Унсигезенче яз ◆

Вәсил чалкан әйләнеп ята. Аның бөтен тәненә ком ябышкан.

— Минемчә,— ди ул, кояштан күзләрен каплап,— эш-хезмәт дигән булып, без бер нәрсәне аңлап житкермибез.

— Нәрсәне?

— Ял итә белмибез...

— Әйттең сүз! Әле соң, хәзер нишлибез без?

— Әнрүсә, зинһар өчен көлмәгез.— Ул тагын әйләнеп ятты.— Мин ял итүне су коенуга гына кайтарып калдырырга теләмим. Син үзең дә аңлыйсың аны. Минемчә, кеше иң әүвәл рухи ял итәргә, ял итүнең рәхәтен таба белергә тиеш.

— Аңламадым, ачыклабрак әйт әле,— дидем мин, көтеп. Ул миңа бу минутта матур сүзләр белән ялтырап күренергә тырыша сыман тоелып китте.

Вәсил кинәт торып утырды:

— Бездә, яшьләрдә дип әйтүем, көч-энергия ташып тора. Без шул көчне кая куярга белми аптырап йөрибез. Нефть чыгару, планны тутыру гына әле ул тулы тормыш белән яшәү дигән сүз түгел. Син бит жырчы-артистка булырга теләгән идең.

— Буш хыял булган ул, Вәсил.

— Буш хыял булган?! Кызык! Ә син тырышып карадыңмы соң? Төн йокыларын йокламыйча өйрәнеп карадыңмы? Юк, дисең. Юк шул менә! Мин сине аңлыйм. Миннән артист чыкмады, бер күренүгә башка сукты-лар, әйеме? Ярый, ди, булмады, ди, алмадылар, ди. Опера артисты чыкмады, ди синнән. Чыкмаса соң — шуннан дөнья бетканмени! Ә нигә үз тиңнәрең алдында жырламаска? Берәүләр сине тыңлап рәхәт табар иде, ә син аларга биргән рәхәтеңнән бәхетле булыр идең. Менә нәрсә ул — рухи ял итү.

— Ә синең үзеңнең хыялың бармы соң? — дидем мин, бераз тын утыргач.

— Минем тормыш башкачарак булды. Әгәр мин, синең кебек, бер-рәттән унны бетергән булсам, белер идем нишләргә икәнен. Миңа унбиш тулганда әти үлде. Әни беркайда да эшләми иде. Кичке мәктәпкә күчәргә, эшкә керергә туры килде. Нинди уку инде ул — көне буена эшләп арыйсың, дәрес тыңлаганда хет керфекләргә шырпы терәтеп куй. Үтте инде. Чыгарыш кичәсендә дүрт өчлемне ярты белән юдым да — вәссәлам! Беренче эчүем түгел иде. Мәгәр исергәнмен. Утырып жылага-ным; кемнедер ни өчендер сүккәнем хәтердә. Шул. Көз көне политехни-ческийга барып карадым. Беренче экзаменнан ук бәреп төшерделәр. Акча туздырып кайтуым гына булды. Кайткач ачудан эшкә тотындым. Жыелышларда житешсезлекләрне ярып салам. Кайберәүләр моны ярат-мадылар. Кырын карый башладылар. Гали ага галәмәт эчә иде бит. Шул юлдан кәкре эшләр дә эшләп ташлый иде. Газетага, цех «Чаян»ына язып бетердем. Шуннан соң исәнләшми башлады. Бер мәл жай китереп шелтә бирдертте. Әнә шул нефть калдыклары өчен Фатих абыйдан әләкте. Ә безнең нефтьнең кая киткәнен үзең беләсең — «Дус-лык» магистраленә китә бит. Йөзгә оят килмәсен өчен, чиста нефть жибәрергә кирәк. Ләкин нефтьне жылытып житкермичә тону чаннарына жибәреп тә саф нефть алып була. Бездә кайчак шулай итәләр дә. Моны Фатих абый бик яхшы белә. Ләкин — план. Промыселлардан килгән ничәмә процентка якын нефтьне, чистартып бетермичә, «дегет күленә» түгәбез. Мин жүләр, тоттым да район газетасына яздым. Китте тикшерү дә төпчену. Таптылар, гаепләләргә шелтә әләкте, ә миңа диспетчерлык-тан китәргә туры килде. Бер гаепсезгә «пульт» эшеннән алдылар, дип жалоба биреп булмый бит инде. Ә минем урынга Гыйлажны куйдылар. Мин, янәсе, булдыра алмаганмын. Менә кайда ул синца дөреслек. Мин

дә көрәшеп карадым. Булмады. Соң, кайчан бер тарыдан ботка пешкәне бар?.. Коллективка ачуым юк минем. Бәлки, аларның күбесе мине аңлап та бетермәгәндер. Соныннан мине яклап идарәгә чаклы баручылар булган. Фатих абыйны беләсең ич син. Эшен эшли, сәләтле, әмма хәйләкәр. Белмим тагын, бәлки аның да планны тутырасы киләдер. Кемнең соң оятка каласы килә. План ул — дәүләт эше. Ләкин нәрсә исәбенә тула соң ул! Халык көчен, халык байлыгын җилгә очыру исәбенәме?

Арканы кояш өтә башлагач, әйләнеп утырдым. Искитәрлек хәл. Васил минем күземне ачкандай булды. Гүя мин әлек цехка сукыр көйгә килгәнмен, берни күрми, берни белми, кушканны гына эшләп йөргәнмен, гүя ияреп йөрүче генә булганмын. Ул миңа нефть турында, электр ярдәмендә нефтьне ничек судан аерулары турында, шуңа карамастан, һаман әле нефтьнең әрәм булуы турында, аерылып бетмәве турында сөйләде. Аннары ул урыныннан сикереп торды да үрелеп минем кулдан эләктерде.

— Коенып чыгабызмы?

Тәнне рәхәт оетып агым су ага. Васил минем белән янәшә йөзә. Ул миннән бер туктаусыз сорый тора:

— Әнрүсә, арымадыңмы?

— Нишләп арыйм ди мин.

— Әнә теге талларга җитә аласыңмы?

— Кирәк булса, арырак та китәрмен...

— Ай-һай,— ди Васил, үзе житез генә селтәнеп мине уза да, таллар янына барып, суга ятып үскән тал ботагына тотына.

Мин дә тал ботагына килеп тотынам. Еш-еш сулыш алам, аякларым белән су төбен эзлим.

— Болайрак кил,— ди Васил, бер кулымнан эләктереп, яр кырыенарак китерә. Ниһаять, минем аякларым йомшак ләмгә тия. Мин басам, ләкин судан муеным гына күренеп тора. — Тагын чыга төш, миңа бу ботакка тотын,— ди Васил.

Минем аякларым шактый каты җиргә тия. Судан күкрәгем калкып чыга. Сулыш алырга җиңел булып китә. Васил юеш чәчен селкеп, кара күзләрен йомып ала. Аның кин кара кашлары кушылып китәләр. Җәйпәк, түгәрәк бит-йөзе гел хәрәкәтләнеп тора.

— Әнрүсә, әйдәгез, капкалап алыйк. Югыйсә, минем урта авылда эчләр өрә башлады.

— Әйдә...

Без каршы ярга таба йөзәбез. Кояш, уч иткәндәй, бүрек хәтле генә болыт астына кереп поскан. Ярга менү белән мин калтырана башладым. Суык булып китте.

— Әйдә, йөгердек,— диде Васил һәм без күз иярмәс тизлек белән алга омтылдык. Мин нәрсәгәдер абынып киттем дә мәтәлчек атып барып төштем. Күз алларым караңгыланып, акылым җуйган кебек булдым. Күзләремне ачсам — Васил мине күтәреп тора. Мин, теләсәм дә, теләмәсәм дә, аның муенына сарылдым.

— Бик нык бәрелдеңме?

— Юк ла. Җибәр мине, төшер.

Аның кайнар сулышы минем битемне кытыклый.

— Җибәр, төшер мине, Васил!

Ул мине җиргә бастырды. Берничә кеше безне уратып алды.

— Ни булды?

— Берни дә юк,— дидем мин, Василгә тотындым да аксый-аксый китеп бардым.

— Бу бер дә шәп булмады,— диде Васил,— шул хәтле чапмасаң соң... Сынган җирең юктыр бит?

— Берни дә юк. Тез капкачым гына азрак авырта.

Цехта һәрвакыт гуләү, гөжләү тавышы. Килгән мәлне газ исе җанга тия торган иде, инде күнегә башладым, аны-моны сизмим. Сырлы баскычтан менеп «проба» алам да колбаларны лабораториягә Нәҗиягә китереп бирәм. Ул пробаларны өлкән лаборанткага тапшыра. Өлкән лаборантка пыяла колбаны электроплита өстенә куя. Берничә секундтан колбадагы нефть кайный, фракцияләр аерыла башлый. Булган нәтиҗәләрне мин мастер Гали агага китереп бирәм. Чак кына нефтьтә тоз яки су күбрәк булса, мастер нефтьне чистарту процессын автомат белән идарә итүче Гыйлаҗ янына керә.

— Дисолванны арттыра төш,— ди ул, боерып. Вәсил дә эшчеләр арасында. Хәзер ул слесарь-автоматчик.

Су коенганнан соң минем аны күргәнем юк иде әле. Ул ничектер ябыгып, сулыгып киткән. Ишек төбендә басып торган арада минем янга килде.

— Исәнме, Әнрүсә!..

— Саумы, Вәсил...

— Хәлләрең ничек?

— Бер көйгә... Үзең ни хәлләрдә ятасың? Күзгә-башка күренмисең.

— Бигайбә. Соңгы көннәрдә вакыт җитми башлады әле. Клубка репетициягә йөрим. Артист ясадылар бит мине. Син дә кил, Әнрүсә, син бит бик матур җырлыйсың.

— Көлмә инде...

— Нигә?.. Көлмим мин. Чынлап әйтәм — кил. Бүген үк...

— Кич укырга йөрим шул мин.

Гали ага миңа җиденче чаннан проба алырга кушты. Мин китеп бардым. Киткәндә янә бер артыма борылып карадым. Берет астыннан кара чәче чыгып торган, төп кебек бәләкәй таза гәүдәле Вәсил, ачкычлар тутырган сумкасын асып, елмаеп басып тора иде.

— Кил, яме! — диде ул, кул болгап калды.

Гали ага безгә әйтте:

— Кызлар, бу айда премиядән мәхрүм калабыз, ахры,— диде.— Ай бетәргә нибары биш көн калды, ә мең тоннадан артык нефть чистартасыбыз бар. План тулуга бер дә охшамаган...

Ә Фатих Гафиятович әйтте, ни генә булмасын, планны үтәрбез, диде.

Гали ага пульт артында утырган Гыйлаҗга күзләрен тасрайтып карап куйды.

— Әйе, сезгә ансат,— диде Гали ага һәм, кулын селтәп, лабораториягә китте. Мин аңа иярдем. Безгә каршы лаборантка Ләйсән килә. Аның төсе качкан, күзләре урыныннан купкан.

— Гали ага, соңгы пробада су артык, тоз да 50 миллиграммнан өстә, нефтьнең чагыштырма авырлыгы түбән, нишләп алай?

Гали ага күзләрен читкә алды.

— Фатих Гафиятович шулай кушты. Нефть кудыручылар белән үзем сөйләштем, диде.

Ләйсәннең ачуы йөзенә чыкты.

— Гали абый, хәзер үк режимны үзгәртегез, ишетәсезме?..

— Тавышланма әле, кызый... Начальство сүзеннән ничек чыгыйм ди мин... Әнә үзе кайтыр, аңлашырсыз, сөйләшерсез, көйләнер...

Ләйсән иренен кысып, каш астыннан карап торды да, борылып, лабораториягә кереп китте. Мин дә аның белән кердем.

— Нәрсә язып бирим мин аларга... Ялган документмы? — диде ул, гасабиланып. Һәм түр якка үтте.

Ләкин шул ук чаннан китергән соңгы пробаның анализы әйбәт иде. Ләйсән тынычлана төште.

— Әллә үткән анализда ялгыштыкмы? — дип сорады ул күршесендә утыручы Нажиядән.

— Кем белә инде аны, Ләйсән Хафизовна.

— Ничек инде «кем белә»?! Синең белән мин белергә тиеш аны, Нажия... һәм бик яхшы, төгәл белергә тиешбез. Гаҗәп тә кыз син, Нажия... Сиңа һәрвакыт барыбер...

Нажия үпкәләп, күзләрен идәнгә текәде.

— Мин сезгә ни әйттем соң әле, Ләйсән Хафизовна...— Нажиянең тавышы калтырап китте,— минем ни гаебем бар...

— Без, Нажия, һәр чанның анализына башыбыз белән җавап бирәбез... Беләсеңме син шуны, юкмы?! «Дуслык» нефть үткәргеченә китә торган «кара алтын» безнең кулдан үтә. Республика намусы...

Ләйсән мин китергән пробаларны алды да җылытырга куйды.

— Тагын бер тапкыр тикшерик әле. Бу — шул иртән алган сигезенче чаннанмы?

— Әйе...

— Бар әле, Әнрүсә, тагын бер тапкыр алып кил әле. Монысын урта катламнан ал. Әллә нигә күңел шикләнә...

Мин чан түбәсенә мендем дә савытларга өч катламнан да проба ала башладым.

Сигезенче чан урман буенда ук. Ул ничектер читтәрәк, аерым тора. Башка чаннарга караганда икеләтә артык нефть сыя аңа. Биек тә соң үзе. Җиде катлы өй түбәсенә менгән кебек хис итәм үземне. Рәхәт. Әнә шәһәребез. Ул ике тау арасына кереп утырган. Цехның сул ягындагы иңкүлектә — «дегет күле». ЭЛОУ эшчеләре цехның «нефть тоткычын» шулай диләр. Нефтьне судан һәм тоздан арындырганнан соң, ташландык нефть фракцияләрен, реагентларны шунда агызалар. Тулып ташып китә башлагач, аңа ут төртәләр. Өсте яна. Ай, афәт булып яна да соң үзе ут төрткәч! Тирә-юньне төтен болыты каплый. Мәхшәр килгән диярсең. Ямьле көннең ямен ала.

Чан түбәсеннән төшим дигәндә генә, баскычтан ашыга-ашыга Вәсилнең менгәнен күрдем.

— Һай, әйбәт икән монда! Нинди хозурлык!.. Карале, Әнрүсә, һәр көнне менәсеңме син монда?

— Чаннар түбәсенәме?

— Әйе.

— Сменага ун-унбиш тапкыр...

— Оһо! Ару гына йөрисең икән... Курыкмыйсыңмы?

— Юк...

Вәсил үзе минем белән сөйләшә, күзләре «дегет күле» ягында.

— Карале, Әнрүсә, кичәгенәк күл өсте ялтырый идеме?

— Ялтырый иде.

— Ялтырый идеме? — дип кабат сорады ул.

— Менә бер атна була — шулай инде ул... Аннары аны яндыралар...

— Анысын гына беләбез...

Вәсил, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, кабаланып баскычка таба китте, ләкин кисәк туктап, миңа таба борылды.

— Кая, савытларыңны үзем алып төшим...

Төштек. Вәсил колбаларны кулыма тоттырды да:

— Әнрүсә, бар, бу савытларыңны тапшыр да буш колбалар алып кил монда. «Дегет күле» янына барып киләбез. «Прожектор» заданиесе буенча...

— Без аннан айга бер генә анализ алып торабыз бит...

Вәсил миңа шундый итеп карады, мин «ярый соң» дигәнемне сизми дә калдым.

Сигезенче чаннан икенче тапкыр алган пробаларны Ләйсәнгә калдырдым да, икенче савытлар алып, Вәсил янына йөгердем. Мин килгәндә, ул цех ихатасы янында тора иде инде.

— Сикереп төшә алырсыңмы?

— Нигә капкадан чыкмыйбыз соң? Күрсәләр, ни әйтерләр...

— Күрсеннәр. Моннан якынрак, урап йөрисе килми. Әйдә, мин сине җилкәмә бастырам. Курыкма.

Ул мине җилкәсенә бастырды да җай гына койма башына менде. Һәм шундук җиргә сикерде. Аннары кулларына алып мине дә төшерде. Миңа сикереп төшәргә дә булмады. Көчле дә соң бу Вәсил!

— Ярый әле — чәнечкеле тимер чыбык тартмаганнар, юкса ничек чыгар идек,— диде ул.— Кайтканда проходнойдан керербез.

Вәсил башындагы беретын сыдырып алды да тир бәреп чыккан битен, маңгаен сөртте.

— Нигә без анда барабыз?

— Әйтәм бит, комсомол «Прожекторы» заданиесе бу. Айның соңгы көннәрендә промыселлардан килгән нефтьнең чыгышы бермә-бер диярлек кими. Шикле нәрсә бу. Планны үтәргә тырышып, кайчак нефтьне җылытып җиткермиләр, нефть аерылып җитми, су һәм реагентлар белән «дегет күленә» китә.

— Ә син ни эшләмәкче буласың?

— «Дегет күле»ннән анализ алабыз.

— Аны бит болай да алып торабыз...

— Айга берме? Ул да күз буяу өчен генә... Цехтан агып килгән җирдән алырга кирәк. Ә сез әнә каян аласыз. Кушылып беткәч...

Без «дегет күле» янына килеп җиттек.

— Каян ала идегез проба?

— Әнә баскычлар...

Мин цехтан килгән торбалардан йөз метрлар арырак торган тимер-бетон баскычларга күрсәттем. Мин килгәндә ул баскычлар тимердән иде. Алары янды. Шуннан соң Фатих Гафиятович тимер-бетон баскычлар куйдырды.

— Юк, чыккан җирдән алырга кирәк,— диде Вәсил.— Китер колбаларыңны?..

Вәсил минем кулдан колбаларны алды да, дегет һәм парафин сеңеп беткән яр буйлап, цех ягыннан чыгып торган ике торба янына төшә башлады. Аннан нефть катыш болганчык су агып ята иде.

— Вәсил, таеп китсәң, батасың бит!

— Батсам, коткарырсың.

Менә ул, итек үкчәсе белән эз ясый-ясый, торба янына җитте. Бер колбага агып яткан сыекчаны тутырып, чокыр ясап утыртып куйды, бөкесен тыкты. Әкрен генә икенче торба янына үтә башлады. Ләкин капыл шуып китеп, бил тиңентен «дегет күле»нә чумды. Мин «аһ» иттем.

— Курыкма, Әнрүсә, тирән түгел икән. Мин хәзер...

Ул, лайлалы су катыш нефтьне ерып, икенче торбага җитте. Колбасын тутырып алып чыга башлады. Ярга менеп җиткәч, өс-башына күз ташлап, көлеп җибәрде.

— Менә мин хәзер чын нефтьче инде. Чалбар биш килога авырайды. Ярар, хәзер кайту белән душка кереп, өсне алыштырырмын,— диде ул.— Киттек!

— Әйттем бит мин сиңа, таясың, дидем.

— Син күз тидерден, юкса таймый идем, күрәзәлегең бар икән,— диде ул, елмаеп.

— Тәнен янмасмы соң, гел кислота бит анда?

— Янса тагын... Социализм өчен көрәшеп үлде, диярләр.

— Туктале, бу кыяфәтең белән син лабораториягә ничек кайтасың?

— Хәзер чалбарны салам.

Ул, минем кып-кызыл булып кызаруымны күреп, тынычландырырга ашыкты:

— Курыкма, ике кат ул минем! Әйдә тизрәк.

Колбаларны ул Ләйсәннең үз кулына тоттырды.

— Ләйсән Хафизовна, бик тиз генә шушы колбалардагы сыекчаларның анализын алыгыз әле.

— Нәрсә бу?

— «Дегет күле»ннән...— диде Васил, житди генә.— Комсомол «Прожекторы»на.

— Ә-ә,— диде Ләйсән нидер аңлагандай һәм колбаларны алып, түр якка кереп китте.

Васил чыгып киткәч, Нажия, иренен бүлтәйтеп, миңа карап торды.

— Бик тиз алыштыра башладың әле син, Әнрүсә, егетләрне.

— Көлмә әле, Нажия. Васил комсомол «Прожекторы» заданиесе белән йөри. Ә мине ярдәмчесе итеп алды. Шул...

— Шул гынамы икән?..

— Нажия!..

Ләйсән әйләнеп керде.

— Куйдым. Ә сигезенче чанның анализлары әйбәт. Гажәп. Мә, Әнрүсә, Гали агага анализларны бир, режимны шулай тотсын, үзгәртмәсен...

Мин диспетчерлык пунктына киттем.

Гали ага анализларны алып папкасына салды, миңа күтәрелеп тә карамады.

Мин янә лабораториягә килдем, яңа колбалар алып, унберенче чанга таба киттем. Бүген ул тулган иде. Гали ага әйтмешли, аның «кара алтын»ын нефть эшкәртү заводларына кудыручы станциягә озатырга тиеш идек. Фатих Гафиятович чанның анализларын икенче вахтага өлгертергә кушкан. Гали ага ашыктырды.

— Тиз йөре, Әнрүсә, бер аягың монда, икенчесе анда булсын,— диде.

Кадала-каплана унберенче чанның түбәсенә мендем. Колбаларны тутырдым да төшә башладым. Каршыма Гали ага килеп басты.

— Әнрүсә, бу чанның анализларын алмый тор, иртәгә алырсың. Тагын бер тәүлек тонырга тиеш дип әйтте Фатих Гафиятович.

— Ярый. Ә нигә соң үзегез жибәрдегез?

— Яңа гына Фатих Гафиятович шалтыратты. Тагын бер тәүлек тонсын әле, ди.

Савытлардагы нефтьне түктем дә лабораториягә кайттым. Анда Фатих Гафиятович утыра иде. Мин килеп керү белән, ул минем якка күз сирпеп алды да, Ләйсәнгә:

— Кая, бир әле «дегет күле» анализларын,— дип, аның янына үтте.

— Әзер түгел әле алар...

— Әзер булгач та миңа кертерсез!..

Фатих Гафиятович лабораториядән чыгып китте. Ләйсән көрсенеп куйды да кайнап торган колбага карады. Микроскоп янында утыручы Нажия янына үтте.

— Унберенче чаннан Гали ага анализ алырга кушмады әле,— дидем мин.

— Ярый. Тугызынчыга бар, ул әзердер,— диде Ләйсән, миңа карамый гына.

Мин тугызынчы чаннан проба алдым да диспетчерлык пункты янына килдем. Гали ага ике егеткә нәрсәдер аңлата иде.

— Барыгыз, хәзер үк,— диде ул.
— Ай азагында гына яндыра идек бит әле элек,— дип каршы төште берсе.
— Я инде, егетләр, әйткәнне тыңлагыз. Фатих Гафиятович үзе кушты,— диде Гали ага.
— Ә пожарниклар мондамы соң?
— Монда, монда, сөйләшкән...
Егетләр киткәч, Гали ага миңа таба борылды, кулымнан тотты.
— Әнрүсә, кызым, бар әле, Ләйсәннән сигезенче чанның анализларын китер. Станциядән сорыйлар. Миндә дә булсын әле бер данәсе...
Лабораториядә Нәжия генә иде.
Ул миңа түргә узарга кушты.
— Укырга йөрисеңме әле син, Әнрүсә?
— Йөрим.
— Димәк, диспетчер булырга исәп?..
— Әйе...
— Ә нигә лабораториядә калмыйсың? Ләйсән апа, Әнрүсә теләсә, мин аны урнаштыра идем, ди...
— Мин тиздән диспетчерлыкка имтихан бирәм инде...
— Кайчан?
— Киләсе атнада...
Нәжия каршысындагы газетага күз ташлап алды, баш түбәсендә күпереп торган чәчен рәтләбрәк куйды.
— Безгә киләсеңме бүген кич белән, Әнрүсә... Әти Казанга китте. Әни курортта... Кил. Егетләр булачак. Магнитофон... Ә?..
— Белмим шул. Мине Вәсил клубка чакырган иде бүген... Вәгъдә биргән идем...
— Нигә?
— Хорга катнашырга чакыра...
— Тагын Казанга барырга исәп тотасың... Шул хыялыңны һаман ташлый алмадыңмыни әле?
— Әллә нигә җырлыйсы килә, Нәжия. Чын әгәр... Исеңдәме, мәктәптә укыганда Казанга смотрга барган идем. Икенче урынны алдым бит мин анда. Сәгать бирделәр, үземә атап, исемемне язып. Менә һаман да исән әле ул...
— Ярты айлык хезмәт хакы тормаган сәгатең дәрәҗәсен күтәрмә әле ачу китереп, пожалуйста...
Мин үпкәләдем.
— Бүләк бит ул, менә җүләр...
Ләйсән килеп керде. Ул борчулы, колакларына хәтле кызарган, күзләрендә яшь ялтырый.
— Нәрсә булды, Ләйсән Хафизовна? — диде Нәжия.
— Берни дә булмады... Болай гына... Карале, Нәжия, нефть кудыру станциясеннән лаборантка килмәдемени бүген?
— Әллә нишләп күренмәде ул, Ләйсән Хафизовна...
Ләйсән минем якка күз сирпеп алды. Матур да соң бу Ләйсән! Озын керфекләренә яшь эленеп торганда, әти әйтмешли, җәннәт фәрештәсенә охшап китә. Спорт костюмын киеп, күнегүләр ясаганда, әни мәрхүмәгә шулай ди торган иде ул. Ә нигә елый икән ул?
— Әнрүсә,— диде Ләйсән, миңа туры карамаска тырышып,— бар әле, Вәсилне чакыр. Фатих Гафиятович дәшә.
— Гали ага сигезенче чанның анализын сорады.
— Нигә кирәк ул аңа?
— Белмим.
— Нәжия, язып бир,— диде Ләйсән Нәҗиягә һәм түргә якка кереп китте.

Мин Гали агага анализ кәгазен бирдем дә Василне эзләп киттем. Васил — слесарь. Бер урында гына тормый. Әүвәл операторныйга кердем, Васил урынына Гыйлаж белән очраштым. Ул эш киемнәре киеп алган, йөзе караңгы иде. Минем белән дә яктырып исәнләшмәде. Васил турында сорагач, каядыр читкә карап:

— Яна гына чыгып китте. Катыкка төшкән тычкан шикелле, дегеткә чумган бит ул. Юынып ятадыр,— диде.

Душ икенче насос бинасында. Ерак, капка янында ук.

Мин цехка күз йөртеп чыктым да душка таба киттем. Күзем «дегет күле» ягына сирпелеп алды. Аннан, бөтен күк йөзен карага буяп, ургыла-ургыла төтен күтәрелә иде. Каяндыр Васил үзе килеп чыкты. Ул минем беләгемнән кысып тотты да:

— Нәрсә бу, Әнрүсә? — диде.

— Белмим, «дегет күле» янадыр.

— Әнрүсә,— диде ул туп-туры күзләремә карап,— син савытларыңда калган пробаны түктеңме?

— Юк, лабораториядә...

Ул сүз катмады, миннән алда лабораториягә йөгерде.

## 8

Икенче көнне иртән иртүк мине Гали ага дәшеп алды.

— Әнрүсә, унберенче чанга барып йөрмә, ул тагын бер тәүлек тонарга тиеш булды әле...

— Ә нигә алай озак?..

— Сулырак нефть эләккән... Гафиятович кушмый...

— Ярый соң...

Төш вакытында ашханәдән чыгып килүче Василне очраттым.

— Ә, Әнрүсә, исәнме!..

Аның өстендә яңа комбинезон, башында яңа берет...

— Кичә өлгерә алмадык. Күргәнсеңдер, яндырдылар,— диде ул, үкенгән сыман.

— Ә анализлар?..

— Нормаль..

— Ничек нормаль?

Васил җавап бирмәде, бүреген салып тезенә сугып алды.

— Димәк, без юкка йөргәнбез,— дидем мин.

— Шулай булып чыга...

Беркавым сүзсез тордык. Васил төпсез зәңгәр һавага карап алды.

— Унберенче чанны менә өч көн инде кудырмыйлар. Нидән булыр икән ул, Васил?

— Тонуы житмәгәндер... Син кайсы катламнан анализ алган идең?

— Мин аннан бер дә проба алмадым әле...

Һәр чанның өч катламыннан да проба алабыз. Иң астагы катламда су күбрәк була һәм шул сәбәпле нефтьнең сыйфаты да түбән була анда...

— Ничек?

— Шулай, Гали ага кушмады, тагы бер тәүлек торасы бар, диде.

Васил, башын иеп, беравык җиргә карап торды. Дегеткә баткан итеге белән йодрык хәтле ташны тибеп җибәрде. Аннары сүзсез генә китеп барды.

Вахта алышыныр алдыннан ул тагы минем янга килде. Аның күзе-башы тонган, ачуы йөзенә чыккан иде.

— Әнрүсә, кичә унберенче чан тулы идеме?

— Әйе, мөлдерәмә тулы иде.

— Бүген буш ул.

— Ничек инде алай?..

— Шулай — буш. Төнлә белән «Дуслык»ка кудырганнар.

— Ә анализ?..

— Анализ?.. Алганнар, күрәсең...

Васил кашларын җыерып, йодрыкларын йомарлады.

— Комсомол «Прожекторы» дигән булабыз. Адым саен төп башына утырталар безне.

— Ә, бәлкем, без үзебез ялгышабыздыр...

— Без?!.

Василнең йөзе бурлаттай кызарып чыкты. Күзләреннән очкын атылды кебек тоелды миңа.

— Менә иртәгә җыелыш була. Барысы да ачыкланыр, күрерсең...

— Васил! Васил! Кызу канлы кеше дә соң син!..

Васил оялып китте. Тынычлана төште.

— Ярар,— диде ул,— җыелыш хәл итәр. Әллә райкомолга житкерми торыйкмы, Әнрүсә?..

— Нәрсәне?..

Ул дәшмәде...

— Ә син Айхәл абыйга әйт. Райком кешесе ул. Ана әйтсәң, төбенә тоз сала инде ул бу эшнең.

— Чынлап та!

Васил, кирәк әйберләрен тапкандай, шатланып китте.

Васил минем тормышыма килеп керде. Атна буе күрми торган чакларда да ул гел минем белән яши, минем белән сөйләшә, мин, әллә ниткән бер сөенечем бар сыман, үз алдыма елмаеп, йокыга китәм, елмаеп уянам; Ык буенда бергә су коенуыбызны, аның шамбы балыгыдай житез йөзүен, бакыр кебек янган матур гәүдәсен күз алдыма китерәм, аның «нефть күленә» батканнан соң да шаяртып, үз итеп дәшүләрен оныта алмый йөрим. Минем бу халәтемне әти дә сизеп алды бугай, минем белән ягымлырак сөйләшә, өйгә кызмача кайтканда да миңа бик күренеп йөрмәскә тырыша иде.

Бер сүз белән әйткәндә, минем үз дөньям барлыкка килде. Әнә шул дөньяда яшәү миңа рәхәт иде. Бер атнадан безнең цехның производство җыелышын җыйдылар. Кварталга бер җыела торган зур җыелыш булгангамы, халык күп килгән иде. Планнар турында, киләчәк көнебез турында, гадәттәгечә, бик күп сөйләделәр, бик күп тавышландылар. Цех начальнигы — сүзнең тәмен белә торган кеше Фатих Гафиятович бер олау сүз сөйләп ташлады. Баш инженер сөйләде, парторг Рәкыйпов яшьләрне заманга лаеклы булырга, дәүләт интереслары белән яшәргә чакырды. Мин аларны рәтләп тыңлый алмадым. Күңелемдә бер генә уй: «Васил сөйләрме, юкмы, тормышта ул житешсезлекләргә бик көенә дә бит, халык алдына чыгып сөйләргә йөрәге житәрме икән?» — дигән уй гына борчыды мине. Райком инструкторы Айхәл абый Хәйдәров сөйләгәннән соң, мин Василнең трибунага чыгуын бигрәк тә ышанып көтә башладым. Безнең коллективта кайбер иптәшләрнең гадел кыланмавын әйтте инструктор. Алар, ягъни гадел булмаган иптәшләр, бергәбергә бару, булган житешсезлекләрне бергәләп бетерешү урынына яла ягу юлына басалар икән. Житмәсә, яла ягучылар яшьләрдән. Бу нәрсә бу? Чәчрәп алга чыгарга тырышумы, әллә яшьлек җиңеллегеме?

— Фамилиясен әйт,— дип кычкырдылар залдан.

Инструктор җилкәсен җыерып куйды, әмма яла ягучының исемен әйтергә теләмәде. Намусы булса, ул үз хатасын үзе белер, дип әйтү белән чикләнде.

Минем күңелемә шик төште: Айхәл абый әллә Василне истә тотып әйтәме? Ул бит миңа, булган хәлне райком инструкторына житкердем, дигән иде. Васил ялгышты микәнни?

Зал беразга тынып торды. Шул тынлык эченнән кемнеңдер сүз сорап дәшкән тавышы ишетелде. Мин, нидер сизенеп, артыма борылып карадым.

Эскәмияләр арасында калган буш юлдан кара костюмлы, җиңел сөякле бер егет трибунага таба килә, дөресрәге, ул атлап килми, ашкынып, йөгереп килә иде. Мин аяк атлауларыннан ук Василне танып алдым. Йөрәгем гөрселдәп кагудан битемә кан йөгерде, башым шаулый башлады. Васил залдан трибунага менә торган баскычка борылып тормады, кызыл почмак идәненнән спортчылар житезлеге белән сәхнәгә сикереп менде дә трибуна янына килеп басты, алга кайтарылып төшкән чәчен кискен генә артка чөйде, трибуна читенә ике куллап ябышып, зал өстенә ярсулы беренче сүзен ташлады:

— Күз бәйләш-сукыр тәкә уйнамыйк! Җитте! Айхәл Хәйдәровичка минем бер соравым бар: кем ул яла ягучы? Монда чит кеше юк, исемен әйтеп сөйләшергә кирәк. Әгәр инде дөреслекне әйтү яла ягуга керә икән, мин туп-туры әйтәм: «нефть куленә» агызып яндырган нефть турында Айхәл Хәйдәровичка мин әйттем,— залда гөж итеп, умарта күчедәй җуылдап алдылар.— Әйе, мин әйттем Айхәл абыйга, хәлләрне тикшереп, ачыклык кертүне сорадым. Райком бу эшне тикшердеме?

— Тикшердек. Махсус комиссия ул эш белән шөгыльләнде. Анализлар нормальный,— диде Айхәл абый, Василне бүлдереп. Бүлдергәне өчен шундук гафу үтенде.

— Бик яхшы. Мәсьәлә алайса тагын да ачыклана төште,— диде Васил, залга төбәлеп.— Сез, димәк, Айхәл Хәйдәрович, анализлар нормальный, ул-бу юк, дисез. Ай-һай, шулай микән? Мин монда кемнеңдер хәйләкәр кулы эшләвен сизенеп, пробаларны Үзәк лабораториягә җибәргән идем. Менә алар! — Васил кесәсеннән кәгазьләр чыгарып, президиумга бирде. Фатих Гафиятович та, аның белән янәшә утырган баш инженер да, күзлек киеп, кәгазьләрне карап чыктылар. Үзара сөйләшеп баш чайкап куйдылар. Васил, аларның укып бетергәнен сабыр гына көтеп алды да туп-туры аларга карап:— Минемчә, Үзәк лаборатория анализлары эшләрнең бигүк тәртиптә булмавын күрсәтә, димәк, алдашуга чик куярга вакыт! — диде.

Зал гөрләтеп кул чапты. Мин барысыннан катырак чаптым. Василнең дулкынланудан алсуланып киткән чибәр йөзенә, трибунага ябышкан зур кулларына карап тордым. Васил өчен күңелем канат какты.

— Тагын, иптәшләр, шуны әйтәсем килә,— диде Васил,— бездә кайчакта нефть тону чаннарында тиешле срогын үзмый торып кудырыла. Ягулыкны нефть эшкәртү заводларына кудыручылар безгә штраф салалар. Һәм кызганып салмыйлар. Бер атна элек унберенче чандагы нефть белән шулай булды. Кичке якта Гали ага лабораториядә эшләүче Әнрүсә Сабитовага әйткән, чандагы нефть тагын бер тәүлек тонарга тиеш әле, анализны алмый тор, дигән. Ә үзе өченче сменага: «Бүген төнлә унберенче чанны кудырып бетерегез»,— дип әмер биргән. Моны ничек аңларга? План үтәү бәрабәренә нефтьне тиешле кондициягә китермичә әрәм-шәрәм итү булмый микән бу? Безне комсомол намуслы булырга өйрәтә, әйтер сүзем шул: без озаткан «кара алтын» чын мәгънәсендә кара алтын булсын иде...

Җыелыштан мин кая басканымны белмичә куанып чыктым. Василне батырлыгы өчен кочаклап үбәсем килде. Ләкин ул эшне эшләү мөмкин түгел иде. Хәер, кочакламавым да әйбәт булды. Иртәгесен комсомол бюросында миңа җыелышка килми калуым өчен шелтә бирделәр. Шелтә бирдерергә аеруча тырышкан кеше бюро члены Васил Байков булды.

Ачык ишектән цехның бөтен мәйданы күренә. Котельныйдан җинелчә гөжләү, насос бинасыннан моторлар гүләве ишетелә. Җиденче чан төбәсендә минем алмашчым Галина Сысоева йөри. Аның өстендә парчалы күлмәк. Ул кечкенә чүмеч белән нефтьне ала да колбаларга сала, бөкесен тыга, кәрзингә тезә. Диспетчер бинасыннан моторлар сызгырган тавыш ишетелеп тора.

Пропускамны вахтерга күрсәтеп цехтан чыгам, арыш басуы аша шәһәргә таба атлыйм. Дөрес, цехка автобус та йөри. Ләкин бүген минем йөрәгем сыкрый... Арыш саргая башлаган. Башаклар авырайганнар, башларын түбән игәннәр. Әкрен генә искән җилгә кыштырдашып, пышылдашып, серләшеп, сөйләшеп алалар. Кояш шактый югары әле. Ул, чыршыга элеп куйган дәү лампочка кебек, бер урында тора сыман. Ә үзе ул хәтле эссе дә түгел, ләкин бөркү, һава дымлы. Көньякта болыт өемнәре күренә. Алар кат-кат булып кояш өстенә киләләр. Кояш гамьсез генә үз эшен эшли. Аның болытка бер дә исе китми. Ләкин менә болыт куера, күперә һәм кыйбла якны кара пәрдә белән каплап, ничектер, дәү кара кош канатына охшап, кояшка сузыла. Тирә-як томанланып, караңгыланып китә. Җил чыга. Дымлы һава исе борынны ярып керә.

Минем күңелемне айкап Вәсил белән су коеныրга төшкән көн күз алдыма килеп баса. Бүген, бу минутта, менә кем кирәк икән миңа. Дөрес, күңелемдә аңа үпкәм бар. Ләкин ул миңа җиргә кирәккән яңгыр кебек кирәк. Күңелем булганчы сөйләшер идем мин синең белән, Вәсил. Ләкин кызлар күңеле горур шул. Син бирдерткән шелтәдән соң, мин мәңге үзем сүз башлыйсы кеше түгел...

Җил көчәя, арыш басулары тирбәлә. Адымнарым кызулатып, олы юлга чыктым. Асфальт юл кырыеннан барам. Мине Ләйсән куып җитте.

— Уф, көчкә... Ни арада шул чаклы җир киткәнсең...

Ул мине култыклап алды.

— Яңгыр килмәкче, өлгерербезме? Йөгерикме, әллә чыланыйкмы?

— Тоз түгел, эремәбез әле.

— Анысы дөрес. Шулай да манма суга каласы килми.

Ул яңа кофтасына, тар яшел юбкасына, ак туфлиләренә күз төшереп алды.

— Бюрога дип, атап киенеп килгән идем. Мин аны тагын бик мөһим мәсьәлә карала дип торам. Өйгә шалтыратты бит. Бик җитди мәсьәлә һәм персональный эш карала, диде. Әйхәл киногa барабыз дигән иде. Кич белән яслеләдән баланы аласы бар. Калдырыр кешебез юк. Шуның өчен көндезге сеансларга йөрибез. Ә син киногa йөрисенме, Әнрүсә?

— Яңа киноны калдырганым юк.

— Син бик матур җырлыйсың дип ишеттем мин.

— Мәктәптә җырлый идем. Бер тапкыр Казанга барган идек.

— Соң?

— Шул. Миннән җырчы, чыкмас, ахры, Ләйсән Хафизовна...

— Нигә?

— Нибарысы ике-өч җыр беләм.

— Эш җыр белүдәмени? Җырлый белүдә, монда, тавышта. Җырны аны соңыннан да өйрәнеп була.

Туктаусыз узып торган машиналар әче төтен чыгарып чаба бирәләр. Ләйсән кул күтәрсә дә, туктатмадылар. Асфальтны шадралатып яңгыр төшә башлады. Ниһаять, бер машина туктады. Автобусны хәтерләткән лаборатория машинасының ишеген пеләш башлы бер абый ачты.

— Кая алып барыйм, чибәрләр?
— Вахит абый, зинһар өчен...— диде Ләйсән.
— Тизрәк утырыгыз,— диде шофер, газга басып, моторын үкертеп алды.

Вахит абый безне шәһәрнең үзәгенә чаклы китерде. Без, аңа рәхмәт әйтеп, нефтьчеләр сарае каршысында төшеп калдык. Шәһәргә яңгыр тимәгән, яңгыр болыты Ык буйлап, Урал ягына таба китеп бара. Ыкның бер башына салават күпере төшкән. Кояш нуры үткән яңгыр чаршавы җирдән болытка барып тоташа.

— Яңгыр яумады, һава гына сафланып калды,— дидем мин.

— Мине көтеп утыргандыр да, кайтмагач, өйдән чыгып киткәндер. Баланы алырга да иртә әле. Әйдә шушында эскәмиягә утырып торыйк. Сиңа ничә яшь, Әнрүсә?

— Миңамы? Унтугыз тулды.

— Унтугыз,— диде Ләйсән, аңламадым дигән сыман, сузып әйтте бу сүзне,— унтугыз... Мин синең яшеңдә беренче тапкыр Айхәлне очраттым.

— Ә кайчан кияүгә чыктыгыз?

— Институт тәмамлагач. Күрдем дә капландым. Инженер, янәсе.

— Нигә алай дисез, Ләйсән апа?

— Апа ук түгел мин сиңа, Әнрүсә. Безнең аерма биш яшь кенә... Бөтен бәла шунда,— диде ул, үз алдына сөйләнгәндәй,— бәхет дигән нәрсәне аера белмибез. Ике төрле була икән ул. Берсе менә синең кебек тиле, яшь чакта, ә икенчесе ир белән тора башлагач. Их, Әнрүсә, Әнрүсә! Очраган бер кешегә эчен бушаганчы сөйләп булмый торган хәлләр бар. Син кем соң миңа? Бер цехта эшлибез, шул гына. Ә сөйлисе иде. Ошыйсың син миңа, Әнрүсә. Беләсеңме ни өчен?..

Ул баеп барган кояшка карады. Яңгырдан соң сирәгәеп, таралып, сүтелеп калган болытлар арасыннан сибелгән кояш нуры каршы яктагы кибетнең тәрәзәсенә төшә. Тәрәзәгә ут капкан диярсез. Ул яңа, дөрли-дөрли яна. Мин Ләйсәннең күзләренә карыйм. Аның да күк күзләрендә дөрләп ут яна кебек. Күзләре аның — үз кояшы, үз дөньясы.

— Әллә сез бәхетсезме, Ләйсән апа?

Ул шәфәкъ нуры төшкән тәрәзәдән күзләрен алды.

— Яшьлек мәхәббәте белән яну — башка нәрсә икән ул, Әнрүсә. Яратам дигән белән генә ярату килми.

— Ләйсән апа, сез Айхәл абыйны яратасызмы?

— Мин аңсыз — канатсыз кош. Ишетәсеңме, канатсыз кош! Дөнья көтәсе бар бит... Мин, Әнрүсә, бүтән кешегә гашыйк. Бәлки бу узар, сүрелер. Минем моны беркемгә дә сөйләгәнем юк. Ни өчен сиңа сөйләп утыруыма да аптырыйм. Сөйләмичә дә түзеп булмый...

Ләйсән, башын ике кулы белән кысып, ак туфлиләренә, матур балтырларына карап утырды. Аннары, кисәк кенә башын күтәреп:

— Әнрүсә, Васил — тупас егет, әйеме? — диде.— Андыйларны кызлар гафу итми. Сиңа ул үзенең кемлеген аңлату өчен шелтә бирдерде. Ул бит сиңа гашыйк үзе...

— Ни сөйлисез, Ләйсән апа!

— Апа димә әле миңа, нинди апа булыйм мин...

— Мин аны яратмыйм,— дидем мин.

— Җүләр.— Ләйсән аптырап китеп, туп-туры күзләремә карады.— Җүләр кыз син... Ул синең хыялыңны аңлардай кеше...

— Минем бернинди хыялым да юк. Һәм минем, Ләйсән, бернинди бөек уйлар уйлап та йөргәнем юк. Агым уңаена гына ага бирәм.

— Юкка. Мин үзем Айхәлгә гашыйк идем. Ул шундый иде, Васил кебек — туры. Дөреслек өчен җаны фида. Ә үзе коры кеше. Ул чакта әле Айхәл минем өчен идеал иде.

— Ә хәзер?
— Хәзерме! Хәзер ул минем ирем.
— Ничек соң инде ул алай?
— Шулай икән шул, Әнрусә, шулай...
Ул сәгатенә карап алды. Көрсенеп куйды.
— Я, ярый, хуш. Мин киттем. Баланы алырга вакыт. Безгә дә килеп утыр. Кичләрен мин бер үзем булам. Айхәл райкомда.
— Рәхмәт, Ләйсән. Бәлки килермен.
Икенче көнне үк Ләйсәннәргә киттем. Никтер семьялы кешеләрнең ничек яшәүләрен үз күзем белән күрәсем килде. Ленин урамын кисеп, Тукташка чыгам, чаттан борылу белән, Ләйсәннәрнең дүрт катлы йортын күрәм. Урамга караган өч тәрәзәдә дә ут бар.
Өченче катка күтәреләм. Дулкынланам. Айхәл абый өйдә түгелме? Өйдә булса, берни сөйләшеп булмас. Ни өчен Ләйсән яратмый аны? Шулай ук яратмаслык, җан җылысы тапмаслык кеше микәнни ул? Звонок төймәсенә басам. Бер басам. Ике. Шактый вакыт узгач кына аяк тавышы ишетелә.
Бусагада елый-елый күзләре кызарып беткән Ләйсән күренде.
— Исәнмесез, Ләйсән!.. Ни булды?
— Ә-ә... Әнрусә!..
Тар коридордан ук зал башлана.
— Уз, әйдә...
— Рәхмәт. Әллә бер-бер бәхетсезлекме?
Ләйсән, тыела алмыйча, ике кулы белән йөзен каплап тагын елап җибәрде.
Мин нишләргә белмичә баскан урынымда таптанып тора башладым.
Түр почмактагы бала караваты өстенә иелеп, чал керә башлаган чәчләрен йөзенә төшергән Айхәл абый басып тора иде.
— Исәнмесез,— дидем мин, пышылдап кына.
Айхәл абый миңа таба борылды да күзләрен читкә алды. Мин Ләйсән янына чыктым.
Ләйсән зал ягында өстәлгә башын куеп утыра, матур чуар халат кигән гәүдәсе, җилкәләре дерелди иде. Мин аны кочтым да әкрен генә:
— Ни булды? — дидем.
Ул күтәрелеп миңа карады, күкрәгемә башын салды — сүз әйтерлек хәле юк иде...

## 10

Ләйсән эшкә дә килмәде. Мине бүген проба алып килергә кушып берәү дә алҗытмый. Мин моңа сөенергә тиеш идем. Ләкин гаҗәп хәл: бүген нәкъ шул җанга тия торган әмернең, таләп итеп торуның булмавы миңа сәер булып, хәтта эчпошыргыч күңелсез булып тоелды. Хикмәт эш кушып торуда гына түгел икән шул. Мин, әни канаты астыннан мәхрүм калган кыз, Ләйсәнне апам итеп, мине кайгыртып торучы әнием итеп күрә башлаганмын. Аннары мин ул көнне үзем өчен тагы бер ачыш ясадым: кызлар күңеле чуар, сөйгән егетең булуы гына җитми, ул хакта кем беләндер серләреңне уртаклашасы да килә икән. Сер бүлешердәй бүтән кешем юк минем, сөйләшсәм мин Ләйсән белән, әнием һәм апамны алыштыргандай кеше белән генә сөйләшә алам.
Сменам беткәнне көч-хәл белән көтеп алдым да Ләйсәннәргә киттем. Кунак бүлмәсендә, башын игән килеш, Айхәл абый утыра.
— Мөмкинме?.. Исәнмесез!..
Айхәл абый башын күтәрмичә генә сәламемне алды.
— Ләйсән апа кайда? (Ләйсән дияргә яхшысынмадым.)

— Китте ул.
— Кая?
— Тулай торакка.
Айхәл абый соры күзләрен тутырып миңа карый. Минем агарып китүемне күреп, аяк өсте баса.
— Утырыгыз, Әнрүсә...
Ул түр тәрәзә каршысына килә. Ике кулы белән таянып, тәрәзә каршындагы юкә агачына карап тора. Инде кояш баеган, офыкка кечкенә шәфәкъ җәелгән, шәфәкъ нуры юкәне моңсу итеп күрсәтә иде.

Мин әкрен генә тордым да сиздерми генә чыгып китмәкче булдым. Ишек янына җиткәч, Айхәл абыйның күкрәк түреннән әрнешеп чыккан тавышы ишетелде:
— Әнрүсә, күрсәң әйт син аңа: мин аны көтәрмен. Һәр кичне, һәр көнне шушы тәрәзә төбендә көтәрмен. Ул мине гафу итәр әле. Кеше йөрәге таш түгел, таш та эри...
Мин урамга чыктым. Колак төбемдә Айхәл абыйның сүзләре яңгырап тора. «Кеше йөрәге таш түгел, таш та эри...» Ни гаебе бар соң аның Ләйсән алдында?..
Бәхет. Нәрсә соң ул бәхет? Кеше каршында нинди роль уйный ул?! Бәхет, и бәхет! Ни хакың бар синең кеше хисе белән, кеше тойгысы белән уйнарга?! Нигә соң кешеләр бер-беренә тәшенеп, бер-берсен аңлап кына яшәмиләр?! Нигә дип шушы дөньяга килгән аз гына гомерләрен ямьсезлиләр?
Шәһәр урамнарын балкытып утлар яна. Асфальт җәйгән тротуардан тулай торакка атлыйм. Башымда мең төрле уй. Нәкъ шул чак каршыма җилкәсенә гитара аскан Вәсил килеп басты.
— Һа, Әнрүсә! Исәнме... — диде ул ерактан ук.
Мин кул бирмим, дәшмим: аны әйләнеп үтеп китмәкче булам.
— Һәй, туктале! Нинди чебен тешләде сине?
Ул минем кулымнан тотты. Күзләремә карады. Ләкин кечкенә лампа якътысында берни дә күрмәде бугай.
— Ни булды сиңа?
— Җибәр!
Вәсил читкәрәк китте һәм ниндидер мин белмәгән җыр җырлый башлады. Тавышы аның йомшак, ягымлы иде.
Мин китеп бардым. Вәсил шундук җырлаудан туктады.

...Ләйсән, йөзтүбән капланып, иптәш кызының караватында ята иде.
— Тсс, йоклый,— диде, чәчен-башын туздырган кыз. Ул прическасы белән мәшгуль иде.— Әле генә йокыга китте. Ике төн елады, күз дә йоммады. Син кем?
— Бергә эшлибез.
— Иртәгә килерсең,— диде кыз, тузгыган чәчләрен кайтарып артка ташлады.
Урамга чыктым. Каршыма тагын Вәсил килеп басты. Мин, аны күрмәмешкә салышып, икенче якка таба киттем. Ләкин ул мине куып житте дә:
— Карале, Әнрүсә... Ну, эндәш, ичмасам! Атаңны үтермәгән бит мин,— диде.
— Вәсил, кайгым бар минем.
Вәсил беләгемнән кысып тотты.
— Кыерсыттылармы әллә?
— Җуләр...
— Нәрсә соң?
Ләйсән ирен ташлап киткән.

— Минә сиңа мә! Ә син аңа ник кайгырасың?

— Вәсил, синең алай дип әйтергә хакың юк. Ишетәсеңме, хакың юк!.. Җибәр мине!

— Җибәрдем бит инде, нигә җикерәсең, кешеләр игътибар итәр...

— Итсеннәр...

— Я инде, җитте. Әйдә, әнә бакчага кереп утырабыз.

Ул мине култыклады да бакчага алып керде.

Без клуб каршына килгәндә шактый соң иде инде. Бер төркем яшьләр берәүне уратып алганнар, ә ул, Вәсил шикелле үк, җилкәсенә гитара аскан да әллә нинди колакка ят җырлар җырлый. Мин монда Вәсил бик сорагач кына, аның иптәшләре начар егетләр түгеллеген мең тапкыр кабатлап әйткәч кенә килдем. Бу хәлне күргәч, ул үзе дә уңайсызланып китте. Түгәрәк уртасына керде дә җырлаучы егетнең гитара кылларына кулын салды. Җыр тукталды, гитара тынды.

— Син нәрсә, Вәсил? — диде чәчен каш өстенә үк төшергән таза гәүдәле егет.

— Әйдәгез, клубка керәбез,— диде Вәсил һәм, янадан сүз дә әйтмичә, гитара күтәргән егетне өстерәп диярлек клубка алып кереп китте. Мине күңелсез хәлдән коткарырга теләде бугай.

Әкрен генә өйгә таба киттем. Күк йөзендә йолдыз туе. Тау артыннан ай кыерчыгы күтәрелеп килә. Шәһәр ничектер бушап калган, моңсу.

Кемгәдер сер сөйлисе, кемнеңдер көчле кочагында буласы килә. Бер секундтан шул уйларыңнан ояласың. Бу шулай.

Ни бу? Әллә Вәсилгә чынлап та гашыйкмы мин?

Борылып бакчага керәм. Караңгы почмактагы эскәмиягә утырып, төпсез күккә карыйм.

Минә минем кебек бер гашыйгы бакча уртасыннан атлый. Юк, икәү икән. Чү, берсе Фатих Гафиятович түгелме? Икенчесе... Күзләремә ышанмыйм. Икенчесе — Ләйсән.

Торып китәргә дип күтәрелгән идем, минем күршедәге эскәмиягә килеп утырдылар.

Фатих Гафиятович Ләйсәнгә мәхәббәтен аңлата. Минем чәчләрем үрә тора. Ул шундый нечкә хисләр турында сөйли, бу сүзләрнең дөрес түгеллегеннән аның өчен мин оялам. Ләкин Ләйсән ник бер сүз каршы әйтсен. Ул аны тыңлый. Фатих Гафиятович аның чәчләрен үбә, маңгаен, күзләрен үбә. Ә ул, Ләйсән, минем апам урынына калган кеше, шуңа риза, канәгать. Шушымы мәхәббәт?

Фатих Гафиятович көтмәгәндә эш хәлләренә күчә. Күрәсең, бу темага аны Ләйсән күчерде. Ләйсән акрын сөйләшә, мин аның сүзләрен ишетмим, аңламыйм.

— Миңа ул гел аяк чалды, күралмыйм мин аны,— ди Фатих Гафиятович,— Ишетәсеңме, күралмыйм мин аны...

— Бүген шушы минутта нигә кирәк ул сиңа? — дип сорый Ләйсән, тавышын күтәрә төшеп.

— Кирәк. Бик тә кирәк ул миңа, Ләйсәнкәем. Минем бит омтылышым изге. Мин бит план тутыру өчен тырышам. Кемнең оятка каласы килә? Йөкләмә бар, дәүләт планы бар... Бәлкем, ерактанрак китереп уйлаганда, минем дә гаебем бардыр. Әмма андый эшкә ансат кына, җиңел генә бара торган кеше түгел мин...

— Синең дөньяга карашың, Фатих, сәер...

— Сәер?

— Әйе, сәер, Фатих. Артык тәвәккәл димме мин сине... Син бу кылanышың белән үзеңне әрәм итәрсең. Ярый әле шелтә алып кына калдың, юкса...

— Нәрсә юкса... Юк, Лэйсәнкәем, мин үземнең гаебемне күрмим монда. Әйе, әйе, күрмим... Син, Лэйсәнкәем, мине аңлап житкермисең...

— Юк, Фатих, аңлыйм мин сине. Мин бит, начармы, яхшымы, аның белән торып карадым. Дөрес, ул минем үземә беркайчан да жаным, бәгырем, мин сине яратам дип әйтмәде. Тик үзенчә, үзе аңлаганча, идеаллаштырып яратты кебек. Ә без, хатын-кызлар, беләсең килсә, ана баласын сөйгән кебек, сөюгә, яратуга мохтаж. Хәер, кем ана мохтаж түгел соң!.. Синме, Фатих, минме? Ә ул аны белмәде, күрмәде, теләмәде.

— Үпкәлисеңме?..

— Аңамы?!

— Әйе.

— Әйе, үпкәлим. Ничек үпкәлим әле!.. Мәхәббәте сукыр булган өчен, хатын-кызларның жан азыгы — сөю сәләте булмаган өчен үпкәлим...

Алар пышылдап сөйләшә башладылар. Мин әкрен генә тордым да китеп бардым. Күрделәрме алар мине, таныдыларммы, белмим. Әмма колагымның ут булып януын тойдым. Тик бераз киткәч кенә артыма әйләнеп карадым. Эскәмиядә бер кеше дә күрмәдем. Бу — төннең артык караңгылыгыннанмы, я булмаса үзем саташаммы, бер нәрсә дә аңламыйча өйгә таба атладым.

## 11

Без Айхәл абый белән яшьләр кичәсендә очрашабыз.

— Исәнме, Энрүсә! — ди ул сүрән генә.

— Саумысыз, Айхәл абый.

— Нигә биемисез?

— Чакыручы юк...

— Ә менә мин чакырсам...

— Сез?..

— Әйе, нигә аптырап калдыгыз?..

Мин текәлеп диярлек Айхәл абыйның күзләренә карыйм. Ул елмая, йөзе тагын да мөлаемлана, матурая. Аның күзләре йомшак итеп карыйлар. Чак кына озынча йөзе, туры борыны, кушылган кара кашлары, көмешләнә башлаган чигә чәче аны шактый олы күрсәтә.

— Я, әйдәгез, мин болай үзем бик ук оста бии белмим, шулай да кеше аягына басканым юк.

— Ә үзегезнекенә бассалар...

— Үзем чакыргач, түзәргә туры килер.

Без вальс көенә бөтереләбез. Айхәл абый күзләре белән кемнедер эзли. Үзе минем белән сөйләшә. Эшем, хезмәтем турында, укырга булган теләгем турында сораша. Нинди институтка керергә теләвемне сорый. Мин, жырчы булырга хыялланып йөрим, дигәч, килешеп баш кага. Аның минем жырлаганны ишеткәне бар икән. Менә ул эзләгән кешесен күрә, нидер әйтмәкче була, әмма авызыннан сүз чыкмый, тик күзләрендә генә өмет чаткылары кабына. Мин, Айхәл абый эзләгән кешене күрергә теләп, як-ягыма карыйм, әмма ул инде минем белән сөйләшә башлый, янә мең төрле сорау бирә. Танцы беткәч кенә, мин түр яктан үтеп баручы Лэйсәнне күрәм. Һәм Айхәл абыйның кемгә карап елмайганын аңлап, Фатих Гафиятович белән Лэйсәнне бакчада күргәнемне искә төшерәм. Миндә җүләр уй туа: «Әгәр дә Лэйсәннен Фатих Гафиятович белән сөйләшкәнен әйтсәм?.. Нигә бу кадәр жан ата соң әле ул Лэйсән өчен?.. Кем ул Лэйсән ул кадәрле?» Шул вакыт безнең янга Васил килеп басты.

— Хәерле кич. Исәнмесез, Айхәл абый. Ни, Айхәл абый, хәзер чарльстон булачак, ни, Энрүсәне рөхсәт итсәгез?..

Айхәл абый күзе-йөзе белән елмая.

— Сез аны, Васил, үзеннән сорагыз...

Васил төбәлеп диярлек минем күзләремә карый.

— Әнрусә, бер танцы, нибарысы бер танцы,— ди ул, ялварып, баш бармагын тырпайтып күрсәтә.

Василнең йөзе шундый пакь, шундый балаларча гади, мин: «Риза, риза»,— дигәнемне сизми дә калам.

Васил мине озата килде. Ул бүген аеруча шат, күп сөйли. Кичәнең яхшы үтүен әйтә, кайберәүләрне тәнкыйтьли.

Ул бигрәк тә артистлар турында сөйләргә ярата. Шул мәлдә ул, ничектер һаваланып киткәндәй, лекция сөйләүче лектор сыман кылана башлый: тавышын үзгәртә, уң кулын күтәрә төшеп, олы дикъкать нясенә әверелә.

Без мин торган өйгә кайтып җитәбез. Әти йоклый бугай инде, безнең тәрәзәдә ут юк. Я булмаса өстәл лампасы белән генә утырамы? Соңгы көннәрдә әти тәүфыйкланып китте әле. Төннәр буе яза, сөйләшми, тартмый. Бу олыгаю галәмәтеме, я булмаса илһам килү моментымы — миңа монысы караңгы.

Подъезд төбенә җиткәч, Васил минем кулдан тотты. Ул бераз ояла, тартына. Мин аз сөйлим, сүз бүген аңа бирелгән. Ниһаять, ул да сүрелеп китә, дәшми-тынмый басып тора.

— Я, әйт инде берәр сүз, юксам мин кереп китәм ич,— дидем мин аңа. Васил подъездның караңгы түшәменә карый, бетон стенага йодрыгы белән сугып ала.

— Беләсеңме, Әнрусә,— ди ул, һәр сүзенә басым ясап,— без клубта хор оештырдык... Киләсеңме, йөрисеңме клубка?

Мин үртәп елмаям. Ярый әле: подъездда караңгы, юкса Васил үпкәләр иде.

— Мин җырлый алмыйм бит, Васил...

— Кыланмасана, дәрәҗәң күтәрәсең,— ди ул.

— Васил!.. Алай түгел. Мин, ышансаң, чынлап та җырлый алмыйм.

— Син моны бүтән берәүгә сөйлә, яме! Синең җырлавың турында күп сөйлиләр...

— Кеше сүзенә ышандыңмы?

— Без кешегә ышанырга өйрәнгән.

— Күптәнме?

— Көлмә.— Ул тайпылып куйды. Ярым караңгылык эчендә мин аның ачулы йөзен күрәм. Икенче каттагы лампадан тоныкк кына яктылык Васил басып торган стенага төшә. Кечкенә тәрәзәдән төшү сәбәпле уч төбе кадәр генә җирне яктырта. Васил кайчак, прожекторга эләккән самолет кебек, шул яктыга эләгә. Нәкъ менә шунда мин аның балаларча үпкәләгән йөзен күрәм. Мин үземнең җырлый алуыма шикләнәм. Дөрес, мәктәп елларында мәктәп абруен саклаган идем. Хәтта бер тапкыр Казанга да бардым. Ләкин моның белән генә сәхнәгә чыгып җырларга... Юк, Васил мине тик клубка йөртер өчен генә тырыша булса кирәк. Кем белә, бәлки, ул мине яратадыр.

— Васил,— дим мин, ялварып,— мин керим.

— Үпкәләдең,— ди ул, башын түбән ия.

— Минем сиңа үпкәләргә хакым юк. Дөрес, бер тапкыр булды...

— Теге көнне ташлап киткәчме? Мин бит анда, җүләр, шунда ук сезгә йөгердем. Биш минут та тормадым. Фирдәвес абыйдан рөхсәт кенә сорадым. Әгәр белсәң, аңласаң иде син, ул төнне мин гел йөреп чыктым, оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым.— Ул кулын селкеп куйды.— Булды инде, гафу ит. Чынлап әйтүем, валлаһи...

Көлдем. Бәлкем кирәкмәгәндер. Юк, бу минутта мин Василнең ба-

лаларча аклануыннан көлмәдем, бу ахмаклык булыр иде, аның шул хәтле гади, беркатлы кыланышыннан көлдем. Вәсилнең миңа ачуы чыкты. Подъезд ишеген ачты да чыгып китте. Миңа ничектер кыен булып китте. Күкрәк түремне, әйтерсең кемдер йомарлап тотты да кыса башлады. Хәзер миңа оят иде. Беренче мәлдә минем Вәсилне артыннан куып житәсем, гафу үтенәсем, кочып үбәсем килде. Икенче мәлдә мин бу уемнан кире кайттым. Бәйрәм ашы — кара-каршы, әйдә бераз өтелсен әле.

Әкрен генә, баскычларны саный-саный өскә күтәреләм.

Нәкъ шул чакта Вәсилнең тавышын ишетәм. Тавышы шундый каты — подъезд коридорының тәрәзә пыялаларын зыңгылдата кебек.

— Әнрүсә, иртәгә клубка кил, репетиция алтыда башлана!.. Әнрүсә, ишетәсеңме, ал-ты-да!!.

Һәм тагын ишек тавышы. Мин бу хәлгә йөрәгем кысылганны тоеп, баскыч култыксасына таянып, беравык басып торам. Шул вакыт мин Вәсилне кичерәм, гафу итәм, шатланып көлеп җибәрәм. Кырылган кәефемне җил алып ташлагандай була.

## 12

Сәгать дүрт. Әти, минем киенеп-ясануыма сокланып, кинаяле елмаеп, диванда утыра.

— Кая болай җыенасың?

— Клубка.

— Шәһәрдә клублар күп.

— Үзебезнекенә. Нефтьчеләрнекенә...

— Ә-ә...— ди ул, аңлаган сыман,— нәрсә, әллә кичә буламы?

— Юк, комсомол җыелышында хорга катнашырга дип әйттеләр.

Ул әнә авыз чите белән генә елмаеп алды.

— Барып җиттек, инде үзешчән түгәрәкләргә дә комсомол җыелышы карары белән йөри башладылар.

Мин «шпилька» туфлиемне киям дә көзге каршына киләм, әти әйткән сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә тырышам. Артык сөйләп ташлавыма үкенеп куям.

— Нигә син бер дә театрга йөрми башладың әле, Әнрүсә?

— Белмим,— дидем мин, җилкәм аша әтигә әйләнеп карап.

— Яңа режиссер килде, яңа артистлар киләләр.— Ул бераз кул бармакларына карап торды.— Минем пьесаны куячаклар, хупладылар.

Минем өчен зур яңалык иде бу. Барысына да ышанырга була, әмма әтинең пьеса кадәр пьеса яза алуына... Күңелемә Мөнирә апа сүзләре килә. «Әтиеңнең кәефе юк, пьеса язды. Ләкин режиссер пьесаны тетеп ташлады. Белсәң... Белми ул пьесаны ничек репертуарга үткәрергә...» Әтинең йөзенә карыйм. Ул шат. Ул елмая. Әти ябыккан, йөзе сулыгып киткән, бит уртасында карчыга борыны гына утырып калган.

— Премьерасы кайчан?

— Белмим әле...

— Барырмын, әти, барырмын...

Мин әтине килеп кочакладым да маңгаеннан үбеп алдым. Ул минем кулымнан тотты, нәрсәдер әйтмәкче итте, әмма әйтмәде, күзләрен читкә алды да:

— Инде бар, бар, соңга кала күрмә тагын! — диде.

Үзем тротуардан атлыйм, үзем аяк тавышымны тыңлап барам. Әти алып биргән кадак үкчәле туфли шома асфальтта шак-шок килә. Әнә шуны ишеткән саен тизрәк атлыйсы, йөгереп китәсе килә. Өстемдә ак-ка күксел шакмак төшкән, турыга тегелгән күлмәк. Күлмәк болай үзе капчык кебек кенә, ләкин билгә пута буып җибәргәч, үзенә-үзен соклануып куясың. Минемчә, һәр кеше үз киемен яратып, кадерен белеп

кирго тиеш. Кием-салым кадерен белмэгэн кеше үз хезмэтенен кадерен дэ белмидер кебек мина.

Вэсил мина каршы чыкты.

— hо,— диде ул,— хэзер үк сэхнэгэ чыгасынмы, репетиция ясап торасы булырмы, янсэ...

— Көлмэ эле, Вэсил...

— Я, я, кэперэя күрмэ тагын, юкса синнэн ерак йөрми ул.

— Вэсил!..

— Бетте, бетте...— Ул ишекне ачып мине үзеннэн алда үткэрде дэ, клуб эченэ кергэч, култыклап алды.

Репетиция башланган иде инде. Баянчы, музыка аhэненен hэр тамчысын аңлагандай, башын беркадэр кырын салып, «Сарман» көен уйный. Өстенэ ялт итеп торган кара атлас күлмэк кигэн кыз, кече залнын сэхнэсенэ басып, очарга җыенган кош кебек, көй башын күтэп тора.

— Талант,— диде мина Вэсил,— Сафура.

— Кем?

— Сафура. Матур җырлый. Репертуары бай. Ике ел җырлый инде. Аңсыз бер концертнын да үткэне юк.

— Күпертмэ... Нишлэп сон мин аны белмим.

Без арткы рэткэ утырдык. Кече залда халык шактый иде. Монда яшьлэр дэ, олылар да бар. Алар Сафурадан күзлэрен алмыйлар. Залда «Карурман» моны йөзэ. Сафуранын тавышы монлы. Ничектер, йөрэкне тибрэтэ, дулкынландыра да күкрэк түрен актарып, кешенен ин нечкэ, ин саф хислэренэ кагылып үтэ. Күзлэр дымлана, бөтен тэн буйлап илаhи бер рэхэт агыла, күңеллэр нечкэрэ, дөньяны онытып торасын.

Җыр туктала. Безнен янга чэчен артка тараган, карсак кына буйлы, чандыр гэүдэле берэү килде. Ул ярым пышылдап исэнлэште дэ алга чыгып торган авызын, чөгендер кадэр борынын кыймылдатып:

— Ялгышмасам, Энрүсэ бугай...— диде.

— Энрүсэ,— диде Вэсил минем өчен hэм, сабыр дигэн кебек, кулын күтэрде,— тыңлыйк эле, аннары...

Залда янэ «Энием» моны йөзэ, анын артыннан «Төнбоек», рус көйлэре, рус җырлары, чуваш, hинд, кытай җырлары. Сафурага уч төбем авырткanчы кул чабам.

Сэхнэ бушап кала. Баянчынын күзлэре начар күрэ икэн, аны кемдер култыклап, сэхнэдэн залга төшерде. Бэлэкэй теннис өстэленнэн чак кына зуррак сэхнэгэ элек безнен белэн сөйлэшеп торган «очлы авыз» менде.

— Иптэшлэр,— диде ул, ак күлмэгенэ каптырып куйган «күбэлэгенэ» кулын тидереп,— хор безнен шактый бай, коллектив зур, олы зал бушады, бу сэхнэгэ сыймабыз дип уйлыйм, олы залга күчик.

Дөбер-шатыр килеп кече залдан чыга башладылар. Олы залда иркен иде. Лэкин безгэ анда керергэ туры килмэде. Фойега чыгу белэн, безне теге «очлы авыз» туктатты.

— Вэсил, син хорга күтэрел, э Энрүсэ белэн без илле алтынчыга үтэрбез.

— Я, бар, кыю бул,— диде Вэсил, эйтерсен, мин имтиханга керэм. Без шактый зур бүлмэгэ кердек.

— Эүвэл таныш булыйк,— диде егет,— минем исемем Марс.

— Марс! — дидем мин, чак кына көлеп җибэрмичэ. Чөнки этинен «Марс» исемле эте бар иде hэм кешелэрдэ мондый исемне hич ишеткэнем юк иде. Ул, ахрысы, моны аңлап алды, акланган сыман җилкэсен җыерып:

— Эгэр кешегэ, тугач, үзенэ исем эзлэргэ калдырсалар иде икэн, эйтик, паспорт алганда... Юкса, минем исемем үземэ ошамый да бит, нишлэмэк кирэк,— диде.

— Гафу итегез, мин болай гына...
— Ярар, Әнрүсә, әйдә сөйләшик, ягъни танышыйк, мин нефтьчеләр клубының конферансьесе. Исемемне инде беләсез, фамилиям — Зыя.
Мин янә елмаеп алдым. Ләкин Марс моны күрмәде.
— Мине,— диде ул, кулын аркасына куеп, бүлмә буйлап йөреп китте,— сезнең тавышыгыз кызыксындыра. Васил миңа: «Минем бер таныш җырчым бар, моннан ике ел элек Казанда смотрда да булган»,— дип сөйләгәч, йокым качты. Сез яшь, сездә көч, куәт һәм, әйтик, җырчы дәрте бар, ди. Ул гына да түгел, җырны, көйне аңлау, белү, аны тою хисе бар, ди. Җыр моңын, җыр аһәнен сиземләү, күзаллау аша сурәтләү — ул кечкенә нәрсә түгел. Кыскасы, Әнрүсә, минем сезне тыңлыйсым килә. Иртәгә үк Фирдәвес абыйга тыңлатырбыз, ул инде җырчыга бәя бирә белә.
Мин моны көтмәгән идем, бер мәлгә каушап калдым.
— Мин бит мәктәп җырларын гына беләм.
Марс кулын уып алды.
— Ярый, нинди җыр да ярый.
Сәхнәгә чыгып баскач, кем генә каушамый! Мин сәхнәдә түгел идем, ләкин түрдә дәү магнитофон әйләнә һәм, томыраеп диярлек күзләремә Марс карап тора. Аның яше инде шактый булса кирәк, маңгаен җыерчыклар ермачлаган һәм маңгай өсте шәрәләнә башлаган иде.
— Я, Әнрүсә...
Ни җырларга? Әйдә, Казанда җырлаган һәм шул җыр өчен икенче бүләкне алган «Пусть всегда будет солнце»ны татарча җырлыйм.
Һәм шулай иттем дә. Сафура кебек, түшәм почмагына карадым. Күз алдыма шул көй, шул моң килде. Зәңгәр күк йөзе ачылды, күкне балкытып кояш күренде. Музыка аһәңе көчәйгәннән көчәйде, менә ул минем колак төбемдә яңгырап тора башлады. Әйтерсең лә, чынлап та, кемдер пианинода уйный һәм менә-менә тынар кебек иде. Шунсыз мин бер ялгызым җырны башлый да алганым юк иде.
Белмим, Марс ни аңлагандыр, ни ишеткәндер, мин аны күрмәдем. Мин тик кояшны, зәңгәр күкне, кулга-кул тотынышкан ата белән баланы гына күрдем. Һәм булдыра алган кадәр шул турыда җырлап бирдем.
Икенче бер мәлдә Марс минем кулларымны кысты.
— Яхшы, искиткеч яхшы бу, Әнрүсә! Сез... сез — талант!.. Ишетәсезме, талант!! Нигә, нишләп әлегә кадәр килмәдегез, ә?! Беләсезме, беләсезме, сез бит татар халкының мактанычы!.. Менә хәзер үзегезне тыңлагыз...
Ул магнитофонның тасмасын кирегә әйләндереп, яңабаштан кучерде. Әүвәл Марсның сүзләре, минем җавапларым, аннары җыр... Мин үз тавышыма, үз моңыма ышанмыйча тыңладым. Минме, Әнрүсәме җырлады бу җырны!.. Җыр шундый тантаналы бетте, хәтта Марс тагын, тагын тыңлады.
Ниһаять, ул тәэсирләнеп китеп, тагын бер җыр башкаруымны сорады. Икенче җырым шофер җыры иде, монысын җырлый алмадым. Ничектер шөбһәләндем, оялдым, үз тавышымның фальшен үзем ишеттем, шуңа күрә булса кирәк, бөтенләй каушап киттем, һәм җыр бетмәс борын ук туктап калдым.
— Ярый, ярый,— диде Марс.— Ярый. Ярый... Бусы синең каушаудан. Зыян юк. Үтә торган нәрсә ул. Диңгезчеләрдә «диңгез чире» дигән авыру бар, корабльгә беренче утырган кеше ул чирне үткәрмичә булдыра алмый, диләр. Ул беравык йомры нягеп учлап тотып торды да:
— Әнрүсә, иртәгәдән үк репетициягә йөри башлагыз, яме,— диде.
Мин уңайсызлана калдым.
— Сез инде, зинһар өчен, йөри күрегез,— диде Марс, ялваргандай,— үзегез өчен бит...

— Сәгать ничәгә килергә?

— Кичке алтыга, менә шунда...

— Ярый,— дидем мин, ничек тә тизрәк котылу өчен.— Әмма мин бит укып та йөрим, атнага ике тапкыр.

— Менә яхшы. Калган көннәрдә монда йөрерсез... Ә хәзер залга чыгабыз. Җырчыларыбыз белән танышырсыз.

Хор «Башмагым»ны башкара иде.

Алгы рәттә ап-ак күлмәк кигән кызлар, ә артта кара костюм, ак күлмәккә күбәләк бәйләгән егетләр. Җыр шундый ятышлы, мин тәэсирләнеп алгарак күчеп утырам. Дирижер кырынып килергә онытткан, олы гына ир. Ул, бермәлгә кечкенә таягын күтәреп, тынып тора да дәртләнеп, җилләнеп таягын тагын болгый башлый.

Минем белән янәшә утырган Марс колагыма пышылдый:

— Фирдәвес абый. Карт артист. Җырчы. Пенсионер. Син шунардан өйрәнерсең. Шәп кеше ул. Сәнгать дигәндә дүртенче каттан сикереп төшәргә риза. Әнә Вәсил, күрәсеңме? Икенче рәттә. Аның да репертуары әйбәт. Фирдәвес абый аны зур җырчы итмәкче. Монда килгәнче гел урам малае иде. Талант ул үстергәндә генә үсә, диләр.

Вәсил турында сүз кузгалу белән йөрәгем дөп-дөп тибә башлады. Марска карадым, ул, берни булмагандай, җыр тыңлап утыра иде.

Клубтан мине Вәсил озата чыкты. Такташ урамында безне бер көтү егет туктатты. Аның берсен мин таныдым, гитара уйнап җырлаучы икән.

— Ә Вәсил,— диде ул, кыланып.— Татарстан даны, талант... Тәбрик итәм... уңышың зур, киләчәгең өметле...

— Җәмил, куй, кирәкмәс,— диде Вәсил.

Егетләр безне уратып алдылар. Кемдер сызгырып җибәрде.

— Җәмил, туктат! — диде Вәсил.

— Нигә алай, Вәсил дус... Әйдә, шаяра бирсеннәр.— Ул мина якын ук килеп карады.— Ә-ә, таныш йөз... Гафу, бигайбә. Егетләр, кая әле минем гитара?

Кемдер аның кулына гитарасын тоттырды. Җәмил гитараны җилкәсенә асты да кылларга кагылып алды.

— Бәлкем, Вәсил дус, берне җырлап бирерсең. Әйтик, «Әниемә хат» янсә «Черный кот»ны, ә? Илһамның «Сәлам»ен?

Вәсил икеләнә иде. Мин аның мине култыклаган кулының йомарлануын тоям. Һәм, эчем нидер сизеп, терсәгем белән аның кулын кысам, «кирәкмәс» дим эчемнән.

Күрәсең, Вәсил моны аңлый, гитарага кулын суза.

— Чада кая? — ди ул, егетләр аша үрелеп карый.— Концерт булгач, Чада җырласын иде. Ә син, Җәмил, үпкәләмә, юкка гитараңны аңа бүләк итмисең.

— Көлмә,— диде Җәмил, гитара кылларына сугып, «Черный кот»ны җырлап җибәрде, аны ташлап, «О, море»га күчте.

— Чада, кил әле монда! — диде Вәсил.

Безнең каршыга кечкенә буйлы, хәтта ярым караңгыда да йөзенең нәфислеге беленеп торган ап-ак чәчле егет килеп басты.

— Бир әле гитараңны Чадага,— диде Вәсил, Җәмил кулындагы гитарага үрелде.

— Рәхим итсен,— Җәмил теләмичә генә гитараны Чадага сузды.

Чада кылларга кагылып алды да беравык тынып торды. Аннары, иреннәрен чак кына ачып, нииндидер, миңа таныш булмаган җыр башлады. Минем күз алдымнан богауланган каторжаннар, явыз жандармнар үтте. Себер урманнары шаулады. Зәһәр суыклары үзәккә үтеп, җилкәләрне туңдырды. Каторжанның туган якларын сагынып йөрәге алгысынды. Һәм ул караңгы буранлы төннәрнең берсендә сакчыны үтереп, урманга качты. Ямьсез, шыксыз тайга аны ун көн коллыкта

тотты. Соңыннан ул зәңгәр күккә карап, ак кар өстенә ятып, яшьлек гомерендәге мәхәббәтен исенә төшереп җан бирде. Ә кайнар йөрәк, карны эретеп, җир куенына сеңде.

Җыр бетте. Егетләр, җырдан тәэсирләнеп, тын калдылар. Тынлыкны Җәмил бозды.

— Бир әле, Чада, синең җырың йөрәкне телә. Фуу, җанны алып атты. Киттек, егетләр... Хуш, Вәсил.

— Хуш,— диде Вәсил, минем терсәкне кысып.

Без тар урамнан, нәкъ юл уртасыннан атлыйбыз. Вәсил аз сөйли. Күрәсең, егетләр белән очрашу аның кәефен бозды. Мин, сүз башларга яхшысынмыйча, үз уйларыма чумып атлыйм. Аннары, минем Чада турында беләсем килеп китә.

— Вәсил, кем ул Чада?

— Чадамы? — диде Вәсил, уянып киткәндәй, сискәнеп.— Чада — егет ул!

— Егет икәнен мин аны синнән башка да күрдем.

— Ә-ә, ул як белән түгел, ирләр киеме киеп йөри торган кызлардан түгел ул Чада. Буе кечкенә булса да бик эмоциональ егет ул. Кызлар аңа бик тиз гашыйк булалар. Җырчы. Кирәк булса, сиңа да ул көй чыгара, сүзләрен дә үзе яза.

— Каторжанны да үземе?

— Үзе булмыйча...

Без подъездга килеп җитәбез. Бу урын безнең соңгы тукталыш. Вәсил минем кулларымнан тота һәм сизелер-сизелмәс кенә үзенә таба тарта. Шул вакыт мин аңыма да килә алмый калам, ул мине кочаклап үбә. Мин бар көчемә аны читкә этәрәм һәм, әйләнеп тә карамыйча, икенче катка йөгерәм.

— Җүләр, җүләр син,— дим мин, ачуланып.

## 13

Фирдәвес абый мине элекке танышы кебек каршы алды. Иң әүвәл, каршына утыртып, тормыш хәлемне сорашты. Ул озын, чандыр гәүдәле, алтмыш биш яшьләрендәге кеше. Мин әтиемне театрда художник булып эшли дигәч, ул хәтта торып, ишекле-түрле йөренеп китте.

— Карасана син аны, алай диген, Галим кызы. Синең әниең бит Мәскәүдә үлде. Ярыш вакытында!.. Әйе, әйе... Карасана син аны, ә!.. Галим кызы. Без бит аның икенче туенда булган идек. Акыллы кеше, зирәк кеше. Ярты сүздән сине аңлап ала. Оста. Нишләп соң әле ул бу арада бер дә күренми?.. Пьеса яза? Китсәнә! Вәт син аны, ә! Премьерасы була... Кайчан? Киләсе атнага!.. Әйттем мин аны карчыкка, буш кеше түгел дип...

Ул минем каршыга килеп басты.

— Әниең бик чибәр иде синең. Сын дисеңме үзендә, күз-йөземе, чын татар Зөһрәсе иде.

Ул, башын кырын салып, бермәл миңа карап торды. Мин оялдым, күзләремне аяк очыма текәдем.

— Син дә, Әнрүсә, әниенә охшагансың, ләкин...

Аннары ул, нидер исенә төшеп, каударланып алды.

— Карасана син аны, онытып җибәрә яздым бит... Синең җырың миңа ошады. Тавышың белән уйныйсың, бигрәк тә әнә шул ошады миңа. Магнитофонның башын әйләндереп бетердем. Дүрт тапкыр тыңладым. Тик, ни, татар җырларын да җырлыйсы иде бит, сиңа, Әнрүсә... Беләсеңме, нинди җырлар бар! Синең тавышыңа, моңга күп җырлар табып була. Тик әүвәл өйрәнәсе булыр, ай үтәрме моңа, елмы... Чын җырчы булуы уен эш түгел. Моның өчен авыз күтәреп җырлау гына җитми. Профессиональ җырчы булу өчен күп көч куярга кирәк. Җыр

кешене жылата да, көлдерә дә, уйландыра да. Җыр ул — кешенең җаны. Шул. Ә хәзер әйдә, пианино янына...

Без түр тәрәзә каршысында торган кара пианино янына килдек. Башта оялып, куркып утырган идем, Фирдәвес абыйның соңгы сүзләреннән соң тынычлана төштем.

— Я, әйтик, шул булыр беренче иман шарты, менә, мә әле сиңа сүзләр. Ә көен мин үзем карармын. Нидән башлыйбыз? Карап чык. Ә мин бармакларны яза торам.

Җырларның яртысы миңа таныш түгел. Үзем бераз белгән җырларны сайлап алдым да Фирдәвес абыйга суздым.

— Тегеләрен гел ишеткәнем дә юк.

— И зрә,— диде Фирдәвес абый,— синен кебек тан сандугачы дөньядагы бар җырны белергә тиеш. Синең, Энрусә, киләчәгең бар, мин сиңа ышанам. Чөнки моң, аһәң дигән нәрсәне ишетү белән бәя бирә беләм. Әлек мин үзем күп җырладым. Я, нидән башлыйбыз?

— «Төнбоек...»

Фирдәвес абый күзләре белән елмаеп алды.

— Хуш, әйдә...

Ул нечкә бармаклары белән пианино телләренә тиеп алды да «Төнбоек»ны уйнап җибәрде. Әнә шул музыка, әнә шул моң матур бер күлне минем күз алдыма китерде. Бәләкәй генә күл, үрдәкләр йөзә, камышлар шаулый, түгәрәк яфраклы төнбоеклар көмеш-сары чәчәкләрен су өстенә җәеп салганнар да, күктә кыздырган кояшның нурларына сокланып, рәхәт гизәләр. Мин яр буена киләм, төнбоекны күрәм һәм табигатьнең матурлыгына таң калам.

Җыр тәмам булгач, Фирдәвес абый беравык кулларын клавишалар өстеннән алмый торды, аннары, башын селкеп:

— Шәп,— диде,— беләсеңме, син безнең клуб өчен кем?.. Йолдыз!.. Вәт — йолдыз. Синең исемең бүгеннән — Йолдыз!..

Ул озын бармагын түшәмгә төртеп, һәр сүзен такмаклап әйтте.

— Тик, тик, өйрәнергә, өйрәнергә, өйрәнергә кирәк. Мин мактады дип исең китмәсен. Синдә әле җырны бозу колагыңны томалап качарлык. Ләкин теләгән кеше анысын җиңә алыр дип ышанам. Бүгенгә житте. Инде хәзер нидән башлыйбыз? — Ул урыныннан торды да тагын минем каршыма килеп басты. Миңа ничектер аның бер күзе үзенеке түгел кебек тоелды. Ул башын кырын салды да: — Син эшлисенме? — диде.

— Эшлим...

— Һм... Димәк, кич белән генә була аласың. Кичке якта минем эш күбрәк була булуын...

Фирдәвес абый янә ишекле-түрле йөреп килде. Ул бер як яңагын тоткан, әйтерсең лә, аның теше сызлый иде. Аннары ул кисәк кенә туктады:

— Менә нәрсә, Энрусә, син кичке дүрткә клубка килә аласыңмы?

— Мин өченче яртыда эштән кайтам.

— Булды! — Фирдәвес абый шатланып китте.— Димәк, килә аласың... Булды. Сиңа атнага өч көн бирәр сәгать вакытымны бүләм. Вәгъдәме?

Ул минем кулны тотты, күзләремә карады. Нәкъ шунда мин аның сул күзенең бераз читкә карап торуын, пыяла булуын күрдем. Ул моны сиздә булса кирәк, карашын читкә алды.

— Вәгъдә,— дидем мин.

Аннары ул тәрәзә каршына барып басты. Һәм тыштагы берәүгә сөйләгән кебек:

— Күземне минем пленда чакта фашистлар сугып агыздылар,— диде.

Бүлмәгә шау-гөр килеп егетләр-кызлар керә башлады. Алар арасында Васил дә бар иде. Ул, гаепле кеше сыман, уңайсызланып, мина таба атлады. Мин ачык ишеккә ташландым. Тышка йөгереп чыккач кына күкрәгем тутырып сулыш алдым.

Эти өйдә иде. Бүген бер ахирәтен алып килгән. Өстәл тулы сыра шешәләре. Эти ахирәтен үбәргә үрелә. Мине күрү белән дусты (мин бу көдрә кара чәчле кешене беренче тапкыр күрәм), дөберштатыр күтәрелеп, кулын йөрәк турысына куеп, баш иде. Янәсе, исәнмесез. Мин, исәнләшеп, үз бүлмәмә кереп киттем. Ишекне яптым да бераз ишек төбендә басып тордым. Эти көдрә чәчле кешегә мыгырдап нидер сөйли. Соңгы айларда гына түгел, хәтта мәнә ел тула, этинең болай исерек чагын күргәнем юк иде әле. Ничектер күңел пошынып куйды. Ни сәбәптән эчте икән? Кем бу көдрә чәчле кеше?

Әле иртә, ятасы килми. Әкрен генә түргә узам, затлы киемнәрем белән караватыма утырам. Кичә генә эти алып кайткан «Ак чәчәкләр» китабын кулыма алам. Ләкин укыйсы килми. Нигәдер эч поша. Нигә соң әле мин Василгә болай... Ни гаебе бар аның?!

Китапны ачып актара башлыйм. Гөлшәһидә... Врач кеше. Олы йөрәк. Ике иргә чыга. Бәхетле. Ләкин бәхетме бу? Күңелемә Айхәл абый килә. Ул һаман, баеп барган кояшка карап, тәрәзә каршында басып тора кебек. Көтә, Ләйсәнен көтә. Сәер дә бу мәхәббәт. Мин аны, Айхәл абыйны, кызганам. Юатасым килә. Җуләр, ни уйлыйм мин?! Тышта инде караңгы, тәрәзә каршына килеп басам. Әле урамда хәрәкәт зур. Кеше хәрәкәте, кеше елгасы.

Мин янә караватым янына килэм, чишенмичә ятам. Эти кереп утны кабыза.

— Карале, Әнрүсә,— ди ул, авызын чупылдатып ала,— кибеткә барып кайт әле, кызым. Бер кызыллы алып кайт. Гаптершин үзе килде бит. Атап килгән. Хәл белергә.

Этинең чәче тузган, күлмәк якасы күтәрелгән. Нейлон күлмәк, үткән атнада гына алган идек. Премьера буласы куанычыннан.

— Я, барасыңмы?

— Барам... Акчаң кая? Кем ул?..

— Кем?

— Гаптершин...

— Ә-ә, ул, редактор ярдәмчесе, фельетончы. Пьесага рецензия язам, ди. Усал яза ул үзе... Я, барасыңмы?

— Барам дим ич. Бир акчаң.

— Акча бетте бит, кызым.

Мин эти каршына килеп басам.

— Ярый, акча табармын, эти. Ләкин, эти, соңгы тапкыр, яме?

Мин кибетче Соня ападан:

— Нигә кеше юк? — дип сорыйм.

— Нигә булмасын, син кеше түгелмени? — дип, ул көлеп җибәрде.

Акчаны алгач, ул шешәне өстәлгә чыгарып бастырды.

— Кәгазьгә төрәсе иде.

— Шешә төрергә түгел, гәҗит чыгарырга да җитми ди әле ул кәгазь.

Мин сумка алмавыма үкенеп, шешәне кофтам астына кыстырып, кибеттән чыгам. Як-ягыма каранам. Күңелсез хәл, кыз башын белән төрелмәгән шешә күтәреп кайт. Ну, бу этине!

Эти мине коридорда ук каршы ала.

— Булдымы? — ди ул, түземлеген җуеп.

— Булды...

Мин куеныма керәм, озын муенлы кара шешә тартып чыгарам.

— «Варна» — ди эти, йөзе ачылып китә.

— «Варна»,— дим мин, начар кызыл булды, ахры, дип шиккә калам.— Шуны бирделәр бит, башка төрле юк иде.

— Шәп,— ди әти,— иң яхшы кызыл бу.— Әүмән-тәүмән атлап залга кереп китә.

Мин бүлмәгә үтәм. Чишенәм. Ятам. Йоклыйсым килми. Күз шар ачык. Күз алдына Вәсил, Айхәл абый, әти, Ләйсән апа, иң соңыннан Фирдәвес абый һәм очлы авыз Марс килә.

Вәсил... Вәсил белән бетте. Мин көрсенеп, борылып ятам. Начар бетте. Коч та уп, имеш. Җүләр, тиле. Мин аны якын җибәрмим хәзер.

Гыйлаҗ мине хәзер күрәлмый. Күзе-башы тонган. Аңа комсомол эше кирәк. Кызлар кулын тотып, күзенә караса да, әхлак темасына мораль укый башлый. Беркатлы кәбестә. Шулай кызлар аны яратырга тиеш дип уйлый, күрәсең. Шиш!

Айхәл абый. Райком эшчесе. Эш дисә дөньясын оныта, хатынын да... Ә Ләйсән Айхәл абыйны гаепли. Җанны өшетә, җанны суыта торган адәм, ди. Айхәл абый барысы белән дә килешә, баш игән. Ярата, сөя. Ә тотып тора алмаган. Хатын табу — бер бәла, гомер итү, тору — мең бәла, ди әти.

Әтинең түбәсе куккә тигән. Пьесасы сәхнәдә уйнала. Бушлай акча алып ята, гонорармы диләр. Һәм бетерә. Ни файда? Их, әти, әти!.. Бәлкем, Мөнирә апа булса, алай ук итмәс иден...

Ләйсән. Фатихның йөрәк турына башын куеп ята бугай. Чибәр хатын. Бәхет ташып тора үзендә.

Мин... Мин... Мин йокыга китәм.

## 14

Без Казанга барабыз. Бер көтү. Смотрга. Вәсил дә бара. Аның янәшәмдә булуы рәхәт миңа. Ләкин мин сер бирмим. Юри кырысрак сөйләшәм. Хәтта Гыйлаҗ да бара. Чада да. Хор. Биючеләр, шигырь сөйләүчеләр, сүз осталары, кыскасы, тел бистәләре, әрәмә сандугачлары.

Чада Җәмилнең гитарасын аскан. Ул аны үзеннән калдырмый. Ул ни татар түгел, ни рус түгел. Тегесе дә, монысы да. Әтисе татар булган, әнисе маржа. Вәт и метис туган. Ике телне дә элдертә, теленә шайтан төкергән. Русча, татарча җырласа да, ул моңлы җырларны ярата. Гитарасы, җилкәсенә аскач, чак кына сөйрәлми. Үзе бик үк игътибар да итмәгән кебек, ә үзе шул гитараны өрмәгән җиргә генә куймый, күз карасы кебек саклый. Җәмилгә бу гитараны Испаниядән әтисе алып кайткан, әле Бөек Ватан сугышына кадәр. Ничек аны Җәмил Чадага биргән, шаккатам...

Аннары тагын шуңа шаккатам. Җилкәсенә гитара асып, йөгәнсез һәм әдәпсез җырлар җырлап йөргән Җәмил үзенең дуслары белән һәркөн хорга килә башлады. Вәсил әйтүенә караганда, аны хорга катнашырга димләп озак йөргән ул. Җәмил тиз генә риза булмаган. Кулыннан тотып, әтисе белән бергә Испаниядә булган Фирдәвес абый янына алып кергәч кенә күнгән. Хөрмәте зур Фирдәвес абыйга Җәмилнең. Мин кайчак көнләп куям. Вәсилдән шул турыда сорагач ул:

— Һәр кешенең йөрәгенә ачкыч таба белергә кирәк,— диде.

Мактана да соң кайчак бу Вәсил. Әллә мактанмыймы? Әллә минем кебек аны барысы да ятатамы? Минем дә йөрәгемә ачкыч тапты кебек бу Вәсил. Сөйләшәсем килә үзе белән, үзенә елышасым, чәчләреннән сыйпыйсым килә. Их ма, бар да син дигәнчә генә булсын икән ул...

Вәсил белән ике ай инде менә җүнләп сөйләшкәнебез юк. Ул миңа үпкәләгән, мин аңа. Минемчә, ул гафу үтенергә тиеш. Ә ул юк, теләми, каты маңгай, тинтәк, менә кем ул...

Фирдәвес абый иң алдагы урында. Кубесе аның тирәсендә чуала. Ул мәзәкләр сөйли. Минем янга Чада килеп утыра. Ул чәчләрен ялты-

ратып бер якка тараган. Күзләре зәп-зәңгәр. Әнисе зәңгәр күзле булган булса кирәк. Күзләр күбрәк әни ягына тарта, диләр. Борыны юка, кашлары калын, терсәкләре очлаеп тора. Буйга ул тәбәнәк, хәтта миннән дә тәбәнәгрәк. Мин аңа өстән торыбрак карыйм. Менә гаҗәп, ул бик оялчан икән. Бер генә дә туры карамый. Ә үзе сөйли, бер татарча, бер русча. Битләре ак, кызларныкы кебек. Хәтта тотып карыйсы килә.

— Чада,— дим мин аңа, ул миңа күтәрелеп карый да күзләрен тез өстендәге гитарасына төшерә, нечкә бармаклары белән кылларын сыпыра.

Автобус тигез генә гүләп алга чаба да чаба.

Без шул гүләү тавышына шактый кычкырып сөйләшәбез.

— Әнрүсә,— ди Чада,— син хорда минем белән янәшә басма.

— Нигә?

— Басма инде!..

— Ярый соң...

Мин үпкәләгәндәй итәм. Чада моңа ышана, аптырап кала.

— Син алай-болай дип уйлама тагын. Беләсең килсә, мин сиңа гашыйк.

— Менә сиңа мә! — дим мин, шаккаткандай итеп, күзләремне зур ачып, чак кына каерылып аңа карыйм.— Нигә соң аны әллә кайчан әйтмәдең?

Чада кып-кызыл була. Хәтта куллары да кызара кебек.

— Көлмәгез, яме, көлмәгез!

Һәм ул җәһәт кенә тора да Фирдәвес абый янына китеп бара.

Минем йөрәкне нидер телеп киткәндәй булды. Ярый әле бу хәл озакка бармады. Күңелемнән оялып, борчылып барсам да, бераздан бу турыда бөтенләй оныттым. Автобус тирбәтүенә йоклап киткәнмен.

Мине Васил уятты.

— Әнрүсә, Әнрүсә, Казан!..

Күзләремне ачтым, автобуска утырган чактагы кырыслыгымны онытып, елмаеп Василгә карадым.

— Казан! — диде ул.— Ишетәсеңме, Казанга житәбез!..

Тәрәзәләргә карадык. Иң әүвәл очын күккә терәгән Сөембикә манарасы күренде, аннары, ап-ак Кремль, аның алтын йолдызы күзгә чалынды.

Казан... Мин тәэсирләнеп киттем, Тукайның Казан турындагы шигырен күңелемнән укыйм:

> «Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап...»

Васил үз алдына сөйләнә:

> — И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Икебез дә бер үк уйны уйлаганга аптырап, мин аңа карыйм. Ул елмая, ул шат, күрәсең, минем дә нәкъ шул турыда уйлаганымны аңлап ала, томыраеп минем күзләремә карый.

— Әнрүсә, Әнрүсә, мин сине яратам,— ди ул, пышылдап,— ишетәсеңме, я-ра-там...

— Ә мин сине я-рат-мыйм...

Үзем гел аңа якынаям, аңа сыенам. Маңгаена төшкән чәчләрен сыйпыйсым килә. Васил моны сизә, тетрәп торган бармаклары белән минем чәчләремә, йөземә кагылып ала.

— Әнрүсә, мин сине бик тә яратам,— ди.

Һәм берәрсе күрер, игътибар итәр дип, кычкырып «Туган тел»не җырлый башлый. Кемдер баян тартып җибәрә. Мин дә Василгә кушылам. Минем тавышым башкаларны да кузгата, барыбыз да җырлыйбыз.

Автобус Казан урамнарына барып керә. Ә безнең җыр ачык тәрәзәләрдән Казан урамнарына тантаналы гимн булып тарала. Үтүчеләр туктап, безнең автобусны күзләре белән озатып калалар.

Концертта без дүртенче чиратта чыгачакбыз. Безнең тирәдә Фирдәвес абый урала.

— Кызларым, каушамагыз. Өйдәге кебек хис итегез үзегезне...

— Нигә без каушарга тиеш? — ди Сафура.

— Шуны әйтәм дә шул,— ди Фирдәвес абый,— нигә каушарга?! Чык та бас, үзебездәге кебек, өйдәге кебек.

Марс көзге алдында ыспайлана.

Фирдәвес абый аңа күз ташлап ала.

— Ыспайланма әле шул хәтле, Марс,— ди ул, аңа карамыйча гына. Марс турсая, авызын очлайтып ала.

— Пушкин кардәше...

— Я инде, күй, Сафура, җәберләмә. Мин бит конферансье. Каушап куюым бар.

Сафура белән Марс бик күптән йөриләр. Ләкин әле өйләнешү дәрәҗәсенә житмәгәннәр. Кайсы өлгермәгән? Марс бугай. Сафура үзе әллә юри, әллә чын, шулай ди.

— Марс жаным,— ди Сафура, мыскыллап,— зинһар өчен гозерләп әйтәм, эт кебек өреп җибәрмә. Юкса бер тапкыр кеше көлдерәм дип, шулай иткән идең бит.

— Сафура!..

Марс усал итеп Сафурага карап куя.

— Җитте сезгә,— ди Фирдәвес абый,— хәзер чыгабыз. Чада! Чада! — ул башлар өстеннән үрелеп Чаданы эзли.— Чада!!

— Мин монда, Фирдәвес Сәгыйтович.

— Кая олактың, бөжыр? Кил әле монда.

Чада аның каршына килеп басты. Аның өстендә жете кара костюм, ак күлмәк, якасында кара күбәләк.

— Ашыкма. Дулкынланма. Кул чапсалар, көт. Ашыкма.

Ул Чаданың кылган сыман чәчен сыпырып куйды. Һәм аның башы аша Вәсилне эзләде.

— Вәсил, Вәсил! Кил әле. Кил инде,— диде Фирдәвес абый, Вәсилнең җиңеннән тотып үзенә таба тартты.— Сузма. Үз вакытыңны үзең бел. Көчәнмә, ишетәсеңме, көчәнмә.

Марс иренен турсайтты, ачуы чыкты.

— Фирдәвес абый, пожалуйста...

— Бетте,— диде Фирдәвес абый,— бетте. Аңлашылды. Урыннарыгызга. Ни, Әнрүсә, син кал. Бер генә секундка...

Мин аның янына килдем. Ул ничектер сәер итеп миңа карады.

— Әйдә утырыйк әле.

Минем өстә озын итәкле җемелдәп торган ак ефәк күлмәк, аякларда Казан читеге, кыскасы, хан кызы мин.

— Мин утырмыйм, күлмәгем бөгәрләнә.

— Я, алайса, утырма. Сина, Әнрүсә, киңәшем бар. Бик алга барып басма, тавышың зәһәр, эффект кими. Аннары, җюри ягына карама. Тамашачыларга кара, оялма.

— Ярый.

— Сина өметем зур, Әнрүсә, үпкәләмә. Мөнирә ул — безнең шәһәр кешесе. Бер семья...

Фирдәвес абый нәрсәдер әйтергә теләгән иде, әйтмәде, торып басты.

Мена чыгарга да вакыт житте. Сәхнәгә Марс чыгып басты. Ул бәрхет кебек йомшак тавышы белән шәһәрнең исемен әйтте, нефтьчеләрдән зур итеп сәлам тапшырды. Аңа гөр килеп кул чаптылар.

Аннары сәхнәне ябып тордылар. Без хорга чыгып бастык. Пәрдә күтәрелде. Тып-тын торабыз. Ә күз бит күрү өчен. Мин сәхнә каршын-

дагы кызыл плюш ашъяулык җәйгән өстәл артындагы жюри членнарын күрәм. Иң уртада — Мөнирә апа. Кулында карандаш, алдында бер бит кәгазь. Без шактый озак җырны башламыйча торабыз. Фирдәвес абый аркасы белән тамашачыларга, алды белән безгә карап, рояль уйнаучының түземсезлек белән уйный башлавын көтә. Тик рояль артына кереп утырган чал чәчле хатын ашыкмый, ноталар актара. Фирдәвес абый бер безгә карый, бер уйнаучыларга карый, пошына. Ниһаять, уйнаучы нотаны таба, бармаклары белән телләргә тиеп ала, Фирдәвес абый тораташтай катып кала. Без дә тынабыз. Мавзолей алдындагы сакчылар, диярсең.

Башлап җырлаучы Сафура. Ул, аз гына алгарак чыгып, җырлап җибәрә. Зал тына, шау-шу ишектән чыгып китә. Түшәм-почмакларга бәрелә-сугыла залда җыр агыла башлый. Безгә йөз прожектор караган Телевизорга төшерәләр.

Аннары кул чабалар. Икенче җырны мин башлыйм. Бер күзем белән жюри комиссиясендә утырган Мөнирә апага карыйм. Ул да күзен миннән алмый. Кулындагы карандашы читтә ята.

Хордан соң ялгыз җырлар башлана. Чада белән без иң соңыннан чыгабыз. Чада миннән алда җырлый, мин аннан соң. Чада бүген сандугач күк сайрый. Зал аны җибәрми, кат-кат сорыйлар. Ул бер рус җырын, бер татар җырын башкара. Һәм аңа гөр килеп кул чабалар. Ул, олы артистларча, күкрәгенә кулын куеп, баш ия. Кылган сыман чәче таралып маңгаена төшә.

Сәхнәгә мин чыгып басам. Зал шып була. Мөнирә апа ике кулы белән башын кысып, кәгазьгә карап утыра. Мин җырлыйм, яшь йөрәгемнән кайнап чыккан моңны, мәхәббәтне залга бирәм. Жюрида карандашлар нидер яза. Мөнирә апа башын калкытып куя, аның күзләре яшь белән тулган кебек тоела миңа. Мине дә кат-кат сорыйлар. Фирдәвес абый, сәхнә артына чыккач, азрак ялынсыннар дип, мине тотып тора, аннары алкышлар басыла башлагач кына янә чыгарып җибәрә. Ләкин смотрда тәртип бар: программаңнан башка артык бер җыр да җырлый алмыйсың.

Соңгы тапкыр сәхнә артына чыккач, Фирдәвес абый мине маңгаемнан үбеп алды. Кызлар мине тәбрикләләр, егетләр кулымны кысарга үреләләр. Иң соңыннан Чада яныма килә.

— Барысын да актарып салдың,— ди ул.

— Син дә,— дим мин.

Һәм без икебез дә елмаешабыз. Чаданың йөзе ап-ак, яңа акшарлаган моржа кебек.

— Син нәрсә,— дим мин,— әллә пудра сөрттеңме?

Чада читкә карады, кулы белән битен сыпырып алды.

— Ә нигә, артистлар кебек булырга теләгән идем. Монда бер апа бар, күрде дә, әйдә, чын егет ясыйм үзеңне, ди. Әйдә, мин әйтәм, кыландырып кара.

— Шуннан, кыландырдымы?

— Күрмисеңмени?

— Юк.

Чада ышанды, ботына сугып алды.

— Менә син аны, убырлы карчык, алдады бит... Ышанасыңмы, бер яртылык акча түләдем бит мин аңа!

— Кемгә?

— Кемгә, кемгә, гардеробчыга.

— Ни өчен?

— Ни өчен, гримировать иткән өчен...

Безнең янга Фирдәвес абый килде.

— Ну, Чада, Әнрүсә, безгә китәргә рөхсәт. Фуу, йөрәк тибә. Әйдәгез!..

Чада аяк терәп каршы килде.

— Мин беркая да бармыйм,— ди.

Фирдәвес абый, кашларын сикертеп, гаҗәпкә калды.

— Син нәрсә?

— Юынасы иде.

— Нигә тагын?

Мин Фирдәвес абыйга Чада белән булган хәл турында сөйләп бирдем. Ул башта моңа ышанмады, соңрак, Чаданы ут яктысына чыгарып карагач, маңгаен җыерды:

— Латыйфа эше. Һаман шул гадәтен ташламаган икән әле, юньсез,— диде.

Ул Чаданы култыклап алды:

— Әйдә, юындырам. Әнрүсә, син киен дә тамашачылар залына чык. Табарбыз без сине.

## 16

Смотрда безгә беренче урынны бирделәр. Берочтан тагын бер-ике клубка барып җырладык. Казан халкы мәзәк ул, сөйләшә русча, җырлый татарча, татар театрын карый. Концерт булган урыннарда басып торыр урын юк.

Иртәгә китәсе дигәндә гостиницага Мөнирә апа килде. Ул болай шат кебек иде. Барыбыз белән дә күрешеп чыкты. Затлы итеп киенгән. Бездән киткәннән бирле үзгәрмәгән дә кебек үзе, күз төпләренә җыерчыклар өстәлгән дә, чәче ак мәрмәр төсенә кергән. Әллә буяткан, әллә картаю галәмәте. Мине ул кочып алды. Кунакка чакырды.

Мин аптырый калдым. Ләкин кызлар үгетли башлагач, киенә башладым. Өстемә карага ак шакмак төшкән күлмәгемне кидем, аягыма биек үкчәле ак туфли элдем. Мөнирә апа сокланып, елмаеп утырды.

Кыры шакмаклы такси безне Ленин урамына, «Бегемот» дип йөртелә торган йорт каршысына китереп туктатты.

Мин монда булсам да, беренче тапкыр күргән кук, Казанга сокландым. Ак Кремльгә, Муса Җәлил һәйкәленә, Идел булып җәелгән Казанкага карап торам. Мөнирә апа моны аңлый, шуңа күрә мине ашыктырмый.

— Матурмы?

— Искиткеч! Таң калырлык...— дим мин.

Без өченче катка күтәреләбез һәм шактый киң коридорлы квартирага керәбез. Чишенәбез. Мөнирә апа миңа булыша, мин оялам. Аннары залга керәбез.

Җиһаз, затлы мебель. Минем әле беркайчан да мондый квартира күргәнем юк.

Мөнирә апа мине йомшак тахтага утырта, үзе кухня ягына чыгып китә.

Мин ашыкмый гына залны күзәтәм. Ике якка ачылышлы ишек янында китап шкафы, түр якта тәрәзәнең ике як почмагында кара кофе төсендәге тумбочкалар. Тумбочканың берсендә телевизор, берсендә кофе төсендәге телефон. Миңа каршы стенада затлы рәсемле келәм. Аның астында буфет. Буфет зур, киң, матур. Алтын ачкычлы, алтын тоткалы, пыяла капкачлы. Дүрт почмакта дүрт кресло. Зал уртасында озынча түгәрәк өстәл. Өстәлнең ике ягында шундый ук кофе төсендәге урындыклар. Стена тулы картиналар, борынгы рәсемнәр.

Шкаф, өстәл, тумбочка өстендә ник бер чүпрәк заты булсын. Гади дә, затлы да, матур да.

Мөнирә апа килеп керде. Ул ничектер мина монсуланып карый. Өстәлгә ашъяулык җәйде, табын әзерли башлады.

— Минем ашыйсым килми, Мөнирә апа.

— Килер әле. Кич озын... Чәй эчәрбез... Бүген син бездә генә кунарсың инде.

— Кызларның үпкәләүләре бар. Кайтам дип әйттем бит.

— Калмыйсыңмыни?

Мөнирә апа кинәт урындыкка утырды, ике күзеннән яшь бөртекләре атылып чыкты. Ул ничектер картаеп, олыгаеп киткән кебек булды.

— Ярый соң,— диде ул, урындыгыннан торып, өстәлгә савыт-саба куя башлады.

— Гафу итегез, Мөнирә апа, мин болай... Яхшы түгел бит...

Ул тәрәзәгә карады, яшь бөртекләрен сөртмичә генә:

— Белмисең шул әле син, хәер, белсәң дә... Галим исәнме? Әтиең диюем?

Бу сорауны көтмәгән идем мин,— әти турында сорагач, каушап калдым.

— Исән ул. Эшли.

— Өйләнмәдеме?

— Олы бит инде ул, юк...

— Әйдә, утыр. Менә моннан. Вино эчәсеңме?

— Гомеремдә капкан әйберем түгел.

— Гомерең синең яңа башлана гына әле, кызым Әнрүсә. Әле виносын да эчәрсең...

Ул, нидер исенә төшеп, каударланып кухняга чыгып китте. Өстәлгә чәйнек чыгарды, алма, торт, виноград китереп куйды.

— Әйдә, аша, эч, тартынма... Бәлки бер рюмка гына эчәрсең?

Мин каршы әйтергә оялдым. Мөнирә апа минем алга кан кебек кызыл вино куйды.

— Эч, берне генә. Затлы вино ул. Ә градусы гел юк... Курыкма...

Мин көч-хәл белән йөткерә-күркә бер рюмка вино эчтем. Күңелем теләгән ризыкларны ашадым. Бер чынаяк чәй эчтем.

— Аша инде, житеш.

— Рәхмәт, ашадым...

— Я, алайса, әйдә монда утырыйк.

Ул килеп терсәгемнән алды да мине үзе белән янәшә тахтага утыртты. Аңардан тәмле хушбуй исе аңкый иде.

— Әтиең мине оныттымы, я булмаса, хәтеренә төшергәлиме?

— Белмим. Мин аның белән аз сөйләшәм. Күп сөйләргә яратмый бит ул. Үз-үзенә йомылып яши бирә...

— Шундыйрак шул. Сүзгә саран кеше иде шул ул...

Мөнирә апа туп-туры күзләремә карады, аннары башымны күкрәгенә салды. Чәчләремнән сыйпый башлады.

— Беләсеңме, мин сиңа кем, Әнрүсә?

— Кем?

— Әниең...

— Әнием!?.

Мөнирә апа мине кочып алды да елап җибәрде. Шашынып мине үбә, иркәли, аркамнан сөя башлады.

Аннары ул, терсәкләрен тезләренә терәп, башын кулларына салып, тын гына утырды.

Мин бу хатынга ни әйтә ала идем... Кем ул миңа? Вакытлыча әти белән яшәгән кешеме, я булмаса... Дөрес, ул мине яратты, үз кызы кебек күрде. Ләкин кеше йөрәге корыч кебекката да, балавыз кебек йомшара да белә икән ул. Мин аны ярата идем, үз әнием кебек күрә идем. (Әти белән торганда.) Хәзер — юк, йөрәгем минем корыч кебек.

Менә шуның өчен ни кызгансам да, ни жәлләсәм дә, мин бу хатынга йөрәгемне ачып бирә алмадым. Тәүге минутта әнә шул нәрсә минем йөрәгемне телде, бәгыремне ашады.

Мөнирә апа сөйли башлады. Ул дулкынлана, аның тавышы калтырый иде:

— Мин синең, Әнрүсә, җан әниең. Әйе, әйе, син хәзер зур инде, үстең, буй җиткердең, акыл алдың, хәзер сөйләргә була. Кем дә кем дөньяда күргән-белгән серен теге дөньяга алып китәргә тели, ул бәхетсез кеше. Әйе, әйе, ул аны кемгә булса да сөйләргә тиеш, бушанып, җиңеләеп калырга тиеш. Инде мин илледән өскә таба киттем. Картайдым, арыдым. Талантым бар иде, җирдән йөрмәдем, туфракка аягым тимәде. Заманында баш әйләндергеч иде дәрәҗәм. Мин уйнаганда билет бер атна алдан сатылып бетә торган иде. Мин бәхетле идем. Нәкъ шул чакны син тудың. Сугыштан соңгы өченче җәй иде. Мин сине тапкач та, үзебезнең режиссер киңәше белән асрамага бирдем. Чөнки мин артист идем, сәхнә өчен яши идем. Ә Галим бала теләде. Ләкин, синең кыз булуыңны белгәч, мине алырга да килмәде. Дөресрәге, шундый сылтау тапты. Ләкин аның килмәве син кыз булганга түгел, мин ул вакытта аңардан күңелем белән киткән идем инде. Шуның өчен килмәде ул. Кешенең күзаллавы үсә барган саен, дөньяга карашы да үзгәрә. Һәм шуннан соң инде ул бала, гаилә колы булып яши алмый башлый. Аңа колач җәеп очарга, үсәргә кирәк, ә аның итәгенә баласы ябышкан. Әнә шулай минем башымны бертуктаусыз әйләндерделәр. Һәм җиңделәр. Мин сине дә, әтиең Галимне дә ташлап, Казанга киттем. Аяныч, әмма бу шулай, Әнрүсә кызым... Аннары, күрәсең, Галим өйләнгән, икенче хатыны сине үз кызы иткән.

Минем күзләрем яна, әчетә. Елыйм...

— Елама,— ди Мөнирә апа,— елама... Син зур бит инде, тиздән үзең әни булырлык кеше...

Ләкин мин тыела алмыйм, аның тезләренә капланып үксим.

— Я инде, җитте. Миңа җиңел дисеңме?..

Аннары ул дәшми. Миңа туйганчы еларга ирек бирә. Мин үксүдән тынычлана төшкәч кенә эндәшә:

— Минем җанымны тик бер нәрсә генә җәберли, тик бер нәрсә генә, Әнрүсә: син мине кичерә алырсыңмы?

— Юк, юк, сез минем әнием түгел, юк!.. Бу дөрес түгел... Юк!..

Мин сикереп торып ишеккә ташландым. Атылып урамга чыктым. Аска, Бауман урамына йөгердем.

Шул көйгә, шул җайга гостиницага кайттым. Номерга кереп, караватыма капландым... Кызлар сикерешеп тордылар, кемдер Фирдәвес абыйга йөгерде. Мин елыйм, мин илереп-илереп елыйм.

Фирдәвес абый кереп, минем караваг янына килеп тезләнде.

— Ни булды сиңа, Әнрүсә, ни булды? — ди ул, аталарча әрнешеп.— Я, Әнрүсә, сөйлә, ни булды?..

— Берни дә бул-ма...ды...

Сафура:

— Мөнирә апа!— дип кычкырып җибәрде.

Номерга, күрәсең, әни килеп керде.

Әнине күрү белән Фирдәвес абый торып басты. Мин дә тынычлана төштем.

— Ни булды? — диде ул, кырыс кына.

Мин, Фирдәвес абыйның йөзен күрмәсәм дә, сорауның әнигә төбәлеп әйтелгәнен аңлап алдым.

— Гафу итегез,— диде әни, кисәк аның тавышы, гитара кылы кебек, калтырап куйды.— Гафу итегез...

Ишек ябылды. Беразга тын тордылар. Аннары Фирдәвес абый:

— Ятыгыз, йоклагыз! Син дә, Энрусә, чишен дә ят...— диде.

Һәм ул песи кебек кенә басып чыгып китте.

Иртән китәр алдыннан гына, Мөнирә апаның әни булуына һаман шикләнеп, Фирдәвес абыйдан сорадым:

— Дөресме бу хәл, Фирдәвес абый, әниемме ул минем?..

Фирдәвес абый башыма кулын куйды. Елый-елый кызарып беткән күзләремә, шешенгән йөземә карады.

— Әниең,— диде ул, кесәсеннән зәңгәр конверт чыгарды.— Мә, укы...

Хатны әни язган иде.

«Кызым Энрусә!

Бу исемне сиңа кушучы — мин. Мин сине йөрәк астыма куеп үстерүче әниең. Икенче әниең үлгәч, гафу итәр, кичерер дип, үзем сезгә килгән идем, тагын тора алмадым. Син боларны, әлбәттә, белмәдең... Син үзең дә әни буласы кеше... Мин елыйм, яза алмыйм... Нибары бер үтенечем бар сиңа, кызым. Кал минем янымда, кал...

Әниең. Көтәм».

Мин тагын еларга керештем. Фирдәвес абый юата башлады.

— Я, житәр инде. Үлмәгәннәр бит әле алар. Соң, шулай булгач, елама... Сиңа хәзер авыр, аңлыйм. Әмма син нык бул. Әгәр дә алар бергә яшәргә теләмиләр икән... Нишләмәк кирәк. Берничшләп тә булмый. Шуны аңла: син генә кушалмыйсың аларны хәзер...

— Ул, ул бит кызым, ди...

— Әйтсә соң, мена жүләр...

Автобус туктау белән мин үзебезгә йөгердем. Вәсил мине озатмакчы була. Мин тукстыйм, Вәсилнең күзләренә карыйм. Ул мине аңлый һәм шул ук вакытта нигә өйгә ашкынуымны аңламый да кебек.

— Иртәгә,— дим мин аңа һәм үбәргә үрелгән авызын кулым белән каплыйм,— иртәгә, Вәсил, яме?..

— Ярый,— ди ул, бераз үпкәләп,— ярый соң...

Ике-өч баскыч аша сикерә-сикерә, квартирабызның ишек бавына килеп тотынам. Әллә нигә йөрәгем ашкына, нидер сизенә. Әтине сагындым, әтине күрәсем килә, исәнме ул?

Бәрелә-сугыла коридорга килеп керәм, залга үтәм. Өстәл, өстәл өстендә шешәләр, ә алар арасында башын кулларына куеп әти утыра.

— Әти, әти!

Мин йөгереп килеп әтинең муенына сарылам.

— Кызым, Энрусә,— ди ул, пышылдап, дерелдәгән юка бармаклары белән, үз күзләренә үзе ышанмагандай, чәчемнән, бит-йөземнән сыйпый.— Я, ничек булды, кызым?..

Мин башымны күтәреп әтинең күзләренә карыйм, үзем авызым жыя алмыйча елмаям. Әти моны күрә, аңлый, ул да елмая.

— Мин бәхетлеләрнең бәхетлесе, әти. Мәскәүдә бөтен Союз эстрада башкаручылары конкурсына катнашачакмын. Ишетәсеңме, әти, Мәскәүдә...

Әти ни әйтергә белми аптырап кала. Мина калса, ул ышанырга да, ышанмаска да белми. Аннары, кисәк уянып киткәндәй шашынып, минем бит-маңгайларымнан, чәчемнән үбә башлый...

— Кызым, Энрусә...— ди ул, гаять тә дулкынланып.— Мин бик тә, бик шат синең өчен, кызым!..

Һәм, яшьле күзләрен миңа күрсәтмәскә тырышып, диванга барып утыра.

— Атна буе өйдән чыкмадым. Тагын бер көн кайтмасаң, шунда үләрмен кебек иде,— диде ул.

Мин барып утны кабыздым. Шул чак әти кинәт каударланып торып басты. Ул ничектер каршы яктагы стенага таба омтылып куйды. Мин шул якка карадым һәм мәрхүмә әниемнең рәсемен күрдем. Һәм, бер

тынга өнсез булып, торараштай катып, таң калдым. Стенада бөтен буй-сынына төшерелгән әниемнең рәсеме. Кайдан бу рәсем? Кем аны ясаган? Әтиме?! Әти булса, кайчан? Нигә ул әлегә кадәр күрсәтмәде аны миңа? Ниндидер сер иде ул минем өчен. Минем хәтеремә томанлы гына булып әтинең айлар буе подвалда югалып торуы исемә төшә. Анда аның мастерское. Миңа анда үз гомеремә нибарысы бер тапкыр гына булырга туры килде. Әллә нигә әти кешеләрне мастерскоена кертми иде.

Дания әнием. Ул әнә гүя исән, гүя келәм өстендә күнегүләр ясый. Ул ничектер аяк очларына гына басып, очарга әзерләнгән кош кебек, кулларын күтәрә төшкән. Миңа ул мена-менә кузгалып, йөгереп китәр, йөгереп китәр дә чынлап та аккош сыман күккә күтәрелер кебек тоела. Әни шундый зифа сынлы, мин аның рәсеменә, аның җанлы сурәтенә ачкан авызымны яба алмыйча карап торам. Аннары әти ягына күз ташлап алам да туп-туры сурәткә таба атлыйм. Минем аны тотып карыйсым килә, әниемнең сылу сынын, матур, мөлаем йөзен якыннанрак күрәсем килә. Ләкин якын килгән саен баягы тәэсирнең югала баруын күреп, артка чикмәкче булам. Минем бу татлы, әчке ләззәт һәм рәхәт тойгылар белән тулы минутларымны озайтасым килә. Нәкъ шул мәлдә минем күзем сурәт почмагындагы имзага төшә. Мин әти кулы белән язылган хәрефләрне укыйм. «Гомер юлдашым, миңа бәхет, олы мәхәббәт, шат тормыш алып килүче һәм тиңсез илһам бирүче Дания Батыевага. С. Галим.»

Мин әтигә карыйм. Ул, башын түбән иеп, гаепле кеше сыман тәрәзә каршысында басып тора. Минем хәтеремдә шундый бер вакыйга яңарды. Әнинең туган көнен үткәргәндә булды бугай ул. Чакырылган кунаклар барысы да әнигә бүләкләр биргәч, берсе әтидән:

— Я, Галим дус, Даниягә нинди бүләк алдың икән, күрсәт әле,— дигән иде.

Әти исә:

— Мин аңа, җәмәгать, кеше күтәрерлек кенә түгел, авырлыгы һәм зурлыгы белән тауга тиң, матурлыгы һәм кыйммәтлеге белән бәһасез булган бүләк алдым, тик мин аны кайбер сәбәпләр аркасында әлегә күрсәтә алмыйм,— диде.

Шул кичне кунаклар киткәч, әти белән әни һавага чыгып, йөреп керделәр. Әни шуннан соң шул хәтле мактады әтине, хәтта мин көнләшә башладым. Син, Галим җаным, Тициан, син тиңсез дип, күккә чөйде. Иркәләде, үпте, яратты. Әлбәттә, мине дә читтә калдырмады. Әти, әни иркәләгәнгә, аннан бигрәк мактаганга эреп киткәндәй, күзләрен йомып торды. «Һай, шат яши идек тә соң без!» — диясем килде минем әтигә, әмма әйтмәдем. Әти янына килдем дә чалара башлаган чәчләренә кагылдым.

— Мин сине кайтмассың дип курыккан идем, кызым,— диде ул, кулларымнан тотып.

— Әти, алай дип әйтергә хакың юк синең. Ишетәсеңме, әти, хакың юк!..

— Рәхмәт, кызым.— Ул торып басты.— Ә син җылама, шатланасы көнебез бүген...

Әти миңа күзләрен тутырып карый да, әйткән сүзләрем ничек тәэсир итте икән дигәндәй, никтер шикләнеп куя. Аның йөзен сакал-мыек баскан, ябыккан чыраенда борыны гына утырып калган.

— Гафу ит, кызым. Әлек мин салгалый идем. Моннан соң ул кабатланмас. Мәрхүмә әниеңә антым булыр бу.

— Әлегә кадәр нигә әчкәли идең, әти?

— Кайгыдан, кызым...

— Әти, мин сине...

Әти, капылт борылды да, минем күзләремә текәлеп карады. Мин курка калдым. Куркыныч итеп карый белә иде ул.

— Әйттемени?!

Мин шунда ук аның ни турыда сораганын аңлап алдым.

— Әйе, әйтте, әти... Әти!

— Тукта!

Ул кузгалды да тәрәзә каршына килеп басты. Гәүдәгә әти ябык, хәтта чандыррак та иде. Чак кына бөкресе беленә. Йөргәндә чатанлабрак атлый. Ләкин бу аңа килешә. Мин дә аның янына килеп басам.

Кич. Эңгер иңеп килә. Әти офыктагы ут кебек янган шәфәкъ яктысына карап тора башлады.

— Әти,— дидем мин, тыныч булырга тырышып,— әти, нигә мин Дания әниемне оныта алмыйм икән? Ә бит минем чын әнием дә исән. Һәм ул мине үзенә чакырды, бик тә чакырды. Ләкин әллә нигә, әти, күңелем белән чын әнием итәсе килми аны. Мин шуны аңладым, әти. Сине тапкан ана — ана түгел, сине баккан ана — ана икән.

— Рәхмәт, кызым...

Ул борылды да ике яңагымнан да кысып тотты, томыраеп күзләремә карады.

— Син, Әнрүсә кызым, минем өчен яңа тудың... Әйе, әйе, бүген тудың...

Һәм ул маңгаемнан үбеп алды да, гаять дулкынланып, әнинең сурәтенә ым какты.

— Кызым... Рөхсәт итсәң, ул шунда торыр инде, яме?!.

— Әти, ничек син алай дип әйтә аласың?..

Әтинең дулкынлануы, әни турында тәэсирләнеп сөйләве миңа кучте. Мин, күзләремә тулган яшьне тыя алмыйча, әтинең күкрәгенә башым куйдым.

Ләкин әти кузгалды да берни булмаган кебек:

— Әйдә, кызым, иң әүвәл өйне җыештырудан башлыйк,— диде.

Өй җыештырылып беткәч, ул, бүлмә уртасына басып, тирәли күз йөртеп чыкты. Канәгать калып, ваннага кереп китте. Аннан ул сакалынмыегын кырып, чистарып чыкты. Күлмәген, галстугын әзли башлады.

— Кая җыенасың, әти?

— Театрга, кызым, премьера бүген...

— Синең пьесаңамы?

— Әйе.

— Мин дә барам.

Ул капылт туктап калды. Маңгаендагы җыерчыклары язылып, йөзе ачылып киткәндәй булды.

— Чынлап та! Нигә соң әле мин сине чакырмый торам!..


Без урамга чыгабыз. Шәһәр өстендә җиңелчә гүләгән аваз эленеп тора. Әле урамда утлар кабынмаган. Әти афишалар янына туктады. Ләкин караңгы. Нәкъ шул чак бөтен урамны балкытып утлар кабынды.

— Менә шулай,— диде әти, әйләнеп тирә-юненә карады. Олы, зур такталы афишада әтинең исем-фамилиясе һәм пьесасы. Мин әтинең кайнар бармакларын кысам. Ул моңа җавап итеп күзләремә карый. Нечкә бармаклары белән чәчемне сыйпый һәм пышылдап:

— Менә син дә үсеп җиттең инде, кызым. Тырышсаң, талантың сүндермәсәң, синең афишаларыңны да күрербез. Ишетерләр әле безне дә! — диде ул, кемгәдер янаган сыман.

Мин әтинең сүзләрен уенга алам, аяк очларыма басып, үсеп күрсәтәм. Әти бөтен уй-кайгыларын онытып көлеп җибәрә.

Ул бәхетле һәм шат. Мин дә.



# ИҖАТ УҢЫШЛАРЫ ТЕЛИБЕЗ СИҢА, ГАКЫЙЛЬ!

*Моннан бер ел элек «Социалистик Татарстан» газетасында Гакыйль Сагыйровның бик матур шигырьләре басылып чыкты. Без шул ук номерда автор ясаган рәсемнәрне дә күрдек. Газета Рәшит Зәкиевнең Гакыйль турындагы мәкаләсен дә урнаштырган иде. Бу кереш сүзне укыганнан соң безнең яшь шагыйрь һәм рәссам белән кызыксынуыбыз бермә-бер артты. Чөнки анда Гакыйльнең унбиш елдан бирле инде кул-аягы хәрәкәтсез икәнлеге, яшь талантның шигырьне дә, рәсемне дә каләмне авызына капкан килеш иҗат итүе әйтелгән иде. Ул вакытта безнең күңелләрдә соклану һәм хәйран калу тойгылары кабынды.*

*...Һәм менә без өч язучы: Гөлшат Зәйнашева, Роберт Әхмәтҗанов һәм мин, Куйбышев өлкәсенә, Гакыйль яшәгән Фәйзулла авылына барабыз. Безне «Социалистик Татарстан»ның үз хәбәрчесе, яшь шагыйрь Рәшит Зәкиев озата бара. Юл буенча аңардан сорашабыз. Ләкин Рәшит никадәр генә тәфсилләп сөйләмәсен, үз күзләребез белән күргәннәребез тагы да тәэсирлерәк булып чыкты.*

*Безне якты чырай белән Гакыйльнең әнисе — дусты һәм ярдәмчесе Хәбибҗамал апа каршылады. Без шулай ук, өй янына машинабыз туктап-туктамас, тәрәзәдән Гакыйльнең дә үз итеп елмайган йөзен күрдек. Барысы да монда самими кунакчыллыкка өртелгән иде. Менә безне Гакыйльнең әнисе өйгә алып керә. Гакыйль алгы бүлмәдә, урам як тәрәзә турысында, агач караватта ята. Аның сынау һәм көлемсерәү белән текәлгән соры күзләрендә шатлык чагыла. Ул безне күрү белән таныган икән. Исәнлек-саулык сорашып беткәннән соң без, күптәнге дуслар кебек, бернинди тартыну-ятсынусыз әңгәмә башлыйбыз. Шигырьләр укыйбыз. Гөлшатны җырлатабыз, аннан үзебез дә кушылабыз. Юк, юк, монда бернинди сентиментларга бирелү мөмкин түгел. Биредә чишмәдәй бәреп торган иҗат атмосферасы. Шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сагыйров моннан сигез ел элек кенә авызына беренче тапкыр каләм алмаган! Барлык авыру-сырхаулардан үзенең өстен икәнлеген дәгъвалап ул иҗат эшенә юкка гына керешмәгән! Ул шигырьләр яза, тушь белән рәсемнәр ясый, читтән торып Мәскәүнең культура институтында укый. Хәзер аның Татарстан китап нәшриятында китабы чыгып килә. Ургылып торган иҗат ташкынына нинди киртәләр комачаулый алсын!*

*Зур иҗат уңышлары телибез сиңа, Гакыйль.*

**АТИЛЛА РАСИХ**

## Ике кояш

Ике кояш бар дөньяда — куктә берсе,
Йөрәкләрдә икенчесе, иң көчлесе;

Тормыш йөзен яктыртучы иң яктысы,
Кышларын да яз китерә бер чаткысы.

Бер чаткысы!.. Хисләренә түзәлмичә
Мин ямьсез дип офтанганны гүзәл итә.

Гел ваемсыз йөргәнне дә уйландыра,
Кыюсызлык йөгәннәрен ул салдыра,

Ул ямь бирә чишмәгә дә, тирәккә дә,
Сулыш өрә сүнеп барган йөрәккә дә.

Мәхәббәт ул... нинди татлы әрни күңел,
Әгәр сүнсә,— күктәгесе бер ни түгел!..

●

Кыш көне дә ачып куям тәрәзәмне;
Күрим әле
Ничек офык ишек ача икән таңга,
Күрим әле иң беренче таң нурлары
Ничек иннек яга икән каеннарга.

Кыш көне дә ачып куям тәрәзәмне;
Күрим әле
Кырлар буйлап житез жилләр йөгергәнен,
Балаларга шуар өчен якты кичтә
Ап-ак таулар ничек үсеп өлгергәнен.


Кыш көне дә ачып куям тәрәзәмне —
Суык димим — керсен өйгә тормыш жиле,
Керсен өйгә, язгы жилләр уянганчы,
Яшәү белән ул сугарсын әле мине.

Бар дөньямны чолгап алган ут эчендә
Янсам да мин, ахры, яшәп туймамындыр,
Хисләремне сөйләп бирер сүзләр тапсам —
Туар иде мәңге сүнмәс бер нәфис жыр.

●

Мең төрле буласың бер кичтә:
Нур чәчеп уйнаган дулкын син.
Сусынны бастырган чишмә син,
Аннары ялкынга охшыйсың.

Мең төрле буласың бер кичтә:
Тормышның нәкъ үзе шикелле.
Давыл бул, янгыр бул, сөйкемлем,
Яратам барыбер — ничек тә.



Г. СӘГЫЙРОВ рәсемнәре. — Чишмә.



Иртә.

# ҮР МЕНЕП ҖИТКӘНДӘ



*1969 ел да җитте. Ил белән бергә Яңа елны Татарстан нефтьчеләре дә каршы алдылар. Көч һәм батырлык, акыл һәм зирәклек таләп итә нефтьче һөнәре. Кара алтын һәм газ чыгару белән нефтьчеләр моторларга «азык» биреп кенә калмыйлар. Зур химиягә чимал, шәһәрләргә җылы һәм яктылык та бирәләр.*

*Яңа ел алдыннан, редакция үтенүе буенча, журналист Марсель Зарипов республикабызның нефть промыселларында булып, Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе начальнигы Әгъзам Вәлиханов белән әңгәмә үткәрде. Татарстан нефтьчеләренең бишьеллык азагына ел саен 100 миллион тонна нефть чыгару өчен нинди киеренке көрәш алып барулары турында сөйләвен үтенде. Шул әңгәмәне журнал укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

**Сорау.** Яңа ел алдыннан гына Татарстан нефтенә егерме биш ел тулу бәйрәме үткәрелгән иде. Чирек гасыр вакыт эчендә Татарстан нефтендә нинди үсеш, үзгәрешләр булды?

**Җавап.** Чирек гасыр — кешелек җәмгыятендә бик аз вакыт. Ә безнең өчен чирек гасыр, бер яктан, академик Губкинның Идел һәм Себер нефте турында әйткән сүзләренең чынга ашуы булса, икенчедән, Ильичның 1918 елда, яшь Советлар иле гаять зур кыенлыклар кичергән бер дәвердә, дәһиләрчә бер зирәклек белән укымышлыны яклап чыгуы һәм Идел-Урал арасында нефть эзләүне оештыруы белән характерлы. Татарстан нефтьчеләре шушы чирек гасыр вакыт эчендә җир асты амбарларын ачып кына калмадылар, республикабыз илнең нефть бирүче иң зур цехына, Зур химиянең чимал җитештерүче ышанычлы базасына әверелде. 1968 елда без 93 миллион тоннадан артык нефть чыгардык. Мондый гигант нәтиҗәгә безнең илдә нефть бирүче бүтән бер генә районның да ирешкәне юк әле.

**Сорау.** 25 яшь — кешенең үсеп, чыныгып, акылга утырып җиту дәвере, диләр. Татарстан нефтьчеләренең барлык коллективлары да егерме биш ел эчендә үсеп-чыныгып җиттеләр дип әйтергә буламы?

**Җавап.** Бүген без елына 100 миллион тонна нефть чыгару турында сүз алып барабыз икән, монда барлык коллективларның да өлеше бар һәм без чын мәгънәсендә реаль сан турында сүз йөртәбез. 100 миллион тонна нефть чыгаруга без 1970 елда, бишьеллыкның соңгы елында, барлык коллективларның катнашы белән ирешәчәкбез.

**Сорау.** Табигать законнары буенча, нефть мәйданнарын эшкарткан саен, нефть бирү кими барырга тиеш. Татарстан промыселларында да шул ук хәлме?

**Җавап.** Хәтерем ялгышмаса, зур һәм зирәк акыллы шагыйрь Уитмен әйткән,

табигать законнары гафу үтенүне белмиләр, диган. Әмма без бу проблемага бүтәнчәрәк карыйбыз. Себер һәм Маңгышлак промыселлары тулы көчкә эшли башламый торып, Татарстан биргән нефтьне бер генә район да бирә алмый. Димәк, Татарстанда кимегән нефтьне каплардай район юк. Шуңа күрә без, табигать законнарына каршы килеп булса да, 100 миллион тонналы мөмкин кадәр озаграк саклап торырга тиешбез. Ничек итеп? Бик зур һәм җитди мәсьәлә бу. Соңгы елларда без өстәмә биш-алты миллион тонна нефть алу өчен ел саен бер миллион 200 мең метр чамасы җир бораулый идек. Иста тотыгыз — өстәмә нефть алу өчен. Хәзер 100 миллион тоннаны саклап тору өчен шулчаклы ук җир бораулап барырга туры киләчәк.

**Сорау.** Инде күптән эшләп килә торган нефть мәйданнары белән әле яңарак кына сафка баскан мәйданнарда скважиналар бораулауның аермасы бармы?

**Җавап.** Бар һәм хәтта бик зур. Моны эшләп торган мартен мичен ремонтлау белән чагыштырырга булыр иде. Чуен коюны туктатмаган хәлдә мартен мичен ремонтлау ифрат кыен бит. Бу мәсьәләдә хәл итүне сорап торган байтак кына проблемалар бар. Моңарчы әле җир астындагы нефть запасларының нибарысы яртысы гына җир өстенә чыгарыла. Ягъни ачылган мәйданнарның нефте дә җир өстенә илле процент кына чыга. Дөнья шуның белән килешеп килә. Ә менә шул запасның 60—70 процентын чыгаруга ничек ирешергә? Без шул хакта баш ватабыз. Моның өчен иң әүвәл катлам басымын саклау, җир асты горизонтларыннан дөрес файдалану проблемаларын хәл итәргә кирәк. Су безнең дустыбыз да, дошманыбыз да. Бездә биш-алты катлам бар, алар суны төрлесе төрлечә сеңдерәләр. Шунлыктан су без теләгән катламга гына бармый, кирәкмәгән берәр катламны әйләндереп ала да, шул участокның нефтен мәңгегә томалап калдыра. Катламнарны бер-берсеннән аеру һәм 300—350 атмосфера басым тудыру өчен безгә ныклы җиһазлар, куәтле насослар кирәк. Үкенечкә каршы, химия һәм нефть промышленностена кирәкле машиналар төзү министрлыклары, промыселлар өчен җиһазлар уйлап табучы галимнәр һәм конструкторлар безнең таләпләрдән артта калалар әле. Моннан берничә ел элек безгә куәтле насослар кирәк булгач, без аларны, ялынып-ялварып, энергетиклардан алырга мәҗбүр булдык.

Төрле ведомстволарның, планлаштыру органнарының үзара килешеп эшләүләре әйбәт түгел әле. Берәр зур проектка яки яңа җиһазга заявка бирсәң, аның үтәлешен биш елдан соң гына көтеп аласың. Заявкаларның төрле вак ведомстволардан госпланга кадәр барып җитү нәкъ биш елга сузыла. Космоска очкан, яңадан-яңа ачышлар, фәнни яңалыклар булып торган дәвердә бу бик озак, заявкалар хәтта искерергә дә мөмкин. Ведомстволарда үзара килешү, фикерләшү срогын киметергә, килеп туган проблемаларны эшлеклерәк, оперативрак хәл итәргә кирәк.

Партия һәм хөкүмәт Татарстан нефть промыселларын үстерүгә моңарчы да бик нык игътибар итеп килде, әле дә игътибар итә. Мәсәлән, безнең капитал төзелеш өчен акча булмаудан беркайчан да интеккәнебез юк. Киресенчә, билгеләнгән сумманы гамәлгә ашыра алмый интегәбез. Хикмәт шунда, безнең промыселларда объектлар төзү эше белән Газ промышленносте министрлыгы төзүчеләре шөгыльләнә. Кыскасы, булсын дип тырыша торганнар. Саратов—Мәскәү, Бохара—Мәскәү, Себер һәм Котып газ магистральләрен төзеп дан алган коллективлар алар. Әмма нефтьчеләргә эш барып терәләме — әлеге данлы төзүчеләр алыштырып куйгандай үзгәрәләр. 9 ел эчендә алар безгә 20 миллион сумлык корылма төземи калдырдылар. Соңгы дүрт ел эчендә генә дә без нефть чыгаруны 24 миллион тоннага арттырдык. Ә төзүчеләр һаман да бер үк урында таптанып калдылар. «Татнефтестрой» комбинаты безгә 1965 елда 4,5 миллион сумлык, өченче елны — 3 миллион сумлык, узган елны — 2,6 миллион сумлык корылмаларны төземи калдырдылар. Билгеле, бер ведомство белән икенче ведомствоның эш алымнары, хезмәт интереслары туры килеп бетмәскә дә мөмкин. Андый очракта өченче бер оешма, әйтик, СССР Госпланы, эшләрне көйләп җибәрергә, промыселларның үсешен очраклы хәлләр язмышына калдырмаска, ныклы уйланылган фәнни нигездә алып барырга тиеш.

**Сорау.** Исәп-хисап, гыйльми рекомендацияләр сезнең көндәлек эшегездә күп буладыр. Яңа реформа промыселларда ничек тормышка ашырыла?

**Җавап.** Яңача эшләү ул — бик җитди исәп-хисап булдыру дигән сүз. Мин — берләшмә җитәкчесе, минем кул астымда ун-

нарча миллион тонна нефть бирә торган 9 идарә эшли. Алар, ягъни нефть идарәләре, бер-берсенә һич тә охшамаганнар. Берсенең нефть катламы баерак, икенчесенеке — ярлырак. Үзәк базадан ераклыклары да төрлечә. Һәрбер промыселга экономик күрсәткечләрне бик төгәл исәплап, дөрес итеп билгеләргә кирәк. Гадәттә һәрбер мәйданны эшкәртүнең аерым проекты төзелә. Проектта промыселларны техник яктан җиһазландыру, эшнең нинди технология белән алып барылырга тиешлеге һәм нефть чыгаруның күләме билгеләнә. Мин ни телим? Һәр промыселның күп елларга алдан ук төзелгән планы булсын, анда максимум төгәллек белән бигрәк мөһим экономик күрсәткечләр билгеләнсен. Соңыннан: «Айһай, монысы болай түгел, ай, монысын дөрес исәпләмәгәнбез ләбаса!» — дип йөрерлек булмасын. Өзлексез төзәтмәләр кертеп тору коллективның нервысын какшата, тыныч күңел белән, ышанып эшләргә ирек бирми.

Сорау. Нефтьчеләрнең соңгы отчетында ике санга аеруча игътибар ителә. Ярты ел эчендә хезмәт хакы 8 процентка, ә хезмәт җитештерүчәнлеге 3,9 процентка гына арткан. Нигә шулай бу?

Җавап. Мин промыселларда хезмәт эффектының даими рәвештә кими баруын әйтер идем. Баштарак скважиналар максимум продукция бирәләр. Мисал өчен, бер скважина 100 тонна нефть бирә дип алыйк. Еллар үтү белән бу сан ике, өч мәртәбә кими. Әмма аңа карап, бу эшкә тотылган хезмәт кимеми бит. Физик хезмәт шул ук кала, хәтта бераз арта да төшә әле. Менә шуңа күрә хезмәт җитештерүчәнлеге кимеган төсле тоела. «Тоела» дип басым ясап әйтәм. Без егерменче гасырда яшибез. Хәзер кеше үз хезмәтенең эффектлылыгын күтәрү өчен күп төрле мөмкинлекләрдән файдалана ала. Беренчесе — производство белән идарә итүне камиллаштерү. Без бораулаучыларның эшен максимум специальләштерергә ирештек. Илнең башка районнарында, мәсәлән, бораулаучылар, скважиналар бораулау белән бергә, ярдәмче эшләрне дә башкарып килделәр. Без бораулаучыларны ярдәмче эшләрдән азат иттек, алар фәкать бораулау белән генә шөгыльләнделәр. Әгәр без бораулауны элекке тәртип белән генә алып барсак, безгә 450—500 бригада кирәк булыр иде, ә без 75 бригада белән котылдык. Шулай да әле безне бораулау бригадалары белән идарә итү канәгатьләндереп җиткерми, чөнки ул күп баскычлы: трест — контора — диспетчерлык хезмәте — бригада. Урта звено булган бораулау конторалары кирәкме соң? Бригадаларны куәтле диспетчерлык хезмәте идарә итә алмыймы? Бу, билгеле, хәзергә әле идея генә, ләкин без аны гамәлгә ашар һәм файдалы булыр дип бик нык ышанабыз.

Икенче мөмкинлек — промыселларны автоматлаштыру. Татарстан нефтьчеләре автоматлар куллануның хәзер икенче баскычына килеп җиттеләр, без хәзер аерым-аерым автоматлардан комплекслы автоматлаштыруга күчә алабыз. Ил күләмендә уйлап чыгарылган 20 дән артык автоматик системаның унбере безнең промыселларда файдалануга куелды. Безнең эшебезгә байтак кына ярдәм иттеләр алар, әмма үзебез хыялланган баш әйләнгеч техник сикерешкә кадәр барып җитәргә ерак әле. Укымышлыларга, конструкторларга һәм приборлар төзү министрлыгына күңелдәге үпкә сүзләрен дә әйтәсе килә. Кагыйдә буларак, барлык фәнни-тикшеренү институтлары аерым объектларны: скважиналарны, нефть җыю пунктларын, насос һәм газ-компрессор станцияләрен автоматка көйләү белән генә шөгыльләнделәр, шуларның барысын комплекслы автоматлаштыру күп өлеш файдалырак булыр иде. Аннары тагын шул ягы да бар — промыселларны автоматлаштыруга җиңелрәк карау яшәп килде. Безнең автоматик системаларның авторлары — Казан университетының радиофизика кафедрасы, Татарстан Гыйльми-тикшеренү институты, Бөтенсоюз гыйльми-тикшеренү нефть-газ институтының Октябрьск филиалы, Гипровостокнефть һ. б. — һәрберсе үз проектларын аерым-аерым эшкәртеп, беренче уңышсызлыкка очраганчы тырыштылар. Әлбәттә, фән эшендә һәрбер тәҗрибәнең уңышлы чыгып бетүе мөмкин түгел, ләкин «башладым — барып чыкмады — ташладым» методы белән эшләгәндә уңышка ирешү турында уйлап та карарга ярамый. Бәлки шуңадыр, промыселларга куелган системаларның күбесе нефть чыгаручыларның эш рәвешләрен үзгәрттеләр, ләкин хезмәт нәтиҗәләрен үстерергә ярдәм итмәделәр. Мисал өчен әйтик, Зәй-Каратай промыселларына Бөтенсоюз гыйльми-тикшеренү институты автомат система куйганнан соң, операторлар элеккедән кимемәде. Кайбер системаларны, бер тиенгә яраксыз иконлекләре беленгәч, алып ташларга туры килде.

Сорау. Зыянны кем каплады соң?

Җавап. Әлбәттә, без — нефтьчеләр. Хәзер барлык нәрсә исәп-хисапка корылган заманда, яңа реформа заманында безгә һәр тиен кадерле. Шуңа күрә тәкъдимнәрне һәр яктан тикшереп карарга, гыйльми рекомендацияләрне практикадан үткәрмичә, киң кулланышка кертмәскә туры килә. Чөнки авыз пешкәне бар. Моннан берничә еллар элек, нефть чыгаруны көчәйтү кен тәртибенә куелгач, нефтьне судан, тоздан арындыру проблемасы кузгалды. Мәскәүнең нефть институты галимнәре нәкъ шул чорда нефть әзерләүдә югары частотлы токлар куллану идеясен күтәреп чыкканнар иде. Без бу идеягә ышандык, шундук нефть чистарткыч алты корылманы (аларның бәясе өч миллионнан тугыз миллион сумга кадәр) яңа технологиягә исәп тотып кордык. Чынында исә югары частотлы токлар көндәлеге хыял гына булып чыктылар, салынып беткән корылмаларны промышленность частотына күчерергә мәҗбүр булдык. Без әле хәзер дә укымышлыларның җиңел акылы, үзебезнең беркатлы ышануыбыз аркасында бюджетка безгә кирәк булмаган җиһазларның алты процентын кертеп барабыз, шул сәбәпле нефтьне әзерләү соңга калып бара. Узган елны кондициягә җитмәгән нефть тапшыруның штрафы 2 миллион сумнан артып китте. Ә технология авторлары бездән гафу да үтенмәделәр, һәрхәлдә, мин гафу үтенеп килүчеләрне хәтерләмим.

Сорау. Без бераз гына читкә киттек бугай. Промыселларда хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең өченче ысулы нинди?

Җавап. Дөресен әйткәндә, ул — өченче түгел, иң үзәк ысул. Сүз стимуллар, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә илтә торган этәргечләр турында бара.

«Татнефть» берләшмәсе илебезнең башка нефть оешмаларына караганда яңа ысулга алданрак күчте. Хәзер безнең барлык эшчәнлегебез табыш (прибыль) алуга нигезләнгән, башка фондлар — производство үсеше, материаль кызыксындыру — барысы да шуңа бәйле... Үз нәүбәтендә материаль кызыксындыру хезмәт хакы өчен тотыла торган чыгымнарга бәйләнгән. Табыш алуның максималь дәрәҗәдә зур булуы мөмкин, ләкин предприятие, хезмәтнең эффектлылыгын күтәрердәй оештыру эшләре һәм техник чаралар үткәреп, эшне аз санлы эшчеләр белән башкарып чыга алса, үзеннән-үзе билгеле, хезмәткә түләү фонды да, аңа бәйләнгән материаль кызыксындыру суммасы да кими. Һәм, киресенчә, эшнең аз продуктивлылыгы эшчеләр санын арттыра, шуңа бәйле рәвештә хезмәткә түләү фонды да арта.

Предприятиеләрдә күп төрле техник һәм оештыру чаралары исәбенә табыш алырга тырышалар, әмма хезмәт хакы чыгымнарын киметергә ашыкмыйлар. Тормыш практикасы мондый каршылык беткән саен эшләр җайлана төшкәнне исбат итте.

Сорау. Бәйрәм алдыннан сөйләшсәк тә безнең аңгәмә бигүк бәйрәмчә килеп чыкмады шикелле. Шулай түгелме?

Җавап. В. И. Ленин әйткән, бәйрәмнәрне үткәрүнең иң яхшы чарасы — игътибарны әле хәл ителмәгән мәсьәләләргә юнәлтү, дигән. Кимчелекләр, хәл ителмәгән мәсьәләләр азайган саен, календарьлардагы кызыл даталарны билгеләп үтү шатлыклырак һәм күңеллерәк булачак. Бездә ул бәйрәмнәр җитәрлек.

Малик Хәмитов

# МИРОВОЙ ӘМИР

ОЧЕРК




Район газетасының илле еллык юбилеена багышланган тантанага халык күп җыелган иде. Культура йортының тамашалар залы шыгрым тулы. Редакциягә район оешмалары да, төрле районнардан килгән кунаклар да, республикабыз башкаласыннан килгән вәкилләр дә бик күп котлау адреслары тапшырдылар. Менә КПССның Мамадыш райкомы секретаре Нәҗип Ганиев сүз алды. Ул район газетасының актив хәбәрчеләрен КПСС райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район Советы Башкарма Комитеты Мактау грамоталары белән бүләкләү турында карарны укыды. Исемлекнең башында диярлек торучы бераүнең фамилиясе минем игътибарны җәлеп итте: «Әмир Ганиев, Тәкәнеш урта мәктәбенең тарих укытучысы».

Әйе, мин аның Тәкәнештән икәнен яхшы беләм. Без аның белән университетны бергә, бер факультетта, бер группада бетердек. Ул берничә курс дәвамында безнең группаның старостасы да булды. Кечерәк кенә буйлы, киң, биек маңгайлы, очлы, туры борынлы, таранка буйсынмый торган каты, куе җирән чәчле егет иде ул. Староста буларак бик кырыс, группа җыелышларында бик җитди иде. Домино уйнаганда исә аңардан да җор кеше юк иде. Һич тә көтмәгәндә, ике күзен дә хәйләкәр кысып, уенга да, тулай торактагы шартларга да кагылышы булмаган бер-ике мәзәк сүз әйтеп куя һәм уенчылар да, уенны карап торучылар да эчләрен тотып көләргә тотыналар иде. Ул үзе бик җитди кала. Уенда җиңелгән кешеләрдән шаяртып көлү аңа гына түгел, барлык карап торучыларга да күңелле була. Шахматта аеруча әйбәт уйный иде ул, укыган вакытта ук икенче разрядны алды. Тагын икенче бер шаян ягы бар иде: һәрберебезгә таныш студентларның яки укытучыларның нәкъ үзләре булып сөйләргә ярата иде ул. Ничәнче курста укыгандадыр инде — икенчедәме, өченчедәме — Биектау районындагы бер колхозга ярдәмгә барәңге алырга китәр алдыннан аның бүлмәсенә җыйналдык. Ул атасыннанмы, бабасыннанмы калган, йоннары коелып беткән мех якалы бер иске бишмәт киеп алды, башына сөлгедән чалма чалды, койкага биш мендәр өеп куйды, шулар өстенә утырды да:

— Мин дуәрән, сезгә, гавәмнәргә, юлга чыгар алдыннан нотык сөйләргә мәҗбүрмен,— дип, таныш бер укытучы булып кыйланырга кереште. Шуннан соң ул безнең группада гына түгел, бөтен курста «дуәрән Әмир» булып китте.

Ләкин шул «дуәрән Әмир»ме икән соң ул?.. Әгәр шул булса, тарих түгел, телədəбият укытырга тиеш иде бит ул. Мөгаен, шулдыр. Тарихны безгә бәйнә-бәйнә укыттылар инде анысы. Античныйдан алып ер-якасына кадәр. Ә Әмир барлык фәннәрдән гел отличнога гына укыды. Эш бер ничек укыганда гына да түгел, үзгәрдеме икән инде егет, бик «серьезный» кеше булдымы, семьясы, бала-чагалары да бардыр? Кыскасы, безнең группа старостасын, җирән чәчле «дуәрән»не минем бик күрәсем килде.

Ләкин бу юлы күрергә туры килмәде. Кар бик күп яуган иде, бураннар бик каты булды, илле-алтмыш чакрым араны үтү өчен бульдозерлар юл салганчы бик озак көтәргә кирәк иде...



...Май ае. Алмагачлар, чиялар, канафер агачлары шау чәчәктә утыра. Сыерчыклар бала чыгарган чак. Куптән түгел генә бик матур сайраган бу кошлар хәзер, оялары янына якынрак килсәң, тәшвишләнеп, разбой салып черелдәргә керешәләр. Күтәрелеп карасаң, томшыгы тулы — бөҗәк-корт. Тынычлансыннар дип, тизрәк китәргә ашыгасың. Ә сандугачлар! Алар, берберсеннән уздырырга тырышып төннәрен дә, көндезләрен дә сайрыйлар...

Ләкин кинәт көчле давыл чыкты. Бакчадагы җимеш куакларына, инеш буйларындагы өянкеләргә кунып сайраучы сандугачлар тынып калды. Шәһәр өстенә тузан болыты күтәрелде. Вятка елгасындагы дулкыннар, түбәләрен күбекләндереп, ярга бик еш бәрелергә керештеләр.

Мамадышка давылның чите генә эләккән икән. Ул Тәкәнеш, Кукмара якларында телеграф баганаларын, үсеп утырган агачларны аударган, аннан соң кинәт килеп яуган яңгыр кайбер урыннарда хәтта утырткан бәрәңгеләрне дә актарып чыгарган.

Без Тәкәнешкә барганда давыл һәм яңгыр нәтиҗәләре күзгә күренеп ята иде: янтайган, ауган телеграф баганалары, язгы ташуда исән калып та бу яңгыр вакытында машина кермәслек булып җимерелгән күперләр...

Ә авыл кешеләренә табигать белән гел көрәшергә туры килә. Менә хәзер дә, яңгырдан соң, салкын яктан җил исү нәтиҗәсендә туфрак өсте тоташ катып киткән. Үсентеләргә тишелеп чыгарга мөмкинлек тудыру өчен механизаторлар кырга чыкканнар — җир өстен тырмалыйлар. Мондый көннәр терлекләргә дә тәэсир итә: колхозчылар сыерлардан көннән-көн арта барган сөт алуны киметмәс өчен тырышалар. Мондый мәшәкатьләр юл кешесенең дә күзенә чагыла...

Мин Мамадыш районының Ямашев исемендәге колхозына барам. Бик үк юл уңае булмаса да, Тәкәнешкә, дәресләргә Тәкәнеш мәктәбенә кереп, Әмир Ганиевне күреп чыгарга уйладым. Юлның як-ягында күренеп калган яңгыр, давыл эзләре уйларны ничектер мәктәп белән бәйли. Әйе, табигать белән көрәш тә, аңарга ярашу да белемсез мөмкин түгел. Ә табигать серләрен яшь буынга әнә шул Әмир кебекләр өйрәтә бит инде...

Тәкәнеш урта мәктәбе авыл кергәч тә нәкъ юл читендә икән. Ул үзе бер шәһәрчек булып урнашкан. Ап-ак чәчәктә утырган җиләк-җимеш бакчалары мәктәп тирәсен һәр яклап әйләндереп алган. Мәктәп ишек алдының нәкъ уртасына утыртылган икенче бер бакчадагы ак чәчәкле канәферләрдән хуш ис бөркелә.

Әмир әле дәрестә икән. Мәктәп директоры Әхмәтов назакәтле һәм бик игътибарлы кеше булып чыкты. Ул миңа мәктәп биналарын, андагы җиһазларны, укучылар көче белән эшләнгән эшләрне, тәҗрибә участокларын күрсәтеп йөри. Физика һәм химия кабинетлары бик бай җиһазландырылган. Нинди генә прибор юк анда! Ләкин мине иң гаҗәпләндергәне укучылар үзләре салган зур спорт комплексы булды. Аның үзәк бинасын нәкъ мәктәп каршысына, юлның ар ягына таштан салганнар. Залы иң зур авыл клубларының тамаша залыннан бер дә ким түгел. Биредә һәртөрле спорт җиһазлары бар. Менә диген практика булган бу алар өчен, һөнәр дә алганнар, үзләренә һәйкәл итеп яхшы эш эшләп тә калдырганнар.

Капка төбендә велосипедлар тора. Аларга утырып моннан унсигез километрдагы Нырты урта мәктәбе укучылары кунакка килгәннәр икән. Әле генә хуҗалар өчен концерт биргәннәр, хәзер исә футбол кырында көч сынашалар, ди.

— Музейга Әмир Ганиевичнең үзе белән менәрсез инде,— диде Әхмәтов.— Ул бушаганчы футбол уйнаганны карый торыйк.

— Нинди музей ул? — дип гаҗәпләндем мин.

— Туган якны өйрәнү музее. Аны да укучылар үзләре булдырдылар. Әмир Ганиевич җитәкчелегендә...

Кунаклар яхшы ук шома уйныйлар... Шулай да юл килеп арыганлыклары сизелә, исәп: хуҗалар файдасына 3—2. Хуҗалар кунаклар капкасына тагын бер туп керттеләр. Кунаклар моңа каты һөҗүм белән җавап бирделәр. Ләкин туп барыбер капкага кермәде...

Таныш тавышка борылып карадым. Каршымда Әмир елмаеп басып тора иде. Шул ук Әмир. Унбиш ел эчендә бөтенләй үзгәрмәгән диярлек. Тик чәчләре шактый юкарган, башына яртылаш диярлек көмеш сибелгән. Ә җиз төсендәге калын кашлары астындагы зәңгәр күзләре элеккечә үк самими дә, азрак хәйләкәррәк тә итеп елмаеп карыйлар. Миңа хәзер ул нинди дә булса бер шаян сүз әйтер кебек.

— Нинди җилләр ташлады, дускай,— диде ул, көрәшергә кулын сузып.— Ничек безнең якларга килеп чыгасы иттең?

— Миңа Ямаш колхозына барышлый хәл-әхвәлеңне белеп чыгыйм дидем.

— Бик әйбәт иткәнсең. Әйдә өйгә кайтабыз, кунак булып китәрсең. Бир чемоданыңны.

— Юк, башта музейны карыйк инде.

— Шулай дисеңме...— ул азрак уйланып торды.— Ярый алайса. Ул арада Миңниса да кайтып җитәр. Әле аның дәресләре бетмәде.

«Миңниса — хатыныдыр инде,— дип уйладым.— Димәк, хатыны да укытучы?» Шул турыда сорарга дип авызымны гына ачкан идем, күкрәгендәге значокка күзем төште.

— Әллә хатыныңныкын таккансың инде? — дидем мин, шаяртkан булып.

— Университетныкы бүтән костюмда,— диде Әмир. минем кинаягә бер дә исе китмичә. Ләкин монысы кемнеке икәнен ачык итеп әйтмәде.

Музей бинасы авылның уртасында ук булып чыкты. Башта мин: «Ул кадәр музей диярлек әйберләре юктыр, көнкүрешкә, бу як табигатенә караган берничә борынгы экспонат сакланадыр шунда»,— дип уйлаган идем. Анда барып кайтырга такъдимне Әмирнең күңеле булсын өчен генә ясадым. Ә гамәлдә исә ишектәннең нәкъ киресе килеп чыкты. Географиягә, этнографиягә, культурага, тарихка, археологиягә караган бик күп экспонатлар булдырганнар икән болар. Барысы да — шушы Таканеш тирәсеннән табылган җирле материаллар.

* * *

Халык күп йөри икән музейга. Тәэсирләр кенәгәсенә тирә-күрше авыллардан, районнардан килгән кешеләр генә түгел, Казаннан, төрле өлкә һәм шәһәрләрдән төрле йомыш белән килгән төрле һөнәр кешеләре үзләренең хисләрен язып калдырганнар, авылда мондый халык музее оештыручыларга рәхмәт әйткәннәр.

Әмир күкрәгендәге әлеге значок белән бу музей арасында турыдан-туры бәйләнеш бар икән. Ләкин мин моны музейга кергәч түгел, соңыннан гына белдем. Шулай да хәзер үк ул турыда әйтмичә булмый.

Укыган вакытта ук Әмир тел, әдәбият фәннәренә караганда да иҗтимагый фәннәр белән күбрәк кызыксына иде. Хәтта, әйтергә кирәк, кирәгеннән артыграк кызыксына иде. Бишенче курста философия тарихы буенча имтиханга әзерләнгәндә ул өч йөзгә якын чыганакның барысын да конспектлап чыкканлыгы хәтеремдә. Ләкин философ имтиханда күп сөйләгәнне яратмый иде. Әмир бу фәнне кабат тапшырырга мәҗбүр булды.

Ләкин эш анда түгел, әлбәттә. Әмир бу фәннән да «отлично» билгесе алды. Моны шуңа әйтүем: бәлки, нәкъ менә бу вакыйгадан соңдыр инде, ул тарих, иҗтимагый фәннәр буенча укытучы булырга уйлагандыр. Уйлаган гына түгел, укыткан. Аннары тарихчы дипломы алырга дигән фикергә килгән. Республика архивларында казынып, бик игътибар белән, Таканеш тарихын өйрәнгән. Шул ук вакытта үзенең максатын

да гамәлгә ашырган: педагогия институтының тарих бүлеген бетергән дә «С отличием» дип кызыл белән язылган диплом алган. Менә шул икән әлеге значокның сере.

Бу значокның музей белән бәйләнеше бар, дигән идек бит әле. Институтта укып йөргәндә, республика, район архивларын актарганда, күп документлар туплаган Әмир. Ватаныбызның, халкыбызның үткәне, бер тамчы чык бөртегендә чагылган кояш кебек, Тәкәнеш тарихында да бик ачык күренә икән лабаса. Моны бит күзгә күренә торган әйберләр белән дә күрсәтергә була. Авылның кайсы гына йортына керсәң дә, үткән сәхифәләрне сурәтли торган бик күп әйберләр бар. Хәзергеләрнең алар берсенә дә кирәкмиләр, күп әйберләр чүплеккә ташланып юкка чыга. Үткән һәм хәзерге көн сәхифәләрен сурәтли торган шаһитләр булсыннар алар!

Менә Тәкәнеш урта мәктәбе укучылары туган якны өйрәнү өчен туристик походка чыгып китә. Алар Вяткага коя торган Шыя елгасының башланган урынын, суның агымын, ярларын өйрәнергә тиешләр. Ләкин максат моның белән генә чикләнми.

Туристлар Шыя елгасының Әбде урманыннан чыккан чишмәдән башланганын ачыклыйлар. VI класс укучылары Рәхимҗанова, Галиева һ. б. лар шул тирәдәге үсемлекләрдән гербарий коллекциясе әзерлиләр. Туристларның икенче группасы исә елгадагы корылмаларны, урман күлендә юкә кабыкларыннан ничек итеп мунчала төшерү ысулларын өйрәнә. VIII класс укучылары Галимуллин белән Заманов күлнең тирәнлеген, киңлеген үлчиләр, ә рәсем остасы Мөбәрәкшин бу тирәдәге табигать күренешләрен, елга, күл буйларын альбомына төшерә. Шыя елгасы буендагы Сәртек, Ишки, Тауиле авылларының тарихы белән дә кызыксыналар алар. Шушы ук Шыя елгасы ярында борынгы заман хайваны — мамонтның ике метр 20 сантиметр озынлыгындагы казык теше һәм бүтән сөякләре табыла.

Болар барысы да музейның беренче экспонатларына әверелгәннәр.

...Мин агач урындык өстенә куелган бер «машина» алдында кинәт туктады калдым. Урындык дигәч тә, ул без күрергә гадәтләнгән урындык түгел, ышкылмаган, шомартылмаган такталардан әмәлләп куелган һәм яшел буяуга буялган бер утыргыч шунда. Бу утыргычтан та бигрәк аның өстендәге «машина» уйга калдырды мине. Ирексездән үң кулымның имән бармагындагы җөйләргә күз төшердем. Әмир моны күзәтеп торган икән:

— Нәрсә, иска төштеме әллә? — дип сорады, көлемсерәп.

Җавап биреп тору урынсыз иде. Мин бу «механизм»ның үзенчәлекләрен өйрәнергә керештем. Бик гади нәрсә, шулай да сугыш вакытында уйга килмәгән бит. Мондый нәрсәне ясау берни түгел, ул булса, бармаклардагы яра эзләре дә булмас иде.

Акыллы кешеләр бәрәңге уу өчен бик уңай «машина» ясаган булганнар икән: бастыргыч юанлыгы агачтан ике тәгәрмәч кисеп алганнар. Иске чиләк калаен кадак белән тыгыз итеп тишкәләгәннәр дә, аны шул тәгәрмәчләргә ураганнар. Тешле торба килеп чыккан. Тәгәрмәчләрнең уртасына юан тимер чыбык кертеп, әйләндергеч куйганнар. Калганы җиңел нәрсә: бәрәңге тыга торган урын һәм «эшкәртелгән продукция» ага торган улак. Бик җайлы, бик уңай. «Без бер бәрәңге уганчы, бу кеше ун бәрәңге угандыр бу кыргычтан»,— дип уйлап куям эчтән, көнләшеп. Ә үзем һаман бармаклардагы җөйләргә карыйм. Балачак җөйләре. Бәрәңге җөйләре. Әни ун өлеш уылган бәрәңгегә бер өлеш он кушып мич тулы ипи пешерә иде, крахмалы исә бөтен нәрсәгә ябыш торган иде...

Әмиргә әйтәм:

— Моның астына халык тудырган бер куплет такмак язып куйсаң, беркем дә гаепкә алмас иде,— дим.

— Нинди такмак,— ди ул, кинәт җитдиләнеп.

«Алдымны да кыралар,
Артымны да кыралар.
Сугыш башланганнан бирле
Минем белән торалар»,

— дим мин, бәрәңге өчен үзем горурланып.— Дөресе шулай иде бит. Ватан сугышында җиңеп чыгуда бәрәңгенең дә роле бар. Халык моны белми әйтмәгән...

Әмирнең йөзе дә, күзләре дә бик житди, кырыс булып китте — староста булганда, группа җыелышларында шундый була торган иде ул. Аннары, беравык уйлап торды да, кесәсеннән блокнотын чыгарып мин әйткән такмакны язып алды.

Бараңге-баһадирның шундый гайрәтен әйтә торган экспонат дөньяның тагын нинди музеенда бар икән?! Мин шул турыда уйларга өлгермәдем, ишек ачылды һәм музейга Нырты мәктәбе укучылары килеп тулды. Мин футбол кырында туп артыннан бик оста йөгереп йөргән егетне танып алдым да сорадым:

— Уен ничек бетте?

— Биш тә ике. Алар файдасына.

Икенче малай сүзгә кушылды:

— Безнең файдага да. Бу иптәшләрчә генә очрашу иде лә.

Өченчесе дә тыңлап торган икән:

— Аларның ике укытучысы да уйнады. Һөҗүмче булып. Мондый футбол кыры булса бездә. Безме...

Әмир килеп чыгып, аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде, барысын да музей залына чакырды.

Залга килеп керү белән, укучыларның күбесе сугыш кораллары куелган почмакка җыелдылар. Пугачев заманыннан бирле сакланган чакмалы пистолетлар да бар монда, кылычлар да, кортиклар да, хәтта гражданнар сугышы вакытыннан калган снаряд ярчыгы да.

— Бу снаряд ярчыгының,— дип сөйләп китте Әмир,— минем өчен әһәмияте бик зур. Бала вакытта ук беләм мин аны. Ярчыгын түгел. Шартламый калган снаряд иде ул. Без сезнең кебек вакытта аны сугыш уены уйнаганда уенчык итеп тә йөртә идек. Кайбер тимерләрен боргаладык та. Әле ярый ахыргача борып җиткермәгәнбез.

Хәрби комиссариаттан, ДОСААФтан вәкилләр чакыртып, тау башында шартлаттык без аны. Моннан дүрт ел элек. Әгәр бала вакытта артыграк тырышкан булсак, барыбызга да Ватан сугышына кадәр үк капут икән...

Бик табигый: малайлар «Максим» пулеметыннан һич кенә дә аерыла алмыйлар. «Максим» турында нинди генә китаплардан укымаганнар алар. Бу пулеметның гражданнар сугышы заманыннан калган, моның белән кызыл гаскәрләр Колчак бандаларына каршы аткан икәнлеген белгәч, аларның кызыксынулары бермәбер артты. Кайсы идәнгә ятып төбәп карый, кайсы лентага кулын суза, кайсы рычагларын боргалый.

Ләкин моннан да кызыклырагы бар икән әле. Хәрби кораллар почмагының иң өстенә бер наган беркетеп куелган. Күрәзгән булса да, чын наган. Бу наганның тарихы китапларда язылган мавыктыргыч вакыйгалардан бер дә ким түгел икән.

Революциягә кадәр үк була бу хәл. Таканештән ерак түгел Дусай дигән авылга урядник килә. Налогларны түли алмаган ярлы-ябагайны куркытып, кенә буе өйдән өйгә йөри дә кичен мулла өенә кунарга керә. Хәзрәт белән икәүләп шактый гына кәеф-сафа кылалар.

Урядник түр өйдә түшәк җәелгән урынга барып җитә алмый, идәнгә егыла да гырлап йокыга китә. Хәзрәт тә, остабикәне ялгыз калдырып, утырган урыныннан сәкегә ава.

Табын җыештырырга керган уналты яшьлек асрау кыз Сәрвәр почмактан очлы борынлы бер кун тартма табып ала. Ачып карый. Эчендә тимер әйбер. «Мылтык», дип уйлап ала да ул, атыла-нитә күрмәсен, харап итмәсен, дип, белгән догаларын укый-укый чыгып китә һәм бакча артына алып барып күмеп куя.

Урядник, иртә белән айнып торгач, нинди гауга булганы хәзер инде безгә мәгълүм түгел. Тик шунысы хас: Сәрвәр әби бу вакыйганы онытмаган, моннан бер-ике ел гына элек шул урынны үзенең Таканеш мәктәбендә укучы оныкларына күрсәткән. Шулай итеп урядник наганы музейга килеп эләккән...

Таканеш авылыннан унсигез кеше, февраль революциясеннән соң, сугышны дәвам иттерергә теләмичә, фронтны ташлап мылтыклары белән туган авылларына кайтканнар. Менә наган астына беркетелгән мылтыкларның берсе шуларныкы. Штыгы да бар. Кулак обрезларының үрнәге дә куелган. Кем белә, бәлки, бик яхшы кешеләрнең башына җиткәндер бу обрезның иясе. Ә сыйнфый көрәш, һәркемгә билгеле, каты булган бу якларда.

Әйтәсе дә юк, гыйбрәтле документлар, экспонатлар күп бирелә. Алар Тәкәнеш кешеләренең генә түгел, бөтен илебез халыкларының якты киләчәк өчен көрәшләрен гәүдәләндерәләр. Менә бер документ. Бу — 1865 елда Казан губернаторының Петербургка җибәргән донесениесенең күчермәсе. «Мамадыш округының төрле авылларында яшәүче дәүләт крестьяннары, татарлар,— диелгән анда,— игеннәрдән аз уңыш алу нәтиҗәсендә бөтенләй ярлыландылар. Аларның үзләрен туйдырырлык та мөмкинлекләре юк. Басулар чәчелми, балалар хәер сораша».

Чиктән ашкан хәерчелектән котылырга теләп, авыл халкы күпләп-күпләп эш эзләргә читкә чыгып китәләр. Рус промышленниклары исә арзан эш кулларына исәп тотып, бу тирәдә төрле предприятиеләр ачып җибәрәләр.

Тәкәнеш янында табылган бакыр рудасын эретү буенча авылда мастерскойлар салына. Руда шахталардан, башлыча, кул көче белән чыгарыла. Рудниклардагы гадәттән тыш авыр хезмәт шартлары эшчеләрдә хуҗаларга каршы ачу тудыра. Алар 1898—99 елларда берничә мәртәбә протест белән чыгалар.

Тәкәнешләләр шулай ук төрле милли бизәкләр, орнаментлар төшерелгән итек басу белән дә шөгыльләнгәннәр икән. Бу турыда музейга куелган тимер мөһер әйтеп тора. «Л. Шамсетдинов, валяно-обувная фабрика деревни В. Ушлан[1], близ Кукмора Петропавловской волости Мамадышского уезда»,— дип язылган аңа. Ул мөһерне укучы Рахимҗанов металлом арасыннан табып алган. Димәк, Тәкәнештә элек итек басу мастерское булган. Эзләнә, сораша торгач, анда егермеләп кеше эшләве ачыклана. Тәкәнеш итекләре Россиянең төрле почмакларына озатыла торган була. Экспонатлар арасында чиккән итек үрнәге дә бар.

Җирсез крестьяннарның бер өлеше такта яру һөнәрен үзләштереп, тирә-як авылларда көнлекче булып эшлиләр...

Тарих дәресендә өйрәнелгән, китаплардан укылган вакыйгаларга иллюстрацияләр күп монда. Шуңа күрәдер инде кунаклар, Нырты мәктәбе укучылары, һәр экспонат, һәр документ алдында озак-озак тукталып торалар, саргаеп беткән кәгазьләрдәге язуларны тырышып-тырышып укыйлар. Ә Әмир абыйлары бу экспонатларның, язуларның һәрберсенә аңлатма бирә.

— Узган гасыр ахырында Тәкәнештә сыйнфый көрәш бик нык кискенләшә,— ди ул, «Шахтерларны тентү» дигән рәсем янына тукталып.— 1891 елда налог түләүчеләрне учетка алу үткәрелә. Бу тыныч кына узмый. Тәкәнеш крестьяны — Гастин дигән кеше — патша хөкүмәтенә каршы ачыктан-ачык агитация белән чыга. Налог түли алмаган крестьяннарның мал-туарын, йорт-җиһазларын җыеп йөргән стражниклар, урядник алдында ул авыл халкын патша хөкүмәтенә каршы күтәрелергә өнди. «Николай патша барыбер дөмегәчәк»,— дип тәмамлый ул үзенең сүзен. Бу чыгышы өчен Гастинны кулга алалар, төрмәгә ябалар.

1904 елны башланган рус-япон сугышына Тәкәнеш кешеләре дә алына. Бу сугыш авыл халкының тормыш хәлен тагы да авырлаштыра. Налоглардан тәмам хәерчелеккә төшкән крестьяннарга сугыш налогы да өстәлә. Сугышка барып, исән калганнары да гарип булып кайталар.

Бик күп тәкәнешләләр уналты-унҗиде яшьтән үк бәхет эзләп читкә китәләр. 1905 елгы беренче рус революциясенә катнашучы якташларыбыз да күп безнең. Һадиулла Дәүләтшин, Абдуллин, Сәйфуллин, Рәхмәтулла Гайфуллин һәм башка Тәкәнеш кешеләре революцияне Томск шәһәрендә каршы алалар. Аларның документларына, стачкада катнашканнары өчен, эшкә алмаска, дигән штамп сугалар.

Илебез тарихындагы һәр күренекле вакыйга Тәкәнеш авылы кешеләре тормышында чагылыш таба дисәк, һич тә ялгыш булмас.

1905 елдагы беренче рус революциясенә катнашкан эшчеләр, шахтерлар — Тәкәнеш кешеләре — революцион фикерләрне туган авылларына да алып кайталар. Заһидулла Сафиуллин исә авылга татарча язылган прокламацияләр дә алып кайта. Крестьяннар арасында ризасызлык хәрәкәте, ул авылга кайткач, бермә-бер үсеп китә. Бу хәрәкәтне бастыру өчен 1906 елда Тәкәнешкә утыз-кырык кешедән торган казаклар отряды килеп төшә. Менә бу рәсемдә нәкъ шул күренеш сурәтләнгән. Һәвәскәр художник Р. Һадиев шушы вакыйганы полотнога төшерде. Әлбәттә, бу рәсем зур

[1] Тәкәнешнең элекке исеме.

сәнгать әсәре булуга дәгъва итми. Шулай да ул заман тормышын шактый дөрес чагылдыра. Мәнә карагыз: полицейский артында теткәләнеп беткән китап ята — ул Тукай шигырьләредер, мөгаен. Бәлки, шахтер русча да укый-яза белгәндер. Патша хөкүмәтен фаш итә торган китап булуы да мөмкин аның. Шунысы хак: аларда, шул вакыттагы халык сүзе белән әйтсәк, зимагурларда, прокламацияләр булуы билгеле. Бу тентүдән соң 18 кешене юкка гына кулга алып волостька озатмаганнар...

Үтеп барышлый Әмирне күреп кенә чыгыйм дип уйлаган идем, музей материалларын караган саен, кызыксынуым арта барды. Бер почмакка утырдым да халык бәхете өчен көрәшүчеләр турында укучылар, укытучылар әзерләгән альбомнар, музейдагы төрле документлар белән танышырга керештем. Документлар бик күп, берсеннән-берсе кызыклы, берсеннән-берсе гыйбрәтле...

Тәкәнеш клубы янындагы бакчада халык бәхете өчен көрәшләрдә һәлак булганнарга һәйкәл тора. Бу һәйкәлне салдыру артыннан да авыл Советы депутаты Әмир йөргән, диләр. Алай гына да түгел, ул һәйкәл Әмир шәкертләре — урта мәктәп укучылары көче белән салынган. Авылларда мондый һәйкәлләр яңалык түгел инде хәзер. Һәр авылда, һәр шәһәрдә аталар-бабалар традициясенең киләчәк буыннарга дәвам итүен сурәтли торган символ булып күтәрелгән алар. Ләкин бу символның эчтәлеге, мәгънәсе һәркемгә мәгълүм түгел бит. Ә менә музейда, Тәкәнештә Әмир оештырган халык музеенда, бу һәйкәлнең мәгънәсе халыкларның киләчәк өчен, өметләрнең гамәлгә ашуы өчен зур көрәшен сурәтли торган дулкынландыргыч бер панорама булып күз алдына килеп баса.

Менә Зәһриев Сәхәбетдингә багышланган экспонат. Гади бер авыл егете булган ул. Унтугыз яшендә Кызыл Гвардия отрядына язылган. Күп сугышларга катнашкан. 1918 елда язмыш аны Азин отряды белән туган якларына китерә. Ләкин туган авылын — Түбән Шәүләнгәрне күрә алмый ул: Колчак бандалары аны Вятка елгасы буендагы сугышларның берсендә әсир итәләр.

Зәһриев Сәхәбетдинне һәм аның белән бүтән патриотларны, Кызыл Армиянең көчле һөҗүмнәре нәтиҗәсендә ашыгып чигенергә мәҗбүр булган ак бандалар Кизнәр станциясендә вагонга бикләп, вагон өстенә керосин сибеп, терелә яндырып үтергәннәр...

Ә бу экспонатка Үзәк хәрби тарих архивының 1615 фондындагы 10 эшкә теркәлгән 18; 19; 20; 21; 22; 23 битләрнең күчермәсе куелган. Вакытлы хөкүмәтнең хәрби трибуналы карары бу. Анда Тәкәнеш егете Габдрахман Әхметов турында да шактый күп нәрсәләр язылган.

Кем соң ул?

Габдрахман Әхметов 1917 елда Двин полкында хезмәт итә. Август аенда солдатлар, большевиклар җитәкчелегендә, «Бетсен сугыш! «Бөтен власть Советларга!» лозунгылары астында коралллы демонстрациягә чыгалар. Вакытлы хөкүмәткә турылыклы гаскәрләр һәм полиция демонстрациячеләрне камап алалар. Бу бәрелештә Габдрахман Әхметов бер офицерны атып үтерә, икенчесен яралый. Демонстрация җитәкчеләре дә, Габдрахман да кулга алына. Аны хәрби трибунал 20 елга каторгага хөкем итә.

Бөек Октябрь революциясен ул Мәскәүдә, Бутыр төрмәсендә каршы ала. Төрмәдән эшчеләр коткара аларны...

Бер экспонатта Г. Галимовның 1920—21 елларда Кремльдә беренче совет пулеметчылары курсында укуы турында таныклык бар. 1921 елдан КПСС члены Г. Галимов бу еллар турында үзе болай яза: «1920 елның ноябрендә мине Казандагы ике еллык мөселман пехота курсларыннан Мәскәүгә пулеметчылар курсына җибәрделәр. Бу курс яңарак кына ачылган иде әле. Уку урыны Кремль бинасында иде. 1920 елның декабрендә курста укучыларның беренче чыгарылышы булды. Шушы кичәгә без дә Кремльнең Зур Сараена килдек. Анда дәһи юлбашчыбыз В. И. Ленин речь белән чыкты. Ул бер сәгатькә якын сөйләде. Без, курсантлар, аны «Ура!» кычкырып каршы алдык. Ильич дошманнарга отпор бирергә чакырды, изге эш — эшче һәм крестьяннар интересы өчен көрәштә уңышлар теләде.

Кремльне саклау безгә, курсантларга, йөкләтелгән иде. Миңа да төрле җаваплы постларда торырга туры килде. Без, постта торучы курсантлар, Владимир Ильичның

һәр көнне иртән Кремль ишеге алдында йөрүен, аннары үзенең эш бүлмәсенә керүен күрә торган идек.

1921 елның башларында якшәмбе көнне безне, Кремльнең зур капкасыннан алып чыгып, сафка тезделәр. Капка турына трамвай килеп туктады. Озак та үтмәде, Кремль капкасыннан бер иптәш белән Владимир Ильич чыкты. Ул сафтагылар белән исәнләште һәм коммунистик өмәләргә катнашырга, анда намус белән эшләргә, халык хуҗалыгын торгызуга ярдәм итәргә кирәклеген аңлатты.

Без, трамвайга утырып, тимер юл станциясенә килдек. Ул җимерек хәлдә иде. Вагоннардан утын бушаттык, төрле җирдә яткан бүрәнәләрне бер урынга җыйдык, ватык юлларны төзәттек. Шуннан соң без һәр атнада коммунистик өмәләргә чыга торган булып киттек. Өмәдән кайткач, партбилетка «Коммунистический субботник» дип штамп сугалар иде.

Кремльнең зур капкасы төбендә сакта торганда, Ильич автомашина эченнән, килеп җиткәнче үк, пропускасын сузып күрсәтә торган иде. Без аның, шундый олы кеше булуына карамастан, кече күңелле һәм тәртип саклаучан булуына сокланa идек».

Ә менә бу документны Түбән Өскебаш авылыннан килеп укучы балалар әле күптән түгел генә музейга тапшырганнар.

«Аерым Кавказ эшче-крестьян Кызыл Армиясенең элекке XI армия Революцион Хәрби Советы, хезмәт иясләрен азат итү өчен героик көрәшләргә өч ел тулуны һәм социалистик Ватанны яклауны билгеләп, шушы грамотаны Кызыл Армия сугышчысы иптәш Хәсәнҗанов Шәрифкә эшче-крестьян Ватаны алдында үзенең бурычын үтәү символы итеп бирә.

Революцион Хәрби Совет члены — Орджоникидзе.

Штаб начальнигы — Пугачев. 1921 ел».

Шәриф абзый Деникин бандасына, врангельчыларга каршы сугышларда катнашкан, Кырымны азат иткәндә контужен булган һәм терелгәч, Кавказдан инглиз, француз интервентларын һәм акгвардиячеләрне куып чыгаруга өлеш керткән. Җиңүче булып, гражданнар сугышыннан кайткач, Донбас шахталарында эшләгән, утызынчы еллар башында туган авылына кайтып, башта бригадир, 1936 елда колхоз председателе булган.

Шәриф Хәсәнҗановның язмышы — үзе бер зур китап. Башыннан алып ахырына кадәр Бөек Ватан сугышына да катнашкан ул. Ике мәртәбә яраланган. Шулай да хәзер дә бирешми Шәриф абзый. Ул әле дә көченнән килгән кадәр колхозга булыша һәм аның рәсеме Почет тактасында тора.

Стенага эленгән рәсемнән борай башагыдай тырпаеп торган мыеклы, җитди карашлы, башына эшләпә кигән бер агай карап тора. Бу — пенсионер Габдулла абзый Шәфигуллин портреты.

Ни өчен аның портреты музейга эленгән соң? Габдулла агай турындагы материаллар белән ныклабрак танышыйк. 1942 елда чыккан район газетасында аның турында болай диелгән: «Габдулла Шәфигуллин, Тәкәнештә беренчеләрдән булып, танк колоннасы төзүгә 1000 сум акча кертте. Ул фронт өчен фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтә».

Моның өчен генә дә түгел икән әле. Үзе дә солдат икән Габдулла ага, карт солдат икән.

Беренче бөтен дөнья сугышыннан яраланып һәм ике Георгиевский ордены тагып кайта ул. Азрак хәл кергәч, аны тагын фронтка озаталар. Бөек Октябрь революциясен окопта каршылап, Г. Шәфигуллин беренчеләрдән булып большевиклар ягына чыга. Деникин гаскәрләренә, Врангельга каршы сугыша. Гражданнар сугышыннан соң, авылда Совет властен ныгыту өчен армый-талмый эшли.

Чыннан да, Габдулла агайның язмышы да бик күпләр өчен үрнәк икән!

Ә легендар Азин дивизиясе солдаты Мәснәви ага Гобәйдуллин үзенең сугышчан юлын Чистай ягыннан башлый. 35 нче дивизиянең 110 нчы полкы составында ул Татарстан, Башкортстан җирләрен, Уралны Колчак бандаларыннан азат итешә, җиде үлемнән исән калып, Байкалга кадәр авыр сугыш юлы үтә.

Күптән түгел, «Родина» авыл хуҗалыгы артеле члennары гражданнар сугышы

һәм колхоз ветераны Мәснәви Гобәйдуллинны почетлы ялга озатканнар. Аның портреты да музей стенасын бизи.

Мондый батырларның мактаулы эшләрен сурәтләгән экспонатлар музейда күп. Аларның һәрберсен кыскача гына санап чыгу да бик озынга китәр иде. Шулай да Таканеш кешеләренең колхоз төзелеше, Бөек Ватан сугышы елларындагы тормышын чагылдырган экспонатларны һич тә читтә калдырасы килми. Әнә, музейны карарга килгән Нырты урта мәктәбе укучылары да ничек кызыксынып карый аларны!

Алар Совет хөкүмәтенең җирне күмәк хуҗалыкларга мәңгегә беркетү турындагы Акт һәм колхозның беренче тракторчысы Н. Нигъмәтуллин рәсеме эленгән почмакка җыелганнар. Ә Әмир күрсәткеч таягын болгый-болгый сөйли:

— Таканеш кешеләре 1929 елда коллектив хуҗалык булып берләшәләр,— ди ул.— Һәм бик тиз арада зур уңышларга ирешәләр. 1935—36 елларда алдынгылардан Гобәйдуллин һәм Хәмидуллин иптәшләр СССР Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә бару өчен путевкалар белән бүләкләнәләр. Менә сез бу экспонатларда бу путевкаларның төп нөсхәләрен күрәсез. Ә безнең колхозның алдынгы кешесе Галиулла абзый Насыйбуллин самолетта очу бәхетенә ирешкән...

Бая хуҗалар капкасына икенче тупны керткән малай, Әмир сүзен бүлдереп:

— Әллә Гайҗан бабай шул булды микән? — диде.

— Булуы да мөмкин,— дип елмайды Әмир.— Шәйхи Маннур безнең якныкы бит. Ул Таканештән ерак түгел Толбай авылыннан. «Яңа җыр килде» хикәясен дә безнең яклардан алып язгандыр әле. Әнә бит музейдагы әйберләр гел мондагы сугышлар турында әйтә. Колчак килгән вакытта алар авылын да аклар алган булган.

Әмир, тарихчы гына түгел, әдәбиятчы да булгангамы, темадан читкә китүгә бер дә уңайсызланмады. Киресенчә, тагы да мавыгыбрак китеп, тормыш, чынбарлык материалы һәм язучының фантазиясе турында сөйләп алды.

— Галиулла абзыйның Гайҗан бабай булуы да бик мөмкин,— дип бетерде ул сүзен.— Ни генә булмасын, аларның икесенең дә шатлыклары, куанычлары уртак булгандыр.

Хәтерегездәме, ничек ди шагыйрь:

Гайҗан бабай сөйли,
Һаман сөйли...
Чәе суына, аны сизми ул;
Куанычы эченә сыймаганга,
Һаман сөйли,
Һаман сөйли ул...

Аннары Әмир тагын тарихка кайтты, музей караучыларны «Элек һәм хәзер» дип исемләнгән стенд янына алып килеп, авылдагы зур үзгәрешләр, салам түбәле кечкенә һәм караңгы куышлар урынына Ильич утлары балкып торган зур йортлар, бердәнбер җыелып сөйләшү урыны булган каравыл куышын Культура йорты, тимерче алачыгын «Сельхозтехника» һәм «Родина» колхозы мастерскойлары алмаштыруы, авылда ике больница, урта мәктәп, кирпеч заводы, яшелчә киптерү, май заводлары, промкомбинат, почта бүлекчәсе һәм җиде магазин булуы, аларның кешеләргә нинди хезмәтләр күрсәтүе турында кыска да, кызыклы да итеп сөйләп бирде.

Аның сөйләвендә бер үзенчәлек бар. Ул үзе бик җитди итеп сөйләгән кебек күренә, ә күзләрендә ниндидер шаян очкыннар кабынып-кабынып китә. Музей карарга килгән укучылар — алар, мөгаен, дәрес вакытында да тын гына тыңлап утырмый торганнардыр әле — иреннәрен очлайта-очлайта аның сөйләгәннәрен йотып торалар. Бу, мөгаен, укучылар күңеленә юл сала белүнең бер галәмәте, тәҗрибә, озак еллар дәвамында туган осталыкны күрсәтә торган әйбердер.

...Нырты укучылары гражданнар сугышы экспонатлары куелган бүлмәгә кабат чыгып киттеләр. Ә мин, үзем генә, Ватан сугышын сурәтләгән әйберләрне карарга керештем. Өстәл өстендә калын-калын альбомнар тора. Шул альбомнарны актарырга керештем. Бу альбомнарны Таканеш пионерлар йорты әзерләгән икән. Пионерлар әтиләренең, абыйларының истәлекләрен язганнар, йорт саен йөреп, сугышта һәлак булганнарның, тылда, үз авылларында, үз колхозларында хезмәт үрнәкләре күрсәткәннәрнең рәсемнәре һәм аларның эшләре турында конкрет, гыйбрәтле бик күп

материаллар тупланганнар. Шунысы игътибарны тарта: пионерлар, бары тик Тәкәнеш кешеләренең генә батырлыкларын сурәтләп, бөтен Бөек Ватан сугышы тарихын күз алдына китереп бастыруга ирешкәннәр. Тәкәнештән 89 кеше сугыштан кайтмаган, сугышка катнашканнарның да һәрберсе Ватаныбызның азатлыгын һәм бәйсезлеген саклап калу өчен өлеш керткән. Тылда калган хатын-кызларның, карт-корыларның, бала-чагаларның һәрберсе җиңү өчен тырышкан. Альбомнарда болар дулкынландыргыч итеп сурәтләнгән.

Менә мисаллар: «Вперед, к победе» исемле фронт газетасында Тәкәнеш егете Хаммат Заһриев расчетының Сталинград трактор заводыннан 200 метр ераклыкта дошманның җиде танкысын һәм гаскәр төялгән күп санлы автомашиналарын юк итүе турында язылган.

Ә Рәхимулла Гайнуллин боздай салкын суда Днепр елгасын беренчеләрдән берсе булып кичеп чыккан. Дошман ягында плацдармны ныгыту өчен зур батырлыклар күрсәткән.

Алтмыш алтынчы укчы дивизия сугышчысы Хәбибрахман Сафин Ленинград шәһәренең тарихи урыннарын саклауда зур батырлык үрнәкләре күрсәткән. Хәзер Ленин шәһәренә барсаң, андагы искиткеч һәйкәлләрнең исән калуында аның да өлеше барлыгын искә төшерми мөмкин түгел...

Тылда калган тәкәнешлеләр җиңү көнен тизрәк якынайтырга теләп, сугышчыларга бик күп җылы киемнәр җыялар, танклар колоннасы, самолетлар эскадрильясы төзү өчен Кызыл Армия, Оборона фондына йөз меңнәрчә сум акча кертәләр һәм Баш командующийдан рәхмәт алалар.

Альбомнар куелган өстәл белән рәттән пыяла белән капланган тартма эчендә тәкәнешлеләрнең Бөек Ватан сугышы фронтларыннан язган хатлары саклана. Гади сугышчыларның ут эченнән язган бу хатларында — никадәр патриотик хисләр, дошманны җиңүгә никадәр зур омтылыш! Хәзерге яшь буынга әтиләрнең, абыйларның һәм бабайларның бәхетле киләчәк өчен ничек көрәшүләрен сурәтли торган, гаять зур тәэсир итү көченә ия булган җанлы документлар алар.

Менә шул хатларның берсе, арадан беренче кулга тигәне:

*«Хәят җаным, Илгизә кызым!*

*Менә бүген, сезнең 22 апрельдә язган хатыгызны алып, бик шатландым, сезнең тормышлар белән, авыл хәлләре белән таныштым. Минем тормышта аерыча үзгәрешләр юк, яхшы гына хезмәт итәм.*

*Хәят, Илгизә!*

*Беренче май бәйрәме уңае белән мин бик күп бүләкләр алдым (печенье, сыр, конфет, төрле җимешләр). Һәрберсен язып бетерерлек түгел. Халкыбызның бу зур бүләкләре, Кызыл Армия өчен бу зур кайгыртулары минем каршыма зур бурычлар куя, минем йөрәгемдә тагы да көчлерәк көрәш дәрте утларын дөрләтә, бетле фашист этләрен җир йөзеннән себереп ташларга чакыра. Мин бу изге бурычларны, бу зур ышанычларны намус белән тулысынча үтәячәкмен, илем өчен, халкым өчен, сезнең киләчәктә бәхетле тормышыгыз өчен... актык тамчы каныма кадәр көрәшәчәкмен, әгәр кирәк булса, җанымны да бирәчәкмен!*

*Хәят, Илгизә!*

*Хатыгызда матур-матур җырлар язгансыз, бик рәхмәт. Менә ул җырларыгызга каршы бүләк итеп рәсемемне җибәрәм. Сагынганда карап, шулай матур итеп җырлар җырларсыз.*

*Сезне үбеп, мәгълүмегез Сафиуллин Хәбиб.*

*8 май, 1942 ел».*

Хәбиб аганың бу хатын мин тулысынча күчереп алдым, андагы бер җөмләне дә төшереп калдырырга күңелем бармады. Чөнки бу — совет сугышчысының семьясына язган хаты гына түгел, чын коммунист кешенең иленә, халкына, партиягә биргән анты да.

Хәбиб ага сугыштан кабат семьясына кайта алмаган, һәлак булган, гәүдәсе туган җирдән еракларда җир куенына кергән. Әмма семьясы өчен генә түгел, бу хатны укыган һәркем өчен ул хәзер дә тере булып, искиткеч олы җанлы, яхшы кеше булып, баһадир солдат булып күз алдына килеп баса.

Әйе, музейда гыйбрәтле документлар, гыйбрәтле әйберләр, гыйбрәтле язмалар бик күп. Аларның һәрберсе күп фикерләр уята, күп нәрсәләрне хәтергә төшерә, моңа кадәр үзең белеп тә асылына төшенеп җитмәгән нәрсәләр турында сиңа акыл бирә. Чын-чынлап гыйбрәтле истәлекләр хәзинәсе ул. Җентекләп карыйсың икән, син аннан рухи баеп чыгасың.

Бөртекләп, бөртекләп җыелган хәзинә бу. Аны оештырырга беркем дә Әмир Ганиевне мәҗбүр итмәгән...

* * *

Мин Тәкәнештә тагын берничә көн булдым. Музейны карау, өстән-өстән генә булса да урта мәктәп белән, Әмирнең семья тормышы белән танышу үзем өчен кайбер кызыклы гына нәтиҗәләр ясарга ярдәм итте.

Районнарда, авылларда булгаларга, укытучыларның тормышлары, аларның омтылышлары белән шактый гына кызыксынырга туры килә миңа. (Бу, әлбәттә, башка бик күп кешеләргә дә шулайдыр.) Бер нәрсә гаҗәпләндерә: югары мәктәп бетереп авылга килгән кайбер укытучылар, студент вакытындагы хыялларын, омтылышларын бик тиз онытып, үз хуҗалыгы, үз кабыгы эченә кереп бикләнәләр. Дәресләкләр буенча әзерләнеп мәктәпкә баралар да дәрес бирәләр, тәнәфес араларында, укытучылар булмасена җыелып, теге-бу турыда сөйләшәләр, өлгермәүче укучыларны өстәмә дәрескә калдыралар һәм аннары, өйләренә кайтып, бакча эшләре белән шөгыльләнәләр, каралты-кура, сыер абзары төзәтәләр. Бу гадәткә әверелә...

Югары мәктәп бетергән укытучы авылга биш ел дәвамында аңына, рухына сеңгән культура, белем, тормышка яңа караш алып килә. Шуларны үз эченә бикләп, бикләп кенә түгел, бөтенләй онытып, әллә кайчаннан, ата-бабалардан калган хосусый милекчелек хисенә, икенче төрле әйтсәк, обывательлеккә күмелеп калырга тиешме соң алар?

Газета-журналларда чыгып килгән яңа әдәби әсәрләрне укымаган, яңа үсеп килгән яки инде укучылар арасында яхшы ук танылган әдипләрнең иҗаты белән бөтенләй таныш булмаган әдәбият-тел укытучылары белән дә сөйләшкәнем бар минем. Алар үзләренең эшенә, укыту эшенә акча китерә торган эш итеп кенә карыйлар. Тәрбия эшенең нәтиҗәсе дә, җәмагать эше дә, авылдагы культура-агарту эше дә, колхозчыларның омтылышы да, экономик, социаль мәсьәләләр дә кызыксындырмый аларны. Аларның үз-үзләренә куйган таләпләре — өемдә минем рәхәт булсын, уңай булсын, бүтәннәр минем эчке дөньяма тыкшынмасын!

Сабакташым Әмир Ганиев һәм аның эшләре белән танышкач, үзеннән-үзе шулар турында уйландым мин. Әмир өчен дә тәүлек — егерме дүрт сәгать, ел — өч йөз да алтмыш биш көн бит. Аның да семьясы, берсеннән дә берсе кечкенә, берсеннән берсе матур бер улы, бер кызы бар, йорты-җире, хуҗалыгы, сыеры, сарыклары, казы, тавыгы бар. Ә шулай да ул барысына да өлгерә. Читтән торып укып, тагын бер диплом алган, актив пропагандист булганы өчен республика Почет кенәгәсенә исеме язылган, «Белем» җәмгыятенең актив лекторы, актив хәбәрче, авыл Советы депутаты һ. б.

Әйе, укытучы — авылда культураның зур көче, ул авыл хуҗалыгындагы эшләрнең һәр тармагына катнаша. Әгәр яшьләр колхоз тарафыннан ун меңнәрчә сумга төшереп салынган зур-зур культура сарайларында, культура йортларында эчләре пошып утырудан кибет ишеге төбен сагалауны артыграк күрәләр икән,— монда укытучыларның да гаебе бар.

Ә Тәкәнеш егетләренең кибет тирәсенә әллә ни исләре китми. Культура йортында һәр кичне, һәр шимбә һәм якшәмбе көннәренда шахмат тактасы өстендә каты бәрелешләр бара. Андагы «шахмат җене» кагылган яшьләрне дә, агайларны да көч сынашырга чакыру өчен зур тәвәккәллек кирәк. Тәкәнешнең шахмат командасы белән ярышырдай командалар район үзәгендә — Мамадышта да, тирә-як авылларда да, тирә-як районнарда да безгә аз. Беренче разрядлы шахматчылар гына да анда дистәләгән. Бу да — Әмир Ганиев эшчәнлегенең нәтиҗәсе. Шахмат командасын ул оештырган, «дошман»нарга каршы шулай каты торырга ул өйрәткән. Ярышларда

җиңеп чыгу турында әйтелгән күп санлы грамоталарда, дипломнарда, таныклыкларда Әмирнең турыдан-туры хезмәте бар.

Тәкәнешлеләр музей белән дә, шахмат белән дә, Әмирнең эшләре һәм аның үзе белән дә горурланалар. Кичесе-олысы аның янына киңәш сорап киләләр.

Әмирнең Мамадыш район газетасында басылып чыккан бер мәкаләсе бар. Ул бу мәкаләне Тәкәнеш авылы буенча үзе җыйган тарихи фактларга — музей материалларына нигезләп язган.

«Халыкта хәзер дә әле төрле кешене төрле кушамат белән атау бар,— дип башлана аның мәкаләсе.— Ул кушаматларның килеп чыгышы төрле вакыйгалар, теге яки бу кешенең характер үзенчәлекләре һ. б.лар белән бәйле. Кушаматларның кешене кимсетеп түгел, олылап кушканнары да күп».

Менә шундый кеше турында яза Әмир.

Ул кеше үлгәнгә инде бик күп еллар үткән. Аның пуҗмасында инде хәзер бүтән кеше яши. Ләкин халык аны һаман онытмый, «Мировой Мирза пуҗмасын» авылда һәркем белә.

Кем булган соң ул?

Мирзакамал Шәмсетдинов, солдатка алынгач, тырышлыгы аркасында русча сөйләшергә генә түгел, хәтта укый-язарга да өйрәнә. Ул беренче бөтен дөнья сугышында катнаша, шахталарда, завод-фабрикаларда эшли. Октябрь революциясеннән соң туган авылына кайта.

Ленин декретларын да, үзәктән килгән башка документларны да авылдашларына иң башлап җиткерүче ул була. Ул авылдашлары өчен русча гариза да яза, акт та төзи, төрле анкеталар да тутыра. Авылга инде белемле укытучылар, врачлар, башка төрле грамотный кешеләр килгәч тә, һәркем Мирза агайга ярдәм сорап бара. Чөнки ул гадел, аның әйткәннәре дә, язганнары да рас килә...

Шуңа күрә ул халык күңеленә кереп калган. Шуңа аңа «Мировой Мирза» дигән кушамат такканнар, хәзер дә аның исемен һәркем хөрмәт итә.

Менә минем дә, халык телендәгечә әйтсәк, «Мировой Мирза» таягын Әмиргә ташлаган»,— диясем килә. Мирзакамал агага тагылган кушамат аңарга да бик лаек кебек.

Хәзер инде Әмир «дуәрән Әмир» түгел, ә «Мировой Әмир» дип әйтәсем килә. Һәм сабакташымның андый булуы белән горурланам мин.

# ЗАМАН БЕЛӘН БЕР ЭЗДӘН



Ленин орденлы татар дәүләт академия театры — Галиәсгар Камал исемендә. Халык драматургы дигән мактаулы исем дә беренче булып Галиәсгар Камалга бирелгән. Мондый зур дәрәҗә, зур исемне алу өчен халык каршында дан казанырга, үзеңнең хезмәтең белән танылырга кирәк.

Галиәсгар Камалның хезмәте озак вакытка, 33 елга (1900—1933) сузылды. Казанның гади кустарь гаиләсендә үскән бу кешенең әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге Россиядәге алмашыну көннәренә, бөек революцияләр чорына туры килде. Ачык әйтергә кирәк: әгәр пролетариат җитәкчелегендәге шул революцияләр булмаса, һәлак булган, эзсез югалган бүтән күп талантлар кебек, Галиәсгар Камалның да онытылып, ачыла алмаган бөре кебек югалып калуы бик мөмкин иде.

Галиәсгар аганың хезмәте катлаулы һәм күпкырлы. Ул — драматург, тәнкыйтьче, журналист, хикәяче, шагыйрь, тәрҗемәче, артист, каллиграфист, художник, талантлы оештыручы һәм җәмәгать эшлеклесе. Мондый күп тармаклы хезмәт үзе бары революцияләр чорында гына була ала, бары бөек революцияләр генә шундый талантларны тудыра һәм аларга җәелеп китәргә мөмкинлек бирә дисәк, ялгышмабыз.

Аның күпкырлы хезмәтен үзара тыгыз бәйләнгән ике чорга бүлеп карарга мөмкин. Беренче чор эшчәнлеге (1900—1917 еллар) революциягә кадәр дәвердәге татар җәмгыятен каплап алган искелекне, туңлыкны, мещан баткаклыгын рәхимсез фаш итүгә, яңалык очкыннарын пропагандалауга багышланган. Моны аның актив катнашы белән язылган кулъязма газета яки прокламацияләрдә, басма матбугатта, әдәби әсәрләрдә — һәркайсында ап-ачык күрергә мөмкин. Беренче чор иҗат дәверендә Галиәсгар ага заманның көзгесе дип әйтерлек драма һәм комедияләр язды, комедия остасы, татар Островские дигән исемнәр алды. Ул «Азат», «Азат халык», «Казан мөхбире» исемле газеталарда эшләде. Әмма аның иң озак һәм дәвамлы эш урыны «Йолдыз» газетасы редакциясе булды. Әдипнең бу чор иҗаты турында күп язылган, күп тикшерелгән. Шуңа күрә без, ул чорны шулай берничә сүз белән үтеп, Галиәсгар аганың икенче дәвер иҗатына (1918—1933 еллар) киңрәк тукталырга уйладык.

«Йолдыз» чыгудан туктагач, Г. Камал урынсыз кала[1]. Шул арада аның тормыш иптәше Гайшә ханым да үлеп китә, дүрт балалы бу гаиләнең тормышы шактый уңайсызлана. Гаилә мәсьәләләрен рәтләп йөргәндә, Идел-Урал буйларында баш күтәргән контрреволюция 1918 елның 6 августында Казанга да килеп җитә. Буржуаз миллатчеләр «Алтай» исемле контрреволюцион газета чыгарырга җыеналар һәм Галиәсгар Камалны да шунда эшләшергә чакыралар. Ләкин ак гвардиячеләрнең революцион эшчеләрне ничек газаплап үтерүләрен һәм әлеге «алтайчы»ларның шул палачлар тирәсендә әйләнүләрен үз күзе белән күргән гуманист әдип аларның бу тәкъдимнәрен җирәнеп кире кага, гаиләсен алып Казаннан бөтенләй чыгып үк китә. Әмма озак тормыйча Казанга кире кайтса да, аклардан качып яши.

Сентябрь аенда ак бандалар Казаннан куыла. Вакытлыча тукталып торган большевистик «Эш» газетасы яңадан чыга башлый. Тәҗрибәле журналист зур энтузиазм белән шул газетада эшләргә керешә (бу газета соңрак «Кызыл көрәшче», «Эшче» исемнәре белән дә чыга). 1919—20 елның кышында, ягу-җылыту эшләре кыенлашкач, редакция Г. Камалның үз йортына күчеп эшли.

Бөек Октябрь революциясеннән соң Г. Камал газета редакцияләрендә эшләү белән генә дә чикләнми. Ул эшчеләр һәм кызыл солдатлар арасында да актив эш алып бара. Хәзерге көндә Казагыстанның Казалинск шәһәрендә яшәүче карт большевик Малик иптәш Шәрипов 1967 елның 23 маенда язган бер хатында болай ди:

«Мин Галиәсгар Камал белән 1919—1921 елларда татар запас батальонында эшләдем. Мин ул кеше белән борыннан да, соңыннан да таныш түгел. Тик гаскәр арасында агитация, пропаганда, мәдәни-агарту эшләрен башкаруда бәйләнешле булдым: бергә эшләргә туры килде.

Камаллар ага-эне өчәү иделәр: Галиәсгар, Габдрахман, Габдулла. Өчәве дә клубта, ягъни сәхнә эшләрендә эшләделәр. Габдрахман батальон клубында Казандагы татар яшьләреннән оешкан труппаның режиссеры иде. Галиәсгар, Габдулла шул труппаның артистлары иделәр. Галиәсгар Камал шактый гына яшькә килеп калса да, яшьләрдән ким түгел, бәлки артыграк активлык белән катнаша торган иде. Бигрәк тә митинг яки җыелышлардан соң спектакльләр, концертлар куйганда, үзе чыгарган критикалы яки көлкеле декламацияләрен... халык бик игътибар белән тыңлаучан иде. Ул декламацияләр минем исемдә юк. Тик бер генәсенең әзләбе исемдә:

Шоколадлар, мармеладлар, алтын, гәүһәрләр
Җәһәннәм поход пошел:
Әхмәт байлар, Мәхмүт байлар —
Алар да шунда дошел,—

дигән шикелле. Әлбәттә, ул вакытларда шоколад, мармеладларны ярлы кеше ашый алмый иде, тик байларның гына көченнән килә торган иде. Аның нигез мәгънәсе — байларның, капиталистларның дәвере җимерелде, эшче-крестьяннарның дәвере туды — дигән мәгънәне бирә иде. Халык аны бик яхшы төшенә иде...»

Малик Шәрипов иптәш үзенең хатында Галиәсгар Камал һәм аның туганнарының Тукай урамында, эшче һәм солдатлар белән бергәләп, клуб ясаулары, солдат казармаларына барып, спектакльләр һәм концертлар биреп йөрүләре хакында да яза. Бу фактлар Габдрахман Камал һәм Әнәс Камал истәлекләре белән дә раслана.

Энесе мәрхүм Габдрахман Камал аның турында болай яза:

«Классик образлар тудыруда бик нык эшләде. Шиллерның «Юлбасарлар» трагедиясендә Патер, «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә музыкант Миллер, Максим Горькийның «На дне» драмасында Актер ролен тиңдәшсез башкара иде. Бу бөек драматургларның образларын сәхнә аша гәүдәләндерер өчен, аларның бөтен әсәр-

[1] Кайбер истәлекләрдә аның «Кызыл байрак» газетасында эшләве хакында да әйтелә. Ләкин без моны раслый торган документка очрамадык.

ләрен укып чыкты. Әсәрнең куелышы турында ясалган тәнкыйтьләрне эзләп тапты, аларны җентекләп тикшерде, аларда күрсәтелгән кимчелекләрне үзе эшли торган образларда булдырмаска тырышты. Аны өчен кирәк булган вак бутафория нәрсәләрен, вак детальләрне өеннән үзе әзерләп алып килә дә, аларны иптәшләргә күрсәтеп йөреп, балаларча шатлана иде...»

1920 елларда Казанда берничә татар театр труппасы эшләп килә. Шулардан «Аң» труппасына «Беренче күргәзмә дәүләт татар драма труппасы» дигән исем бирелә. «Татарстан» һәм «Крестьян газеты» редакцияләрендә эшләү белән бергә, Г. Камал профессиональ артист булып ике ел элеге труппада эшли, шул ук вакытта эшче районнарындагы клуб сәхнәләренең эшенә дә катнаша. Гомеренең соңгы ике елында Г. Камал Казан мех комбинатының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшли. Эшче яшьләрдән мех комбинаты клубы өчен труппа оештыра.

Сәнгать, билгеле булганча, матур һәм ямьсез, бөек һәм түбән, трагик һәм комик күренешләр хакында сөйләп, кешедәге иҗади омтылышны үстерә, аны уйларга өйрәтә. Матур һәм ямьсезлек, бөеклек һәм түбәнлек, трагизм һәм комизм — сәнгатьнең бу төп сыйфатлары үз чиратында чор, социаль тормыш шартлары белән тыгыз бәйләнгән. Г. Камал сәнгатьнең шул бәйләнешен тирән аңлады һәм үзенең каләмен, театр һәм клуб сәхнәләрен менә шул яңаны, матурны яклап, ямьсезне, искелекне тәнкыйтьләү эшендә, социализм тормышы төзүне пропагандалау эшендә искиткеч осталык һәм гаҗәп бер тырышлык белән файдаланды. Г. Камалның иҗатын бер-берсенә бик якын торган ике жанрга бүлеп карарга кирәк: 1) тезмә яки чәчмә формада язылган инсценировкалар; 2) пьеса формасында язылган, ләкин шул ук инсценировкаларга якын драма әсәрләре. Бу ике төрдән тыш, тагын комедия жанрында язылган әсәрләре бар.

Гражданнар сугышы чоры — безнең ил тарихында чиксез әһәмиятле көрәш һәм борылыш дәвере. Бу чор турында бүгенге көндә дә зур-зур романнар языла һәм киләчәктә дә язылыр. Үз заманы белән бер эздән барган Галиәсгар ага гражданнар сугышы чоры һавасы белән сугарылган беренче әсәрләрне тудыручы һәм шул һаваны массага җиткерү юлында эшләүче беренче активистлардан булды. Идел-Урал буйларында гражданнар сугышы активлашуны ак чехословак солдатлары һәм «учредительное собрание комитеты» дип йөртелгән оешма тирәсендәге акгвардиячеләрнең Казанга керүләреннән башларга мөмкин. Галиәсгар Камалның Октябрьдан соңгы революцион эчтәлекле беренче шигырьләре исә нәкъ әнә шул вакыйгаларга карата языла да.

Бер заман Казанга чехлар керде,
«Большевиктан коткарабыз сезне»,— диде,
Бу сүзгә байларның бик кәефе килде,
Бундин артык тәкый гаҗәп дынлари бар.

«Тәкый гаҗәп яки ахры заман» исемле кечкенә күләмле тезмә әсәргә ияреп язылган бу озын шигырендә Г. Камал ак чех һәм ак офицерлар, шулай ук элекке байлар кулы белән эшләнгән җинаятьләр хакында сөйли, бик оста һәм шул заман кешесенә бик аңлаешлы итеп, Кызыл Гаскәр басымы астында, аларның Казаннан ничек качуларын әйтә.

Халык арасында күп таралган борынгы әдәбият үрнәкләре, бигрәк тә тезмә әсәрләр, формасына ияреп сатирик һәм юмористик әсәрләр язу безнең әдәбият өчен яңа нәрсә түгел. Без моны Г. Тукай һәм башка әдипләрнең 1905—06 елларда язган тезмә әсәрләрендә, шулай ук 1908—10 елларда чыга башлаган «Яшен» һәм «Ялт-Йолт» кебек сатирик журналларда урнаштырылган төрле характердагы әсәрләрдә күп очратабыз. 1918 елда Г. Камал электән килгән шул гадәтне тагын кузгатып җибәрә һәм, «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Алма китабы», «Хакка шөкер китабы» кебек әсәрләрдәге аерым шигырьләрнең форма төзелешеннән файдаланып, күп кенә шигырьләрен яза. Ул бу елларда халык җырларына ияреп тә яңа шигырьләр иҗат итә. Мәсәлән:

Байлар киде каракул,
Эшче киде эшләпә;
Бай аһ ора, ярлылар шат,
Менә Совет нишләтә!

Бу жыр революциягә чаклы болай жырлана иде:

Байлар кия каракул,
Без киябез эшләпә;
Ходай бәхетне бирмәсә,
Баеп булмый эшләп тә.

Күрәсез, Г. Камал халык жырында чагылыш тапкан социаль тигезсезлек мотивларын үткән заманга, революциягә чаклы чорга кайтарып калдыра да, Совет власте җиңгәч, ярлы катлауның шатлануы, ә байларның «аһ оруы» турында яза. Арада «Матур яр кенәри», «Җизнәкәй», «Сандугач-күгәрчен», «Бию көе» дип йөртелә торган халык көйләре үлчәвендә, шулардагы ритм һәм рифманы файдаланып язылган революцион эчтәлекле шигырьләр дә бар. Бу да Г. Камал иҗатындагы халыкчанлыкның бер күренеше.

Мең еллар буена изүчеләр өчен эшләп килү күпмедер дәрәҗәдә кешеләрдә хезмәткә нәфрәт белән карау хисе дә тәрбияләгән, һәм ул хис аларның «канына сеңгән иде». Владимир Ильич Ленин әйткәнчә, Советлар дәүләте шул материал, алпавытлар җәмгыяте, капиталистлар җәмгыяте тарафыннан гасырлар буе гарипләндерелгән шул кешеләр, шул материал ярдәмендә яңа, социалистик җәмгыять төзәргә тиеш иде, чөнки бүтән көч, бүтән материал юк иде. Моның өчен кешеләрнең күз алдына ике тормышны — иске һәм яңа тормышны китереп куярга, шул юл белән искегә нәфрәт тудырырга кирәк иде. Моның өчен кешеләрнең аңыннан ялкаулыкны, прогул, исереклек кебек капитализм калдыкларын һәм әшәке гадәтләрне кысрыклап чыгарып, хезмәтнең дан эше, шөһрәт эше, батырлык эше икәнен төшендерергә кирәк иде. Бөек Октябрь революциясе булу белән Советлар дәүләте алдына бу җаваплы бурыч бөтен тулылыгы, зурлыгы, әһәмияте белән килеп басты. Карт әдипнең социализм төзү эшенә керткән иң зур, иң кыйммәтле өлеше шунда: ул үзенең бөтен иҗат көчен әнә шул чиксез зур бурычны үтәү эшенә җикте. Монда ул элеккедән килә торган әдәби традицияләргә дә таянды: искегә яңаны каршы куя белде. Ләкин аның революциядән соңгы яңасы — либераль юнәлештәге кешеләр, ә искесе — наданлык, фанатизм эченә чумып, шунда катып калган Кәрим бай, Хәмзә байлар гына түгел иде инде. Аның яңасы — социалистик җәмгыять төзү өчен удар темп белән эшләүче актив эшчеләр, ә искесе — миләреннән капитализм калдыгы чыгып өлгермәгән ялкаулар, прогулчылар, исерекләр иде. Менә шул ике төркемне ул массалар өчен бик тә аңлаешлы картиналарда, тип һәм образларда клуб сәхнәләренә китереп куя белде.

Г. Камалның Октябрьга чаклы язылган әсәрләрендә, аеруча, «Яшен» журналында басылган әйберләрендә, дин башлыкларыннан, аларның комсызлыкларыннан көлү мотивлары көчле иде. Аның театр өлкәсендәге эшчәнлеге дә үз заманында диннән көлү, дин бозу дип каралган иде. Октябрьдан соң дингә каршы көрәштә ул комедия жанры кулланды.

«Могҗиза» исемле комедиясендә дингә ышанучы карт буын белән дин сөременнән азат яшь буын алына. Нәфисә, Мәрьям, Мәгъри исемле карчыклар «холхоз»ның барлык начарлыкка сәбәп булуы, шуның аркасында алланың каһәре төшүе турында сөйлиләр. Боларга яшь кыз Рокыя образы каршы куелган. Әсәрдә әлеге карчыклар, үзләренең наданлыклары сәбәпле, көлкегә калалар.

1929—31 елларда язылган «Тәкыйгаҗәп яки ахыр заман» исемле өч пәрдәлек комедия-инсценировка түбәндәге шигъри өзек белән башлана:

Замана ахыры җитсә, ниләр булгай,
Дөньяга төрле-төрле бәла тугай,
Галимнәр, чагыр эчеп, зина кылгай,
Мондыйн артык тәкый гаҗәп дыңларый вар.

Беренче пәрдә Октябрьга кадәрге чорга карый һәм әлеге елларда әйтелгән сүзләрне җанлы күренешләр аша иллюстрацияләп күрсәтә. Сәхнәдә яшерен фәхешханә күренеше. Катнашучылар: мулла, мәзин, сукыр карый, мөрит, бай-бәтчә, сәүдәгәр, гармунчы егет, фәхешханә тотучы хатын Нәгыймә, фахишә кызлар. Өстәлдә аракы, сыра... Менә бервакыт фәхешханәгә шул мәхәлләнең байлары килеп чыгалар һәм ишек кага башлыйлар. Мулла да, мәзин дә, карый да аптырап калалар. Мәхәллә

байларына бу кыяфәттә күренү куркыныч, ә байлар һаман ишек кагалар. Мулла әшне тиз генә җайлап ала: биленнән сүтеп, чалманы башка чолгый, аракылар җыелып алына, идәнгә урын әзерләнә һәм эчке мәҗлесе никах мәҗлесенә әйләнә. Фахешханә тотучы Нәгыймә, янәсе, әлеге бай-бәтчәгә кияүгә чыга да, мулла шуларга никах укырга килгән булып чыга. Бу хәлгә хәтта байлар да аптырап кала.

Икенче һәм өченче пәрдәдәге күренешләр һәртөрле контрреволюцион элементларның советка каршы көрәш оештырырга йөрүләрен фаш итүгә багышланган. Монда ишан да, буржуаз милләтче инженер, адвокат, шагыйрь, байлар, генерал һәм офицерлар, поплар да бар. Комедия барлык контрреволюционерларның, барлык кара көчләрнең хурлыкка калулары белән тәмамлана.

Инсценировка калыбында язылган «Өч тормыш» исемле бер пәрдәлек пьеса өч күренештән тора. Беренче күренештә капитализм чорындагы эшчеләр тормышы, икенче күренештә шул чордагы байлар тормышы һәм хезмәт ияләренең бер-берсенә мөнәсәбәте күрсәтелә, өченче күренеш исә Бөек Октябрьдан соңгы эшчеләр тормышын сурәтләүгә багышланган. Әсәр гадәттәге пьесалардан шактый аерыла. Монда «алып баручы» (резонер) да кертелгән. Ул һәр күренеш алдыннан сәхнәгә чыгып, бу күренештә нәрсә турында сөйләнә-күрсәтеләсен әйтеп бара. Алып баручыны кертеп, Г. Камал үз әсәрләрен гади тамашачыга аңлаешлырак итәргә теләгән булса кирәк. Әсәрдә тирән һәм тулы эшләнгән характерлар юк диярлек. Ул, эшче һәм хуҗаларның төрле социаль шартларда ничек яшәүләрен күрсәтү аркылы, революциягә мәхәббәтне көчәйтү теләге белән язылган.

Борынгы әдәбият үрнәкләреннән файдаланып язылган сатирик әсәрләрнең бер үрнәге итеп «Җан Таһир белән Җан Зөһрә» исемле комедиясен күрсәтергә мөмкин.

Татар драматургиясендә музыкаль әсәрләр соңрак мәйданга килделәр. Аларның беренче һәм хәзергә чаклы сәхнәдән төшмичә уйналып килгәне — Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» әсәре. Г. Камалның 1923 елда язылып, 1929 елда басылган «Хафизалам иркәм» исемле 4 пәрдәлек комедиясе дә шундый типтагы әсәрләрнең берсе. Әсәрдәге конфликт урта хәлле крестьян егете Хафиз белән кулак малае Кәрим арасында бара.

Хафиз Хафизә исемле эшчән кызны ярата, алар бергә тормыш төзәргә уйлыйлар. Кәрим дә Хафизәне үзенә каратырга тырышып йөри. Кәрим тирәсендә бүтән егетләр дә бар. Алар — кулак егетенең әче балы белән симез казына сатылучылар.

Хафиз — саф күңелле, эшчән егет. Аның иптәшләре дә шундыйлар. Алар Кәримгә, кулак булганы өчен, сыйнфый ачу саклыйлар. Үзенең байлыгына, сатлык егетләрнең ярдәменә таянып, Хафизны юк итәргә җыенса да, Кәрим үзе казыган базга үзе килеп төшә. Чөнки инде дөньялар үзгәргән, кулакның көче сындырылган. Шуңа күрә Хафиз белән Хафизә инде, Галиябану белән Хәлил кебек, һәлак булмыйлар.

Г. Камал Октябрьның беренче елларында, оригиналь әсәрләр язу белән бергә, тәрҗемә эшләрен дә дәвам иттерә. 1918 елның январь аенда төрек әдәбияты классигы Габделхак Хәмиднең «Һинд кызы» исемле драмасын, шул ук елның февраль башында «Кара пәрдә» («Билгесез хатын») исемле әсәрне тәрҗемә итә. 1919 елның 7 мартында Казан сәхнәсендә беренче тапкыр «Эшчеләр бистәсе» (Карповтан тәрҗемә) уйнала. Шул ук елда Испания әдәбияты классигы Лопе де Веганың «Сарык чишмәсе» исемле әсәрен тәрҗемә итеп сәхнәгә куйдыра.

Билгеле, Г. Камалның бу елларда язган шигырьләре, сәхнә әсәрләре хәзерге заман таләпләренә тулысынча җавап биреп бетермәскә дә мөмкин. Әмма эчтәлекләре, күтәргән иҗтимагый проблемалары ягыннан Г. Камалның Бөек Октябрьдан соң язган әсәрләренең кыйммәтләре әле югалмаган. Чөнки ул әсәрләрне тудырган сәбәпләр (эш планнарын үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәш, исереклек, прогул, эшка салкын карау, төрле дини уйдырмаларга ышану кебек начар күренешләргә каршы, антисоциалистик чыгышларга каршы кискен көрәш, массаларны социализм рухында тәрбияләү h. б.) бүген дә үзләренең актуальлекләрен саклыйлар.

Галиәсгар Камал безнең әдәбият тарихында реализмның көчле вәкиле, комедия остасы булып танылды. Г. Камал реализмы, күпләр уйлаганча, иске тормышның искелек калдыкларын тәнкыйть белән генә чикләнми. Ул бер үк вакытта яңаны, алга таба үсешне, гуманизмны ялкынлы яклаучы да. Аның тәнкыйте һәрбер чорда, революциягә чаклы да, революциядән соң да, искелеккә һәм аның калдыкларына юнәлгән булса,

позитив программасы яңалыкны яклауга һәм үстерүгә юнәлде. Аның һәр ике чорда язган әсәрләре конкрет фактлар һәм реаль тормыш җирлегендә конкрет шәхесләрнең эш-хәрәкәтләрен типиклаштыру рәвешендә барды. Аның комизмы кайбер очракта көчле сатира, ә кайберләрендә җиңелчә юмор төсен алды. Совет чорында язылган әсәрләрендә социалистик реализм, социалистик мөнәсәбәтләрнең өстенлеген раслаучы метод аның иҗат методы булды. Әлбәттә, Г. Камал язган елларда, кешеләрнең аңыннан капитализм, хәтта феодализм калдыкларын кысып чыгару өчен кискен көрәш барган чорда, тәнкыйть һәм фаш итү социалистик реализм методы белән язылган әсәрләрнең дә аерылгысыз бер сыйфаты булды.

Г. Камал әсәрләрендә бик күп төрле типлар, характерлар гәүдәләнде. Үзенең типларын иҗат иткәндә, аларның тышкы кыяфәтләренә дә, эш һәм кыланышларына да, сөйләү манераларына да ул бик нык әһәмият бирде. Шуңа күрә дә ул безнең әдәбият тарихында татар драматургиясенең телен тудыручы итеп танылды. Ул драма әсәрләрен сәхнәдә реальләштерүче артистлар телен дә бик зур игътибар белән күзәтеп барды. Үзенең бер мәкаләсендә: «Татар театрларында уйнаучыларның күбесендә телгә саксызлык күренә. Бу эш гафу ителергә тиеш түгел... Шуның өчен мин күп артист вә артисткаларга карт бер язучы булуым сыйфаты белән самими рәвештә шул киңәшне бирер идем... «Театр эшенә ничек сөйләсәң дә, нәрсә сөйләсәң дә ярый, бары тик тукталып кына калма диган карашны күптән ташларга вакыт»,— диган иде («Эш» газетасы. 1919 ел. 158 сан).

Кеше язмышы, кеше рухы өчен бөтен дөнья күләмендә үткен һәм кискен көрәш дәвам итә. Озакка, гасырларга сузылган көрәш бу. Аның нигезендә социаль гаделлек белән гаделсезлек, гуманизм белән антигуманизм арасындагы кискен каршылык ята. Г. Камал һәрвакыт менә шул көрәштә гаделлекнең, гуманизмның, бөек кешелеклелекнең кара, явыз көчләрне җиңүе ягында булды, шуңа күрә без аны гуманист әдип дип атыйбыз.

**Хәй ХИСМӘТУЛЛИН,**
филология фәннәре кандидаты.

# ҮЛЕМ ТУРЫНДА УЙЛАМА...



**Шагыйрьнең кемнәр белән мавыкканын, кемнәрне күбрәк яратканын беләсең килсә, аның китапханәсенә күзең төшер. Фатих Кәримнең Казандагы квартирасы... Китап шкафы, китаплар. Байрон, Лермонтов, Такташ... Шунда ук үзенең өч томы. Ачам, укыйм:**

һәр шагыйрьнең бер алласы була,
Мин дә шагыйрь, табынам бераугә:
Табына торган аллам — Байрон минем,
һәм Лермонтов — минем пәйгамбәр.

**Болар кайбер шагыйрьләрчә кыланып, аларга охшарга тырышып кына әйтелгән юллар түгел. Фатих Кәрим бу өч шагыйрьне бөтен рухы белән ярата иде. Бигрәк тә аның Бөек Ватан сугышы елларында иҗат иткән лирик шигырьләрендә, баллада һәм поэмаларында шул өч шагыйрьнең кайсыдыр якларын искә төшереп, хәтерләтеп торган нәрсәдер бар. Нәрсә ул! Мин шуны эзлим, табарга, тоярга телим. Ә ул өстә күренеп ятмый, шагыйрьнең җанында, фидакарьлегендә, гражданлык сүзендә...**

**Фатих Кәрим әдәбиятка 1926—27 елларда — Һади Такташның татар совет поэзиясендә иң шаулаган чорында килеп керә һәм ул Такташтан аерылмый. Ватан сугышында да аннан аерылмый.**

Бар шагыйрьләр тавышын бергә җыеп,
Мин команда бирәм, тыңлагыз.
Снарядлар, Такташ җырларының
Нәфрәтләре булып чыңлагыз!

**Такташ! Үз артыннан ничаклы талантларны иярткән, аларны икенче чорларга чыгарып калдырган. Алар Такташка лаек булдылар, акладылар.**

**Фатих Кәрим бераз негрга тартым. Тырпаеп торган кара чәч, керпе чәч. Биографиясе аның болай бер караганда әллә ни катлаулы да түгел шикелле. Ул элекке Уфа губернасы, Бәләбәй өязе, Ает авылында туа. Татар, башкорт халкының борынгы озын җырлары белән дан тоткан Дим буе... Шагыйрь үзенең 1944 елда язган кыска гына автобиографиясендә әдәбиятка ничек килүе турында да әйтеп узган. «...Әдәби әсәрләр язу теләге бала чагымнан ук йөрәгемә кереп урнашты. Егет чагыннан ук тома сукыр әтиемнең үзе өчен язган шигырьләрен безгә укыштыргалаганын ишетү, анам Мәрьямнең үз дәфтәренә Дим буе табигатен тасвирлап язган күп кенә шигырьләрен башкалардан яшереп миңа гына укуы, революция еллары башлангач, абыем**

ярлы Кәримнең матбугатта чыгып барган шигырьләрен уку — болар минем әдәбият өлкәсенә табан юнәлеш ясавыма төп һәм башлангыч этәргеч булдылар...»

Шагыйрь ярлы Кәрим. Гражданнар сугышы чорында исеме шактый таралган шагыйрьләрнең берсе. Халык үзе дә ярлы, шагыйре дә ярлы.

Фатих Казанда Җир төзелеше техникумында укый. Җирне яңа баштан корырга кирәк, халыкны икмәкле итәргә, кайгысыз итәргә кирәк. Шагыйрь һәм җир төзүче... Икесе дә җир белән эш итә, икесе дә бер үк җиргә, ата-бабалардан килгән борынгы җиргә таяна...

Поэзиягә беренче адымнар, беренче җыентык... Шуннан бер-бер артлы яңа шигырьләр, яңа поэмалар. Поэмаларның исемнәреннән үк чорны танып була. Урал эшчеләре тормышыннан «Җиденче мич», авылда колхоз хәрәкәтенең беренче елларын тасвирлаган «Тавышлы таң», пограничникларның батырлыгын җырлаган «Аникин» һ. б.

Биографиясе аның бер караганда катлаулы түгел шикелле. Ләкин бу бер караганда гына шулай. Фатих Кәрим дә шәхес культының корбаны була язды, әдәбияттан берничә ел аерылып торды... Аннан инде Бөек Ватан сугышы. Ул — сапер, ул — разведчик, ул — взвод командиры.

Иделдән алып Балтика ярларына чаклы сузылган ара солдат өчен җиңел булмады. Ул мең үлем, мең батырлык сорый торган ара.

Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде...

Казанда, Казан музеенда аның пулялардан тишкәләнгән шинеле, фронтта шул шинель җылысында язылган шигырьләре саклана...

Аңа утыз алты яшь иде. Ә Муса Җәлилгә — утыз сигез яшь. Шагыйрь өчен зур гомерме ни ул! Нәрсә соң ул зур гомер! Алар узган юл ничек кенә авыр, үкенечле булмасын, мин аларның язмышларын көнлим.

Биектә сез, анда менәр өчен
Шактый гайрәт кирәк, көч кирәк,
Сезнең язмышны мин көнлим хәзер,
Торган саен көнлим көчлерәк.

Шагыйрь булып, солдат булып көнлим,
Безнең куллар бергә ут ачкан...
Бүленми ян, сүрелми ян икән,
Бер генә ян икән тоташтан...

Бер вакыт шулай Чаллы район китапханәсендә үткәрелгән укучылар конференциясендә олы яшьтәге бер апаның «Сезнең әсәрләр үз артларыннан безнең гомерләрне нярта» дигән сүзләрен ишетеп мин гаҗәпсенгән идем. Әдәбиятка гомер нярә. Муса Җәлилләр, Фатих Кәримнәр язмышы — шундый бәхетле язмыш.

Тоташтан яну. Бөтен шагыйрьләр дә тоташтан янамы! Юк. Бу фәкать чын шагыйрьләргә генә хас сыйфат. Фатих Кәримнең иҗатының башында ук Байрон, Лермонтов, Такташлар рухында алынып китүендә үк аның шагыйрь буларак характерын билгели торган шигъри сер, рух ята. Олы йөрәкле шагыйрьләр. Аларның гомерләрендә мин заманның утларын-ялкыннарын күреп калам. Аларның язганнары үзләре эшләгән батырлыкка туры килә. Бу шагыйрьләрнең әсәрләре дә көрәш кискенләшкән чакта үзләре кебек алгы сызыкка чыгалар. Халык шул шагыйрьләрнең әсәрләрен эзли башлый, шуларга тотына.

Муса Җәлилне дә, Фатих Кәримне дә Бөек Ватан сугышы зур шагыйрь итте. Поэзия тавының алар икесе ике ягыннан күтәрелделәр...

Ә сугышка кадәр! Сугышка кадәр дә алар әйбәт шагыйрь. Китаплары басыла, үзләренең укучылары бар, актив җәмәгать эшлекләре. Аларның олы поэзиягә юл яруларына берәү дә шикләнми. Ләкин укучы әле аларның киләчәгенә күбрәк өмет баглый иде. Менә мин хәзер аларның иҗатына чирек гасырдан соң яңадан күз те-

шерәм. «Җиденче мич», «Яшен яктысы», «Тавышлы таң», «Аникин» — үз вакытында шактый шаулаган, тәнкыйтьчеләрне җәлеп иткән әсәрләр. Шулар белән мин «Идел егете», «Үлем уены», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Өмет юлдызы» кебек поэмаларны, «Тимер һәм тимерче» турында балладаларын янәшә куеп карыйм. Сугышка кадәрге әсәрләр белән сугышта туган әсәрләр арасындагы аерманы әзлим. Бу урында әзлим дип әйтү урынсыз. Ул аерма просто кычкырып тора. Шагыйрьнең шагыйрьлеге нәрсәдә икәнен белү өчен шушылай чагыштыру кирәк. Сугышка кадәрге шигырьләр... Аларда шул чорның көндәлек вакыйгалары: Германия комсомолына хат, Америка пионеры Гарри Айзманны яклап язылган шигырь, яшьлек, мәхәббәт... Шигырьләр бар да бик актуаль, тигез, әйбәт. Барысын да мөмкин кадәр теркәп калырга омтылу сизелеп тора. Хистән бигрәк факт үзе күзгә бәрелә.

Шагыйрьгә әйбәт булу гына җитми, күрәсең. Нниндидер уртачалык. Шагыйрь моны үзе дә сизенә, ләкин шушы ноктадан югары күтәрелер өчен аңа нинди илаһи көч кирәк!

Фатих Кәримнең «Моң һәм көч» исемле шигыре бар.

Җырның көче — ярсу, хыялый моң,
Ул моң кайнап чыга йөрәктән...

Моң кайнап чыга. Шагыйрь үзен кысып торган тар рамканы вата, кинәт ачыла, хисләр дөньясы зурая, ул ун-унбиш ел буена таба алмаганнарын ике-өч ел эчендә биреп ташлый...

Бездә әле моң сүзеннән куркучылар да күп, әйтерсең, ул бары төшенкелекне генә аңлата. Ә мин моң төшенчәсен билгеле бер халыкның узган юлы, тарихы, җиреннән әзлим. Аны шул төшенчәләрдән аерып булмый. Фатих Кәримдәге ярсу, хыялый моң Бөек Ватан сугышы чорында шулай ташый башлый икән, гаҗәп түгел, чөнки ил язмышы, халык язмышы — шагыйрьнең җаны аша уза.

Авыр чорда халкың: «Улым!» — дисен,
«Таянычым!» — дисен Туган ил.

Фатих Кәрим сугышка кадәр үк формалашкан, дөньяга карашы нык булган талантлы шагыйрь иде. Аның озак вакыт хәзерләнгән рухи көче ачылып, җәелеп китү өчен бары моментны гына көткән. Шәхес, шагыйрь үзен зур бәрелешләрдә таба. Сугыш, фашизмга каршы көрәш совет шагыйре алдында я үлем, я җиңү дигән нәрсәне куйды. Шагыйрь үзенең бөтен ихтыяр көчен туплады, җире, тарихы, халкы исеменнән алгы сызыкка басты. Халыклар язмышы белән бәйле вакыйгаларның эчендә турыдан-туры үзең катнашудан туган хисләрне, кичерешләрне нәрсә алыштыра алсын! Шагыйрьнең әсәрләрен урталыктан бөеклеккә күтәргән тере илаһи көч менә шунда. Шагыйрь үзе тарихны тудыручыга әйләнә.

Мин рядовой солдат бу сугышта,
Тик бер нәрсәм белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.

Шагыйрь җыр яза. Вакыт шундый тар... Ул — сапер, һөҗүмгә баручыларның алдында үрмәләп, миналарны ерып, тимер чыбыкларны кисә, юл сала...

Вакыт шундый тар... Ул разведчик, «тел» кирәк, нинди генә юл белән булса да тап, алып кайт, дошманның планнарын ач... Шунысы гаҗәп: шагыйрьнең язу активлыгы бермәбер арта. Уйлаган поэма, иезләгән шигырь, «Разведчик язмалары» да шул тыгыз арада туа. Мин үзем дә фронтта булдым, алгы сызыкта шигырь язар өчен нинди шартлар барлыгын бик яхшы беләм. Татар поэзиясендә Муса Җәлилдән кала Фатих Кәрим кебек батырлык эшләгән яңадан бер генә шагыйрь да юк. Ул һәрвакыт Муса Җәлил белән рәттән басып тора торган, янәшә атлап бара торган шагыйрь. Фатих Кәрим куләгәдә калып килә, аның Ватан сугышы чоры лирикасы «Моабит дәфтәре»ндәге шигырьләрнең дәвамы, алар кайдадыр бергә кушылалар, бергә яңгырый башлыйлар, гомерләре бер.

Шагыйрь образы. Төрле шагыйрьне төрлечә күз алдына китердем мин. Такташны давыллы елларның уйчан шагыйре итеп, таң алдында кайдадыр сөялеп, еракка карап торган хәлдә. Туфанны чор аша узып баручы юлчы итеп... Муса Җәлил... Элек кечкенә генә чана тартып, авылдан авылга йөреп, китап сатучы кешеләр була торган иде. Урта буйлы кеше. Ишектән керә, ягымлы, көләч, китапларын җәеп сала, кайберләрен укып күрсәтә... Буранда тагын каядыр кереп югала. Нигә шулай күз алдына китерәм! Бәлки бу минем биографиямнең бер фантазияседер, белмим, аңлатуы читен...

Фатих Кәримнең «Тимер һәм тимерче» балладасы бар. Шагыйрь кара тәреле танкка колхоз тимерчесен каршы куя. Тимер тавы тимерчегә бәрелеп, җирне таптаудан туктый.

Сулый Саттар танк янында,
Гүя аны өреп яндыра...

Ничектер шушы тимер тавын чәлпәрәмә китергән баһадир тимерче образы шагыйрь образы белән бергә кушыла. Шагыйрь образы романтик бер төскә кереп, зурая, үзе генә торып кала. Утны шагыйрь дөрләтә. Танклар арасында чүкеч чыңлый, мин шагыйрь җырының шунда чыңлаганын ишетәм. Шагыйрь халык белән кушыла. Шагыйрь, минемчә, шушындый вакытта үзен иң бәхетле кеше итеп тоя, күңелдә һәртөрле икеләнүләр беткән, аның гомере ил язмышында, гомере аның ничектер сизелмичә генә җырга әйләнеп бара, взводындагы солдатлар җырын аның күтәреп алалар:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була...

Фатих Кәрим шигырьләренең искиткеч якты тагын бер ягы бар. Сез аларда шагыйрьнең үз тормышыннан гомумән әз генә булса зарлану, әз генә булса да кемгәдер үпкә белдергән мотивларны һич тә таба алмассыз. Саф алар, оптимистик алар, яшәргә, көрәшергә чакыручы шигырьләр. Рус теленә тәрҗемә иткәннән соң русның күренекле шагыйре Ярослав Смеляков та ул әсәрләрнең көчен танырга мәҗбүр булды һәм ул Фатих Кәримгә багышлап иң матур шигырьләренең берсен язды.

Фатих Кәрим Ватан сугышы бетәр алдыннан, 1945 елның 19 февралендә, Кенигсберг янында батырларча һәлак булды. Бер уйласаң, аны миллионнар арасыннан табып алу мөмкин булмаган хәл. Кабере аның билгесез иде. Ләкин тереләр сугышта гомерләрен биргән солдатлар турында һәрвакыт кайгыртalar. Балтик фронтында хезмәт итүче яшь моряклар татар шагыйренең каберен эзләп таптылар, исемен язып, каберенә мәрмәр такта куйдылар, тере чәчәкләр тезделәр. Флотка җырларын соратып алдылар. Җырлары аның үзе кебек халыкка тугры хезмәт итә.

Сибгат ХӘКИМ

**Үзбәк Байчура,**
*филология фәннәре докторы*

# ӘДӘБИ ТЕЛЕБЕЗ ҺӘМ ЯҢА ЛИНГВИСТИК ЫСУЛЛАР

*Фән, математикадан файдаланырга өйрәнгәч кенә, камиллеккә ирешеп җитә.*

*К. МАРКС*

Тарихи яктан якын килеп, сүзләрнең төп мәгънәләрен исәпкә алганда, әдәби тел төшенчәсе беренче чиратта киң мәгънәдә әдәбият телен, язу телен белдерә, дип әйтә алабыз[1]. Ләкин, язма формасыннан башка, әдәби телнең сөйләм формасы да бар: соңгысы сәхнәдә, радио-телевидениедә, мәктәпләрдә кулланыла, көндәлек тормышыбызда аралашу чарасы да булып тора[2]. Эчтәлеге ягыннан исә әдәби тел халыкның материаль һәм рухи культурасын чагылдыра, халыкның җанлы тарихы һәм зур байлыгы була. Чыганагы ягыннан әдәби тел, кагыйдә буларак, халык сөйләменә нигезләнә. Тик сирәк очракларда (мәсәлән, теге яки бу халыкны читләр яулап алганда) эш башкаручыларның — яулап алучыларның — бер телдә, ә халыкның икенче телдә сөйләшүе мөмкин.

Ләкин әдәби тел халык сөйләменә турыдан-туры нигезләнми. Әдәби тел ул — күп буын укымышлылар тарафыннан эшкәртелгән, билгеле дәрәҗәдә, әйтергә мөмкин, халык сөйләме нигезендә укымышлылар тарафыннан яңа баштан иҗат ителгән тел. Рус әдәби теле, барыннан да элек, Пушкин, Толстой, Чехов һәм башка классик әдипләр теле булган кебек, татар әдәби теле дә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Камал, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, М. Җәлил, Н. Исәнбәт һәм башка язучылар теле була. Әмма матур әдәбият теле әле гомуми әдәби телнең бер өлеше генә. Моңардан тыш аның фән, сәнгать, политика, экономика һәм башкаларга караган күп яклары бар. Аларны да исәпкә алырга кирәк.

Тамырлары халык сөйләмендә булса да, сүзлек составының һәм грамматик формаларының байлыгы ягыннан әдәби тел халык теленнән, диалект һәм жаргоннардан нык аерыла, алардан күп өстен тора. Моны шуннан да күрергә мөмкин: әдәби телнең диалектларда һәм халык телендә бөтенләй булмаган махсус өлкәләре бар. Мәсәлән, математика, астрономия, химия һ. б. телләре... Бу өлкәләрдә, шул телнең борын-борыннан килгән үз сүзләреннән тыш, башка чит телләрдән алынган терминнар да, әлеге телнең үз чаралары ярдәмендә ясалган сүзләр дә гаять күп очрый. Диалектларда һәм халык телендә исә андый специаль сүзләр юк дәрәҗәсендә аз була. Шуңа күрә, әдәби телне белү өчен, берәр фән яки һөнәрне өйрәнгән кебек үк, аны өйрәнергә кирәк.

---

[1] Латинча «littera» сүзе дә «хәреф» мәгънәсен белдерә һәм шул мәгънәдә ул рус һәм башка күп кенә телләрдә кабул ителгән; русча «литература» термины да шул ук латин сүзеннән ясалган.

[2] Шуңа күрә немецларның әдәби телне «Bühnesprache» дип, ягъни «сәхнә теле» дип атаулары һич тә нигезсез түгел.

Инде әдәби тел белән халык телен якынлаштыру мәсьәләсенә килик. Үз вакытында бу хакта төрле фикерләр әйтелде. Кайбер авторлар, мәсәлән, әдәби телне өйрәнү урынына, аны үзенә якын булган бер диалектка яки сөйләшкә, әйтик, Ульянов өлкәсендәге Мәләкәс, Саратов өлкәсендәге Хвалын, Татарстандагы Чистай районы сөйләшләренә якынайтып үзгәртергә тырышып карадылар. Икенчеләр территориаль яки этнографик принциплардан түгел, бәлки социаль яктан чыгып эш алып бардылар һәм әдәби телне халыкның әзрәк укыган катлаулары сөйләменә якынайтып үзгәртергә тәкъдим иттеләр. Әлбәттә, бу соңгы караш та фәннилектән бик ерак тора. Әдәби тел белән халык телен якынлаштыру халык сөйләмен мөмкин чаклы әдәби тел дәрәҗәсенә үстерү юлы белән алып барылырга тиеш. Әгәр телебезне татарча укымаган кешеләр сөйләме дәрәҗәсенә төшерергә, артка чигендерергә юл тотсак, ул чакта без, кайчандыр пролеткультчылар тәкъдим иткәнчә, күп гасырлар буе эшкәртелеп килгән әдәби телебезне дә, гомумән татар телен дә әкренләп юкка чыгаруга алып барачакбыз.

Әмма без, андый тәкъдимнәрнең «фәнни кыйммәте» ни дәрәҗәдә булуына тукталып тормастан (аның кирәге дә юк), шуны әйтергә тиешбез: әдәби телне фәнни нигезләп үзгәртүдән элек (әгәр бу гомумән мөмкин эш булса әле), аны, ягъни әдәби телне, өйрәнергә, фәнни тикшерергә кирәк, дибез. Ансыз әдәби телнең яңа (үзгәртелгән) вариантының элекке (үзгәртелмәгән) вариантыннан яхшырак булу-булмавын да фәнгә нигезләп исбат итә алмабыз. Ә инде әдәби телне, аның төрле якларын һәм тармакларын бөтен тулылыгы белән фәнни тикшерү өчен, төгәл һәм объектив лингвистик ысуллар зур ярдәм итә алалар. Ул гына да түгел, түбәндә күрсәтелгәнчә, хәзерге чорда тел белеменең бик күп мәсьәләләре яңа ысуллардан башка хәл ителә дә алмый.

Яңа лингвистик ысулларны башлыча өч төркемгә бүләргә мөмкин: 1) инструменталь-фонетик, ягъни физик-техник һәм физиологик ысуллар; 2) статистик-комбинатор, ягъни математик ысуллар; 3) инженерлык лингвистикасы (бу соңгысы тел белеме мәсьәләләрен хәл итүдә электрон-санау машиналарын файдаланудан гыйбарәт).

Инструменталь-фонетик ысуллар, төрле физик һәм физиологик приборлар ярдәмендә, телнең аваз ягын, ягъни фонетикасын өйрәнә. Мәсәлән, кимография, палатография, рентгенография, осциллография, акустик спектрография һәм башка ысуллар ярдәме белән сөйләмнең физиологиясе, аэродинамикасы, акустикасы (авазларның акустик спектры, тон һәм басым хәрәкәте һ. б.) бу ысуллардан башка мөмкин булмаган зур төгәллек белән өйрәнелә. Татар теленең аваз төзелешен өйрәнүдә инструменталь (экспериментал) фонетиканың роле турында миңа берничә мәртәбә матбугатта чыгыш ясарга туры килгән иде инде[1]. Ә инженерлык лингвистикасы беренче чиратта техника өлкәсенә карый; шуңа күрә бу мәкаләдә безгә башлыча математика ысулларына кагылып китәргә туры киләчәк[2].

Традицион тел белеменнән яңа лингвистик ысуллар үзләренең зур төгәллекләре һәм объективлыклары белән аерылалар. Алар, традицион лингвистика туплаган мәгълүматларны тикшереп, ул мәгълүматларның үзләрен дә, боларга нигезләнгән нәтиҗәләрне дә төгәлләргә, төзәтергә, кирәк булса, иске карашларны кире кагып, яңа нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәләр. Ләкин яңа ысулларның төп бурычы, аларны куллануның төп максаты — моңа хәтле өйрәнергә читен булган, яки бөтенләй мөмкин булмаган өлкәләрдә принципиаль яңа, төгәл һәм тирән фәнни мәгълүмат алудан гыйбарәт.

Тел белемендә математика ысулларын куллануның фәнни нигезе шунда: табигать һәм җәмгыятьтәге теләсә нинди күренешләрне ике яктан — сыйфат һәм микъдар ягыннан — өйрәнергә мөмкин һәм кирәк тә. Традицион тел белеме күренешләрнең башлыча

---

[1] Ү. Ш. Байчура. Экспериментал фонетика һәм аның практик әһәмияте. «Башкортостан укытыусыһы» журналы. Өфө. 1955 ел. 5 сан; Татар теленең аваз төзелешен өйрәнүдә экспериментал фонетиканың хезмәте турында. «Совет мәктәбе» журналы. Казан. 1959 ел. 11 сан; Звуковой строй татарского языка (экспериментально-фонетический очерк). Часть I. Казань. Рус телендә. 1959 ел; Звуковой строй татарского языка в связи с некоторыми другими тюркскими и финно-угорскими языками. Часть II. Казань. Рус телендә. 1961 ел.

[2] Безнең илебездә соңгы вакытта бу өлкәдә чыккан хезмәтләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: Р. Г. Пиотровский. Моделирование фонологических систем и методы их сравнения. Москва-Ленинград. Рус телендә. 1966 ел; Н. Д. Андреев. Статистико-комбинаторные методы в теоретическом и прикладном языковедении. Ленинград. Рус телендә. 1967 ел.

сыйфат ягына игътибар иткән, ә аларның микъдари ягы турында ул чама белән генә фикер йөрткән, математик төгәл анализ бирә алмаган. Математик лингвистика исә беренче чиратта телдәге күренешләрнең микъдар ягына игътибар итә, аларга математик анализ ясый. Мәгълүм булганча, микъдар һәм сыйфат арасында һәрвакыт диалектик бәйләнеш була. Менә шуның өчен дә, математик лингвистика телнең сан ягын өйрәнү нәтиҗәсендә аның сыйфаты турында да кыйммәтле мәгълүмат туплый ала. Бу фикерне ачыклый төшәр өчен, бер мисал китерик. Себердә яшәүче кет халкы телендә исемнәрдә күплек категориясен белдерер өчен уңлап чара кулланыла (суффиксация; эчке флексия; басым урынын алмаштыру; авазларның озынлыгын үзгәртү һ. б.). Статистик якны исәпкә алмаганда, бу телдә күплек категориясен белдерү өчен гаять күп төрле чара кулланыла икән, диган нәтиҗәгә килергә мөмкин. Әмма проф. А. П. Дульзон ясаган статистик анализ мәгълүматларына караганда, бу телдәге исемнәрнең 93 процентында күплек категориясе кушымчалар (-н яки -н) ялгау юлы белән, ягъни аффиксация ярдәмендә белдерелә, тәгъбир итеlә икән. Калган башка формалар барлык исемнәрнең нибары 7 процентында гына кулланыла [1]. Бу — әһәмиятле төзәтмә. Мондый һәм аннан катлаулырак мисалларны күп китерергә мөмкин.

Математик лингвистика ысуллары тел белеменең теләсә нинди өлкәсендә (фонетика, грамматика, лексикология, лексикография, стилистика, тел тарихы, семасиология һәм башкаларда) кулланыла алалар һәм кулланырга тиешләр. Математик лингвистика хәзерге (башлангыч) чорында үзенең төп игътибарын бүгенге телләрнең формаль элементларына статистик-комбинатор (ягъни сан һәм тәртип ягыннан) анализ бирүгә юнәлдерә. Шуңа карап, кайберәүләр математик лингвистиканың гомуми проблематикасы традицион тел белеменең проблематикасына караганда таррак булырга тиеш, диган фикергә килгән булганнар. Ләкин бу караш дөрес түгел. Математик лингвистиканың проблематикасы традицион тел белеменекеннән таррак түгел. Киресенчә, аңардан киңрәк тә әле. Беренчедән, традицион проблематика бөтен тулысы белән математика чаралары белән дә өйрәнелә ала, икенчедән, яңа методлар яңа проблематика да тудыра, шуның белән тел белемендә фәнни тикшеренү өчен яңа өлкәләр ачыла.

Яңа лингвистик ысулларның тел белеме өчен, шул исәптән татар теле өйрәнү өчен, әһәмияте һәм перспективасы ни дәрәҗәдә зур икәнлеге югарыда сөйләнгәннәрдән ачык аңлашылса кирәк. Иртәме, соңмы тел белеме тулысынча яңа төгәл ысуллар белән эшләүгә күчәргә тиеш булачак.

Математик һәм инструменталь-фонетик ысуллар XIX нчы гасырда ук булганнар. Татар тел белеме өлкәсендә бу яңа ысуллар XX нче йөздә, кайберәүләре исә соңгы елларда гына кулланыла башладылар. Татар теленең экспериментал-фонетик ысуллар ярдәмендә фәнни тикшерү 20 нче елларда В. А. Богородицкий һәм Г. Шәрәф тарафыннан башланган [2]. Татар лексикографиясе өлкәсендә статистика ысулын беренче булып Гаян Әмиров үзенең Г. Тукай теленә багышланган докторлык диссертациясендә кулланды (Казан, 1967). Г. Әмиров, Г. Тукай әсәрләренең тулы сүзлеген төзеп (өч томда), анда һәр сүзнең куллану ешлыгын күрсәтте. Соңгы елларда Казан университетында да математик һәм инженерлык лингвистикасы өлкәсендә кайбер тәҗрибәләр үткәрелде. Хәзер инде татар тел белеме алдында яңа лингвистик ысулларны, бигрәк тә математик лингвистиканы (ягъни статистик-комбинатор ысулларны) тел мәсьәләләрен өйрәнүдә мөмкин чаклы киң куллану, тормышка ашыру бурычы тора [3].

---

[1] А. П. Дульзон. Очерки по грамматике кетского языка. Томск. Рус телендә, 1964 ел. 58 бит.

[2] Бу ике авторның татар телен эксперименталь тикшерүгә багышланган хезмәтләре түбәндәгеләр: В. А. Богородицкий. Движение тона в словах двусложных и трехсложных в татарском языке. «Вестник Научного Общества Татароведения» журналы. Казан. 1926 ел. 4 сан. (күләме — 8 бит); Г. Шараф. Палатограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими (күләме — 37 бит). Шунда ук. Казан. 1927 ел. 7 сан; Г. Шараф. Сонорная длительность татарских гласных (длительность гласного а). Шунда ук. Казан. 1928 ел. 8 сан. (күләме — 88 бит).

[3] Кайберәүләр «математик лингвистика» дигән терминның мәгънәсен нигезсез киңәйтеп, аңа структурализм тәгълиматын да бәйләргә тырышалар. Ләкин фәннән бик ерак торган мондый алым бары тик структурализмны математика артына качырып, ул идеалистик тәгълиматны фәнни тәнкыйтьтән коткаруны гына күздә тота ала, чөнки чынбарлыкта структурализм белән лингвистикадагы математик ысуллар арасында һичбер бәйләнеш юк һәм була да алмый. Без математик лингвистика, дип башлыча статистик-комбинатор алымнарны билгелибез.

Түбәндә без математик лингвистика ысулларының татар телен, аның лексикасын, грамматикасын һәм башка өлкәләрен өйрәнүдә никадәр ярдәм итә алганлыгын күрсәтер өчен кайбер мисаллар китерәбез.

Лингвистика һәм математика фәннәренең уңышларына таянып, хәзер без әдәби телне ниндидер бер абстракт төшенчә итеп түгел, бәлки аны әдәбиятта (беренче чиратта әдәби классиклар һәм фән иясләренең әсәрләрендә) һәм әдәби сөйләм телендә кулланыла торган сүзләрнең, грамматик һәм фонетик элементларның математика, санау техникасы һәм башка төгәл ысуллар ярдәмендә тулысынча санап чыгарга мөмкин булган бик конкрет бер җыелмасы, дип билгели алабыз.

Билгеле булганча, әдәби тел фонетика, морфология, синтаксис, лексика, стилистика һәм башка тармакларны үз эченә ала. Башка яктан якын килгәндә — югарыда күрсәтелгәнчә — әдәби телнең лексик, грамматик, фонетик, стилистик һәм башка үзенчәлекләргә ия булган тагын берничә бүлеге бар. Мәсәлән, матур әдәбият, экономика, политика, махсус фәнни өлкәләр һәм башкаларга караган тел бүлекләре. Әдәби телнең һәм аның аерым бүлекләренең бөтен сүзлек материалын математик методлар ярдәмендә тулысынча һәм тәмам төгәл үлчәп һәм санап чыгарга мөмкин.

Матур әдәбият теле фәнни хезмәтләр теленнән бөтән төрле сүзләрне куллануы белән генә түгел, бәлки кайбер принципиаль яклардан да аерылып тора. Бу принципиаль аерма иң башта шунда күренә, матур әдәбиятта кулланылган сүзләр үзләренең күп мәгънәлелеге белән характерлы булалар һәм биредә синонимнар һәм омонимнар да күп кулланыла. Инде фәнни һәм башка махсус әдәбиятта күбрәк терминнар, ягъни гадәттә бер генә мәгънәле сүзләр кулланыла. Әдәби телнең бу ике зур өлкәсендә (беренчесе — матур әдәбият; икенчесе — фәнни һәм башка махсус әдәбият) аларны берсен икенчесеннән аера торган башка үзенчәлекләр дә бар. Мәсәлән, фәнни әдәбият лексикасында күбесенчә халыкара (латин, грек, гарәп, фарсы һ. б.) терминнар еш очрый, ә матур әдәбият телендә исә чит сүзләрнең саны гадәттә күп мәртәбә ким була. (Ләкин фән телендә чит сүзләрнең артык булуы һичбер мәҗбүри закон түгел, һәм моны немец теле мисалында күрсәтергә мөмкин). Морфологик яктан фән теле өчен табигать күренешләрен һәм фәнни төшенчәләрне белдерә торган кушма сүзләр (т а в ы ш т о т к ы ч, т а м ы р а я к л ы л а р, т а п к ы р ч ы г ы ш, с ү з б ә й л ә н е ш һәм башкалар кебек) саны бик күп булуы характерлы.

Объектив математик ысуллар ярдәмендә әдәби тел лексикасын, ягъни телнең сүзлек составын билгеләү принципта бик гади эш: әдәби тел лексикасы — ул теге яки бу телнең бөтен әдәбиятындагы барлык сүзләр суммасы, һәм аны бер сүзгә чаклы төгәллек белән санап чыгарга мөмкин (монда әдәби әсәрләрдә кайвакыт очрый торган диалекталь һ. б. шундый сүзләр, әлбәттә, кермиләр[1]). Матур әдәбият телен өйрәнгәндә, гадәттә, эшне башлап җибәрү өчен 10—20 иң күренекле әдип телен өйрәнү белән чикләнәләр, ә фәнни әдәбият телен өйрәнү өчен шулай ук күренекле галимнәрнең әсәрләрен һәм дәреслекләрне тикшерәләр. Вакытлы матбугат, бигрәк тә газит теле — үзенә аерым бер тармак тәшкил итә. Шул рәвешчә материалны сайлап алгач, сүзләрне статистика кагыйдәләре буенча санап чыгалар һәм һәрбер сүзнең куллану ешлыгын билгелиләр. Сүзнең ешлыгы, ягъни аның телдә нихәтле еш очравы, ул сүзнең ни дәрәҗәдә киң кулланылуын, димәк, аның тел өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын күрсәтә. Ешлыкның бер төрен гомуми ешлык дип билгеләргә мөмкин. Гомуми ешлык сүзнең телдә гомумән ничаклы киң кулланылуын күрсәтә. Ешлыкның икенче төрен махсус ешлык дип атарга була һәм бу соңгысы сүзнең теге яки бу специаль өлкәдә куллануы дәрәҗәсен белдерә. Бер үк сүз өчен бу ике төрле ешлык күрсәткечләре бер-берсеннән нык аерылырга мөмкин. Мәсәлән, математика өлкәсендә т и г е з л ә м ә, т а п к ы р ч ы г ы ш һ. б., геометриядә к ы с ы н к ы п о ч м а к л ы, т и г е з ъ я н л ы л ы к һ. б. кебек терминнар бик еш кулланыла. Ләкин шул ук сүзләрнең матур әдәбиятта очраулары ихтималдан бик ерак. Һәм киресенчә, әдәби телдә еш очрый торган и к м ә к, т ы й ш ы к кебек сүзләрне математика фәненә караган әдәбиятта очрату мөмкинлеге бик шикле.

Берәр сүзнең конкрет тексттагы ешлыгы ул сүзнең телдәге гомуми ешлыгыннан нык аерылса, ул сүз специаль лексикага керә торган була. Әгәрдә теге яки бу сүзнең

[1] Язма әдәбиятка кергән диалекталь һ. б. шундый сүзләрне аеру юллары турында түбәндә кара.

гомуми ешлыгы аның махсус ешлыгыннан аерылмаса яки аз аерылса, ул чагында әлеге сүз махсус термин була алмый (мәсәлән, бәйлекләр, теркәгечләр һ. б.). Һәм киресенчә, әгәр сүзнең конкрет текстагы ешлыгы ул сүзнең телдәге гомуми ешлыгыннан нык аерылса, без бу текстны махсус текст дип билгели алабыз. Шулай итеп, югарыда билгеләнгән закончылык биредә инде үзе текстларны билгеләү һәм бәяләү өчен бер критерий булып әверелә.

Шулай итеп, сүзләрнең телдәге ешлык дәрәҗәсе төгәл саннар белән билгеләнә һәм һәрбер сүзнең ешлыгы аның куллану дәрәҗәсен, нихәтле киң таралганлыгын күрсәтә.

Югарыда тасвир ителгән математик ысулларны, алымнарны лексикография фәнендә куллану сүзлекләр төзү өлкәсендә һаман да әле хөкем сөреп килгән субъективлыкны бөтенләй бетерә. (Дөрес, бу башлыча лексикографиянең теория ягына гына карый, практикада исә мондый төгәл ысулларны тормышка ашырасы бар әле). Эш шунда ки, югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, бер генә кеше дә әдәби телне бөтен тулылыгы белән белә алмый, чөнки моның өчен аңа бөтен фәннәрдәге барлык сүзләрне, башкача әйткәндә, барлык фәннәрне, белергә кирәк булыр иде. Шуңа да карамастан, кайбер сүзлек төзүчеләр һичбертөрле объектив, фәнни критерийлар белән исәпләшмичә (бәлки андый критерийларның барлыгын да белмичә), әдәби телебездәге бик күп сүзләрне лөгатьләргә кертмичә килгәннәр. Һичбер нигезсез бик күп әдәби сүзләрне «искергән», «сирәк кулланышлы», «тарихи», «әдәби түгел» һәм башка шундый искәрмәләр белән бирәләр, ул гына да түгел, шул сылтаулар белән күп кенә әдәби сүзләрне сүзлектән бөтенләй чыгарып ташлыйлар иде. Математика ысулларын куллану лексикографиядә моңа чаклы очрап килгән субъективизм күренешләрен бетерергә мөмкинлек бирә. Без хәзер, әлеге яңа ысуллар ярдәме белән, әдәби телебезнең лексик составын һәм һәрбер сүзнең куллану ешлыгын, димәк, аның әһәмиятен объектив критерийлар нигезендә, математика төгәллеге белән саннар аркылы билгели алабыз.

Хәзерге чорда беренче чираттагы бурычыбыз — тәртип-ешлык (распределительный словарь) сүзлеге төзү. Бу лөгатькә сүзләрнең, телдәге элементларның гомуми һәм махсус ешлыклары да, аларның нинди комбинацияләрдә, нинди тәртиптә килә алулары да төгәл саннар ярдәмендә күрсәтелергә тиеш. Мондый сүзлекләр төзәр өчен исә, ешлык (частотность) принцибы буенча төзелгән, хәзерге заман фәне таләпләренә җавап бирерлек, телнең аерым тармакларының һәм аерым авторларның телен мөмкин дәрәҗәдә тулы рәвештә чагылдыра торган картотека базасы булырга тиеш.

Икенче яктан, әдәби телнең лексикасын билгеләү — аны диалекталь лексикадан аеруны күздә тота. Бу үзе яңа мәсьәлә түгел. Ләкин объектив ысуллар ярдәмендә бу эш тә янача хәл ителә. Иң элек шуны әйтергә кирәк: әдәби лексика математик ысуллар ярдәмендә барлап, тикшереп чыгыла һәм, шуның нәтиҗәсендә, тик аерым төбәкләрдә генә таралган, кагыйдә буларак, бары диалектологик сүзлекләргә һәм башка шундый материалларга гына кереп тә, язма әдәбиятта гадәттә кулланылмый торган сүзләр әдәби телдән автоматик рәвештә чыгарылалар. Шулай итеп, әдәбиятта очрый торган аерым диалекталь сүзләр автоматик рәвештә специаль лексикага кертеләләр.

Әдәби тел диалектларга караганда һәр вакыт байрак була. Бу байлык, бер яктан, әдәби телдә әйтелә торган төшенчәләрнең (мәсәлән, фәнни төшенчәләрнең) диалектлардагыга караганда күбрәк санда булуы белән аңлатыла. Икенче яктан, әдәби телнең байлыгы мәгънәнең теге яки бу төсмерләрен күрсәтү өчен еш кулланыла торган синонимнарның күплегеннән килеп чыга. Синонимнарның роле һәм әһәмияте әдәби телнең төрле өлкәләре өчен бер төсле булмый. Фәнни-техник әдәбият өчен синонимнар куллану гомумән муафыйк түгел, чөнки бу өлкәдә, аңлашылмау тумасын өчен, кагыйдә буларак, бер генә мәгънәле сүзләр — терминнар кулланылырга тиеш. Матур әдәбият өчен исә, киресенчә, сүзләрнең күп мәгънәле булуы, синонимнарның мул кулланылуы характерлы. Алар фикерләр һәм хисләрнең иң нечкә төсмерләрен чагылдыруны тәэмин итәләр, төрле стильләр тудыруда чыганаклардан берсе буларак, бик әһәмиятле урын тоталар.

Әдәби телдә бер үк яки бер-беренә охшаш төшенчәләрне белдерү, аңлату өчен берәр генә сүз булырга тиеш, дигән нигезсез карашларны да очратырга туры килә. Ләкин бу — бөтенләй ялгыш караш. Ул — бер объектны, ягъни бөтен әдәби телне, башка объект белән, ягъни әдәби телнең бер тармагын гына тәшкил иткән фән теле белән алмаштыруга «нигезләнгән» караш һәм бу алмаштыру нәтиҗәдә әдәби телне

ярлыландыруга алып бара. Фикеребезне дәлилләү өчен шундый бер мисал китерик. Әйтик, *ашау*, *сыйлану*, *капкалау*, *туену*, *туклану* кебек синонимнар төркеменнән шул мәгънәне аңлату өчен бары тик бер генә сүз калдырып, бүтәннәрен «алар артык» яки «алар әдәби түгел» дип сүзлекләрдән чыгарып ташласак,— без мондый юл белән телне күп тапкыр ярлыландырып, аның тасвирлау чараларын бик нык чикләр идек. Бу — алынма сүзләргә дә карый.

Синонимнар әдәби тел составына еш кына диалектлардан килеп керә һәм шуңа карап, кайберәүләр, бик киң даирәләргә билгеле булган сүзләрне еш кына әдәби телдән куып чыгарырга тырышып, шуның аркасында әдәби телне ярлыландыруга алып баралар. Мәсәлән, әдәби телдә бик күптәннән бирле яшәп, кулланылып килгән *камчы* һ. б. (А. А. Юлдашев) [1], *куй*, *икмәк*, *инеш*, *кизләү*, *бүтән*, *чебеш* һ. б. [Л. Җәләй] [2], *чак*, *юнь*, *иму* һ. б. (Н. Б. Борһанова һәм Л. Т. Мәхмутова) [3] кебек сүзләрне алар диалекталь сүзләр дип игълан итәләр. Мондый авторлар шулайрак фикер йөртәләр булса кирәк. Янәсе, югарыда күрсәтелгән сүзләр, бердән, әдәби телдә генә түгел, бәлки диалектларда да очрый, икенчедән, әдәби телдә ул сүзләргә синоним булган *чыбыркы*, *сарык*, *ипи*, *елга*, *чишмә*, *башка*, *чеби*, *арзан* һ. б. кебек сүзләр бар. Шуңа нигезләнеп, алар беренче төркем сүзләрне (*камчы*, *куй*, *икмәк* һ. б.) диалекталь сүз дип билгеләмәкче булалар. Хәлбуки, теге яки бу сүзнең әдәби булу-булмавы, аның диалектларда да очравы белән генә билгеләнми. Диалектлар лексикасының күп өлеше һәрвакыт әдәби тел лексикасы белән уртак була. Шулай булмаганда ул бу телнең диалекты да була алмас иде. Алай гына да түгел, югарыда китерелгән беренче рәт сүзләр (*куй*, *икмәк*, *чебеш*) күнбатыш диалекты һәм әдәби тел өчен уртак булса (башка кайбер сөйләшләрдә дә очрый), икенче рәт сүзләр исә (*сарык*, *ипи*, *чеби* һ. б.) әдәби телгә дә, Татарстан территориясендәге урта татар диалектының сөйләшләренә дә хас. Димәк, әгәр без бу ялгыш логика буенча фикер йөртсәк, икмәк, ипи, сарык, куй һәм башка бик күп әдәби сүзләрнең барысы да диалекталь булып чыгар иде, чөнки мондый сүзләр, әдәби телдән тыш, диалектларда да очрый. Нәтиҗәдә, әгәр дә без болай фикер йөртсәк, бу сүзләр белдергән күренешләрне һәм төшенчәләрне аңлатыр өчен әдәби телебездә бер генә сүз дә калмас иде. Мәсәлән, *иму* сүзенең әдәби телдә синонимы юк. Шуңа күрә ул сүзне (кайберәүләр кебек) диалекталь дип игълан итсәк,— ул чакта «бала имә» төшенчәсен әдәби телдә ничек белдерергә кирәк дигән сорау килеп чыга. Чынбарлыкта исә, теге яки бу сүзнең әдәби булу-булмавы беренче чиратта ул сүзнең әдәби телдә куллану дәрәҗәсе белән билгеләнә. Бу кадәресен инде әлеге сүзнең гомуми һәм махсус куллану ешлыгын санап чыгу юлы белән ачыклыйлар.

Телнең лексикасын камилләштерү сүзлек составын баету исәбенә алып барылырга тиеш. Телнең сүзлек составын баету (димәк, лексиканы камилләштерү) исә лөгатьтән сүзләрне чыгарып ташлау юлы белән түгел, бәлки киресенчә, лөгатькә яңа сүзләр өстәү юлы белән барырга тиешлеге һәркемгә ачык булса кирәк. Әмма әнә шул ачык хакыйкатьне дә искә төшерергә туры килә. Чөнки бу карашның киресен яклаучы, ягъни телдән сүзләрне куып чыгару юлы белән телне камилләштерергә мөмкин һәм кирәк дип дәгъва итүче кешеләр дә бар бит. Моның мисаллары югарыда күрсәтелде.

Инде телне баету юлларына килсәк, югарыда әйтелгәннән күренгәнчә, әдәби тел башлыча өч төп чыганак хисабына: 1) телнең эчке грамматик һәм лексик чаралары ярдәмендә яңа сүзләр һәм формалар ясау; 2) диалектлардан яңа сүзләр һәм формалар алу; 3) чит телләрдән сүзләр һәм грамматик элементлар кабул итү хисабына баеый, камилләшә. Ләкин бу чыганаклар арасында принципиаль аерма барлыгын истә тотарга кирәк: әгәрдә беренчесе һәм икенчесе бик киң, практик чикләнмәгән рәвештә кулланыла алса,— өченче чыганактан файдалану исә, ягъни башка телләрдән сүзләр һәм грамматик элементлар кабул итү юлы белән телне баетуның, билгеле, объектив лингвистик законнар тарафыннан куелган чикләре бар.

Академик Арн. Чикобаваның әйтүенә караганда, телләр арасындагы йогынтыны

---

[1] «Вопросы языкознания» журналы. Мәскәү. 1967 ел. 5 сан. 122 бит.

[2] Л. Җәләй. Татар диалектологиясе. Казан. 1947 ел; Диалектологик сүзлек. I—III. Казан. 1948, 1953, 1958 ел.

[3] Н. Б. Борһанова, Л. Т. Мәхмутова. Диалектологик сүзлек, III, Казан. 1958 ел. Болар да Л. Җәләй кебек, сүзлекләрендә *икмәк*, *куй* һәм башка шундый сүзләрне диалекталь сүзләр дип игълан итәләр.

өйрәнгәндә ике төрле дәрәҗәдәге тәэсирне: 1) чикләнгән (тигезләнгән, «уравновешенное» һәм 2) чикләнмәгән (тигезләнмәгән, «неуравновешенное») йогынтыны исәпкә алырга кирәк була. Беренче очракта (чикләнгән тәэсир) башка телләрдән сүзләрне кабул итүче тел алынма сүзләрне үзләштерә һәм үзенең законнарына буйсындыра, нәтиҗәдә тел байый, камилләшә. Икенче очракта исә (чикләнмәгән тәэсир) чит сүзләрне кабул итә торган тел бер өзлексез һәм чамасыз күләмдә артып барган алынма сүзләрне үзләштерәп һәм үз законнарына буйсындырып өлгерә алмый, нәтиҗәдә бу тел үз спецификасын югалта, башка тел тарафыннан йотылып юкка чыгуы да мөмкин...[1]

Моңа хәтле без күбрәк лексика мәсьәләләре турында сүз алып бардык. Грамматика һәм фонетика өлкәләрен өйрәнүдә математик ысулларны тагын да киңрәк кулланырга мөмкин. Чөнки биредә тел күренешләренең сан ягын (ягъни статистика ягын) гына түгел, бәлки тәртип ягын да (ягъни күренешләрнең тегe яки бу комбинациядә килә алулары) исәпкә алырга киңрәк мөмкинлек туа. Шуңа карап, ысулның исеме дә статистик-комбинатор метод дип билгеләнә. Телнең грамматик һәм фонетик элементлары лексика элементлары кебек үк (ягъни аларның әдәби телдәге гомуми һәм махсус ешлыклары буенча) билгеләнәләр. Ләкин, лексик элементлардан аермалы буларак, грамматик элементларны аларның тәртибе, ягъни бер-берсе белән янәшә килә алу-алмаулары ягыннан киңрәк рәвештә өйрәнергә була. Ә математик лингвистиканың бу өлкәдәге иң мөһим нәтиҗәләреннән берсе шул: тегe яки бу телнең аерым элементлары сыйфат ягыннан үзара охшаш булса, шул ук элементлар (сыйфат ягыннан үзара охшаш булган элементлар) микъдари (сан һәм тәртип) характеристикалары ягыннан да үзара охшаш булалар. Бу исә бик күп лингвистик күренешләргә һәм төшенчәләргә абсолют объектив һәм математик төгәл билгеләмә бирергә мөмкинлек тудыра. Ягъни санарга мөмкин булган микъдари якка нигезләнеп, санарга мөмкин булмаган сыйфат ягына төгәл характеристика бирергә юл ача. Сыйфат һәм микъдар арасында булган бу диалектик бәйләнеш телне фәнни өйрәнүдә бер чара итеп файдаланыла. Соңгы фикерне ачыклый төшәр өчен бер-ике мисал китерик. Математик лингвистика ысуллары ярдәме белән төрле телләрне тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтте: тегe яки бу грамматик элементлар телдә төрле ешлыкта һәм тәртиптә, башка грамматик элементлар белән төрле комбинацияләрдә киләләр. Шул исәптән, сүз төрләндергеч кушымчалар, сүз ясагыч кушымчаларга караганда, текстларда күп (унлап) мәртәбә ешрак очрый. Нәтиҗәдә, без тикшерә торган кушымчаларның семантикасын бөтенләй белмәсәк тә, бары тик аларның ешлыгына карап, төрләндергеч кушымчаларны ясагыч кушымчалардан зур төгәллек белән аера һәм шуның белән кай вакыт бәхәсле булган мәсьәләләрне фәнни нигездә хәл итә алабыз. Мондый алым сүз төркемнәрен һәм башка грамматик элементларны билгеләүдә дә кулланыла ала.

Стилистика өчен дә математик ысулларның әһәмияте бик зур. Тегe яки бу авторның, әсәрнең яки әдәби персонажның телендә стилистик үзенчәлекләр лексик, грамматик һәм хәтта фонетик характерда да була. Франциядә үткәрелгән фәнни тикшеренүләргә караганда, мәсәлән, П. Корнель пьесаларындагы укымышлы геройлар, укымаган персонажларга караганда, якынча ике өлеш озынрак булган җөмләләр белән сөйлиләр, укымышлы хуҗалар укымаган хезмәткәрләренә караганда, чама белән әйткәндә, бер ярым — ике мәртәбә озынрак сүзләр кулланалар. Болар инде синтаксик һәм морфологик үзенчәлекләргә керә. Хәтта тегe яки бу авазларны куллануда төрле персонажлар һәм хәтта авторлар арасында да нык сизелә торган аерма булырга мөмкин һәм моны статистик ысуллар ярдәмендә ачарга була.

Сөйләм статистикасы белән үткән гасырның башында ук шөгыльләнсәләр дә, ләкин математик лингвистика бары тик соңгы 20—30 ел эчендә генә тел белемендә киңрәк рәвештә кулланыла башлады. Әмма кыска вакыт узуга карамастан, математик лингвистика, сизелерлек рәвештә алга китеп, инде игътибарга лаеклы булган уңышларга ирешеп килә. Инструменталь фонетика, инженерлык лингвистикасы өлкәләрендәге уңышлар белән бергә, математик лингвистика уңышлары теориядә тел белемен геология, геофизика кебек чагыштырмача төгәл фәннәр дәрәҗәсенә күтәрде инде диярга мөмкин. Хәзер безнең алдыбызда яңа объектив ысулларны, ул ысуллар аша алынган нәтиҗәләрне киң рәвештә тел белеме практикасына кертү бурычы тора. Ул вакытта инде тел белеме өлкәсендә субъективизмга урын калмаячак.

---

[1] Арн. Чикобава. Эволюция языка: внутренние стимулы и внешние факторы. Материалы Всесоюзной конференции по общему языкознанию. Основные проблемы эволюции языка. Самарканд. Часть I. 1966. 5—6 битләр.

Рафаэль Мостафин

# ТИК БЕР ӨМЕТ

БИШЕНЧЕ ОЧЕРК



Өзлексез эзләнәсең. Еш кына шул эзләнү сине бөтенләй уйламаган сукмакларга алып кереп китә. Һәм һич көтмәгән төштә ачыш-табышларга юлыгасың, күпме иза чиктергән серле йомгакның рәтенә төшенәсең, җеп очын табасың. Бу юлы да нәкъ шулай булды...

«Идел — Урал» легионы, фашистларның үз терминнары белән әйткәндә, «Идел — татар» легионы әсирләреннән оештырылган Беренче батальонның[1] гитлерчыларга каршы коралы көрәшкә күтәрелүе һәм тулы составы белән партизаннарга кушылуы хакында безнең матбугатта бер генә тапкыр язылмады. Әмма восстаниенең җитәкчеләрен дә, батальонның нинди шартларда партизаннарга кушылуын да һәм башка бик мөһим нәрсәләрне без юньләп белми идек. Еллар буе эзләнә торгач, Гази Кашшаф бу хәрәкәткә катнашкан бер кешене таба табуын. Кызганычка каршы, Габделхак Шакиров дигән ул кеше гади «легионер» булып чыга, яшерен оешманың эшчәнлеге хакында телгә алырлык яңалык әйтә алмый. Җитмәсә, үзе белән булган кешеләрнең исем-фамилияләрен, күп кенә дата һәм фактларны да онытkan икән.

Аптырагач, эзләнүләрне башка юл белән алып барырга — татар батальоны кушылган партизан отрядын, татар солдатлары белән иңгә-иң торып сугышкан белорус партизаннарын эзләп карарга булдым. Белоруссиянең партия архивына һәм КПССның Витебск шәһәр комитетына хатлар яздым. Мин партизан отрядларының исемнәрен дә, партизаннарның фамилияләрен дә тәгаен генә белми идем. Шуңа күрә, баштарак бу хатлар да шатланырлык хәбәр китермәде.

1967 елның кышында Казанга партизаннар хәрәкәте Белорус штабының элекке начальнигы Пантелеймон Кондратьевич Пономаренко килә. Бөек Ватан сугышы елларындагы партизаннар хәрәкәте турында сөйләгәндә, ул 825 нче батальонның эшчәнлегенә дә туктала, татар солдатларының батырлыгына югары бәя бирә.

Мин аның лекциясендә була алмадым һәм ул хакта П. К. Пономаренко Казаннан киткәннән соң гына ишеттем. Шунда ук хат салдым. Языша башладык. Соңрак Пантелеймон Кондратьевичның үзе белән очраштым һәм ул миңа 825 нче батальонны каршы алган партизан җитәкчеләренең исем-фамилияләрен әйтте, адресларын бирде. Алар арасында Витебскидагы Беренче партизан бригадасының элекке командиры Михаил Федорович Бирюлин, шул ук бригаданың комиссары Владимир Андреевич Хабаров, бригаданың штаб начальнигы Лев Павлович Корнеев, Ленин комсомолы исе-

[1] Немецларның рәсми документларында 825 нче батальон дип йөртелә.

мендәге партизан бригадасының элекке командиры Даниил Федорович Райцев һәм башкалар бар иде. Бу кешеләрнең күбесе әле бүген дә Витебск шәһәрендә һәм Витебск өлкәсендә яшиләр икән.

Алар белән хәбәрләшкәннән соң, Белоруссиягә киттем. Элекке партизаннар белән очраштым, сораштым, үзәмә кирәкле күп нәрсәләрне ачыкладым, архивларда казындым. Күз алдында әкренләп моннан 25 ел элек булып узган вакыйгалар җанланды.

* * *

— Немецлар килгән!

Авыл берьюлы тынып, сагаеп кала. Этләр өрми, сыерлар мөгрәми, хәтта этәч тавышлары да ишетелми. Булган мал-туарны, кош-кортны яшереп бетергәннәр. Кулына корал тотардай һәр кеше партизаннар янына киткән. Авылда карт-коры һәм балалар гына торып калган.

Әммә килүчеләр сәер гадәтле немецлар булып чыга. Кемгә дә кагылмыйлар, әсмый-кисми, таламый, үтермиләр. Бер савыт бәрәңге яки чүлмәге белән сөтне дә, немец маркасы түләп, сатып алалар. Телләре дә немецныкына охшамаган, кызу-кызу ниндидер сәер телдә сөйләшәләр, ничек аңлашып өлгерәләрдер. Җырлары да әллә нинди: озын, үзәкләрне өзәрлек, йөрәкләрне тетрәтерлек моңлы. Тагын һәрберсе диярлек әйбәт кенә русча сөйләшә белә.

Шулай бервакыт тегеләрнең немец офицеры формасындагы берсе Буйниченколарның авыл читендә утырган йортына килеп керә. Әдәпле генә исәнләшә һәм, баш киемен кулына тоткан килеш, бусагада туктап кала. Олы яшьләрдәге хуҗа хатын исә кунакны күрмәмешкә салыша: бөтенләй ягылмаган миче каршына килеп, ухват белән дебердәргә тотына. Керүче кеше хуҗа хатынның караңгы чырай күрсәтүенә артык игътибар итми, хәл-әхвәл сораша, немецлар бик җәберләмиләрме, ди. Хатын усал гына сорап куя:

— Ә син үзең ниндирәк бәндә соң? Әллә үзебезнекеме?

— Үзебезнеке, үзебезнеке,— ди керүче кеше, шатланып.— Минем фамилиям Жуков. Ә исемем — Григорий. Мондагы кешеләрнең барысы да хәрби әсирләр...

— Нигәдер телең русныкына охшап бетми...

— Рус кешесе түгел мин, чуваш... Иделдән...

— Иделдән дисең? — хатын ухватын идәнгә ыргыта, нәфрәтләнеп, ачуына буылырдай булып, Жуков каршына килеп баса.

— Ничек әле син, хәшәрәт, «үзебезнеке» булдың? Өстеңдә фашист кием бит. Димак, үзебезнекеләргә каршы атарга җыенасың? Эт син, хәшәрәт, башка беркем дә түгел...

Хатынның ире беренче герман сугышыннан ук яраланып кайта һәм шул ярадан үлеп тә китә. Ике улы бу сугышта йөри. Юк инде, Буйниченконы алдый алмассың. Үз гомерендә күпне күргән карчык ул. Әммә фашист киемендәге «үзебезнекеләрне» — аллам сакласын... Жуковны сүккәндә, шуңа да ул бер генә сүздән дә тартынып тормый. Тегә дәшми генә тыңлап тора, аннары, башын тагын да ия төшеп, акрын гына сөйли башлый:

— Әйе, мин начар кеше, үзем дә аңлыйм. Тик сатлык җан түгел мин, апакай. Башкаларыбыз да сатлык җан түгел. Үз иркебез белән кимәдек без бу шинельләрне. Үзебезнекеләргә каршы атарга җыенмыйбыз да. Сезнең авылда партизаннар булган дип ишеттек. Бәлки, әйтерсең, алар белән элемтә урнаштырып булмасмы?

Хатын, нидер уйланып, дәшми тора, тагын бер кат Жуковны күздән кичерә. Аннары кырт кисеп:

— Бернинди партизаннарны да белмим,— ди.

— Син безнең бу киемнәргә карама. Без алардан үзебез дә туйдык, салып кына атар идек. Ләкин ничек салырга икәнлеген белмибез.

— Ничек кигән булсагыз, шулай салыгыз...

һәм карчык, керүчегә арты белән борылып, тагын мич каршында кайнашырга тотына. Жуков китүгә, мич артыннан карчыкның унсигез яшьлек кызы Нина килеп чыга. Кыз ул-бу булмасын дип, шунда яшеренеп яткан икән. Ул әле күптән түгел генә

унынчы классны тәмамлаган, комсомолка. Партизаннар аны элемтәче итеп авылда калдырганнар.

— Әни, бәлки ул, чыннан да, алдамыйдыр?

— Кем белсен аларны, кызым. Бер сатылган кеше теләсә нинди этлеккә бара ул.

— Юк, әни, болар үзебезнекеләргә каршы сугышырга җыенмыйлар кебек. Ни булса булыр, мин аларны отряд белән бәйләнешкә кертәм.

— Кара аны, кызым, саграк кылан... Иң элек Бирюлин белән киңәш...

* * *

Бригада штабының ныклап ягылган землянкасында түзә алмаслык тынчу, юеш, күзләргә керерлек тәмәке тетене. Бер почмакта керләнеп-дымланып беткән сырмалар, каеры туннар өеме. Тактадан ясалган озын өстәл тирәли партизан отрядларының командирлары һәм комиссарлар тезелешкән. Беренче Витебск партизан бригадасында ашыгыч киңәшмә бара. Күрше бригадалардан да вәкилләр бар. Снаряд гильзасыннан эшләнгән сукыр лампа; аның нурлары шул кадәр зәгыйфь, сакал-мыек баскан бу кешеләрне юньләп танып та булмый. Бирюлин бригадасының разведка начальнигы Яков Ефимович Анащенко сөйли:

— Моннан өч көн элек, партизаннар хәрәкәтен бастыру өчен җибәрелгән немец гаскәрләренә ярдәмгә, Витебскидан яңа көчләр китерелде. Разведка мәгълүматларына караганда, ул — «Идел — татар» легионы дип йөртелгән берләшмәнең 825 нче батальоны. Батальон әсир төшкән Идел буе халыкларыннан, нигездә, татар һәм башкортлардан оештырылган. Составында 1200 гә якын кеше бар. Батальон баштанаяк коралланган, партизаннарга каршы көрәшү өчен махсус өйрәтелгән. Бөтен командирлар, разведка бүлеге һәм сакчылар — немецлардан. Алары йөзгә якын.

Батальонның төп көчләре, чама белән яртысы диярлек була, Витебскидан 12 км төньяктагы Сеньково авылында урнашты. Калганы — Гралево һәм Сувары авылларында. Элемтәчеләребезнең хәбәренә караганда, батальон солдатлары немец командирларының приказларына буйсынырга теләмиләр икән. Җирле халыкка карата явызлык кылганнары күренми. Беренче көннән үк, партизаннар ягына чыгу максаты белән, җирле халык белән элемтә урнаштырырга тырышып караганнар. Жуков фамилияле хәрби врач, мәсәлән, безнең элемтәчебез Нина Буйниченколар өендә берничә тапкыр була. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, башта Нина аңа берни әйтми, хәтта сөйләшеп тә тормый. Ахырдан, безнең белән киңәшкәннән соң, партизаннар белән сөйләшүләр алып бару өчен, дүрт илче җибәрергә куша. Бригадага илчеләрне Сеньково авылы кешесе Михальченко Степан алып килде. Немецлар шикләнмәсен өчен, аны да немец киемнәренә киендергәннәр.

Илчеләрне алдан килешенгән урында партизаннар каршылады. Алар үзләренең яшерен оешмалары булуын, шул оешмалары кушканча хәрәкәт итүләрен сөйләделәр. Яшерен оешмалары Польшадагы Едлино авылы янында батальон оешкан көннәрдән әлип үк эшләп килә икән. Сөйләүләренә караганда, яшерен оешманың башында ниндидер татар шагыйре тора, үзе хәзергә Германиядә, ди. Илчеләр башка төрле мәгълүматлар бирүдән баш тарттылар, иң зур җитәкчебез белән очраштыруны сорыйлар. Хәзер ял итәләр һәм безнең карарны көтәләр.

Анащенко докладыннан соң бераз тынып калдылар. Эш бик җитди, алдын-артын уйламый нинди дә карар чыгарырга ярамый. Аннан соң күптән түгел булган гыйбрәтле һәм күңелсез бер вакыйга әле хәзер дә һәммәсенең хәтерендә иде.

1942 елның җәендә була бу хәл. Щелбовск урманында партизаннар чолганыштан чыгып килүче совет сугышчыларын очраталар. Барысы 100 ләп кеше. Бөтен документлары диярлек тәртиптә. Командирлары башын марляга ураган аз сүзле бер кеше, артиллерия майоры була. Аларны туганнарча каршылыйлар: яраларын бәйлиләр, тамакларын туйдыралар, ял бирәләр. Үзебезнекеләргә таба баруыбыз, диләр чолганыштан чыгучылар, каршы килмәсәгез, сезнең белән бергәләп көрәшергә дә риза, диләр. Әмма партизаннар разведкасы шул ук кичне Щелбовск урманы авызында, нәкъ әлеге кешеләр килгән юнәлештә машина көпчәге эзләре күрә. Бу хакта кунакларның үзләреннән сорашкач, алар, алдан ук өйрәтеп куйган әзер сүзләрне кабатла-

ган сыман: «Әйе, урман авызында берничә немец машинасына юлыктык. Без ут ачкач, качып котылдылар», диләр. Әлеге урынны җентекләп тикшергәч, башка нәрсә ачыклана: машиналар, урман авызында байтак вакыт туктап торып, ниндидер йөк бушатканнар, аннан ашыкмый гына кире борылганнар һәм килгән юллары белән кайтып киткәннәр... Шуннан партизаннар «кунакларны» сынап карарга уйлыйлар.

Якын араларда гына партизан отрядларының берсеннән җиде кеше качкан була. Берничә көннән аларның Сураж дигән район үзәгендә яшәве белена. Партизаннардан берсе бу хәбәрне «ялгыш кына» кунакларга җиткерә. Имештер, Суражда җиде кешедән торган диверсион группа хәрәкәт итә. Һәм җидесенең дә исем-фамилияләрен әйтә. Икенче көнне үк хәбәр килә: немецлар качакларның җидесен дә тотып асканнар, күкрәкләренә «партизан-диверсант» дип язылган такталар элгәннәр. Шулай итеп, кунакларның немецлар белән даими бәйләнештә яшәүләре, партизаннар арасында булган барлык хәлләрне немецларга җиткереп торулары ачыла. Кинәт һөҗүм итеп, «чолганыштан чыгучы» кунакларны коралсызландыралар.

Ахырдан мәгълүм була: иң әшәке хыянәтчеләрдән оештырылган әлеге группа Гитлер ставкасының махсус күрсәтмәсе буенча хәрәкәт иткән. Алар партизаннарга каршы көрәшнең төрле ысул һәм алымнарын өйрәнергә, партизаннар хәрәкәтенең иң күренекле җитәкчеләрен урларга яки үтерергә тиеш булганнар. Группа белән совет майоры киеменә яшеренгән гестапочы, обершарфюрер Карл Шульц командалык иткән. Кулга алуга, партизаннар аны махсус самолет белән тылга озаталар.

Әмма ни генә булмасын, никадәр генә уңайсыз хәлдә калмасыннар, ул чагында партизаннарга нибары 100 кеше белән эш итәргә туры килә. Хәзер исә — меңнән артык. Бу — Беренче партизан бригадасының бөтен составы кадәр кеше дигән сүз.

— Шул-а-й...,— дип суза бригада командиры Бирюлин, карандашын уйната-уйната.— Әгәр хәйлә генә булып чыкса?

— Кәҗәне кәбестә янына ябып кара! — дип өсти кемдер, аны куәтләп.

Үз тылыңа шул кадәр коралны кеше кертүнең үтә куркыныч һәм хәвефле эш икәнен һәркем әйбәт аңлый иде. Бигрәк тә хәзерге кебек авыр хәлдә калганда. Немецлар бу юлы үзләренә күп мәшәкать тудырган һәм күп корбаннар китергән Витебск партизаннарын бер сугуда аяктан егарга җыеналар иде булса кирәк. Шулай тоела. Фронттан җиденче корпусның 2281 нче дивизиясен чакырып алдылар. Һәм, атна буе барган канлы бәрелешләр нәтиҗәсендә, партизаннарны өч яктан камап алырга да өлгерделәр инде. Бүген-иртәгә партизаннар бөтенләй камалышта калырга мөмкин. Разведка туплаган мәгълүматларга караганда, якын көннәрдә соңгы, хәлиткеч һөҗүм башланырга тиеш. Әгәр теләсә нинди этлеккә сәләтле фашистлар чираттагы әшәкелекләрен эшләргә генә ниятләнгән булсалар?..

— Мине иң кызыктырган нәрсә аларның кораллары,— дип сүзгә кушыла беренче отряд командиры Сысоев.— Монда һәр патрон санаулы, һәр снаряд исәптә. Аларның сугыш кирәк-яраклары олаулап.

— Ә бәлки, кушылырга ризалык биргән булырбыз да, җайлырак урын сайлап, пулеметтан барысын да кырып салырбыз? — дип киңәш итә кемдер.— Барыбер сатлык җаннар ич...

Ләкин бу тәкъдим шунда ук кире кагыла. М. Ф. Бирюлин татарларның бер сугышта да катнашмауларына, җирле халыкка карата дустанә мөнәсәбәттә булуларына басым ясый. Әгәр немецлар аларны безгә каршы сугышырга мәҗбүр итсәләр, совет кешеләренең канына буяп өлгерсәләр — ул чагында мәсьәлә катлауланачак. Немецлар белән бергәләп сугышудан башка юллары калмаячак.

Үзенең кыска гына чыгышын командир түбәндәге сүзләр белән тәмамлый:

— Без һәр төрле саклык чараларын күрергә, уяу булырга тиеш. Ләкин бернәрсәне онытырга ярамый: эшләр уңышлы чыкса, немецлардан көчлерәк калабыз, бу авыр һәм тигезсез сугышта без җиңеп чыгабыз.

Күрше бригадалардан килгән вәкилләр дә аның бу фикерләрен хуп күрәләр, кирәк була калса ярдәмгә килербез дип ышандыралар.

Күп бәхәсләшә торгач, кушылу шартлары мәсьәләсендә дә уртак тел табыла. Партизаннар ягына чыгу өчен, 825 нче батальон түбәндәге шартларга күнәргә тиеш була. Беренче һәм иң мөһим шарт — бөтен немец офицерларын, үз араларындагы сатлык җаннарны кырып бетерергә, немецларның Сеньково, Гралево, Сувары

авылларында урнашкан гарнизоннарын тар-мар итәргә. Икенче шарт — партизаннар ягына бөтен батальон белән түгел, ә өч группага бүленеп, гарнизонлап чыгарга. Һәм өченче шарт — пушка, миномет, пулеметларның һәм сугыш кирәк-яраклары төялгән олауларның бөтенесен үзләре белән алып чыгарга һәм чыгу белән партизаннарга тапшырырга.

Шулар өстенә тагын, бу якка чыгу белән, 825 нче батальон, сугышчан берәмлек буларак, таратылырга тиеш. Аерым төркемнәргә бүлгәләп, аны партизан отрядларына кушачаклар. Партизаннар ягына күчү өчен махсус урын да сайлана. Руба заводы янында Двина елгасының текә ярлы бер җире бар. Батальон солдатлары партизаннар ягына әнә шул турыдан чыгарга тиеш. Беренчедән, бу урын пулемет расчетлары яшерергә җайлы. Икенчедән, әгәр ул-бу була калса, батальон солдатлары боз өстендә, уч төбедәй ачык урында калачаклар. Батальоннан килгән илчеләр партизаннар куйган барлык шартларга берсүзсез риза була.

Бригада штабы, алар белән бергәләп, операциянең җентекле планын төзи. 22 февральдә 24.00 сәгатьтә батальон кораллы восстаниегә күтәрелергә тиеш. Восстание башлануын белдергән сигнал — Сеньководагы немец штабын шартлату. Немец гарнизонын юк иткәннән соң восстание күтәрүчеләр өч сигнал ракетасы җибәрәләр. Тапшырылган эш үтәлде, күчәргә хәзербез, дигән сүз бу. Шуннан батальон Двинага хәрәкәт итә башлый. Руба заводы янындагы чуп-чар ташлана торган урынга җиткәч, ак, кызыл, яшел утлар ярдәмендә кесә фонаре белән сигнал бирергә. Мәгънәсе: елга аша чыга башладык, каршылагыз. Илчеләрнең икесе заложник итеп калдырыла, ә калган икесен Сеньковога озаталар.

* * *

Беренче партизан отрядының комиссары Исаак Георгиевич Григорьев, яшь нарат агачының кар белән капланган ылысларын як-якка аерып, озак кына аксыл караңгылыкка карап торды. Буранлап тора. Кайдадыр, сыек болытлар артында тулы ай күренеп тора, аның көмештәй нурлары яктысында аргы яктагы биек ярларны шәйләргә мөмкин. Григорьев тынычсызланып сәгатенә тагын бер кат күз төшереп алды. Беренче унбиш минут булып килә. Сеньково ягында шылт иткән тавыш та ишетелми, бернинди хәрәкәт сизелми.

Ашыгып, отряд командиры Сысоев килеп җитә.

— Сеньково янындагы күзәтүчеләр авылда тулы тынлык хөкем сөрә, дип хәбәр иттеләр. Восстание билгеләнгән сәгатьтә башланмаган.

Григорьев, килешеп, баш кага.

— Безне кәкре каенга терәтеп калдырдылар шикелле, — дип дәвам итә Сысоев.— Егетләр инде өч сәгать кар өстендә, туңып беттеләр. Иртәгә — сугышка.

— Нәтиҗә ясарга ашыкма,— ди Григорьев каршы ярдан күзләрен алмыйча. Күренеп тора: аның Сысоев белән бәхәсләшергә теләге дә, нияте дә юк.

— Тылны һәм флангларны күзәтүне көчәйтергә куштым, берничә пулемет та куйдырдым. Нигәдер миңа бу эш ошамый әле...

Җавап көтеп күпмедер торгач, Сысоев каядыр китеп бара.

Алдадылар микәнни?.. Алай дисәң, илчеләр бер дә шикле күренмәде бит. Григорьевның әле дә күз алдында: тәбәнәк буйлы киң яңаклы, калын кашлы, кара чәчле берсе, Фәхретдинов фамилиялесе:

«Безнең илебез, әниләребез, йөрәгебез монда. Ничек немецлар белән булыйк?» — дип сөйләгән иде. Юк, алдашмаслар.

Шулчак Сеньково ягыннан тонык шартлау тавыш яңгырады. Григорьев күпме көтте ул тавышны, инде ишетелгәч, сизмәстән сискәнеп китте. Авыл өстендә янгын шәүләсе күтәрелде. Винтовка тавышлары яңгырады, автоматлар тырылдады. Йөгереп элемтәче килеп җитте.

— Иптәш комиссар, башланды! Сеньководагы штаб шартлатылган!

— Ишетәм,— диде Григорьев, шатлануын яшерә алмыйча.

Атыш тавышлары көчәйгәннән-көчәя барды һәм бераздан тоташ гөрелдәүгә әйләнде. Ләкин 10—15 минуттан яңадан тынлык урнашты. Авылның төньяк очында гына тагын күпмедер вакыт берән-сәрән аткан мылтык тавышлары ишетелеп торды. Менә авыл уртасыннан һавага өч ракета күтәрелде. Димәк, барысы да тәртиптә. Сысоев тиз

гена Бирюлинга хәбәр итәргә кушты, операциянең ничек баруы турында ул инде ике тапкыр кызыксынган иде.

Ярты сәгатьтән аргы якта кара шәүләләр күренде, һәм ак, кызыл, яшел утлар белән, килешенгән сигналларны бирделәр. Григорьев текә ярдан түбән төшә башлады, шунда аны Сысоев туктатты:

— Исаак, бәлки, икенче берәүне җибәрербез? Ни әйтсәң дә, комиссарыбыз бер генә бит...

— Илчеләр белән мин сөйләштем. Алар мине таный, мин аларны. Кайгырма, берни дә булмас.

Сысоев ачудан кулларын йодрыклады.

— Ярый, ул-бу булса, без аларга күрсәтербез. Берсе генә дә исән китә алмас...

— Тузга язмаганны сөйләмә,— диде Григорьев китеп барышлый.

Елга уртасында җил көчәя төште. Ул вак кар бөртекләрен себереп китерә дә әчеттереп-авырттырып йөзгә бәрә, тун итәкләре астына сырыштыра. Винтовкалар аскан, соры-яшел бушлат кигән кешеләр тезмәсен Григорьев ерактан ук шәйләп алды. Йөкчеләр авыр йөк төялгән чаналарга җигелгән атларын саклык белән генә түбәнгә төшерәләр. Берничә метр ара калды.

Григорьев беренче булып килүче Фәхретдиновны танып ала. Ул ничектер чайкалыбрак, аксаклап атлый иде. Фәхретдинов та Григорьевны таный һәм килеп җитәргә ике адым ара калгач, туктап рапорт бирә:

— Иптәш партизан отряды комиссары! Бурыч үтәлде. Сеньководагы штаб шартлатылды. Немец гарнизоны тар-мар ителде. Батальонны кабул итегез...

Сөйләп бетерергә өлгермәстән чайкалып китә һәм ава башлый, Григорьев аңа ташлана.

— Ни булды?

— Яраландым, иптәш комиссар,— дип пышылдый Фәхретдинов көч-хәл белән.— Кешеләрне кабул итегез. Аларның барысы да... саф намуслы...

Иптәшләре, йөгереп килеп, аны култыклап алалар.

Партизаннар белән нәкъ яр кырыенда ук очрашалар. Күрсәгез иде шундагы хәлләрне! Кочаклашулар, күз яшьләре, шатлык авазлары. Винтовкаларын чаналарга ташлап, легионерлар иңнәрендәге немец погоннарын өзеп аталар, аларны җиргә салып таптарга керешәләр. Күпләр яр читен, җилләр ашап, шомартып бетергән туң җирне үбә. Үзеннән-үзе митинг башланып китә. Григорьев, агач төбенә басып, күп җәфалар күргән, әмма беркайчан да дошманнарга буйсынмаган һәм буйсынмаячак изге белорус җирендә татар кардәшләрне кайнар котлый. Батальон исеменнән чыгыш ясаучылар фашист әсирлегендә күргән михнәт-газаплары, корбан булган иптәшләренең каны өчен вәхшиләрдән рәхимсез үч алырга ант итәләр. Кемдер татарча язылган шигырьләр сөйли. Аларны әсир төшкән татар шагыйре язды, диләр.

Дөрес, ахырдан Григорьевка бу митинг өчен яхшы ук каты элгә.

— Әгәр немецлар батальон артыннан куа чыккан булсалар? Минометлардан берничә залп бирерләр һәм юеш урыннарыгыз гына калыр иде. Кайда, кайчан җыелыш ясарга икәнен дә аңларга кирәк ләбаса! — дип әрли аны Бирюлин.

— Беләсезме, Михаил Федорович, халыкның рухи халәте шундый иде... Алар чын йөрәктән кушылдылар бит... Шунда булсагыз, үзегез ук түзмәс идегез, барыбер берничә сүз әйтер идегез...

Бирюлин йомшый төшә, шулай да кисәтеп куя:

— Кара аны, соңгысы булсын...

Соңга калып күтәрелүнең дә сәбәбе ачыклана. Башта һәр нәрсә алдан уйланган план буенча бара. Яшерен оешманың утырышы уздырыла, вазифалар бүленә, сигналлар хакында килешәләр. Батальондагы роталарның командирлары итеп немецлар үзләренә турылыклы кешеләрне — элекке кулак һәм бай малайларын куйган булалар. Восстание башланыр алдыннан әүвәл шул сатлык җаннарны юк итәргә карар кылына. Әмма билгеләнгән вакыт җитәргә берничә сәгать кала немецлар яшерен оешманың төп җитәкчеләрен — хәрби врач Жуковны, батальон командиры адъютанты Таҗиевны, хуҗалык бүлеге мөдире Рәхимовны һәм яшерен комитетның тагын берничә җитәкчесен кулга алалар. Ахырдан ачыклана: аларны батальон командирының шоферы

Ходаяров диган бәндә саткан булып чыга. Кулга алынган кешеләрдән, кыйный-кыйный сорау алалар, аннары, аяк-кулларын бәйләп, Витебскига озаталар.

Шуннан соң яшерен комитет члены Хәсәен Мөхәммәтов инициативаны үз кулына ала. Аның туганы Хәниф Мөхәммәтов вакытында батальондагы бөтен яшерен оешманың җитәкчесе булган. Әмма, кемнеңдер сатуы буенча, немецлар аны Едлинодан ук Бухенвальдка озаталар һәм ул шунда һәлак тә була.

Төп җитәкчеләрне кулга алу восстаниене бераз тоткарлый тоткарлавын. Ләкин ярты сәгать соңга калып булса да восстание башлана. Бер сизенгәч, немецлар да әзерләнеп торган була һәм бик нык каршы торалар. Аларның бик азы гына исән-сау килеш качып котыла. Ахырдан исәплиләр: бу төнне Сеньково урамнарында 74 немец офицеры ятып кала. Кызганычка каршы, батальон командиры Цек качып котыла. Аны сатлык җан Ходаяров коткара.

Батальонның Грапево һәм Сувары авылларында урнашкан көчләре дә шул ук төнне партизаннар ягына чыга. Тик бәләкәй генә авылда урнашкан бер взводлап солдат кына өлгерми кала, немецлар килеп җитеп аларны коралсызландыралар. Шулай итеп, 1943 елда, 22 февральдән 23 февральгә каршы төндә белорус партизаннары сафына тулы сугышчан хәзерлекле 900 гә якын татар солдаты кушыла. Үзләре белән алты миномет, өч 45 миллиметрлы пушка, унике станоклы һәм йөзләп кул пулеметы, меңнән артык мылтык һәм пистолет, төрле сугыш кирәк-яраклары төялгән 26 олау йөк алып чыгалар. Элекке легионерлар, икенче көнне үк отрядларга бүленеп, партизаннарны төрле яктан камап алган гитлерчыларга каршы сугыш башлый.

* * *

825 нче батальонның нинди шартларда партизаннарга кушылуы турында миңа бик тәфсилләп һәм озаклап сөйләделәр. Ә яшерен оешманың эшчәнлеге, бигрәк тә аның Берлиндагы җитәкче үзәк белән бәйләнеше хакында берән-сәрән мәгълүматлар гына туплый алдым.

— Яшерен оешмаларның эше турында татарлар миңа күп сөйләгәннәр иде,— дип искә ала М. Ф. Бирюлин.— Әлеге восстаниегә Едлинода чакта ук хәзерләнә башладык, Көнчыгыш фронтка җибәрүләрен дә үзебез сорадык, диделәр. Алар анда эшне киң күләмдә куйган булганнар. Легионерлар арасында листовкалар таратылган. Лагерьның үзешчән көчләре әсирләр өчен әдәби кичәләр уздырган. Ул кичәләрдә җырлар җырланган, шигырьләр укылган. Хәтта дини намазларга хәтле гитлерчыларга каршы агитация өчен файдаланылган. Миңа бу хакта батальонның элекке мулласы үзе сөйләде. Фамилиясен хәтерләмим. Ул шулай ук үзләре белән бер татар шагыйре җитәкчелек итүен, аның Германиядә калуын әйткән иде. Вакытында бу нәрсәләргә артык игътибар бирмәдем. Сугыш бетеп бернichә ел үтүгә матбугат битләрендә Муса Җәлил исеме шаулый башлагач, аңладым: сүз ачык турында барган икән.

Исаак Георгиевич Григорьевта 825 нче батальонның партизаннар ягына чыгуы хакында Белоруссия Коммунистлар партиясенең Үзәк комитеты исеменә язылган рәсми белдермәнең күчермәсе саклана. Ул кәгазьдә легионерлар восстаниесенең бөтен барышы тасвирлана, әлеге күтәрелешне оештырган кайбер җитәкчеләрнең фамилияләре телгә алына. Аларның бер ишен — партизаннар белән беренче булып элемтә урнаштырган хәрби врач Жуковны [1], батальон командиры адъютанты Рәшит Таҗиевны, хуҗалык бүлеге мөдире Рәхимовны һәм башкаларны немецлар Витебскида асып үтерәләр. Шуннан соң восстание белән штаб ротасы командиры Хәсәен Мөхәммәтов, взвод командиры Юсупов, рядовойлар Мамеджанов һәм Галиев җитәкчелек итә.

Восстаниедә Ганиев (восстание башланыр алдыннан ул рота командиры сатлык җан Минһаҗовны атып үтерә), Габделхак Шакиров (ул үз группасындагы кешеләр белән немец штабын чолгап ала һәм аны шартлата), Аксануллин, Шәрәфиев һәм башкалар актив катнаша. Әлеге язмалардан күренгәнчә, восстание белән гел командирлар арасыннан чыккан кешеләр җитәкчелек иткән. Моңа да гаҗәпләнмәскә кирәк. Батальон оешкан чорда ук яшерен оешма барлык командирлык урыннарына ышанычлы

[1] Чын фамилиясе Волков.

кешеләрне, нигездә элекке офицерларны куярга өлгерә. Дөрес, фактта подразделениеләр белән немецлар командалык итә.

Партизаннар янына илче булып В. Х. Лотфуллин (1944 елда фронтта үлә), отделение командиры Александр Трубкин һәм Фәхретдинов (соңгы язмышы билгесез) бара.

825 нче батальонның партизаннар ягына чыгуы Витебщина урманнарында барган вакыйгаларга җитди үзгәреш кертә. Немецлар, партизаннарга каршы көрәшү өчен, «Идел — татар» батальоны белән бергә, «Рус азатлык армиясе» дип йөртелгән легионерлардан төзелгән тагын берничә батальон солдат (алар арасында Дон казаклары байтак була) китертәләр. Татар батальоны партизаннарга кушылуга, куркып, аларны ашыгыч рәвештә кире чакыртып алалар. Бу исә немецларның позициясен нык йомшарта.

Идел татарларының «хыянәт итүе» турындагы хәбәр Гитлер ставкасына кадәр ишетелә, болай да җиңел холыклы фюрер ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитә. Бу вакыйгадан соң Польша һәм Германиядә калган башка татар легионнары «иң ышанычсызлар» рәтенә кертелә, аларны сугыш хәрәкәтләре барган районнарга җибәрергә бүтән кыймыйлар. «Витебск партизаннарын бөтенләй юк итү» максаты белән башланган февраль экспедициясе хурлыклы рәвештә өзелә. Бер Бирюлин бригадасы районында гына да 880 мәетләрен калдырып, немецлар кире китәләр.

Мин очрашкан кешеләрнең барысы да татар егетләренең батырлыгына гаять югары бәя бирде.

— Татарлар менә диген итеп сугыштылар, шундый солдатлар күбрәк булсын иде,— диде партизан бригадасы командиры Д. Ф. Райцев.— Оборона тотарга приказ булдымы — соңгы кешеләре исән калганчы сугышалар. Шуның аркасында, аларның күбесе беренче сугышларда ук һәлак булды. Кайберләрен хәтта исемлекләргә теркәргә дә өлгермәдек. Элекке легионерлар арасыннан үз ирке белән әсир төшкән бер генә кешене дә хәтерләмим. Хәер, бу аңлашыла да. Алар немец концлагерьларының бөтен газабын үз җилкәләрендә татыган кешеләр, аларны җиңел генә алдый алмыйсың.

Витебск музее архивында партизан бригадалары һәм отрядларының белешмәләре белән танышып утырганда, дистәләрчә татарча фамилияләр очраттым. «Немецлар белән барган каты бәрелештә Николай Сарбай командалык иткән икенче отряд сугышчысы Сәхәветдинов Хәсән зур батырлык күрсәтте», диелә аларның берсендә. Икенче бер донесениедә 1943 елның 13 мартында Великолук юлында партизаннар оештырган засада турында сөйләнә: «Биш тонналы машина сафтан чыгарылды, җиде немец үтерелде, өчесе әсир ителде. Немецларның станоклы пулеметы, ике автомат, ике пистолет, җиде мылтык, сугыш кирәк-яраклары һәм документлар кулга төшерелде. Тимошенко, Кабанов, Сергинко, Гароткин һәм Юсуповлар аеруча зур батырлык күрсәттеләр». Сеньководагы восстание җитәкчеләренең дә берсе Юсупов фамилияле иде. Кем белә, бу мактау сүзләре, бәлки, нәкъ аның турындадыр? Кызганычка каршы, партизан донесениеләрендә инициаллар күрсәтү гадәте булмаган.

Бик күп партизаннар бер легендар татар пулеметчысы турында сөйләделәр. Немецлар, зур көчләр белән, отрядны өч яктан камап алгач, ул гитлерчыларны тоткарлап торырга кала. Немецларны ярты сәгать буе туктатып тора. Патроннары беткәч, кул сугышына ташлана. Пулеметчы үлә, аның каравы отряд котылып кала.

Бу вакыйга архив материалларында да телгә алына. 1943 елның 17 мартында Гребеницы авылы тирәсендә була бу хәл. Пулеметчының фамилиясе — Шәрәфетдинов. Аңа ярдәмче итеп партизан Хоронжин калдырыла. Икесе бергә 29 фрицны юк итәләр һәм 12 сен яралыйлар, барыннан да бигрәк — отрядка югалтуларсыз чигенергә мөмкинлек бирәләр. Әмма тиздән Хоронжин яралана һәм шуышып отряд артыннан китә. Күрәсең, Хоронжин исән калгандыр. Язмаларның берсендә мин аның фамилиясен кабат очраттым:

«Пулеметчылардан Сәлихов, Казанов искиткеч оста хәрәкәт иттеләр, уннан артык гитлерчыны егып салдылар. Фазылов, Пиндюрин, Хоронжин һәм Абдулаев кебек пулеметчылар һәр кайсы 5—8 гитлерчыны юк иттеләр».

Татарлар чыннан да батыр сугышчылар булганнар, архивта сакланган документларда аларның фамилияләре еш кабатлана:

«Станоклы пулеметтан атучы Сәлихов һәм Казанов зур батырлык күрсәттеләр».

«Пулеметчылардан Фазылов, Абдулаев, Хәбибуллин, Миргалиев батырлык күрсәттә».

Кызганычка каршы, болар — артык киң таралган фамилияләр. Аларга нигезләнеп кенә эзләнү эшләре башлап җибәрергә кыен. Тагын шунысын да истән чыгармаска кирәк, аерым фамилияләрнең ялгыш язылган булуы да мөмкин.

825 нче батальон солдатлары белорус партизаннары белән иңгә-иң торып көрәшәләр. Белоруссия җиренә совет гаскәрләре килеп җиткәч, аларга я азат ителгән җирләрдә тыныч тормыш торгызу өчен калырга, я совет армиясе сафларына керергә кушыла. Барлык татар әсирләре, кызыл армиягә кушылып, фашистларны кууны артыграк күрәләр.

* * *

1942 елның көзендә фашистлар күренекле татар шагыйре Муса Җәлилне авыр яралы хәлендә әсир итәләр һәм чәнечкеле тимер чыбык киртә артына ыргыталар. Әмма батыр йөрәкле, саф намуслы шагыйрь шул гаять авыр шартларда да төшенкелеккә бирелми, азатлык турында, исән-сау килеш илгә кайту турында хыяллана:

**Тик бер өмет: кара август төне**
**Илтер мине шунда җитәкләп.**
**Өстен килер түбән әсирлеккә**
**Үч һәм илгә кергез мәхәббәт.**

**Тик бер өмет: дуслар, сезнең сафта**
**Табар соңгы көрәш теләгән,**
**Яраланган, ләкин тар коллыкка**
**Баш имәгән кергез йөрәгем.**

Муса Җәлилгә ирекка чыгу насыйп булмады. 825 нче батальон восстание күтәреп берничә ай узгач, яшерен оешманың башка әгъзалары белән бергә, фашистлар аны кулга алалар һәм үлемгә хөкем итәләр. Әмма ышанып әйтә алабыз: җәллад кулыннан һәлак булган башка иптәшләре кебек үк, Җәлил үзе дә, белорус партизаннары белән иңгә-иң торып, гитлерчыларга каршы көрәште, аларны туган илдән кууда булышты. 825 нче батальонның партизаннар ягына чыгуы Җәлил җитәкчелегендә яшерен оешма башкарган күп төрле эшләрнең иң зурысы һәм иң нәтиҗәлесе иде.

Аркадий Файнберг

# ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЛЕ РӘССАМ



Караңгы татар авылында туып, яшьли ятим калган бер малай танылган рәссам булып китә... Әсәрләре даими рәвештә Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия күргәзмәләренә куелып килә. Казан, Мәскәү, Чебоксар, Түбән Тагил һәм башка шәһәрләрнең музейлары ул иҗат иткән картиналарны кадерләп саклый. Сынлы сәнгать өлкәсендәге иҗат уңышлары өчен аңа ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә, иң яхшы хезмәтләре Дәүләт һәм Габдулла Тукай исемендәге премияләр белән бүләкләнә. Иҗат эшчәнлеге хакында бик күп мәкаләләр һәм фәнни хезмәтләр языла. Әсәрләрен, исемен илебезнең бөтен почмакларында диярлек беләләр... Бик гыйбрәтле һәм хәйран калырлык күренеш бу. Икенче бер шартларда, икенче бер җәмгыятьтә яшәгән татар баласы мондый дан-шөһрәтне, билгеле, төшендә дә күрә алмас иде. Социализм эпохасы өчен исә талантның, нинди милләттән булуына карамастан, шулай тиз чәчәк атып, тиз танылуы гадәти һәм табигый бер нәрсә санала.

* * *

Горький өлкәсенең Сергач районында Анды исемле татар авылы бар. Октябрь революциясенең бер еллык бәйрәме якынлашып килгән көннәрдә — 1918 елның 27 сентябрендә — шул авылда, Габделмән атлы крестьян гаиләсендә бер ир бала дөньяга килә. Аңа Лотфулла дип исем кушалар. Ләкин, малай туып күп тә үтми, Габделмән абзый үзе үлеп китә. Тиздән Лотфулла әнисез дә кала.

Лотфулла тырыш һәм сәләтле бала булып чыга. Бераз үсә һәм ныгый төшүгә, бик тиз укырга-язарга өйрәнә. Шуннан күпмедер вакыт узгач, япа-ялгызы җәяүләп Казанга чыгып китә. Ул чагында аңа нибары 13 яшь була.

Казанга килүгә, шәһәрдәге мәктәпләрнең берсенә кереп, ул укуын дәвам итә. Ә үзенең торыр урыны да булмый: бик күп төннәрен шул ук мәктәпнең класс бүлмәләрендә йоклап үткәрә.

Биредә укыганда, Лотфулла Харис Якупов белән таныша. Бу ике рәссам арасындагы иҗади дуслык җепләре әнә шул көннәрдән үк башлана. Бергәләп Казан сәнгать училищесына керәләр, бергәләп Кызыл Армия сафларына китәләр. Тик Бөек Ватан сугышы елларында гына аларның юллары вакытлыча аерылып тора...

Фашист палачлары башлап җибәргән дөнья сугышы Лотфулла Фәттахов җилкәсенә дә әллә ни кадәр сагыш, кайгы-хәсрәт һәм кыенлык сала: коточкыч әсирлек көннәре, ачлык, үлем лагерьлары, әсирлектән качу... Сугышны ул яңадан Совет Армиясе сафларында тәмамлый.

Сугыш еллары аны тормышны тагын да тирәнрәк аңларга, яшәүнең кадерен белергә өйрәтә. Л. Фәттахов ясаган фронт күренешләрен, бигрәк тә аның сугыш кырларында натурадан төшергән солдатларын күргәнегез бармы икән? Кешегә күпме мәхәббәт,

никадәр ягымлылык һәм шаян юмор ул рәсемнәрдә! Фәттаховның «9 май иртәсе» (1947 ел) исемле картинасы да сугышның кайнар эзләре буенча дирлек язылган. Тагын шунысы характерлы, үзенең күләмле беренче әсәрен үк рәссам илебез тормышындагы тантаналы, зур вакыйгага багышлый. Һәм бу картинада шактый ачык тәсмерләнгән төп ике тенденция — тормышчанлык һәм халыкчанлык — аның бөтен иҗаты буйлап кызыл җеп булып сузыла. «Ватан турында җыр» (1948) исемле икенче зур күләмле картинасында Лотфулла Фәттаховның тагын бер шәхси үзенчәлеге шактый тулы ачыла. Сүз аның әсәрләренә хас тирән эмоциональлек һәм шигъри лиризм хисенең көче хакында бара. Аны шагыйрь күңелле рәссам дип йөртәләр. «Ватан турында җыр»дан соң Фәттахов «Максим Горький Казанка ярында», «Максим Горький икмәк пешерүче Семеновта» кебек композицияле картиналар эшли. Бу исә аның катлаулы төзелешле сәнгать әсәрләре тудыру юлындагы эш тәҗрибәсен тагын да баета һәм камилләштерә төшә. Шул рәвешчә, 1950 еллар башына Лотфулла Фәттахов зур гына тәҗрибә туплаган үзенчәлекле художник булып формалашып өлгерә.

1950 елда Лотфулла Фәттахов белән Харис Якупов «В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» исемле картина өстендә эшләргә алыналар. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, ифрат җаваплы һәм иҗади бу тема рәссамнардан күп көч куюны сорый. Алар әллә ни кадәр әдәбият белән танышып чыгалар, В. И. Ленинның Мәскәү шәһәрендәге Үзәк музеенда еш булалар, Кремльдәге эш бүлмәсен җентекләп өйрәнәләр, дөнья кадәр материал туплыйлар. Күп төрле вариантлар эшләп караганнан һәм озак фикер алышканнан соң, ниһаять, уртак бер карарга киләләр: өстәл артында утыручы Ленин образы үзәктә булган соңгы вариантка тукталалар.

Ленинның гади кешеләргә тирән хөрмәт белән каравы һәркемгә мәгълүм. Аның рыясыз, гади һәм эшлекле аңгәмә алып бара алу осталыгына күпләр сокланган. Якупов белән Фәттахов пролетариатның даһи юлбашчысын нәкъ шулай сурәтлиләр дә. Рәсемдә сурәтләнгән Ленин — сизгер күңелле әйбәт кеше һәм иң изге серләреңне дә шикләнми сөйләрлек игътибарлы утырдаш. Әнә ул, делегатларга карап, нидер аңлата. Уң кулына игътибар итегез! Никадәр отышлы һәм хәтердә калырлык хәрәкәт. Күренеп тора: бүлмәдәгеләр үзләрен бик иркен һәм кыю тоталар. Бер бабай әнә, рәхмәт сиңа дигәндәй, Ленинга төбәлгән. Башка делегатларның күз карашларында да юлбашчыга тирән ихтирам хисләре укырга мөмкин. Арткы пландарак басып торган ачык йөзле хатын-кыз образы игътибарны җәлеп итә... Рәсемдә юлбашчы һәм халык массалары арасындагы ныклы бәйләнеш тирән һәм ышандырырлык итеп тасвирланган. Тигез төшкән йомшак якты нурлар һәм алтын сыман тон картинадагы персонажларны үзара берләштерә, бер-берсенә тагын да якынайта төшкән.

«В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» исемле әсәрләре өчен Фәттахов белән Якуповка Дәүләт премиясе лауреатлары дигән мактаулы исем бирелде. Татарстанның 30 еллыгына багышланып эшләнгән бу сәнгать әсәренә зур әһәмият салынган. Анда, СССР территориясендәге башка милләтләр кебек үк, татар халкының да иректә үсеш юлына чыгу тарихы гәүдәләндерелә. Сынлы сәнгать өлкәсендәге мондый теманы халык эпослары иҗат итү белән бер рәткә куярга мөмкин. Үзенең колачы ягыннан да, чынбарлыкны танып-белүнең күләме буенча да бу рәсем безнең сәнгать тарихыбызда зур урын тота.

Шуннан соңгы әсәрләрендә ул Ленин идеяләренең шифалы нурлары тәэсирендә гөрләп алга киткән гүзәл тормышыбыз турында җырлый. Совет хөкүмәте һәм коммунистлар партиясе Лотфулла Фәттахов өчен ниндидер абстракт нәрсәләр түгел иде. Совет дәүләтенең татар халкына нинди мөмкинлекләр тудыруын ул бик яхшы күрә. Ә үзенә, караңгы татар авылыннан чыккан ятим малайга, Совет күрсәткән игелекләрне ничек онытсын?!. Менә ни өчен безнең илебез белән шулай горурлана, безнең уңышларыбызга шулай шатлана ул. Һәм аның күпчелек әсәрләре социалистик ватанга, үз халкына мәңгелек гимн булып яңгырыйлар. Бу яктан караганда, Л. Фәттаховның заман темасына багышланган ике әсәре аеруча характерлы. Аларның берсе — «Игеннәр өлгерде» (1954 ел), икенчесе — «Сабан туе» (1957 ел) исемле.

«Игеннәр өлгерде» исемле картинасында автор колхоз кырларының мәһабәт панорамасын күрсәтә. Җир-анага олы мәхәббәт, иксез-чиксез иген кырларының гүзәллегенә чын күңелдән соклану әсәрдә көчле пафос белән тасвирланган. Мул иген кырларын карап куану-шатлануы турында рәссам бөтен көчкә сөйли.



*Игеннәр өлгерде.*

Колхозчылар да табигать белән органик бәйләнештә сурәтләнәләр. Персонажлар шактый уңышлы сайланган: алар төрле-төрле һәм бер-берсен тулыландыралар. Беренче караштан ук аларның безнең замандашларыбыз икәнлеге күренеп тора. Рулетка, газеталар, велосипед кебек детальләр бу хисне тагын да көчәйтә төшә. Хикмәт, билгеле, күзгә ташланып торган тышкы сыйфатларда гына түгел. Колхозчы образларындагы төп нәрсә — аларның характерларында. Күз карашларына игътибар итегез: эчке горурлык, иген язмышы турында хуҗаларча кайгырту әллә каян сизелеп, кычкырып тора.

Безнең уебызча, «Сабан туе» картинасы тагын да зуррак әһәмияткә ия. Бәйрәмнең иң кызган чагы. Татарча көрәш бара. Бер батыр, әнә, сөлге белән биленнән эләктереп алган да, көндәшен һавага күтәргән. Тагын бер мизгелдән ул аны, мөгаен, җиргә орачак. Судья картларның күзе гел шуларда. Халык исә гөр килә. Як-яктан, көрәшчеләргә көч-куәт биреп, аларны дәртләндереп торалар, шәһәрчәрәк киенгән бер хатын фотога төшереп азаплана, яшь кызлар дулкынлана, малайлар шаулаша. Колга башларына эленгән чуп-чуар сөлгеләрне, ямь-яшел каен яфракларын җилфердәткән җәйге җил мәйдандагы атмосфераны, кеше хисләренең киеренкелеген тагын да көчәйтә сыман. Әллә каян күзгә ташланып, чекерәеп торган төсләр: кызыл, яшел, сары, ал, зәңгәр... Халык шау итә, сөлгеләр җилферди, каен яфраклары шеберди. Менә шул ачык төсләр һәм күп төрле авазлар, барысы бергә җыелалар да, күңелле бәйрәм атмосферасына кушылалар. Үз чиратын көтеп читтә басып торган пәһлеван гәүдәле яшь егетнең генә гүя көрәшчеләргә дә, шау-шуга да исе китми. Ул көрәшчеләр ягына карамый да. Нидер сөйләп, сөйгәнен көлдерә. Тагын сул як читтә утырган бер карт, хәйләкәр елмаеп, безгә — тамашачыларга — карап тора. Исләре китмәгән кыяфәтле шушы ике персонаж башкалардагы киеренкелек һәм дулкынлануны көчәйтә генә төшә.

Фәттахов — көнкүреш темаларына һәм табигать күренешләренә багышланган әсәрләр остасы. «Сабан туе»нда аның бу сыйфатлары тагын да тулырак һәм тирәнрәк ачыла. Шуның белән бергә, бу әсәре белән ул үзен зур социаль яңгырашка ия тирән эчтәлекле полотнолар иҗат итәргә сәләтле рәссам итеп тә танытты. «Сабан туе» — татар халкының бәхетле, шатлыклы тормышын күрсәтүгә багышланган әсәр, ул — төс һәм тавышлар бәйрәме, милли йола һәм бәйрәмнәр аша халык оптимизмын, аның көр күңелле булуын сурәтләүгә багышланган күтәренке рухлы поэма.



*Яңа буралар.*

Лотфулла Фәттаховның иҗаты елдан-ел активлаша, әсәрләренең әдәби-эстетик дәрәҗәсе торган саен күтәрелә бара. «Яңа буралар» (1959), «Райком секретаре иртәсе» (1962), «Шәһәрдән кайтыш» (1964) кебек бүгенге авыл темасына караган әсәрләрендә ул тагын да индивидуальләшкән, тагын да конкретрак һәм хәтердә ныграк калырлык образлар тудыра. Шул кадәресен басым ясап әйтергә кирәк, үз картиналары өчен материалны да һәм образларны да ул чынбарлык тормыштан ала. Хәтерлисездер, «Яңа буралар» исемле рәсемдә кыска туның җилбәгәй җибәргән, өлкән яшьләрдәге балта остасы бар. Әлеге образның прототибы реаль тормыштан алынган. Ул — авторның күптәнге танышы, Сергач районы Анды авылы кешесе Идрис Бәдретдинов. «Райком секретаре иртәсе» исемле картинадагы төп геройның прототибы Арча районыннан, коммунист Ибраһимов. Шулай ук Фәттаховның яхшы танышы.



*Райком секретаре иртәсе.*

Башка әсәрләрендәге кебек үк, биредә дә кеше, аның характеры табигать күренешләре белән тыгыз бәйләнештә ачыла. Әмма картина Фәттахов өчен ятрак исәпләнгән аксыл-соры буяулар белән язылган. Мондый сабыр тон җыйнак, кырыс атмосфера тудырырга ярдәм иткән.

Әсәрнең композициясе артык катлаулы түгел. Картинада төп образлар икәү: райком секретаре һәм яңа гына сөреп ташланган басу. Секретарь уйга калган.

Күрәсең, аны нидер борчый. Тикмәгә генә шулай иртә кырда йөрмәс иде, билгеле. Әсәрнең пейзажы искиткеч шигъри эшләнгән: иртәнге томанга өртелгән ераклык, офык артына үк кереп югалган чирәмлекләр...

«Шәһәрдән кайтыш» исемле картина «Советская Россия» күргәзмәсендә катнашты һәм тамашачылар арасында кызыксыну уятты. Авторның игътибар үзәгендә монда да авыл кешеләре. Алар, сатып алган әйберләрен аллы-артлы күтәреп, шәһәрдән кайтып киләләр. Колакчын бүреген кыңгыр салган бер бабайны автор аеруча яратып сурәтли. Ул алган әйберләрнең төре үк тамашачыда җылы юмор һәм елмаю хисләре уята: обой кебек хуҗалык өчен бик кирәк әйберләр дә һәм оныгы өчен алынган чаңгылар кебек кирәклеге чамалырак нәрсәләр дә бар анда. Карт кеше кулында әлеге чаңгылар бигрәк тә мәзәк күренә.

Яшьлек... Кеше тормышының иң гүзәл чоры: якты омтылышлар, татлы хыяллар белән тулы чор. Фәттахов исә үзенең табигате белән үк шагыйрь йөрәкле романтик кеше. Аңа яшь кызның яңа кузгалып килгән беренче мәхәббәт хисләре дә, малайлардагы хисләрнең давыллы кайнарлыгы да таныш. Рәссам тарафыннан яшьлеккә багышланган дистәләрчә әсәрләр иҗат ителгән. Чәчәк аткан алма бакчасында, сөйгән егетеннән килгән хатны учлап, чирәмдә утыручы яшь кызны хәтерегезгә төшерегез («Яшьлек»)! Күпме мөлаемлык һәм гүзәллек, күпме инсафлык ул образда. Тәрәз рамнарыннан кышкы тузанны юып төшерүче кыз да шундый ук («Яз», 1959 ел). Кызларның икесе дә ак киемнән, икесе дә айдай якты йөзләләр, әйтерсең, йөзләреннән нур ява. Зур игътибар белән койма башыннан торып спорт ярышы күзәтүче малайлар («Болельщиклар», 1955 ел) мәзәк һәм көлке. Киез итекләр белән язгы суда уйнаучы сабый бала да («Әни күрмәгәндә», 1956 ел) күңелдә искиткеч җылы хисләр уята.



*Тынгысыз яшьлек.*

«Тынгысыз яшьлек» (1958 ел) исемле картина ерак юллар романтикасын сурәтләүгә багышланган. Көчле җил күктәге болытлар өерен куып йөртә, яр читендәге егетнең плащ чабуларын җилфердәтә, ә ерактагы су өстенә якынлашып килгән пароходның ак төтене җәелгән. Гашыйклар күңелен авыр кайгы, аерылышу кайгысы баскан. Егет читкә китәргә тиеш. Нишлисең, вакыт җиткәч, кош балалары да оясыннан очып китә... Бу әсәрдә без искиткеч оста тасвирланган табигать белән очрашабыз. Таныш Идел ярлары, йөри-йөри, күрә-күрә гадәтләнеп беткән дебаркадерлар, тирән яр кырындагы агачлар һәм бөлекәй алан, пристаньга кадәр сузылган тәбәнәк коймалар.

барысы да таныш, иялəнгəн, гади нəрсəлəр. Бернинди экзотика юк. Əммə бала чактан бирле үзебез күреп үскəн күренешлəр, искиткеч кадерле һəм якын күренешлəр. Чит җирлəргə китəргə җыенган яшь егет, туган якның төсе итеп, күңелендə нəкъ əнə шул күренешлəрне йөртер. Нинди генə хислəрне белдерми бу табигать. Аерылу ачысын да, кавышу килəчəген сизенүдəн туган татлы хисне дə, ерак юллар романтикасын да, зур эшлəр башкарырга баруыңны аңлап горур ану хисен дə тоябыз без бу əсəрдə. «Тынгысыз яшьлек»тə күңелнең иң нечкə хислəрен кузгатырлык көчле лиризм бар. Фəттаховның бу əсəре əйбəт җыр кебек яңгырый. Аның мотивлары буенча əллə ни күпне дəгъва итми торган, сюжет-композициялəре белəн гади генə əсəрлəре, əнə шулай, зур фəлсəфи мəгънəгə иялəр, тамашачы күңелендə яхшы хислəр уяталар һəм аны уйландыралар.

Кайбер очракларда əсəрнең исеме үк эчтəлекне ачарга ярдəм итə, картинаның мəгънə тирəнлеген аңларга булыша. Мисалга «Тургайлар» (1959) исемле картинаны алырга мөмкин. Анда, кырга чыгып, тургайлар җырын тыңлап яткан бер төркем балалар сурəтлəнə. Автор аларга карап үзе дə соклана һəм əйтə кебек: «Сезнең бит əле, һавадагы тургайлар кебек, кайгы-хəсрəтсез, бəхетле чагыгыз!»

Лотфулла Фəттахов чын мəгънəсендə халык рəссамы. Хикмəт аның гади халык арасыннан чыгуында гына түгел, билгеле. Дөньяга, тормыш күренешлəренə халык күзе белəн карый алуында, халыкча уйлый, халыкча кичерə белүендə. Бу сыйфат хəтта аның сатирик əсəрлəрендə дə сизелə. «Утырыш җене кагылганнар» (1953), «Ялачы» кебек картиналары əнə шундыйлар. Бюрократларны һəм формалистларны, яла ягучыларны совет кешелəре һəрвакыт дошман күрделəр. Һəм Фəттахов бу əсəрлəрендə халык массаларының шул карашларын гəүдəлəндерə.

Нəгыш сəнгатендə (живопись) сатира һəм гротеск алымнарын куллану нихəтле урынлыдыр, рəссам күтəргəн мəсьəлəлəр никадəр мөһимдер, ул үз ниятен ничегрəк тормышка ашыргандыр — болары хакында бəхəслəшергə мөмкин. Əммə авторның чын күңелдəн социализм төзү эшенə ярдəм итəргə телəве — бəхəссез.

Лотфулла Фəттахов төбендə көнкүреш рəсемнəре остасы, əммə сирəк-сирəк булса да, ул тарихи-революцион темаларга да мөрəҗəгать итə. Аерым алганда, соңгы күргəзмəлəрдə күрсəтелгəн «Мулланур Вахитов» (1964) һəм «Совет властеның беренче елларында» (1967 ел) исемле картиналарын атарга мөмкин.

«Мулланур Вахитов» исемле əсəрдə мəгълүм тарихи шəхес, шуның белəн бергə, гражданнар сугышы елларындагы коммунист-комиссарның гомумилəштерелгəн җыелма образы гəүдəлəнгəн. Кеше батырлыгының гүзəллеге хакындагы бу сəнгать əсəре халык авыз иҗаты традициялəренə нигезлəнгəн. Нəкъ шундый комиссарларның исемнəрен халык үз йөрəгендə саклап йөртə һəм алар хакында легендалар иҗат итə.

Тыштан караганда, картинадагы һəрнəрсə тыныч кебек. Казан Кремле алдындагы мəйдан фонында эре план белəн Мулланур Вахитов фигурасы ясалган. Тик картинаның тоны күп сыйдырышлы, зур яңгырашлы: офык читендə авыр давыл болытлары, җилдə җилфердəүче ямь-яшел яфраклар, Кремльнең ак стеналары, кояшта янган комиссарның хəрбилəрчə төз, зифа гəүдəсе... Папаха һəм кара бурка, зəңгəр төстəге френч, ап-ак якалы күлмəк, кара галстук. Шулар барысы бергə күңелдə нииндидер күтəренке хислəр кузгаталар.

Комиссарның төз гəүдəсе аеруча тəэсирле чыккан. Җил белəн ачылып киткəн кара бурка күренеклə революционерның, курку белмəс комиссарның тəвəккəллеген һəм батырлыгын, хəр табигатен тагын да калкурак итеп күрсəтə. Мулланур Вахитов образын тудырганда, кайбер вак детальлəрдə автор, бəлки, документаль төгəллектəн читкə дə киткəлəгəндер, əммə аның революция эшенə хезмəт итүенең мəгънəсен һəм асылын дөрес сурəтлəгəн.

«Совет властеның беренче елларында» исемле картинасында Фəттахов, рəссам карамагындагы барлык сурəтлəү чаралары ярдəмендə, татар авылына революция китергəн яңалыкка дан җырлый, социализм төзү өчен кəраш шатлыгын раслый.

...Кояш нурларына күмелгəн авыл урамы. Яшел чирəм, зəп-зəңгəр һава. Табигать шулкадəр тын һəм саф, əйтерсең, яңа гына сафландыргыч яшенле яңгыр узган. Түбəсенə кызыл флаг кадалган йорт тирəсенə кешелəр җыела. Аз гына арырак мəчет манарасы күренə. Яңа гына азатлыкка чыккан крестьян тормышында хəзергə əле искелек яңалык белəн бергə яши. Алгы планда ике буынның ике вəкиле кызыл флаг-



*Мулланур Вахитов.*

лар тотып кила. Берсе култык таягы белән йөри, икенчесе — 12—13 яшьлек малай — китап букчасы аскан. Өлкәне, көрәшләрдә кан коеп, совет властен яулашкан, кечесе социализм төзиячәк. Йөзләрендә горурлык һәм үз-үзләренә тирән ышаныч: эксплуататорлар куылды, интервентлар җимерелде, эшче халык җиңеп чыкты!

Тәнкыйтьнең Лотфулла Фәттахов әсәрләре хакындагы фикере шактый каршылыклы. Аның һәр әсәрендә диярлек теге яки бу характердагы кимчелекләр табалар. Бернинди искәрмәсез, бертавыштан кабул ителгән әсәрләре юк диярлек. Әмма вакыт, тормыш сынавы Фәттахов әсәрләренә карата да үз төзәтмәләрен кертә тора. Гомер күбрәк узган саен, бер нәрсә ачыклана бара: рәссам кыю рәвештә зур мәсьәләләрне хәл итә. Ул — күп кеше катнашкан катлаулы композицияләр остасы, ул тұры канлы, ышандырырлык образлар иҗат итүче. Бары аңа гына хас төп сыйфатларны саклаган хәлдә, аның һәр яңа әсәре кайсы ягы беләндер яңача, көтелмәгәнчә. Еллар узу белән Л. Фәттахов әсәрләренең кыйммәте, әһәмияте һаман арта бара.

Нәгыш сәнгате (живопись) Фәттахов шөгыльләнгән бердәнбер өлкә түгел. Агитплакат һәм сатирик графика өлкәсендә дә ул уңышлы гына эшләп килә. Аның татар язучыларыннан Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, К. Нәҗми, Г. Гобәй, Г. Ахунов әсәрләренә ясаган иллюстрацияләре тамашачылар арасында зур кызыксыну уятты. Рәссамның иҗат кешеләренә багышланган «Үзебез турында» исемле рәсемнәр сериясе хакында да шуны ук әйтергә кирәк. Шулай да Л. Фәттаховның график эшләре арасында иң уңышлылары дип халык әкиятләре буенча ясалган рәсемнәрен санарга кирәктер. Фәттахов иҗатына хас реалистик стиль хәтта ул ясаган әкият геройларында да ачык күзгә ташлана. Аның барлык әкият геройлары диярлек реаль кешеләргә тартым. Әкият геройларына җир кешеләренә хас сыйфатлар салынган, аларны чолгап алган тирәлек тә вак-төяк детальләргә кадәр төгәллек саклап сурәтләнгән. («Гөлчәчәк», «Алдар таз», «Чакма таш»). Хәтта фантастик персонажларына кадәр конкрет сыйфатлары белән, тормышчан һәм ышандырырлык итеп тасвирланган.

Шул рәвешчә, татар совет сынлы сәнгатендә Лотфулла Фәттахов үз сүзен әйткән һәм зур сүз әйткән рәссам. Шул ук вакытта бөтенсоюз күләмендә дә ул танылган рәссамнардан санала. Ул РСФСР художниклар союзы идарәсенең секретаре итеп сайланды. Күптән түгел хөкүмәтебез аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде. Ул зур хыяллар, зур иҗат планнары белән яши. Аңа чын күңелдән уңышлар теләп калабыз.

# ПСЕВДОНИМНАР ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

*Псевдонимнар (мөстәгар исем, кушамат) куллану әдәбият, сәнгать, сәясәт өлкәсендә эшләүчеләр арасында киң таралган. Безнең татар әдәбияты дөньясында да псевдонимнар гаять күп. Аларның беришләре, танылган язучыларныкы булып, күпләргә мәгълүм. Икенчеләре, кайчандыр киң җәмәгатьчелеккә анык булып та, хәзерге көндә бик аз кешеләргә билгеле. Ә өченчеләре исә бөтенләй онытылган, аларның чын авторларын ачыклау мөмкин дә түгел диярлек.*

*Псевдонимнарны ачу, ягъни кушаматлар артына яшеренгән авторларның кем икәнлекләрен билгеләү, әдәбият фәне өчен цфрат кирәкле эш. Газета-журнал битләрендә, гомумән, вакытлы матбугатта кайчандыр псевдонимнар белән генә басылып чыккан күп кенә әдәби әсәрләрнең, эшлекле тәнкыйть мәкаләләренең, эпиграммаларның авторлары, күпчелек очракта, әдәбиятка олы өлеш керткән зур әдипләр һәм язучылар булганга күрә, ул әдәби материалларның чыннан да фәлән язучыныкы икәнен билгеләү белгечләр өчен дә, киң катлау укучылар өчен дә кызыксыз булмас дип уйлыйм. Дөрес, биредә китерелә торган барлык псевдонимнар да танылган, зур язучыларга карамыйлар. Азмы-күпме әдәби хәрәкәткә катнашкан, заманында татар мәдәниятенә тегеләйме-болаймы тәэсир иткән кайбер билгесезрәк кешеләрнең псевдонимнары да бирелә. Ахыр чиктә, ул псевдонимнарны бүтәннәрнеке белән бутамау өчен генә булса да, аларны да белеп тору кирәк саналды.*

*Мин псевдонимнар җыю һәм ачу белән яшьтән үк шөгыльләнәм. Мәдәни һәм әдәби үсеш үзәгендә торган күп кенә язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре белән шәхси таныш булуым да бу эштә күп ярдәм итте. Заманында Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Ибраһимов һәм башка олы язучылар, эшемне хуплап, булышлык күрсәтеп килделәр.*

*Псевдонимнарның авторларын ачыклау, алда әйткәнемчә, шактый авыр хезмәт. Аның белән җитди шөгыльләнер өчен бик күп казынырга һәм актарынырга кирәк. Кайсы язучының нинди стильдә язуын, уйлау һәм җөмлә төзү алымнарын, үзенең чыгышы ягыннан кайсы төбәкнеке икәнлеген, ул җирлектә нинди сүз-тәгъбирләр кулланылуын һәм башка бик күп моментларны ачыклагач кына дөрес нәтиҗәгә килергә мөмкин. Бу эштә, япа-ялгыз булу сәбәпле, мин, әлбәттә, мәсьәләне фәнни югарылыкта ук башкарып чыктым дип әйтә алмыйм. Мин бары тик үземә билгеле булган кешеләрнең псевдонимнарын гына теркәдем һәм алар турында, белгән кадәремчә, кыскача биографик мәгълүматлар китердем. Шуңа күрә татар әдәбиятында булган бөтен псевдонимнарны җыйдым дип дәгъва кылмыйм. Әгәр журнал укучылар үзләренә мәгълүм теге яки бу псевдонимның кемнеке икәнен ачуда булышсалар, авторлары турында белгәннәрен язып җибәрсәләр, аларга чиксез рәхмәтләр укылыр иде.*

*Псевдонимнар сүзлеге алфавит тәртибендә төзелде. Башта шәхесләрнең чын исем-фамилияләре һәм алар турында кыскача мәгълүмат бирелде, соңыннан псевдонимнары санап чыгылды.*

**МӘХМҮТ ҺАДИ.**

# ПСЕВДОНИМНАР СҮЗЛЕГЕ[1]

**Аллабердиев Габдрахман Хаҗимөхәммәт улы.** 1906 елның 29 сентябрендә Астрахань шәһәрендә туа. Танылган татар совет язучысы.

Псевдонимнары: 1. Г. Минский; 2. М. Тимербулат; 3. Г. М.

**Алпаров Гыйбадулла Хәбибулла улы** (1888—1936). Башкортстанның Корманай авылында туган. Күренекле тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор.

Псевдонимнары: 1. Г. Алпар; 2. А. Авыргазый; 3. Г. А.

**Атнагулов Сәләхетдин Садретдин улы** (1893—1937). Башкортстанның Бәләбәй өязе Суккул авылында туган. Талантлы журналист, педагог һәм галим.

Псевдонимнары: 1. С. Атнагул; 2. Азамат; 3. Сәләй; 4. Кара малай.

**Бабич Шәйхзадә Мөхәммәтзакир улы** (1895—1919). Башкортстанның Бөре районы Әсән авылында туган. Татар һәм башкорт халыкларының талантлы шагыйре. Гражданнар сугышы чорында вакытсыз һәлак булды.

Псевдонимнары: 1. Ш. Бабич; 2. Шепшә; 3. Бәбәй чүп; 4. Чытырман; 5. Таулы башкорты; 6. Башкорт; 7. Кара куз.

**Байгильдеев Шәриф Камалетдин улы** (1884—1942). Мордва АССРның Рузаевка районы Пешлә авылында туган. Татар әдәбиятының классик язучысы.

Псевдонимнары: 1. Ш. Камал; 2. Ш. К., 3. ШК.

**Башмаков Ибраһим** (1893—1913). Пенза губернасы Инсар өязе Урләдем авылында туган. Шагыйрь.

Псевдонимнары: 1. Ибраһим Б.; 2. Бикморза.

**Баянов Нур Галим улы** (1905—1945). Татарстанның Актаныш районы Әнәк авылында туган. Күренекле татар совет шагыйре, Австрияне немец фашистларыннан азат иткәндә һәлак булды.

Псевдонимнары: 1. Н. Баян; 2. Гөләндәм.

**Борһанов Сафа.** Танылган журналист. «Татарстан» газетасының редакторы булып эшләде.

Псевдонимнары: 1. С. Борһан; 2. Сабур; 3. С. Б.

**Бурнашев Фәтхелислам Закир улы** (1898—1946). Чувашстанның Бикбиш авылында туган. Танылган шагыйрь, драматург һәм тәҗрибәле журналист. Вафатыннан соң бик күп һәм бик кыйммәтле әдәби мирас калдырды.

Псевдонимнары: 1. Ф. Бурнаш; 2. Буф; 3. Физальба; 4. Кәбәй; 5. Мишәр; 6. Закир улы; 7. З. Закир; 8. Иген игүче; 9. Номерсыз урындык.

**Бәдәйли Мәхмүт Кәшфелһади улы** 1895 елда Мамадыш районының Ямашев авылында туа. Кәлке хикәяләр авторы.

Псевдонимнары: 1. Кигәвен; 2. Чытлык; 3. Гап-каһар; 4. Без; 5. Философ; 6. Әйтмим; 1. Әйтермен әле; 8. Кашфизадә; 9. Мөхбир; 10. Шәрык кигәвене; 11. Большевик; 12. Карт студент; 13. Мәхмүт һади; 14. М. Б.

**Вәлидов Җамалетдин Җамалетдин улы** (1887—1932). Татарстанның Апас авылында туган. Танылган тел галиме.

Псевдонимнары: 1. Җ. Вәлиди; 2. Җәләй.

**Галиев Мөхәммәт Вәли улы** (1893—1952). Татарстанның Балык Бистәсе районы Олы Юлга авылында туган. Танылган язучы һәм әдәбият галиме.

Псевдонимнары: 1. М. Гали; 2. Гибди; 3. Тахави; 4. Мөхәммәт Юлгави; 5. Г. Мөхәммәт; 6. Хәбәрче; 7. Мөхбир.

**Гафуров Габделмәҗит Нургани улы** (1880—1934). Башкортстанның Гафури районы Җилемкаран авылында туган. Татар һәм башкорт халыкларының классик шагыйре.

Псевдонимнары: 1. Мәҗит Гафури; 2. Ильяс; 3. Тимер каләм.

**Гыйззәтуллин Төхфәтулла Ченәкәй.** Шагыйрь һәм журналист, күп кенә шигъри әсәрләр авторы.

Псевдонимнары: 1. Ченәкәй; 2. Сәмави; 3. Яканеч; 4. Т. Ченәкәй; 5. Кеч-кенәкәй; 6. Кечкентәй; 7. Курәзә; 8. Авылчы.

**Гобәйдуллин Габделгазиз Салих улы** (1887—1938). Әдәбият галиме, журналист һәм тарихчы. Профессор.

Псевдонимнары: 1. Г. Газиз; 2. Г. Сәлман; 3. Әбү Сәлман; 4. Габделгазиз; 5. Газиз Салих улы; 6. Г. Г.

**Усманов Шамил Хәйрулла улы** (1898—1937). Куйбышев өлкәсенең Пәндәлкә авы-

---

[1] Кыскартып басыла. **Редакция.**

лында туган. Күренекле татар язучысы һәм җаваплы хәрби эшләр башкарган кеше.

Псевдонимнары: 1. Шамил Госманов; 2. Тарикъ; 3. Батырша; 4. Рәисә; 5. Исрафил.

**Мәрҗани Мәхмүт Галәветдин улы** (1887—1937). Татарстанның Арча районы Ташкичү авылында туган. «Ник язылганнар», «Мөһаҗирләр», «Болганчык» һәм башка әдәби әсәрләр авторы.

Псевдонимнары: 1. Мәхмүт Мәрҗани; 2. Мәхмүт Галәү; 3. Мин; 4. Мин сиңайтим.

**Ибраһимов Галимҗан Гыйрфан улы** (1887—1938). Башкортстанның Авыргазы районы Солтанморат авылында туган. Татар халкының классик әдибе. Зур галим һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе.

Псевдонимнары: 1. Габди; 2. Гыйрфан улы; 3. Гыйрфанзадә; 4. Г. җан Ибраһим; 5. Мөхбирегез; 6. Г. И.

**Камалетдинов Галиәсгар Галиәкбәр улы** (1879—1933). Казан шәһәрендә туган. Татар әдәбиятының классик драматургы.

Псевдонимнары: 1. Г. Камал; 2. Ишан; 3. Әүлия; 4. Ишангали; 5. Кызыл; 6. Сонп; 7. Зәйнәп Камалетдинова; 8. Сагыйка; 9. Һади; 10. Барика; 11. Яшенче; 12. Г. Казани; 13. Г. Камалетдинова; 14. Г. К-ва; 15. Г. К.

**Коләхметов Габделгафур Юныс улы** (1881—1918). Пензада туган. Танылган революционер, күренекле драматург.

Псевдонимы: 1. Татарин театраль.

**Кутуев Гаделша Нурмөхәммәт улы** (1903—1945). Саратов өлкәсенең Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында туган. Танылган прозаик, шагыйрь һәм тәнкыйтьче. Бөек Ватан сугышы бетәр алдыннан гына Польшада һәлак булды.

Псевдонимнары: 1. Гадел Кутуй; 2. Казбек; 3. Утмалай; 4. Һималай; 5. Руслан; 6. Тимерче малае; 7. Әкәлим гөләп.

**Кәримов Фатих Вәли улы** (1909—1945). Башкортстанның Бишбүләк районы Аеп авылында туган. Татар поэзиясендә зур урын тотучы талантлы шагыйрь. Ватан сугышында һәлак булды.

Псевдонимнары: 1. Фатих Кәрим; 2. Рим; 3. Дим; 4. Мирәк; 5. Ф. К.

**Кәримов Хөснетдин Минһаҗетдин улы** (1887—1965). Башкортстанның Туймәрза авылында туган. Педагог, җәмәгать эшлеклесе һәм язучы.

Псевдонимнары: 1. Хөсни Кәрим; 2. Кузәтүче; 3. Кайгыртучы; 4. Х. К.

**Рәхмәтуллин Габдрахман Хәбибулла улы** (1878—1947). Журналист һәм театр тәнкыйтьчесе.

Псевдонимнары: 1. Габдрахман Кәрам; 2. Г. Кәрам; 3. Әкъмәли.

**Көеков Мөхәммәтгали Габдессалих улы** (1826—1886). Башкортстанның Иске Чокыр авылында туган. Шигъри әсәрләр авторы.

Псевдонимы: 1. Гали Чокрый.

**Максудов Мәхмүт Гыйсаметдин улы** (1900—1963). Татарстанның Теләче районы Югары Кибәхуҗа авылында туган. Танылган татар совет язучысы.

Псевдонимнары: 1. Мәхмүт Максуд; 2. Нур; 3. Тәлгат; 4. Кызыл солдат; 5. Магис; 6. Әптери малае; 7. Мим.

**Манатов Шәриф Әхмәтҗан улы** (1892—1936). Башкортстанның Манат авылында туган. Революция елларында Мулланур Вахитовлар белән бергә эшләде.

Псевдонимнары: 1. Ш. Манатов; 2. Ш. Әхмәтҗанов, 3. Гайнетдин.

**Мифтахетдин Мөхәммәдьяр улы** (1831—1895). Башкортстанның Туксанбай авылында туган. XIX йөзнең танылган шагыйре.

Псевдонимы: 1. Акмулла.

**Мостакаев Гадбелкаюм Габдерәхим улы.** 1885 елда Ульяновск өлкәсенең Иске Зелёный авылында туган. Күп еллар буе «Татарстан» газетасында эшләде. Хәзер пенсиядә.

Псевдонимнары: 1. Каюм Рәхим; 2. Рәхим; 3. Әхмәди К; 4. Гөлгазар; 5. Ил мөхбире; 6. Мөгаллимә Гаян.

**Мәүлетов Сәхаб Камал улы** (1907—1957). Ульянов өлкәсенең Кече Кандал районы Тат. Урайкино авылында туган. Татар совет шагыйре.

Псевдонимы: 1. Сәхаб Урайский.

**Мөхәммәдов Шакир** (1865—1923). Оренбургта чыккан «Карчыга» исемле көлке журналның нашире һәм редакторы. Хөсәен Ямашевның дусты.

Псевдонимнары: 1. Авыл кешесе; 2. Кайчылы; 3. Бичура; 4. Мышьяк; 5. М. Ш.

**Нуркин Зәһидулла Садретдин улы** (1889—1966). Мордва АССРның Сыркыды авылында туган. Революциядән соң Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итүчеләрнең берсе.

Псевдонимнары: 1. З. Нуркин; 2. Дәрвиш; 3. Парчинский.

**Нәҗметдинов Кави Һибәтулла улы** (1901—1957). Горький өлкәсенең Петрякс районы Красный Остров авылында туган. Танылган татар совет язучысы.

Псевдонимнары: 1. Кави Нәҗми; 2. Каҗ; 3. Кам; 4. Канәҗ; 5. Кангазәл.

**Рахимов Мөхәммәтгали Шакир улы** (1892—1938). Татарстанның Арча районы Мәңгәр авылында туган. Әдәбият тарихчысы һәм тәнкыйтьче, күп кенә хикәя һәм повестьлар авторы.

Псевдонимнары: 1. Гали Рахим; 2. Р. Гали; 3. Р. Габдрахманов; 4. Гөлгазар; 5. Бикчәнтәй улы.

**Рахматуллин Габделбари Сибгатулла улы** (1897—1957). Гурьев өлкәсе Жилая Коса поселогында туган. Танылган балалар язучысы.

Псевдонимнары: 1. Бари Рәхмәт; 2. Б. Сибгат; 3. Рахматулла малае; 4. Сибгат Бари.

**Сагдетдинов Габдрахман Гайнан улы** (1889—1942). Әдәбият белгече, профессор.

Псевдонимнары: 1. Габдрахман Сәгъди; 2. Зәукый; 3. Фикри; 4. Рухи.

**Сүнчәләй Сәгыйть Хәмидулла улы** (1889—1941). Танылган шагыйрь, Г. Тукайның дусларыннан берсе.

Псевдонимнары: 1. Сәгыйть Вәккас; 2. Сәгыйть Әбүлфәрит; 3. Әбүл Ваккас; 4. Хәмит.

**Сәйфуллин Фатих Камалетдин улы** (1888—1939). Танылган язучы һәм әдәбият галиме.

Псевдонимнары: 1. Фатих Сәйфи-Казанлы; 2. Исәнбай; 3. Бакыр күз; 4. Батыр күз; 5. Гәрби; 6. Ф. Камалова.

**Сәйфетдинов Галимҗан.** Күренекле большевик Хөсәен Ямашевның якын дусты.

Псевдонимнары: 1. Гассан; 2. Баязит; 3. Баязитов.

**Такташев һади Хәйрулла улы** (1901—1931). Мордва АССРның Тарбеева районы Сыркыды авылында туган. Татар халкының сөекле шагыйре.

Псевдонимнары: 1. һади Такташ; 2. Аллан; 3. Мокамай; 4. Камай; 5. Шагыйрь № 1; 6. Ата шагыйрь; 7. Чабата; 8. Мокамайның якын кардәше; 9. һадия Такташева; 10. Точка; 11. h. Т. таш; 12. Атакай; 13. һадия Хәйрулла кызы; 14. Хәйрулла малае.

**Тахтамышев Нәҗип Сибгатулла улы** (1883—1933). Татарстанның Аксубай районы Яңа-Дума авылында туган. Педагог һәм шагыйрь.

Псевдонимнары: 1. Нәҗип Думави; 2. Өй анасы; 3. Әбүл Фаикъ; 4. Чистаполи; 5. Домовой.

**Таһиров Афзал Мөхетдин улы** (1890—1938). Татарстанның Әлмәт районы Габдрахман авылында туган. Күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе.

Псевдонимы: 1. Бичура.

**Тукаев Габдулла Мөхәммәтгариф улы** (1886—1913). Татар халкының бөек шагыйре.

Псевдонимнары: 1. Г. Тукай; 2. Шүрәле; 3. Тик тормас; 4. һәд-һәд; 5. Бичура; 6. Феакут; 7. Имам Хатип; 8. Имзасыз да Ярәретдинов; 9. Тәнкыйть сөюче; 10. Бик усал; 11. Т. Г. Т.; 12. Мин язмадым; 13. Гөмберт; 14. Кыйсасыль Әнбия-Рабгузи; 15. Кырмыска; 16. Милләтче; 17. Мәҗнүн; 18. Сөемсез; 19. Ишан менкире; 20. Хаятел хайванаттан кучерүче; 21. Догачы шүрәле; 22. Сәгыйт Аннук Самакай малае.

**Туктаров Идрис Ильяс улы.** 1896 елда Башкортстанның Сәфәр районы Булышлы авылында туа. Татар совет язучысы.

Псевдонимнары: 1. Идрис Туктар; 2. Җамакай; 3. Кучкар егете; 4. Мәртәт; 5. Әлеф.

**Фәйзуллин Әхмәт Әхмәтсафа улы** (1903—1958). Уфа шәһәрендә туган. Танылган татар совет әдибе.

Псевдонимнары: 1. Әхмәт Фәйзи; 2. Әхмәт Фәез Идел; 3. Фәез Идел; 4. Кызыл җырчы; 5. Зәңгәр Әхмәт.

**Ямашев Хөсәен Минһаҗетдин улы** (1882—1912). Казанда туган. Татар халкының атаклы революционеры.

Псевдонимнары: 1. Али; 2. Гали; 3. Кызыл; 4. Сул; 5. Вәли.

**Әмиров Кәрим Хөсәен улы** (1893—1962). Башкортстанның Тәтешле районы Булканнан авылында туган. Шагыйрь һәм журналист.

Псевдонимнары: 1. Кәрим Әмири; 2. Карт чаян; 3. Черки; 4. Борча; 5. Кәлай; 6. Әрәм; 7. Хәбәрче трест.

**Әмирханов Фатих Зариф улы** (1886—1926). Казанда Яңа бистәдә туган. Татар халкының классик язучысы.

Псевдонимнары: 1. Фатих Әмирхан; 2. Дамелла; 3. Ташмөхәммәт; 4. Замзаметдинов; 5. Т-д; 6. Имгәк; 7. Марксист; 8. Әүлия углаһдан бер залим.

**Җәлилов Муса Мостафа улы** (1906—1944). Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туган. Татар халкының бөек шагыйре һәм герой улы. Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы герое.

Псевдонимнары: 1. Муса Җәлил; 2. Җәлил; 3. М. Мостафа малае; 4. Шахмат.

# КАНАТЛАР КАЯ ИЛТӘ?

Хыялымда үземне, аз гына вакытка булса да, укучы бала итеп хис итәм. Менә, мәктәптән кайтышлый, китап кибетенә керәм. Нинди китаплар кайтты икән — яңалары, кызыклары. И-и-и! Күп икән алар монда... Шунда, ничектер, бер китапның тышлыгына игътибар иттем. Күгелҗем фонда — ак җилкәнле ялгыз көймә. Мачта тирәсендә бер кош канатын җәйгән. Китапның исеменә, авторына күз төште: «Канатлар кая илтә?» Гариф Ахунов. Тиз-тиз китапның битләрен актара башладым. Теге биттән, бу биттән аерым җөмләләргә күз төшереп үттем. Менә бер җирдә: «Булат Әлмәт шәһәренең иң зур, иң якты мәктәбендә алтынчы класста укый», диелгән. Димәк, әсәрдә сүз нефтьчеләр турында бара икән. Нефтьче була инде бу Булат.

Тагын караштырам. Әй, юк икән... «Әкият батыры ничек туган илгә кайтты» дигән бүлеккә күз йөртеп чыктым да, Муса турында икән бу дип уйладым. Әнә, «Җәлил» дигән махсус бүлек тә бар икән. Тагы — Михаил Девятаев, Газинур Гафиятуллин, генерал Сафиуллин, Брест каһарманнары, 165 герой... Әнә, безнең илне фашистлардан саклап калган үлмәс батырлар турында икән бу китап. Укырга яратам мин андыйларны.

Тагын битләр актарам, тагын укыйм: «Татарстан кырларында дүрт меңгә якын скважина фонтан атып тора... Советлар Союзында чыгарыла торган барлык нефтьнең өчтән берен Татарстан бирә»... Юк, башлыча нефтьчеләр турындадыр, ахры, бу китап. Булат та, Зиннур да, капитан да, профессор да булмаслар, ә Корбан Вәлиев, Михаил Гринь кебек атаклы нефтьче булырлар, аларның даннары бөтен илгә таралыр!

Алай дисәң, бик борын-борын заманнар турында да язылган анда. Алтынчы гасырлар... унынчы гасырлар... Болгар ханлыгы, Казан ханлыгы, Пугачев явы, революцион хәрәкәт, Октябрь җилләре. Тарихи китап булып чыга түгелме? Булат белән Зиннур да юкка чыктылар бит. «Әле ул чакта Булат белән Зиннур дөньяда булмаганнар. Аларның әтиләре дә булмаган. Бабалары, хәтта җиденче буын бабалары да булмаганнар». Шулай да, нәрсә турында булыр икән бу китап? Шунда китапның төрле язуларын яңадан карый башлыйм. Әһә, «Туган җир турында повесть» диелгән икән һәм «Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен» дип тә күрсәтелгән. Димәк, нәкъ менә минем өчен язылган икән бу китап. Ә нәрсә турында икәнен тәгаен белү өчен, аны баштан ахырынача укып чыгарга кирәк... һәм мин аны, өйгә алып кайтып, бик җентекләп укып чыгам: урта яшьтәге мәктәп баласы булып та, шушы рецензияне язучы булып та.

Башта ук әйтеп китим: һәр икебезне кызыксындырды ул. Китап кибетендә битләрен актарганда игътибар ителгән төрле-төрле вакыйгалар, кешеләр, эшләр, чорлар чыннан да барысы да бар анда. Ләкин алар, башта бик күп төрле һәм таркау булып күренсәләр дә, оста кул белән бер җепкә тезелгәннәр, һәм ул җепнең очы Булат белән Зиннурда. Туган җир турында, Татарстан турындагы повесть әнә шундый үзенчәлекле, мавыктыргыч формада язылган. Еллар һәм чорлар буйлап, шәһәрләр, авыллар буйлап, күп кешеләр һәм аларның эшләре белән танышып, без шул ике малай белән бергә кызыклы сәяхәт итеп йөрибез... Китап туган илебезне, туган җирләребезне — үткәнен һәм бүгенгесен — киңрәк, тирәнрәк, тулырак белергә-өйрәнергә өнди, аның кадерен белергә, аны ярату көчен арттыруга булыша, аның данын, куәтен тагын да үстерү өчен, аны дошманнардан саклау өчен, тарихи зур юл үткән ата-аналар эстафетасын, Чапайлар, Мусалар байрагын югары күтәреп бару өчен үз-үзеңне аямыйча көрәшергә кирәклеген дә гел искә төшереп тора.

Әйткәнебезчә, китап, асылда, Татарстан тарихы, татар халкы тарихы, халыклар

дуслыгы турында. Әмма ул балалар өчен язылган, һәм аны әдип язган. Шуңа күрә дә ул гади тарих китапларыннан, мәктәпләрдә укыла торган тарих дәреслекләреннән аерылып тора. Анда, тарихны сөйләп күрсәтеп бирү өчен, үзенчәлекле, уңышлы мавыктыргыч алымнар кулланылган.

Булат белән Зиннур исемле ике укучы малай тарих дәресен яраталар, аның белән нык кызыксыналар. Аларның бу кызыксыну-мавыгулары шуңа барып житә ки, үзләренең исемнәрен дә тарихка кертеп калдырырга уйлыйлар. Тарих дигәнебез шуннан башланып китә дә. Ике малайның уйлары һәм эшләре, төрле сәяхәтләре һәм мажаралары аша автор укучыга кызыклы итеп, мавыктыргыч итеп тарих дәресе бирә.

Монда китапның эчтәлеге турында сөйләп торуның кирәге юктыр дип уйлыйм. «Татарстан дигән ил кайда?», «Батырлар ватаны», «Үткәннәргә сәяхәт», «Ике бәйрәм, ике туй», «Шәһәрләр сөйләшә» — болар китап бүлекләренең исемнәре. Шушы бүлек исемнәре һәм С. Хәким, Г. Тукай, Ф. Кәрим, Х. Туфан, Н. Исәнбәт, Ә. Давыдовларның һәр бүлек алдында эпиграф итеп китерелгән шигырьләре аның эчтәлеген, колачын, язылу стилен күрсәтеп торалар.

Татарстанны, аның тарихын, үсешен автор безнең бөек Ватаныбыздан аерып алып түгел, ә аның аерылмас органик бер кисәге итеп күрсәтә алган. Моның да үзенчәлекле алымнары бар. Менә Булат белән Зиннур алларына Татарстан картасын җәеп салганнар. Зиннур республикабызның зурлыгы, киңлеге, анда күпме шәһәр, район булуы турында мәгълүм саннарны сөйли. Булат аны туктата. «Профессорларча килеп чыга, гел цифрлар гына, болай ярамый», ди. Син шуны әйт әле, 67 мең квадрат километр дигәнең азмы, күпме ул?.. Бу сан конкретлаштырыла: Татарстан җирләре ике Бельгия, дүрт Израил мәйданы хәтле икән. Татарстанны илебезнең башка республикалары белән дә чагыштырып чыгалар... Шунда кинәт бер ачыш та ясала! Сәнгатьчә алым буларак кызыклы һәм әһәмиятле бу урынны китапның үзеннән күчереп китмичә һич булдыра алмыйм.

«Булат дустының сүзләрен картадан күзен алмый тыңлап утырды. Кинәт ул сөенеп кычкырып җибәрде:

— Кара әле бер генә. Күрәсеңме менә моны?

— Нәрсәне? Нәрсәне? — диде Зиннур, аңламыйча.

— Соң картаны әйтәм бит инде.

Зиннур, күзлеген сөртә-сөртә, Татарстан картасына озак кына карап торды, ләкин берни дә аңламыйча, җилкәсен сикертеп куйды.

— Юк, син ныгытыбрак кара. Күрмисеңмени, Татарстанның чикләре гел менә Советлар Союзының чикләре төсле бит.

Бу ачыштан шаккатып калган Зиннур тагын бер тапкыр күзлеген сөртеп киде.

— Кызык! Кара син аны! Алайса, болай була: зур ил — әнисе, кечкенә ил — аның баласы! Дөресме? — диде ул, Булатка төбәлеп.

— Бик дөрес, нәкъ шулай! — диде Булат, дустының сүзләрен хуплап» (20—21 битләр).

*Җиңел дә, балаларча да, ә нинди тирән эчтәлекле эпизод!*

Зиннур белән Булат үзләренең туган якларын өйрәнәләр, аның кешеләрен, аерым әһәмиятле вакыйгаларын бүгенгенең тарихы итеп кәгазьгә, рәсемгә, магнитофон тасмасына терки барып, шуның белән үз исемнәрен дә тарихка кертеп калдыру турында хыялланалар. Ләкин, балаларга хас булганча, шул эшләрнең барысын да беркемгә белдермичә, яшертен алып баралар. Әсәрнең мажаралы моментлары әнә шул серлелеккә бәйләнгән.

Җыйналган материаллар күбәя баргач, аларны каядыр яшерергә, инде күмеп үк куярга вакыт, дигән карарга киләләр. Моның өчен мәктәпнең ярым ташландык подвалын иң җайлы урын дип табалар, кыйммәтле төргәкләрен шуның идән астына күмәләр. Ләкин аларның бу эшләре ачыла һәм алар кайберәүләр тарафыннан җинаятьчелектә гаепләнәләр: «Стена җимереп, подвал басалар диген, ә!» ди бер укытучы. Әмма, аларның күмеп яшергән төргәкләрен табып алып, андагы материаллар белән танышкач, вакыйга икенче юнәлеш ала һәм, директор бүлмәсендә бу мәсьәләгә багышлап үткәрелгән махсус киңәшмәдә, малайларны яклап калалар...

Китапның характерлы, үзенчәлекле бер ягы тагын шунда, ул бик конкрет бер җирлектән торып язылган. Бу — Әлмәт. Китапның катлаулы, әтрафлы сюжетын бергә туплый торган Булат белән Зиннур — Әлмәт мәктәбе укучылары. Китап Әлмәт белән башлана, Әлмәт белән тәгаалләнә. Татарстанның бөтен тарихын, үткәнен һәм бүгенгесен, шәһәрләрен һәм авылларын, экономикасын һәм культурасын, әдәбиятын һәм сәнгатен, төрле өлкәләрдәге атаклы кеше-

ләрен кызыклы формада сөйләп биргән. Бу китап бик конкрет жирлектән торып, шуңа акцент ясап язылган. Моңа каршы бер сүз дә әйтеп булмый. Дөрес эшләгән автор, үзе яхшы белгән-өйрәнгән, үз иткән-яраткан жирлектән торып язган. Әгәр шулай булмаса, ихтимал, без аның интонациясен, кан тибешен тиешенчә тоя алмый калган да булыр идек. Аннары, шунысы да бар бит: Әлмәт, республикабызның күзгеләреннән берседәй булып, бер тамчы суда зур дәрьялар чагылганы кебек, Әлмәт хәтле Әлмәттә, аның тарихында, аның үсеш темпларында, аның торган урынында безнең Татарстаныбыз үзе чагыла түгелме?! Шулай бу.

Китапның кимчелекле яклары бармы?

Аз гына булса да, алары да бар икән. Әсәр баштанаяк диярлек бер сюжетка корылган, аны Булат белән Зиннур уйлары, эшләре, мажаралары белән бәйләп алып барыла. Отышлы алым. Әмма монда эзлеклелек юк. Менә без татар халкының килеп чыгышы, үсеш тарихы, Россиядә Октябрь жилләре башлану турында укыйбыз. Аерым бүлекләре бу зур тарихның аерым этапларына багышланган. «Чал тарих ни сөйли» бүлегендә алтынчы гасыр, унычы гасыр, Болгар ханлыгы, Казан ханлыгы турында сүз бара. Әмма малайлар — Булат, Зиннур — юк. Автор баштанаяк үзе сөйли. «Ямалкә тавы» бүлегендә — исеменнән үк күренеп тора — Емельян Пугачев житәкчелегендәге крестьяннар хәрәкәте, анда Идел буе халыкларының, татарларның катнашы турында бәян ителә... Ә безнең малайлар һаман юк. «Азатлык жилләре» бүлегендә, шулай ук исеменнән үк аңлашыла, Октябрь революциясенә хәзерләнү еллары турында сөйләнелә. Балалар биредә дә юк.

Шулай итеп, китапның бу өлеше үзенең язылыш алымы ягыннан, ничектер, аерылып тора, гади тарих язу формасында алып барыла. Ә бит ул бүлекләрнең һәркайсын шул ук Булат, Зиннур уйлары аша да бирергә мөмкин булыр иде һәм ул чакта озынга сузылган бу тарих (100 биттән артык) уңышлы башланган һәм соңра да шулай дәвам иттерелгән сюжетның аерылмас бер кисәге булып калыр һәм укылыр иде. Булат белән Зиннур Казанда, Үзәк музейда булганда да экспонатлар яныннан йөгереп кенә үтәләр кебек. Ә бит татар халкының, Татарстанның китапта башта коры сөйләнгән тарихын күрсәтүдә нәкъ менә шул унайдан файдаланылган булса, малайлар читтә торып калмаган булырлар иде.

Шундый ук кимчелек Девятаев биографиясенә дә хас. Гомуми жанлы, динамик стильдән аерылып тора. Ул гел үзе сөйли, озын итеп сөйли. Хикмәт аның 20 биткә сузылуында да түгел: таң калырлык батырлыклар эшләгән герой ул Девятаев. Һәм аның турында тагын күбрәк һәм озынрак итеп тә сөйләргә мөмкин. Тик аны шулай ук малайлар кичерешләре белән аралаштырырга мөмкин иде. Ә автор малайларның магнитофонны көйләп, язып алулары белән генә чикләнгән. Аннары «капонир», «струбцин» кебек аңлашылмый торган сүзләр дә очрый анда.

Малайларның «подвалны басып керү»ләре жинаять түгел, ә бик кызыклы, патриотик эш икәне ачыклангач, тарих укытучысы Бари абый Янчурин, башка классларның да житәкчеләре белән бергә, пионерлардан кызыл эзтабарлар төркеме оештыра. Алар, штабтан махсус задание алып, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Жәлил шәһәрләре пионерлары белән хат язышa башлыйлар. Кама буе шәһәрләренә — Алабугага, Чистайга, Чаллыга, Зәйгә дә шундый хатлар китә. «Ләкин боларның барысы да хәзергә яшерен рәвештә эшләнде,—дип яза Г. Ахунов. — Булат белән Зиннур бу хакта берни белмиләр». Мәктәптә ниндидер яңа хәрәкәт башлануы турында алар нәрсәдер сизенәләр, әлбәттә. «Ләкин безнең яшь тарихчылар, — дип дәвам итә автор, — күпме генә тырышсалар да, иптәшләренең серен әйттерә алмадылар. Аларны гүя бөек бер ант берләштерә, һәм алар берни әйтергә теләмиләр иде» (111 бит).

Башта ике малайның — Булат белән Зиннурның — үз эшләре турында сер саклаулары аңлашыла. Ул мөмкин һәм ышандыра. Шулай кызыграк, мавыктыргычрак та булып чыга. Әмма бөтен мәктәп күләмендә укытучылар житәкчелегендә үткәрелә торган зур эшне Булатлардан сер итеп яшертен эшләү ышандырмый, моның кирәге дә юк.

Гомумән алганда уңышлы, кирәкле, файдалы бу китап бер генә тапкыр басылып калмас, укучылар, бигрәк тә яшьләр, мәктәп балалары тарафыннан аңа сорау күп булыр дип уйлыйм. (Китап Мәскәүнең «Детгиз» нәшриятында рус телендә дә басылды.) Шуңа күрә дә, икенче басмаларын хәзерләгәндә, автор аны яңадан карап чыгар, әйтелгән кимчелекләрне төзәтер, урыны-урыны белән яңартыр, өстәр әле, дип ышанырга кирәк.

Башта китапның тышлыгы турында берничә сүз әйтелгән иде. Тагын шуны әйтисе килә: бу китапның эчке һәм тышкы оформлениесендә художник И. Язынинның хезмәте зур. Киң диңгездә җилфердәп торган җилкән, ана тоташып җәелгән кош канатлары — яхшы символ ул. Булатның капитан булырга хыяллануы — тышкы ассоциация генә. Ә тирән эчтәлек — китапның үзендә, аның азагында. Бер төркем мәктәп балалары туган ил буйлап походка чыгып китәләр. Аларны юлга озатканда, Бөтенсоюз походының үзәк штабы вәкиле атаклы генерал сөйли: «...Бабаларыгыз һәм әтиләрегез сезгә зур мирас калдыралар. Завод-автоматлар һәм яңа калалар, университетлар һәм театрлар, атом бозваткычлары һәм радио башнялары...

Сез бай мирас аласыз! Ләкин әле бу без калдыра торган байлыкның иң зурысы түгел. Фән йортларында белем алып, хезмәт иясе халкы җыйган тәҗрибәне кабул иткәч, сез канатлы буласыз. Ләкин канатлар кая илткәнне сез белергә тиешсез. Әгәр әтиләрегезнең батырлыгын, хезмәт яратуын, илгә һәм партиягә турылыгын мирас итеп алсагыз, әгәр Ленин идеяләренә гомер буе турылыклы булып калсагыз — әнә шул чагында сез чын мәгънәсендә канатлы булырсыз! Хәерле юл сезгә!»

Китапны укып чыккач, без дә барлык яшь укучыларга, иртәгесе көннең төзүчесе һәм хуҗасы булачак яшь канатларга, хәерле юл телибез. «Канатлар кая илтә?» дигән сорауга җавап бер: катлаулы тормыш диңгезендә ата-аналар үткән данлыклы юл буйлап, тагын да яктырак, тагын да бәхетле, шатлыклырак киләчәккә — коммунизмга илтә ул канатлар.

**Газиз ИДЕЛЛЕ.**

# ДИҢГЕЗ ЭЗЛИМ

Китап киштәләренә ай саен диярлек дистәләгән яңа шигырь җыентыклары өстәлеп тора. Һәрбер яңа җыентык — укучы өчен шатлык. Әгәр дә электән яратып укыган шагыйрьнең яңа җыентыгын очратсаң, куаныч икеләтә арта.

Рәдиф Гатауллин да менә берничә ел инде укучыларны үзенең җыентыклары белән куандырып килә. Шигырь — заманның поэтик һәм интеллектуаль көзгесе ул; бигрәк тә яшьләрнең канатлы аты, моңлы сазы. Шигырьләрдә һәр буын үзенең уйхисләрен, каршылыкларын, интеллектын һәм идеалларын чагылдыра.

Рәдиф Гатауллинның «Диңгез эзлим» исемле яңа шигырьләр җыентыгы турында сүз алып барганда, аның элек дөнья күргән җыентыкларын искә алмыйча китеп булмый. Бу өч җыентык шагыйрьнең өйрәнү, үсү дәверен гәүдәләндерәләр һәм темалары, материалы, композицияләре буенча шигъри трилогия хасил итәләр. Киләчәктә аларның бер тышлык эчендә дөнья күрүләре дә бик мөмкин.

Беренче «Гөлләр су сорыйлар» исемле җыентыгында шагыйрь күп нәрсәгә хыял, романтика күзлегеннән карый иде әле. Бу аның шагыйрәнә балалыгы иде. «Кояшлы утраулар»ында ул инде тупланылган тормыш тәҗрибәсе нигезендә хыял белән тормыш фактларын синтезлаштыра башлады. Кайбер хыяллары тормышка ашу ал-




дында торды. Аның хыял белән союзы нык әле һәм «бик күрәсе килә диңгезне». Бусы аның шагыйрәнә яшьлеге.

Ә без сүз алып бара торган өченче җыентыгында исә күп кенә тормыш кануннарын татыган, тәҗрибале, батыр горуррак та, күрәшкә сәләтле шәхесне күрәбез. Ул инде диңгезне дә күргән. Ә хыялга ул гына житми, хәзер аның «бик ошыйсы килә Диңгезгә». Шагыйрьнең хыялы куып житкесез тиз йөгерә;

> **Гомер бакый**
> **булган — ышанганнар,**
> **булган — алданганнар.**
> **Хыяллар, чынлык, дуслар, яшәү-язмыш**
> **күп чак алдаганнар.**

Хыял шагыйрьне алдап та өлгергән. Балки, алдануда үзе гаепледер, ләкин барыбер шагыйрь өчен бу дөнья куркыныч түгел. Ул кешегә, аның ихтыярына һәм көченә ышана, чөнки шул кешеләр:

**...Мең мәртәбә алданып та,**
**Мең дә беренче очракка**
**барырга көч табалганнар.**
**Уйлан, каләм:**
**әнә шундый кешеләр бугай**
**шагыйрь дигән ат алганнар!**

Бу өченче җыентык яшьлек белән саубуллашу шикелле. Ләкин хыял белән түгел. Хыял мәңгелек юлдаш, тик көчлеләр генә хыялны тормышка ашыра алалар дип әйтергә тели шагыйрь.

«Дингез эзлим» җыентыгы ике бүлектән тора. Һәрберсендә исемсез шигырьләр — лирик уйланулар күп. «Гомер бакый бул ган — ышанганнар»..., «О, күңелнең көче...» «Буй-буй кофта... зәңгәр күлмәк...» «Бала чак истәлеге...», «Мин элекке һаман...» шигырьләрендә көчле ассоциация һәм кабатланмас поэтик картиналар тудырылган. Бу шигырьләр үзләренең тирәнлеге, сәнгатьлелеге белән аерылып тора.

«Чао аморе» шигырен шагыйрь буржуаз чынбарлык, буржуаз җәмгыятьтәге сәнгать һәм сәнгать кешеләре язмышы трагедиясенә полемика рәвешендә корырга теләгән. Үз максатына ирешә дә язган, ләкин шигырьне, иниктер, «Без оптимист» дигән декларатив аваз белән тәмамлаган. Оптимистларда каршылыклы, хәтта аянычлы мәхәббәт булмыймыни?.. Үзенең идеясен дәлилләү өчен шагыйрь бу әсәрендә тиешле сәнгать алымнарын тапмаган, хакыйкать һәм сәнгать законнарына хыянәт иткән.

Рәдиф Гатауллин шигырьләренең отышлы ягы — аларның самимилегендә, безгә якын уй-хисләрне дулкынлану, шигъри аһәң белән яңадан үзебезгә җиткерә белүендә.

Ләкин аның кайбер шигырьләрен укыганнан соң шундый тойгы кала: әйтерсең лә бу шигырьләр чынбарлыктан килмиләр, кайдандыр, киштәдәнме, сикереп төшкәннәр. Шуңа күрә аларның ышандыру көче азрак, күңелдә үк янып бетәләр, багажлары җиңел, фейерверк шикелле генә.

Бу җыентык Рәдиф Гатауллин иҗатының беренче, башлангыч чорын тәмамлый кебек. Яңа китабы белән ул безгә үзен икенче, без әле белмәгән яктан күрсәтергә тиеш. Зур тормышта бары шуңа сәләтлеләр генә «шагыйрь дигән ат алганнар».

**Фатих МАКАЕВ.**

# СОЛДАТ ХАТЛАРЫ




«...Бу хат сентябрь ахырында Болгар илендә языла башлаган иде. Җөмлә уртасында диярлек бүленеп калды. Менә хәзер мин аны декабрь ахырында Мажар җирендә тәмам итәм. Моңар син, һәрхалдә, ачуланмассың. Бу хатның бик зур бер үзенчәлеге бар: аның языла башлавы белән язылып бетүе арасында өч айдан артык вакыт үтте, һәм ул үзе, минем кыр сумкасында бер дә ашыкмый ятканы хәлдә, Шипкада булды, берничә башкала күрде, берничә тапкыр Дунайны кичте... Югалтма син аны, Фәйзи! Әгәр синнән элек үлсәм — икебезгә дә кимендә җитмешәр ел гомер телим — иптәшләргә укырсың...»

Бу юлларны мин әле шушы көннәрдә генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Солдат хатлары» исемле китаптан, Мәхмүт Максуд хатыннан күчереп алдым. Ул аларны каләмдәше һәм дусты әдип Әхмәт Фәйзигә язган.

Әйе, хат озак язылган. Әмма бу бер дә гаҗәп түгел. Чөнки кызу сугыш вакытында, дошман белән йөзгә-йөз бәрелеш барганда, солдатның хәтта кош теле кадәр генә хат язып салырга да вакыты булмады. Солдат хатларының барысы да диярлек бер кулы-

на мылтык тоткан хәлдә окопларда язылган. Ул хатлар бик кыска. Әмма алардан кайнар хис, йөрәк жылысы бөркелеп тора. Язылуларына инде чирек гасыр үткән булса да, алар әле дә күңелне тетрәтәләр һәм Совет солдатлары сугышның беренче айларында кичергән кыенлыкларны да, дошманны куа башлаган көннәрдәге куанычлы минутларны да, ниһаять, җиңү шатлыгын да бик ачык итеп күз алдына китереп бастыралар.

Җыентыкка кертелгән хатлар язучылары буенча да, хәрби дәрәҗәләре буенча да төрле кешеләр тарафыннан язылган. Семьяга, туган-тумачаларга адресланган хатлар да, бөтен бер колхоз яисә предприятие коллективларына атап язылган хатлар да бар монда. Ләкин әнә шул хәрби дәрәҗәләре, яшьләре һәм белемнәре төрле кешеләр тарафыннан язылган хатларның барысына да бер уртак сыйфат хас: аларның һәркайсы туган илгә чиксез мәхәббәт, дошманга ачы нәфрәт һәм җиңүгә ышану хисе белән сугарылган. Хәтта сугышның безнең Совет Армиясе өчен иң кыен булган беренче айларында, фашистлар Мәскәүгә якынлашкан көннәрдә язылган хатларда да берниндн шик яисә күңел төшенкелеге сизелми. «...Гайшә! Син миннән кайсы якта, нинди шәһәр янында торасыз дип сорыйсың. Мин сиңа алдагы хатымда язган идем, без Көнбатыш фронтта, безнең житәкчебез иптәш Тимошенко. Безнең янда Великие Луки, Ржев дигән шәһәрләр урнашкан, безгә Мәскәү 400 километр гына. Без Мәскәүне саклыйбыз!

Гайшә! Сугыш әле көннән-көн кыза гына. Кайтулар, исән булсак та, тиз генә булмас дип уйлыйм. Мин бу хатны да үзебез торган җирдән 90 километр читтә язып бетерергә туры килде. Командировкага барганда, машина батылып, урман эчендә утырабыз. Сәгать 5 тә чыккан идек, хәзер инде кичке 8 инде, ашаган-эчкән юк, ә син жылашабыз дип язасың. Җылап, Гайшә, бертөрле дә файда юк, ул хәл синдә генә түгел»...

Бу хатны Лотфулла Гайнуллин 1941 елның 11 сентябрендә, сугышның иң авыр көннәрендә тормыш иптәше Гайшәгә язган. Хаттан күренгәнчә, Лотфулла сугышның әле тиз генә бетмәячәген, киресенчә, тагын да катырак булачагын яхшы белә. Бәлки, үзе дә һәлак булып калырын да истә тота. Әмма ул һич тә хафаланмый, аптырамый. Шундый шартларда да семьясын кайгырта, нык булырга чакыра. Шул ук чорда — 1941 елның 21 сентябрендә — язылган Харис Корбангалин хатында җиңүгә ышаныч, туган илне сөю хисе тагын да ачыграк әйтелгән: «Әнкәй, — дип яза ул, — 6 тапкыр сугышта булдым. Менә тагын керергә әзерләнәбез. Бездә бер генә теләк — Ватан өчен геройларча көрәшү, сезне, бәхетле аналарны һәм балаларны, бөек совет халкын гитлерчы корткычларның һөҗүменнән саклау, бәхетле тормышыбызны дәвам иттерүне тәэмин итү. Безнең һәрбер сугышчыбыз шул теләк белән яна... Үзеңнең улларыңның... кадерле Ватаныбызны дошманга бервакытта да бирмәячәкләренә нык ышан!.. Без җиңәрбез! Фронтта — без, тылда — сез, бер көч булып, дошман йөрәгенә ук булыйк. Дошман җир йөзеннән мәңгегә себерелеп түгелер. Ул вакытта тормышыбыз тагын да матуррак булыр».

Бу хатны Харис Корбангалин үз әнисенә язган. Батыр булып, яхшы булып күренү өчен түгел, бәлки чын күңеленнән, үзе ничек уйласа — шулай язган ул бу хатны.

Җыентыктагы хатларның барысы да дип әйтерлек менә шулай зур ышаныч, киләчәккә якты өмет белән язылган. Ул хатларның күп кенә авторлары хәзер дә исән һәм төрлесе төрле җирдә әле дә хезмәт итәләр икән. Җыентыкны төзегән язучы Самат Шакир аларның һәркайсы турында белешмә биреп барган. Ә байтагы инде дөньяда юк: кайсы сугышта һәлак булып калган, кайберләре туган илгә исән кайтып житсә дә, соңыннан вафат булган. Ләкин аларның бу китапта басылган хатлары, авыр сугыш елларында совет солдатларының уй-хисләрен, теләк һәм омтылышларын туплаган кыйммәтле документ буларак, укучылар күңелендә озак еллар сакланыр.

Вакыйф НУРУЛЛИН.

# ШАГЫЙРЬ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

1918 елның февраль ае булырга кирәк, әдәбият кичәсе ясау дәрте белән без, берничә кеше, Уфадагы Учительская семинариядән Татар гимназиясенә килдек. Чөнки боларда буш бүлмәләр дә, пианино да бар иде. Дәресләр беткән, укучылар өйләренә таралган вакыт иде бу. Димәк, бүлмәләр буш. Кичәдә Татар гимназиясеннән дә катнашучылар булып, без унбиш-егермеләп кеше җыелдык.

Яшьләрне әдәбият түгәрәгенә күбрәк тарту нияте белән «Галия» мәдрәсәсенә дә, әдәбият кичәсе төзүдә катнашырга теләүчеләр юкмы, дип телефоннан шалтыраттык. Аннан да берничә кеше килде. Кайсыбыз җырлый белә, кайсыбыз бии, сөйли. Мандолинада һәм гармоньда уйный белүчеләр дә бар иде. Кыскасы, без һөнәрләребезне күрсәтә башладык. Кайтып китәргә өлгермәгән берничә малай калган икән (ул кичәдә кызлар гына булырга тиеш иде), шулар бер кереп, бер чыгып безгә комачаулый башладылар. Арабыздан берәү торды да аларны куып чыгара башлады. Бар да чыгып китте шикелле булган иде. Янә җырлый башласак, бер кечерәк буйлы, күзлекле малай безгә якын ук килеп карап тора. Үзе шауламый да, тыйнак кына карап тора, шулай да уңайсызлый төсле. Теге иптәш якадан барып, ул малайның җиңеннән тотып:

— Син ник чыкмадың, әйдәле! — дип тарткалый башлады. Малай ычкынып китте дә:

— Мин чыкмыйм, минем әдәбият кичәсендә катнашасым килә! — диде.

— Син нәрсә эшли беләсең соң! Җырлыйсыңмы, әллә бисеңме! — дип көлештек. Ул:

— Мин Тукай абыйның бик күп шигырьләрен яттан беләм, мандолинада да уйный беләм, — диде.

Безгә бу хәл бик кызык тоелды.

— Я әле, я, нинди шигырьләрен беләсең, сөйләп күрсәт әле! — диештек.

Ул Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» дигән шигырен бер дә тотлыкмыйча сөйләп бирде. Мандолинада «Баламишкин», «Сүнмәс дәрт» көйләрен бик матур итеп уйнап күрсәтте.

Без, бик яратып, шунда аны әдәбият кичәсе ясаучылар түгәрәгенә алдык. Ләкин, кызганычка каршы, ни сәбәптәндер, бу әдәбият түгәрәге оешып бетә алмады. Шулай итеп күзлекле малай — булачак шагыйрь Әхмәт тә сәхнәгә чыга алмый калды.

Аннан соң бик күп еллар үтте. Без инде Казанда яшибез. Әхмәт дигән малайның бар икәнен дә оныткан идек инде.

Бервакыт минем тормыш иптәшем Шакир Шамильский белән бер күзлекле кеше көлешә-көлешә, сөйләшә-сөйләшә ишектән килеп керделәр. Шамильский миңа:

— Җанкәш, карале, бу егетне танысыңмы! Ә ул сине бик яхшы белә, — диде.

— Бу шул Татар гимназиясендә укыган Әхмәт ич! — дидем мин, бераз карап торгач. Бик якын иске дусларча исәнләштек. Инде танылган шагыйрь һәм аның тышкы кыяфәте дә шуңа бик лаек иде. Әхмәт озын буйлы, киң күкрәкле мәһабәт гәүдәсенә килешеп торган җайлы, пөхтә киемнәр кигән. Башын аз гына сулга бөгеп көләч йөз белән сөйләшкән вакытында аеруча ягымлы күренә.

Шулай итеп, без ул кичне бергә уздырдык. Уфадагы яшьлек хатирәләрен, Татар гимназиясен һәм әлеге әдәбият түгәрәген дә искә алдык. Соңыннан мин артистка булып киткәч, ул мине сәхнәдә бик күп мәртәбәләр күргән, мин башкарган рольләрне сокланып карап йөргән, ләкин янә минем янга килеп «мин дә артист булам»

дип әйтә алмаган. Әхмәт шуларны сөйләп көлдереп алды.

Шул кичтән соң инде ул безнең гаиләнең аерылмас дусты булып калды. Ул киткәннән соң Шамильский:

— Гаҗәп акыллы кеше, әдәбият, сәнгать, музыка, җырлар хакында бик күпне белә. Андый кеше белән сөйләшеп утыру үзе бер гыйлем өйрәнү шикелле бит. Их, шундый күпкырлы белемле кешеләр күбрәк булса иде! — дип куйды.

Аннан соң инде янә бик күп вакытлар узды, бик күп сулар акты, заманалар үзгәрде. Мин дә инде артистка түгел. Ватан сугышы башлангач, мин фронтка киттем һәм исән-сау йөреп кайттым. Казанда тормыш бик нык үзгәргән иде. Тормыш иптәшем Шамильский үлеп киткән... Шулай итеп 1948 елда ялгызым яшәп торган вакытымда, Әхмәт Мәскәүдән Казанга килгән. Ул безгә дә кергән булган, мин өйдә юк, эштә булганмын. Шунлыктан Әхмәт кыска гына язу калдырган: «Профессор Вадим Александрович Кондаков сезне бик күрәсе килә, алып килергә кушты, кайчан барэ алабыз! Шушы номер белән телефоннан шалтыратыгыз әле. Әхмәт».

Дөресен әйтергә кирәк, язуны укыгач мин аңламыйрак тордым. Кая барырга! Кемгә барырга!.. Ахырда шалтыратырга булдым. Аннары Әхмәтне үзебезгә чакырдым. Ул килде.

Бу очрашу минем өчен бик шатлыклы да, шул ук вакытта кайгылы да булды. Чөнки теге очрашуда кечкенә генә булса да гаиләм бар иде. Бүген мин ялгыз... Шулай да бу очрашу үзенә күрә тантаналы да булды. Япа-ялгыз тормыш итеп яткан вакытымда, беренче дуслык кулын сузып, саф йөрәктән хәсрәтемне бүлешеп, авырлыкларымны уртаклашучы Әхмәт булды. Кочаклашып күрештек, нык дулкынланулар белән үткәннәрне искә алдык. Шамильский хакында байтак гәпләштек. Шуннан төп максатка кайтып, профессор Кондаковка бару хакында сөйләштек.

Вадим Александрович Кондаков Уфада беренче тапкыр татар-башкортлар өчен русча укытучылар әзерләү семинариясе ачып, ирләр һәм хатын-кызларны бергә укытуны башлап җибәргән кеше. Мин шул беренче мәртәбә ачылган семинариядә укыган идем.

Аннан соң, 1917 елда Татар гимназиясе ачылгач, В. А. Кондаков бу гимназиянең директоры булды. Әхмәт тә шул Татар гимназиясендә укыган кеше. Димәк, Вадим Александрович Кондаков һәр икебезне дә мәгърифәт юлына бастырган кеше. Үзе дә татар-башкортларны бик ярата һәм аларны белемле-культуралы итү эшендә армыйталмый ныклап эшләгән, бөтен көче белән шул максатка ирешергә тырышкан кеше иде.

Без икенче көнне үк укытучыбыз профессор В. А. Кондаков янына бардык. Ул Казанда Лесгафт урамында 19 нчы йортта тора иде.

Анда барып керү шулкадәр дулкынландырды, беренче баскычны менгәч мин хәтта, бераз сулышым тигезләнгәнче керми торыйк әле, дип үтендем Әхмәттән. Ул шунда бераз гаҗәпләнеп: «Мин сезнең артистка вакытыгызда бик күп спектакльләрдә бик күп рольләр башкарганыгызны карадым. Сез анда һәрвакыт бик үткен, бик батыр, хәтта кайвакытларда бик чая да булып күренә идегез. Сезнең болай дулкынланып-югалып калырга торуыгызны һич күз алдыма китерә алмый идем» — диде.

— Юк инде, Әхмәт дус, аның белән күрешмәгәнгә 30 ел гомер узган бит. Ул безнең тормыш юлы белән кызыксынган, яхшы-яман якларны ишетеп торган. Менә шуларны төзәткәләп аңлашканчы дулкынланмыйча булмый ич, — дидем.

Вадим Александрович, хатыны белән бергәләп, безне бик әйбәт каршы алды. Әхмәт алар өчен яңа кунак түгел икән. Мин беренче мәртәбә булганга күрә, Вадим Александрович мине хатыны белән таныштырды.

Әхмәтне профессор бик ярата икән. Аңа Әхмәт Сафич дип мөрәҗәгать итә. Хатыны Фаина Аполлинариевна миңа зарлана төшеп әйтте: «Менә Әхмәт Сафич килсә, бу бөтен дөньясын онытып, кичләр буенча аерыла алмый сөйләшеп утыра», — диде. Вадим Александрович, аны дәвам иттергән сыман итеп: «Без шулай инде. Әхмәт Сафич килсә, дөньябыз тигезләнә шул. Сезне алып килүне мин бик үтендем. Моннан соң сез безне шаять ташламассыз инде, килгәләрсез. Ә, туктагыз әле, сез Әхмәт Сафичка ничек дип эндәшәсез! Сездә бит атасы исеме белән эндәшү гадәте юк, әллә сез дә атасы исеме белән дәшәсезме! — ди.

— Юк, мин атасы исеме белән мөрәҗәгать итмим, яшьтән үк бик яхшы белгәнгә күрә «Әхмәт дус» дип кенә әйтәм.

Болай диюем аңа бик ошады булырга кирәк, хатынына карап:

— Анасы, ишетәсеңме! Нинди сөйкемле, йомшак мөрәҗәгать: «Әхмәт дус, Әхмәт дус», — дип, кат-кат әйтеп карады.

Бераз үткән заманнарны искә алып, укытучылар семинариясе, Татар гимназиясе хакында сөйләшеп утырганнан соң, Вадим Александрович Әхмәтнең иҗат эшләренә күчеп:

— Әхмәт Сафич, мин сезнең шигырьләр белән бик кызыксынам, русчага тәрҗемә ителгәннәрен укыйм. Бауман урамына төшкәндә китап магазинына кереп, сезнең яңа әсәрләрегез чыкмады микән дип, белешми калмыйм. Сезнең һәрбер яңа чыккан әсәрегез мине бик шатландыра, менә татарның талантлы шагыйре үсә дип горурланам! — диде.

Әхмәт тә аның кәефенә килерлек итеп җавап бирде:

— Вадим Александрович, мин үземнең сез үстергән җимеш икәнемне онытмыйм бит, димәк, чәчкән орлыкларыгыз саф булганнар.

— Әхмәт Сафич, сез үзегез язган шигырьләрегезнең барын да бертигез яратасызмы, әллә алар арасында аеруча яраткан шигырьләрегез дә бармы! — диде Вадим Александрович.

— Сез, Вадим Александрович, балалар атасы. Балаларыгызны барын да бертигез яратасызмы, әллә кайберләрен артыграк якын күрәсезме!.. Минем дә шигырьләрем шулай: язганда бик яратып язам, әмма берникадәр вакыт узгач, кайберләрендә байтак җитешсезлекләр табам. Шуңа күрә кайсы шигыремдә җитешсезлекләр азрак тоелса, шуларны ярата төшәм, — диде Әхмәт.

Аннары Вадим Александрович, миңа мөрәҗәгать итеп:

— Менә мин шулай, аңа имтихан да ясап алам һәм аның җавапларны мине бик канәгатьләндерә. Тик шунысы кызганыч, аның ни өчендер Казанда яшисе килми. Мин аның Казанда торуын бик теләр идем, айлар буе күрешә алмый яшибез. Ә Казанда торса, еш кына кичләрне бергәләп уздырыр идек, — диде.

Чынлап та, Әхмәтнең Мәскәүдә яшәве үзе өчен яхшы булгандыр, әлбәттә, әмма безнең өчен җайсызрак иде шул. Үзе җай табып Казанга килсә генә күреп каласың. Тик шул кадәресе яхшы: ул Казанга килсә, хәбәр итми калмый. Мин дә, бөтен эшемне җайлап, Әхмәт белән очрашуны тантаналырак рәвештә уздырырга тырышып, кайвакыт аның янына берничә язучы яки артистлардан аны белгән иптәшләрне дә чакыра идем. Иптәшләр белән бергә утырганда ул бик тапкыр, күңел күтәргеч сүзләр сөйләп мәҗлесне ямьләндерә иде.

Шундый мәҗлеснең берсендә ул 1927—28 елларда Арча кантонында торган вакытта, үзешчән яшьләр җыелып, Арча клубында спектакльләр куйганнарын һәм шунда «Галиябану» пьесасын куйган вакытта Хәлил ролен уйнавын сөйләде. Галиябану ролен яшь кенә кыз уйный, Исмәгыйльне уйнаучы да бик чибәр яшь егет, тик ул җырлый белми, Әхмәт җырлый белә икән. Шуның өчен Хәлил ролен аңа биргәннәр. Спектакль барышында тамашачылар арасында мәсьәләгә төшенә алмаучылар күп булган, ягъни Галиябану ничек соң япь-яшь чибәр егетне яратмыйча, кап-карт, ямьсез егетне ярата ала икән, дип аптыраганнар. Берсе түзмәгән:

— Исмәгыйльне ярат, ул Хәлилгә караганда яшь тә, матуррак та! — дип кычкырган. Шуңа каршы бер апа:

— Ямьсез булса ни, мәхәббәт җамал теләмәс! — дип өстәп тә куйган. Әмма Әхмәт: «Үз ролемне ахырына кадәр уйнап чыктым бит», — диде. Барыбыз да дәррәү көлеп җибәрдек.

Әхмәт киң күңелле, кешегә ярдәмчел, ачык йөзле, һичбервакыт масаюны-тәкәбберлекне белми торган матур табигатьле кеше иде. Ул, эшләре күп булуга да карамастан, дуслар хәтере өчен вакыт таба белә торган, үзенең дәрәҗәсенә бертөрле дә тап төшермәс хәлдә түбәнчелекле иде. Мәскәүдән вакытлы гына Казанга килгән араларда да килеп хәл белергә вакыт таба һәм килгән вакытларында «мин бик ашыгам» яки «минем эшем бик күп, вакытым тыгыз» кебек сүзләр белән борчымый. Сөйләшә, серләшә, сораша. Тиешле киңәшләр бирергә дә онытмый. Күңел ачардай кызыклы сүзләр дә сөйләп ала, әмма һичбер вакыт үзенең иҗат эшләре хакында сөйләп һаваланмый. Сорагагнда да җиңел генә:

— Эш күп, әлбәттә, язасы нәрсәләр дә күп, кайберләрен язып беткәндәй дә булам. Ләкин күңел тынычланганы юк әле, язган саен язасы нәрсәләр күбәеп кенә бара, — дип җавап бирә иде.

МИРВӘЛИЕВА МАҺИРӘ.

# КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ БЕР ИСТӘЛЕК

Егерменче еллар татар әдәбияты төрле әдәби берләшмәләр, алар арасында барган үзара ызгышлар белән дә аерылып тора. Ул вакытларда аеруча «пролеткультчылар» тәэсире зур булды. Әдәбиятка алар анархизм һәм нигилистик тенденцияләр алып килделәр. Озак та үтмәде, тагын бер агым — футуристчылар, сулфчылар аерылып чыктылар. Дөрес, «сулфчыларның» гомере бик кыска булды. Бу әдәби берләшмә бер-ике ел гына яшәде. Ләкин шулай да социалистик реализм методын төп корал итеп алган совет әдәбиятының үсеп китүенә алар зур тоткарлык ясадылар. Татар әдәбиятына килеп кергән мондый чит агымнарның вәкилләре — пролеткультчылар, футуристлар, алар шаукымына ияргән кайбер язучылар үзләренә охшамаган пролетар язучы һәм шагыйрьләргә халык алдында «Әдәби суд» оештыруны модага керттеләр. Шундый суд, мәсәлән, һади Такташка да оештырылган иде.

1924 елның язы. Элекке Чернышевский һәм Пионерский урамнарының чатындагы коммунистик клуб йортында (хәзер авиация техникумы бинасы) шагыйрь һади Такташка әдәби суд булачагы мәгълүм булды. Клуб залы халык белән шыгрым тулы. Биредә укучы яшьләр, яшь язучылар да бар. Ара-тирә гаскәриләр дә күренгәли. Суд сулфчылар тарафыннан оештырылды. Такташның әдәби алымнарын кискен тәнкыйть күзлегеннән карап төзелгән доклад белән Татар коммунистик университетында (ТКУда) укучы Ризванов дигән кеше чыкты. Кызганычка каршы, докладның төп фикерләрен тулысынча язган кәгазьләрем югалган. Шулай да фикер алышуда катнашкан кайбер иптәшләрнең, Такташның һәм Гаяз Ризвановның йомгаклау сүзе язылган кәгазьләре сакланганнар. Суд барышында вакыйга ничек язылган булса, шулай ук бирүне мәслихәт күреп, судның барышын шул тәртибендә китерәм.

Хәтеремдә калганча, докладчы Ризванов «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын тәнкыйтьләде. Алай гына да түгел, «Такташ сәяси белемсез... Ул революция темпын сизә алмый... Такташ эшче-крестьян шагыйре түгел, вак буржуаз шагыйрь... Такташны алкышлаучыларның күбесе мещаннар иде», дигән сүзләрне әйтте. Аның докладында Такташ иҗатын аңламый тәнкыйтьләү ачык күренде. Конкрет дәлилләр белән исбатлау булмаганлыктан, фикер алышу да бик шау-шулы булды.

Фикер алышуларда катнашкан Фоад Соловьев: «Такташ үзенең соңгы шигырьләрендә үткән көннәрен каһәрләгәнен күрә торып, аны үз арабызга ала алмыйбыз, дип әйтү дөрес булмас»,— диде.

Исмәгыйль Хәмзин: «Ризванов үзенең докладында тулы дәлилләр күрсәтә алмады. Такташның «һәйкәл ясыйбыз» дигән шигыреннән бер өзеген генә тикшереп, үз хакында гына — индивидуально — язган, диде. Ә чыннан карағанда Такташ үзенең шигырен һәйкәл итеп күрсәтергә тырыша. Шулай да без аның хәзерге яшьләргә әдәбиятта юл ачканын тәкъдир итәргә тиешбез. Ул бит милләтче, динче булмаган, мещаннар арасына кермәгән. Такташта поэтическое чутье бар».

Трибунада тагын бер гаскәри (фамилиясе язылмаган): «Такташның язмаларына суд ясау иртәрәк. Аның хәзер үзенең юлын үзгәрткәнен күрәбез. Шуңа күрә дә, ул киләчәктә пролетариат шагыйре булырга тиеш, дип уйлыйбыз».

Кәбиров: «Меньшевиклар, правый эсерлар исеменнән трибунага чыккан Такташны арабыздан чыгарып ташларга кирәк. Мәхәббәт мәсьәләсендә дә шулай ук».

һади Такташ үзенең чыгышын бик борчылып башлады. Торган саен кыза барды. Тавышында ачу яңгырады. Көченә нык ышанган, алдагы чыгышларга бер дә исе китмәгән сыман, гайрәтле тавыш белән

кычкырып сөйли: «Ни өчен бу суд оештырылды, диган сорау туа. Соңгы вакытларда газета битләрендә минем язмаларга шактый тәнкыйтьләр булып үтте. Мин аларның күбесенә кушыла бардым. Хаталарым булганын мин, әлбәттә, инкарь итмим, ләкин мин әле хәзергә кадәр аз вакыт эшләгәнлектән, яшьлегемне дә искә алганда, әле миңа әдәби суд ясарга иртә иде. Тик минем соңгы вакытларда гигантларча адымнар белән алга китүемне күреп, тизрәк диспут ясарга булдылар. Мин бу турыда сулфчыларның үзләренә дә әйттем. Доклад турында шуны гына әйтәм — бер генә дә ачык һәм житди дәлилләр китерелмәгән. Шигырьләрнең аерым бүлекләрен алып сөйләсә дә, берсен дә аңламаганлык күренеп тора. Минем сыйнфый чыгышым крестьян семьясыннан. «Җир уллары» шигырем алдынгы марксистлар тарафыннан минем беренче революционный әсәрем, дип кабул ителде.

Такташ үзенең шул әсәрләрен язган вакытта бу иптәшләр нәрсә карадылар икән соң? Ә Такташны шул әсәрләре өчен чуть үтермәделәр.

Әле футуристлар тормышка, аның эченә керә алганнары юк. Такташ инде күптәннән бирле тормыш уртасына кереп, мещаннарга каршы сугыш уты ачты. Такташта революционнасть юк, дия алмыйсыз. Докладчик минем бер дәвердәге шигырьләремне генә алып күрсәтә дә, нигә соң ул минем соңгы дәвердә иске тормышка каршы атап язылган шигырьләремнең берсен дә тикшерми?

Мин, шушы көннән башлап, үземнең идеологиядәге ялгышларыма крест куйдым.

Тәнкыйть сулфчылар тарафыннан барганлыктан, алар турында да бераз тукталып үтәргә уйлыйм. Аларда психологическая искренность юк. Алар техниканы, машина-заводларны җырлап, аларны кем эшләп чыгарганын әйтмиләр, яшерәләр. Ә Такташ, революциягә ныклап катнашканлыктан, тормышның эченә керә.

Пролетариатның юлбашчысы Ленинны язарга сүз таба алмаган бер кеше, ничек итеп шулкадәр зур гвардиянең алдыннан барырга батырчылык итә?— командир мин, ди.

Демогогия таратасыз, эшләми торып, звание алмакчы буласыз.

Такташ революциягә киләме, юкмы, дип көтәсе юк, ул хәзер килгән инде».

Докладчы Ризванов үзенең соңгы сүзендә: «Такташ үзенең чыгышында елап сөйләде.

Такташны бары печән базары вәкилләре генә яклап чыкты. Мин аларга игътибар итмим»,— диде.

«Кызыл Татарстан» газетасының 13 май санында бу диспут турында шундый юллар язылды: «Ачы фактларга таянып, бу диспутның интрига өчен генә эшләнгәнлеген исбат иткән һади Такташ зур аудитория тарафыннан давыллы алкышлар белән каршыланды. һади Такташ үзенең иҗаты белән көннән-көн пролетариат идеологиясенә якынлашуын, футуристлардагы ялгыш идеологияне, сайлыкны, талантсызлыкны байтак мисаллар белән күрсәтеп үтте. Диспуттагы фикерләрнең күпчелеге һади Такташның пролетариат идеологиясенә якынлаша баруын, бу көчле каләмнең эшче-крестьяннар тормышыннан тирән мәгънәле инкыйлаби әсәрләр бирә башлавын тәстикъ иттеләр. Шагыйрьне кат-кат алкышлагач, резолюциясез-нисез генә диспут ябылды».

С. РӘИМОВ.







## Шәүкәт Галиев

# Кырмыскалар туп уйный

Бер кырмыска туп тапкан,
Иптәшләрен туктаткан:
— Йөреп тә туйдык, дигән,
Йөгереп уйныйк, дигән.
Башкалар: — Хуп, дигәннәр,
Уйныйбыз туп! — дигәннәр.
Тик берсе каршы килгән:
— Хуҗасы кемдер, дигән,
Күрер дә килер, дигән,
Кирәкне бирер, дигән.

Кайсыдыр тупка типкән,
Бәхәс тә шунда беткән.
Әй, киткән уен, киткән,
Хәтәр уйныйлар икән!
Йөгереп тә киләләр,
Китереп тә тибәләр.
Туп мескенкәй «доңк!» итә,
«Доңк!» итә, очып китә.
Сикерә үрле-кырлы,
Йөгерә әрле-бирле.
Шәп уйный кырмыскалар,
Кырмыскалар — осталар.
Капкачылар — Яшин күк,
Һөҗүмчеләр яшен күк!

Өлкән кырмыска килә,
Туктарга әмер бирә:
— Бу шайтан туе нигә?!
Җитәр, ташлагыз, ди дә,

Ачудан тупка тибә,
һәм үзе дә кызыгып
Йөри башлый туп куып.
— Тик ерак китмәгез, ди,
Бик каты типмәгез, ди.
Саклый гына күрегез,
Шартлый гына күрмәсен.
Килеп чыкса иясе,
Булыр кире бирәсе.

...Сузып кына муенны
Бу әкәмәт уенны
Карап тордым мин читтән,
һәйбәт уйныйлар икән!
Тубы да шәп, нык иде,
Ул бит минем туп иде.
Югын үзе юк иде,
Әмма җитез, шук иде!..

## Чаналар ла чаналар



Чаналар ла чаналар,
Чабалар да чабалар,
Табаннары яналар!
Атланып та төшәбез,
Якланып та төшәбез,
Капланып та төшәбез!..

Чаналар ла чаналар,
Искеләр дә яңалар,
Таудан ут чыгаралар!
Бозлы таудан шуабыз,
Бетон таудан шуабыз,
Бөтен таудан шуабыз!



Чаналар ла чаналар,
Чамалаган чамалар —
Тамчылар да тамалар...
Ычкынгансыз бәйдән сез,
Чабыгыз, чап, әйдә сез,
Ял итәрсез җәйгә сез!

## Химчисткага бирәм, ди...

Габит кергән урамнан,
Баштанаяк буялган.
Пычранган бар төше дә,
Хәтта менә — теше дә!
Тамак кыра атасы,
Ах-вах килә анасы:
— Ничек шулай батасың,
Әллә аунап ятамсың?!

Балчыгын кыра-кыра,
Орышырга тотына:
— Сак йөрергә өйрән, ди,
Юкса җаен беләм, ди,
Химчисткага бирәм! ди.
Машинага тыгарлар,
Юарлар да сыгарлар,
Пычрагын бетерерләр.
Эләрләр-киптерерләр,
Үтүкләп китерерләр!

...Габит урамга чыкты.
Пычрак төшне очратты.
Урап үткәч пычракны,
Болай диде шул чакны:
— Чисталыкка өйрән, ди,
Юкса җаен беләм, ди,
Химчисткага бирәм! ди.
Машинага тыгарлар,
Юарлар да сыгарлар,
Пычрагың бетерерләр.
Эләрләр-киптерерләр,
Үтүкләп китерерләр!..



## Җайдак

Кузла — атка охшаган.
Охшаган бит? Охшаган!
Кулыма чыбык алам,
Менәмен дә атланам,
Һап-һап дип терсәк кагам!
Мин җайдакка охшадым.

Охшадым бит? Охшадым!
Селкеткәлим кузламны.
Кузла, кузла, кузгалды!
Карагыз минем атны —
Арт аякларга басты!
Үзе ул басып калды,
Ә мине егып салды...

Сәбәбен сез белгәнсез —
Тыңламый ат йөгәнсез!



## Шаян

Әнисе эш кушкач
Хәйләкәр Ясинә:
— Өйдә юк куллар, дип,
Артына яшерә.

— Кызганыч, ди ана,
Вакытым тар иде...
Кемгә соң бирермен,
Конфетым бар иде?

Авызын ача да
Ясинә тиз генә:
— Тешләрем өйдә ич,
Каптыр, ди, үземә!



## Табышмак шигырь

Сөләй, Сәрдек, Сәлиман,
Синтәк, Сәпәй, Сикәнәс.
Чураш, Чутай, Чөгәнә,
Чүти, Чәмәк, Чикәнәс.

Мәмсә, Мәртен, Мәнәвес,
Мәмәй, Мәмәт, Мәмәшир.
Шәпке, Шәрбан, Шөкрәле,
Шәбез, Шәмәк, Шүширмә.

Тулбай, Тупач, Теләче,
Турай, Тәкмәк, Тәрнәче.
Күзкәй, Көлкәш, Күҗәкә,
Күкшем, Күкшел, Күктәкә.
Табышмакның җавабын
Кемнәр белә — шул әйтә!

*(Җавабы: Татарстандагы авыл исемнәре...)*

## Гәрәй Рәхим

### Таныш шагыйрьгә

*Китабын укып чыгу уңае белән*

Өй коргансың —
Түшәме бар, идәне юк.
Кыз биргәнсең —
Туе булган, кияве юк.
Сыерыңның
Аягы бар, тоягы юк.
Расемеңнең
Киндере бар, буявы юк.

Зур елгаңның
Ярлары бар, сулары юк.
Кавказыңның
Болыны бар, таулары юк.
Син әйтерсең: «Үзеңдә дә
Шигырьләр бар, шедевр юк».
Ә бит синең китабыңның
Шигыре юк.

## Шәүкәт Шәрәпов

### Энә

*Мәсәл*

Резервта буларсың дип
Кадаганнар энәне мукка.
Оныткканнармы, ни булгандыр,
Резервлык киткән бик купка.
Ай киткән, ел киткән энә,
Алып караучы булмаган бер генә.
Бер көнне ашыгыч кирәк булгач энә
Өлкән тегүченең төшкән бит хәтеренә.
Бик шатланып алган бу энәне муктан,
Ләкин... күгәргән булган ул күптән.

## Әдхәт Синегулов

### Түбәтәй юу

Ал минем түбәтәем,
Гөл минем түбәтәем,
Түбәтәй алган шатлыктан,
Дөньясын гүләтәем:
Әйдәле түбәтәем,
Чамалыйк «бәләкәен».

И тәти түбәтәем,
Каян рәт юнәтәем!
Инде үзеңне сатыйм да...
Башымны тезәтәем.

# ГЫЙБАД АЛПАРОВ

Узган елның декабрендә күренекле тел галиме, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, профессор Гыйбад Алпаровның тууына 80 ел тулды.

Гыйбад Хәбибулла улы Алпаров 1888 елның 3 декабрендә хәзерге Башкортстан республикасының Авыргазы районы Корманай авылында туа. Берничә еллар авыл мәктәбендә укыганнан соң, Гыйбад, Уфага килеп, Госмания һәм Галия мәдрәсәләрендә белем ала, ә 1913 елда Казанда Учительская школаны тәмамлый.

Гыйбад Алпаровның иҗат һәм иҗтимагый эшчәнлеге Совет властеның беренче көннәреннән үк башлана диярлек. 1919—21 елларда ул Уфада укытучылык итә, бер үк вакытта «Кызыл юл» һәм «Урал» исемле газета редакцияләрендә дә эшли: сотрудник була, секретарь һәм редакторлык вазифаларын башкара. 1921 елда Гыйбад Алпаров, дәвалану һәм сәламәтлеген ныгыту өчен, Урта Азиягә җибәрелә. Каты авыру булуына карамастан, анда да киң күләмдә җәмәгать эшләре алып бара: партия мәктәбендә лекцияләр укый, төрле газета-журнал редакцияләрендә («Чолпан», «Ак жол», «Төркмән мәдәнияте» һ. б.) эшли. Биредә ул үзлегеннән төркмән, казакъ, кыргыз һәм үзбәк телләрен өйрәнә, бу исә аның алдагы гыйльми эшчәнлегенә зур ярдәм итә. Берничә елдан соң Г. Алпаров яңадан Уфага кайта, Башкортстан мәгариф комиссариаты каршындагы гыйльми үзәктә эшли башлый һәм «Белем» журналында секретарьлык итә. 1926 елда ул Казанга күчеп килә.

Гыйбад Алпаров бары совет власте елларында гына чын мәгънәсендә зур галим булып җитеште. 1928 елда ул Ленинград көнчыгыш институтының төрки телләр бүлеген, 1930 елда шул ук институт каршындагы аспирантураны тәмамлый.

Ленинградтан Казанга кайткач, Гыйбад Алпаров педагогия институтында һәм шәһәребезнең башка уку йортларында татар теле, шулай ук гомуми тел белеме буенча лекцияләр укый, тел белеменең төрле тармакларына караган фәнни-тикшеренү эшләре алып бара, аспирантлар һәм яшь белгечләргә җитәкчелек итә. Г. Алпаров, каты һәм озак авырудан соң, 1936 елның 31 июлендә Казанда үлә.

Кыска гына иҗат гомерендә Гыйбад Алпаров тел белеменең төрле тармакларына караган дистәләрчә фәнни хезмәт, бик күп мәкаләләр калдырды. Аның «Татар теленең шәкли нигездә грамматикасы», «Тел белеменең нигез мәсьәләләре» кебек совет чорында язылган хезмәтләре хәтта киң катлау укучыларга да яхшы таныш.

1945 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйбад Алпаровның «Сайланма хезмәтләре»н бастырып чыгарган иде. Бу китап инде күптән таралып бетте. Аның төзәтелгән һәм тулыландырылган яңа басмасын чыгарырга вакыт. Бу — галимнең күп кырлы фәнни эшчәнлеген ихтирам итү билгесе һәм тел галимнәре, югары мәктәпләрнең укытучылары, шулай ук студентлар өчен файдалы кулланма булыр иде.

Г. К. ЯКУПОВА.



*Г. Алпаров һәм Г. Ибраһимов.*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## УТЫРЫШ БИК ҖАНЛЫ ҮТТЕ

Моннан бер ай элек Татарстан язучылар союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышы булды. Анда «Казан утлары» журналының 1968 елгы 5—6—7—8—9 саннарында басылган әсәрләр тикшерелде. Язучылар союзының Әлмәт бүлеге секретаре Равил Фәйзуллин бүгенге поэзиябезнең торышын, андагы уңай һәм тискәре тенденцияләрне характерлый торган әсәрләргә тукталып үтте.

— Поэзиябез,— диде ул,— үсә, төрләнә. Шушы үсеш журнал битләрендә чагылыш табамы? Әйе, таба. Чөнки журнал шагыйрьләрнең иң яхшы әсәрләрен чыгарырга тырыша. Шулай да бу очракта ниндидер бер эзлекле системаның житенкерәмәве турында әйтеп китми булмый. Әгәр дә соңгы өч-дүрт ел эчендә журналда басылып чыккан шигырь-поэмаларның библиографик картасын төзесәң, байтак гыйбрәтле нәрсәләр күзгә ташланыр иде. Әйтик, шигъри кабатлаулар! Бер үк темага төрле югарылыкта язылган әсәрләр. Әйтик, бер санда теге яки бу авторның бер шигъри циклы чыга, ярты яки бер елдан шул ук авторның элеккеләреннән кайтыш шигырьләре басыла... Бәлки, бу хәл журнал өчен котылгысыз, диярләр. Теләсә нәрсә дисәләр дә, бу күренешнең булмавы хәерле. Поэзиябез үсә. Сайлап алырлык шагыйрьләр бар, сайлап алырлык әсәрләр бар, поэзия әсәрләренең журналдан журналга үсеп баруын таләп итәргә хакыбыз бар.

Шуннан соң Фәйзуллин журналда басылган күләмле әсәрләрнең кайберләренә тукталып китә.

— И. Юзеевнең «Соңгы сынау» әсәрен алып карыйк. Мондый әсәрнең язылуы һәм дөнья күрүе куанычлы хәл. Шагыйрьнең материалы кызык, әйтергә теләгән фикере зур. Анда сүз олы нәрсәләр: яшәү мәгънәсе, шәхес, халык, азатлыкның иң зурысы — рухи азатлык, үлем һәм үлемсезлек турында бара. Публицистик янгырашлы бу әсәр канәгатьләнерлек фәлсәфи тирәнлектә эшләнгән. Буш сүзләр юк дәрәҗәсендә, драматик алымнар белән таныш булуы авторга ярдәм иткәнлек сизелә. Кара-каршы сөйләшүләр — диалоглар — ышандыра, алар логик яктан бәйләнешле. Мин үзем әсәрне яратып укыдым. Поэзиябезнең күтәрелүенә бер дәлил бу. Димәк, безнең шагыйрьләр дә мефистофельләр белән бәхәсләшә ала, һәм рухи яктан аларны җиңә ала хәзер. Эш, әлбәттә, шагыйрьдә генә түгел. Хикмәт иблис фәлсәфәсенә каршы тора алырлык һәм үлемне җинә алырлык, үлемне үлемсезлек итә алырлык батыр һәм газиз кешеләребездә, аларның безнең халык арасында байтак булуында. Менә кайда илһамның башы, менә кайда шагыйрьләрне ризыкландыручы туфрак.

Р. Фәйзуллин «Соңгы сынау»ның үзен канәгатьләндереп бетермәгән якларына да тукталды. Ул поэманың бөтен җире дә тигез үк эшләнмәвен, бик яхшы урыннары белән бергә, йомшаграк юллары да булуын әйтте һәм, мисал итеп, Тиран образына тукталды. Ул бу образның тирәнрәк ачылуын теләвен әйтте, шулай эшләгәндә әсәр тагын да яхшырак, отышлырак чыгар иде, диде.

Аннары Р. Фәйзуллин Ренат Харисовның «Мулланур» исемле шигыренә тукталды:

— Мулланур турында,— диде ул — язарга кирәк һәм шәп итеп язарга кирәк. Аның турында, санный калсаң, әсәрләр бар да сыман (Р. Нәфигов, Н. Исәнбәт, В. Исхаков әсәрләре, шигырьләр, җырлар). Тик аны киң катлам халык җитәрлек кадәр, кирәк кадәр белми әле. Р. Харисов шигыре җыелып килгән хәзинәгә нәрсә дә булса өстиме соң? Биографик яктан караганда — юк, ә Мулланур Вахитов шәхесен поэтик зурлау ягыннан караганда — әйе. Шигырь Мулланур каберенең билгесез икәнлегеннән, аның нинди үлем белән үлгәне дә билгесез икәнлеген әйтеп башлана. Шагыйрьне мондый билгесезлек борчый, ул күңеле белән ачына.

Шуннан соң автор үлемнең төрле вариантлары турында уйлый: ату, асу, суга батыру.

Аны асалар. Ул киерелеп сулый, һәм тирә-юнь һавасыз кала. Палачлар тончыгып җиргә ава. Ә ул басып кала.

Аны суга батыралар. Ярларыннан Идел ташып чыгып палачларны өереп ала.

Төп фикер: халыкның батыр улын ничек кенә юк итсәләр дә, ул мәңге исән!

Шигырь оригиналь. Аны яратырга мөмкин, яратмаска мөмкин. Мөгаен, әсәрне шулай кабул иткәннәрдер дә. Мин «Мулланур»ны кабат-кабат укыдым. Әмма бернәрсәдә шигем юк: ул — буш әсәр түгел.

Ахырдан Р. Фәйзуллин Хисам Камаловның «Тормыш дулкыннары» исемле поэмасы турында сөйләде.

— Берәүләргә — диде ул,— озын, тасвирлау формасында язылган поэмалар ошамый, берәүләр, киресенчә, андыйларны күбрәк укыйлар. Күрәсең, эш зәвыкка

бәйләнгән. Минемчә, поэмалар, гомумән поэзия, тормыштагы хәлләрне бәйнә-бәйнә тасвирлауга гына корылган булырга тиеш түгел. Югыйсә поэзия, көтүче чыбыркысы кебек, бик түбәннән шуа башлый. Поэзия, киреәксә, карлыгачтай күккә күтәрелсен ул, кирәксә, яшен кук жиргә дә кереп китсен, кирәк икән, язгы нәфис жилләр кебек, туфракны да иркәләп үпсен.

Х. Камалның поэмасы мин өнәп бетермәгән тасвирлауга корылган. Шулай да, мин аны чын поэзия әсәре дип кабул итәм. Ни өчен? Чөнки аның материалы тормышчан, идеясе кешелекле, анда фикри яктан тыгыз, образлы сурәтләр, тәгъбирләр күп, ул — формасы ягыннан камил.

Әсгать кызык образ. Моңарчы безнең поэзиядә андый Әсгатьләр юк иде шикелле. Алар тормышта бар. Тик Әсгатьнең әтисе белән мөгамәләсе миңа бик аңлашылып житми. Әтисе белән шулкадәр аңлашылмаучылык каян килгән? Кирәклек кенәме ул? Янсә берәр мөһим сәбәп тә бармы?

Мин бу поэманы күп кешеләр яратып укыганын беләм. Андый поэмалар журналда басылырга тиешләр дип уйлыйм.

Журналның тикшерелә торган саннарында басылган проза әсәрләре турында язучы Хәсән Сарьян сөйләде. Ул үзенең чыгышында әлеге саннарда ни бары ике генә хикәя басылуын һәм бу шактый борчулы хәл икәнлеген искәртеп үтте дә нигездә Гариф Ахуновның «Хуҗалар» романы турында сүз алып барды.

— «Хуҗалар» «Хәзинә» романының дәвамы, икенче китабы. «Хәзинә»дә башланып, бетми калган язмышлар «Хуҗалар»да тәмам хәл ителеп, ачылып бетә. Шул ук вакытта «Хуҗалар» — тормыштан умырып алган материалы белән дә, күтәргән проблемалары белән дә үзенә башка, мөстәкыйль бер роман. Ләкин аны, барыннан да бигрәк, кешеләр язмышы роман итә. Арслан Гобәйдуллиннар, Тажи Вилдановлар, Лотфулла Дияровлар, Атнабайлар, Фәйрүзәләр, Сакалбайлар роман итә. Саный китсәң, күләме ягыннан әллә ни зур булмаган романда күпме кешеләр язмышы!

Бүгенге әдәбиятта иң авыр мәсьәлә — житәкче кешеләрне яза белү.

Минемчә, романның иң зур уңышы — авторның житәкче кадрларны, бер-берсен кабатламастан, бирә, яза белүендә. Хәтта эпизодик образлар да әнә шулар аша ачыла. Мин монда, мәсәлән, партком секретаре Тажи Вилдановның оператор Мәхмүтләргә баруын әйтер идем. Шушы кечкенә генә эпизодта әр-яңа өч кешенең, ягъни Мәхмүтнең (ул — бозау), әнисенең (ул — хәйләкәр, усал), Василәнең (ул — эшчән), һәм, шуларның өчесе аша Тажи Вилдановның үзенең характеры ачыла.

Г. Ахунов бу романында фәлсәфи яктан тирәнгәрәк төшкән. Тормыш фәлсәфәсенә тагын да кыюрак тотынган. Ялда йөреп кайткач, Булат Дияровның уй үзгәреше, Буяновның «алтын аркасында бәлагә тару» хикәяте, Гәрәйшин аша демократиягә мөнәсәбәт, Шәвәли карт фәлсәфәсе, шуңа бәйләнешле яшьләр-картлар проблемасы, һәм, милли тойгылар — һәммәсенә карата автор үз фикерен әйтә бара. Ләкин ул аларны безгә көчләп, кычкырынып такмый, әдәби тукыма аркылы бирә.

Романның теле матур, чигүле-бизәкле түгел, табигый матур, ягымлы-йомшак, салмак кына ага да ага. Яңа сүзләргә, яңа формаларга бай. Геройларның үз ягындагы сүзләр күп. 38 меңлек сүзлегебездә булмаган диcтәләгән яңа сүзләрне мисалга китерергә булыр иде.

Шул ук вакытта роман житешсезлекләрдән дә азат түгел. Менә, мәсәлән, Мөстәкыймов образы ышандырып бетерми. Ул ничектер ясалма килеп чыккан. Арслан Гобәйдуллинны партбюрога куйдыруы уйланып житмәгән. Арслан Гобәйдуллинның болай да нык репутациясен ясалма «сулыш» биреп ныгытуның бер кирәге дә юк иде.

Икенчедән, Буянов главасы — романда табылган алтын. Глава буларак, ул искиткеч художество көче белән язылган, ләкин ул ахырына кадәр файдаланылмаган, ягъни Буяновның потенциаль мөмкинлекләре бөтенләй ачылмый кала. Комсомол билетына ни булып бетә, Буяновның үзенә ни була — берсе дә аныкланмый.

Өченчедән, ахырдагы янгын мәсьәләсе. Ул үзе шулай ук бик киеренке эпизод. Ләкин ул романга файда итми. Бу инде, Сәгыйдәне үтереп, Арсланны беренче мәхәббәте Мөнәвәрә белән кавыштыру өчен генә кирәк булган.

Чыгыш ясаучылардан Нәби Дәүли, поэзия әсәрләренә тукталып, И. Юзеевнең «Соңгы сынавы»да, Р. Харисовның «Мулланур»ы да кирәкле, файдалы әсәрләр булуын әйтте дә, нигездә, аларның үзенә ошап бетмәгән яклары турында сүз алып барды. «Соңгы сынау» да, диде ул, Муса образы тиешле югарылыкка күтәрелеп сурәтләнмәгән. Аныңча, И. Юзеевнең «Фауст» геройларын әсәренә кертүе дә уңышлы түгел. Р. Харисовның «Мулланур» әсәрендә Мулланурны утта да янмый, суда да батмый, пуля да алмый итеп күрсәтүе белән Н. Дәүли шулай ук килешеп бетмәвен белдерде һәм бу әсәрнең теле кытыршы, авыр укылуын искәртеп үтте. Аннары ул журналның тикшерелә торган саннарында басылган яшьләр шигырьләренә дә тукталды, яшьләр әсәрләрен басканда журнал талымсызлык күрсәтә, дигән фикерне әйтте һәм, шул сүзләренә мисал итеп, Э. Мостафинның «Көймә көтеп утырабыз», Э. Рәшитовның «Мунчадан репортаж» исемле шигырьләрен китерде.

Аның бу фикерләре утырышта шактый кызу бәхәс тудырды. Сибгат Хәким, мәсәлән, Н. Дәүлинең И. Юзеев поэмасына карата әйткән фикерләре белән һич тә килешә алмавы турында әйтте.

— Соңгы вакытларда,— диде ул,— мин Илдарның барлык әсәрләрен укып чыктым. Минемчә, ул соңгы әсәрләрендә фәлсәфи тирәнәя бара. «Тынлык белән сөйләшү»е дә әйбәт иде аның. Ә «Соңгы сынау»ы тагын да фәлсәфи тирәнрәк. Илдар бу поэмада драматик минутны алган.

Нәби, Муса әсәрдә кечерәя, ул татар теле турында гына уйлый, ди. Тел турында уйлау ни өчен кечерәйтә, ди? Татар халкының теле турында да, үзе турында да уйлау — ил турында уйлау бит ул. Бу кечкенә нәрсә түгел. Сугышта йөргәндә миңа Курск та, Ржев та чит түгел иде. Әмма шул ук вакытта мин туган телем, туган илем турында да уйлана идем. Муса да шулай уйланган икән, бу аны кечерәйтәмени?

Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Газиз Иделле дә, Н. Дәүли белән килешмәүләрен әйтеп, С. Хәким фикерен куәтләп чыктылар.

Х. Сарьянның Г. Ахунов романына карата әйткән фикерләре белән бәхәскә керүчеләр дә булды. Ф. Хөсни, мәсәлән, Х. Сарьян «Хуҗалар»ны гел мактарга гына тырышты, шул мактавын беркадәр каплау өчен, аерым кимчелекләрен өстәнөстән әйтеп үтү белән генә чикләнде, роман турында житди сөйләшергә кирәк иде, диде. Р. Мостафин да Х. Сарьян фикере белән кушыла алмавын әйтте. «Без,— диде ул,— Гарифның «Хәзинә»сен укыдык. Ул безнең өчен яңа иде. Ә мәнә «Хуҗалар»га карата алай әйтә алмыйм. Вакыйгалар, кешеләр күп, ә роман йомшак. Әсәрдә зур конфликт житенкерәми. Конфликтлар вак. Автор бөтен жепләрне бергә бәйли алмаган. Ул безнең заманның житәкче образын күрсәтергә тели. Ләкин ничек итеп? Сабан туенда жиңә Арслан, авария вакытында батырлык эшли. Ягъни житәкче физик геройлык кына күрсәтә, ә ул акыллы житәкче булырак күренсен иде.

Буянов вакыйгасы — миңа дигән хикәя. Сабантуй эпизоды да аерым алганда матур. Әмма автор аларны тиешенчә бергә бәйләп бирә алмаган.

Фикер алышуда Мирсәй Әмир, Госман Бакир, Заки Нури һәм язучылар союзы председателе Ибраһим Гази да катнашты. Алар да күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр, тәкъдимнәрен әйттеләр. Кыскасы, утырыш бик жанлы, кызыклы узды.



*Илдар Юзеев*



*Васил Маликов*

## БЕРЕНЧЕ ЛАУРЕАТЛАР

Татарстан комсомолының Муса Жәлил исемендәге премияләр комитеты 1968 ел премияләрен бирү турында карар чыгарды. Ул карар нигезендә Муса Жәлил исемендәге беренче премияләр «Миләүшә» исемле поэма һәм балладалар жыентыгы өчен шагыйрь Илдар Юзеевка һәм «Һади Такташ», «Муллануp Вахитов», «Муса Жәлил», «Хәтерлисеңме, иптәш» һәм Совет власте өчен көрәштә һәлак булучыларга куелган монумент өчен эшләнгән сугышчы фигурасы өчен скульптор Васил Маликовка бирелде.

Без И. Юзеев һәм В. Маликов иптәшләрне бу зур бүләккә лаек булулары белән чын күңелдән котлыйбыз һәм киләчәктә иҗатларында тагын да зуррак уңышларга ирешүләрен телибез.

## ЯҢА ИЖАДИ БЕРЛӘШМӘ

ВЛКСМның Түбән Кама шәһәр комитеты һәм «Ленин нурлары» редакциясе каршында яшь татар язучыларының яңа ижади берләшмәсе төзелде. Берләшмә яшь авторларны әдәбиятка, иҗтимагый тормышка тагын да якынайтуны, аларны туплауны, татар сәнгате казанышларын пропагандалауны үзенең төп максаты итеп куя.

Жыде кешедән торган бюро сайланды. Бюрода өч сектор: матбугат, әдәби консультантлар һәм культураны пропагандалау секторы эшли. Бюроның председате-

ле һәм җаваплы секретарьлары итеп яшь шагыйрьләр Рәшит Юнысов, Айдар Хәлим сайланды.

Берләшмә членнары 16 номерлы техник училищеның актлар залында, Уратма авылында һәм «Нефтехимик» клубында комсомолның 50 еллыгына багышланган кичәдә чыгышлар ясады инде.

## ОТЛИЧНИКЛАР

Язучыларыбыздан Зәки Нури, Нәби Дәүли Совет Армиясендә хезмәт итүче солдатлар һәм офицерлар белән еш кына очрашып, аларны хәзерге татар әдәбиятындагы яңалыклар белән таныштырып киләләр иде.

Менә шул активлыклары өчен, Зәки Нури һәм Нәби Дәүли «СССР Кораллы көчләренә культура шефлыгы күрсәтү отличнигы» значогы белән бүләкләнделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР һӘМ «СӘЙЯР» ЭСТРАДА ТРУППАСЫ 111 нче МӘКТӘПТӘ

Язучыларыбыз Казан каласының 111 нче рус мәктәбендә укучылар һәм ата-аналар белән очрашу үткәрделәр.

Биш йөз кеше сыярлык зал шыгрым тулы иде.

Очрашуда Абдулла Сәләхетдинов, Касыйм Фәсәхов һәм Роберт Батуллиннар катнашты.

Кичәне шул мәктәпнең татар теле укытучысы, яшь язучы Маннур Саттаров ачып җибәрде.

Язучылар татар әдәбиятына, мәдәниятына кагылышлы мәсьәләләр турында сөйләделәр, шигырьләр, хикәяләр укыдылар.

Тәнәфес вакытында китап сату оештырылган иде. Кунаклар тамашачыларга истәлек имзалары язып, китаплар бүләк иттеләр.

Кичәнең икенче бүлегендә Казан химия-технология институтының «Сәйяр» һәвәскәр эстрада ансамбле труппасы да чыгыш ясады.

111 нче мәктәп укучылары да, укытучылары да һәм ата-аналар да бу кичәдән бик канәгать калдылар.

## ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫГЫ

Үткән елның ноябрь ае ахырында республикабызның Чүпрәле районында әдәбият атналыгы үткәрелде. Анда язучылардан Гариф Галиев, Атилла Расих, Нәби Дәүли, Зәки Нури, Галимҗан Латыйп, Мостафа Ногман, Шамил Рәкыйпов, Әхсән Баянов, Туфан Миңнуллин, композитор Арслан Батыршин һәм җырчы Таһир Якупов иптәшләр катнашты. Алар Чүпрәле культура йортында, Бауман исемендәге колхоз клубында, «Йолдыз» колхозы культура йортында, Фрунзе исемендәге һәм «Алга» колхозлары клубларында, «Ирек», «XXII партсъезд» исемендәге колхозларның культура йортларында әдәби кичәләр үткәрделәр һәм Татар Бизнәсе, Татар Төкесе, Зур Чынлы сигезьеллык мәктәпләре һәм Чүпрәле урта мәктәбе укучылары белән очраштылар. Әдәби кичәләр һәм очрашулар вакытында атналыкта катнашучы язучыларның китапларын сату да оештырылган иде. Бу эш бик уңышлы үтте — 350 сумлык китап сатылды.

Атналыкта катнашкан әдипләрне Чүпрәле районы хезмәткәрләре бик җылы каршы алдылар һәм иҗатларында уңышлар теләп озатып калдылар. Атналыкка барган барлык иптәшләр дә КПССның Чүпрәле райкомы һәм район Советы башкарма комитетының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

* * *

Шагыйрьләр секциясенең бюро членнары Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе Р. Зәкиев Куйбышев өлкәсе, Кошкинск районы, Иске Фәйзулла авылында яшәүче яшь шагыйрь Гакыйль Сәгыйров янында булдылар. Алар яшь авторның яңа шигырьләрен укыдылар һәм әсәрләре буенча фикер алыштылар. Гакыйльнең яңа шигырьләренә яхшы бәя бирелде. Алар матбугатка тәкъдим ителде.

Шуннан соң Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев Октябрь Норлаты районы газетасының сотрудниклары һәм яшь язучылар белән очраштылар. Әдәбияттагы соңгы яңалыклар турында җанлы сөйләшүләрдән соң, Ш. Галиев һәм И. Юзеев үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Сажидә Сөләйманова һәм Әдип Маликов Салкын-Алан авылы (Әлмәт районы) клубында чыгыш ясап, яңа шигырьләре белән колхозчыларны, укытучыларны таныштырдылар. Татарстанның атказанган укытучысы Нури Сибгатуллинны һәм укытучы Сәйдә Шәмсетдинова иптәшләрне пенсиягә озатырга килгән авылдашлары автор башкаруында «Салкын-Алан» поэмасыннан өзекләрне кызыксынып тыңладылар. Әдип Маликовның бу әсәре Салкын-Алан кешеләренә багышланган.


* * *

Комсомолның 50 еллык бәйрәме алдыннан Әлмәт шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Сажидә Сөләйманова, Әлмәт музыка училищесы директоры, композитор Мәсгут Имашев, училищеның яшь укытучысы Фарит Галиевләр нефтьче һәм игенче яшьләр белән очрашулар оештырдылар. Очрашулар Миңлебай, Чупай, Колшәрип, Югары Мактама, Васильевка авылларында үтте. Яшьләрнең Софиядә уздырылган IX Бөтендөнья фестивалендә катнашкан Равил Фәйзуллин совет яшьләренең дөнья иминлеге ныгытудагы роле турында сөйләде. Аннан соң сәхнәдән шигырь, җыр, музыка яңгырады. С. Сөләйманова яңа шигырьләрен укыды, М. Имашев комсомолның 50 еллыгына багышланган җырларын башкарды. Сәнгатьнең төрле тармакларын эченә алган мондый кичәләр тамашачыларда зур тәэсир калдырды.

# БЕЗНЕҢ ЖЫР

АРСЛАН БАТЫРШИН МУЗЫКАСЫ

НӘБИ ДӘҮЛИ сүзләре




Без барган юллар очрашыр әле,
Ерак булса да син торган яклар.
Куллар кулларның,
Күзләр күзләренең,
Йөрәк йөрәкнең
Жылысын саклар.

Кушымта: Чын дуслар өчен
Юл ерак түгел.
Тимер күперле
Безнең киң Идел.
Теләсәң әгәр
Безне табарга,—
Көмеш юллар бар
Зәңгәр һавада.

Без бәхет өчен көрәштә бергә.
Ал байрак белән яктырган сафлар.
Куллар кулларның,
Күзләр күзләренең,
Йөрәк йөрәкнең
Жылысын саклар.

Кушымта

Яшәсен тормыш, яшәсен кеше,
Балкысын жирдә кояшлы таңнар.
Куллар кулларның,
Күзләр күзләренең,
Йөрәк йөрәкнең
Жылысын саклар.

Кушымта: Чын дуслар өчен
Юл ерак түгел.
Тимер күперле
Безнең киң Идел.
Теләсәң әгәр
Безне табарга,—
Көмеш юллар бар
Зәңгәр һавада.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210

## *ЖУРНАЛ УКУЧЫЛАР ИГЬТИБАРЫНА*

**ХӨРМӘТЛЕ ИПТӘШЛӘР!**

1969 елда журналыбыз ике табакка арту сәбәпле, аның язылу бәясе дә алты сум булды.

Әгәр сез журналга иске бәя белән язылган булсагыз, соңгы ике санны алмый калачаксыз. Шуңа күрә 11—12 саннар өчен өстәмә рәвештә язылуыгызны үтенәбез.

Журналга теләсә кайсы сан өчен теләсә кайсы айда язылырга мөмкин. Язылганда журналның 73210 номерлы индексын әйтергә онытмагыз.

*РЕДАКЦИЯ.*